Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2007



Классик язучыларыбыз

# Ибраһим Гази һәм Мирсәй Әмир

туууларына 100 ел



**Ибраһим Гази**
*(1907–1971)*



**Мирсәй Әмир**
*(1907–1980)*

# Казан утлары
# Qazan utları

2007

**2**

**(1012)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркатип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
: **Факс**—(843) 541-38-77.
: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Киңлекләргә дәшә дала җиле. *Шигырьләр.* 5
Фәнис ЯРУЛЛИН. Кыйбласызлар. *Повесть.* 10
Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласына. *Шигырьләр.* 59
Җәүдәт ИЛЬЯСОВ. Еланнар әфсенләүче. *Роман.* 62
Рифә РАХМАН. Атлар чаба. *Шигырьләр.* 77
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Безнең нәсел сынмас, сынатмас... *Шигырьләр.* 80
Фәнил ГАЙНУЛЛИН. Кучтәнәч. *Хикәя.* 83

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. 96

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әдәби тәнкыйтьне ничек җанландырырга? («Түгәрәк өстәл янында сөйләшү») . 104

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 115
Фаяз ХУҖИН. Алабугага ничә яшь? 120
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 128
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. «Яңа япун мөхбире» мәҗмугасы. 134
Фоат ВӘЛИЕВ. Татар телен фәннән куалау. 142

**ВАСИЛИЙ РАДЛОВНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ**

Ризаэтдин ФӘХРЕТДИН. Василий Васильевич Радлов җәнапләренең илле еллык (1859–1909) бәйрәме. 132

**СӘНГАТЬ**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Милли мирасыбыз җәүһәрләре. 147
Әзһәр ШАКИРОВ. Язмыш һәм узмыш *(Артист язмалары).* 176

**ГАЙ ТАҺИРОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Рашат НИЗАМИ. Яфраклар балет биюе башкара. 156

**МӘХМҮТ ӘХМӘТҖАНОВКА 80 ЯШЬ**

Фәнзаман БАТТАЛ. Милләт җанлы каләмдәшебез. 159

**ХӘТЕР**

Бакый ЗЫЯТДИНОВ. Һәрбер музей—тормыш дәвамы. 163
Раиф МӘРДАНОВ. «Тәрбияи әтфаль» журналына йөз ел. 180

**МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Аның «Саф күңел»е, «Агыйдел»е... *(Көндәлек сәхифәләре).* 169

**ЮМОР-САТИРА**

Илдар ХӘЙРУЛЛИН. *Шаян хикәяләр.* 182
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Дж. ИЛЬЯСОВА «Заклинатель змей» (начало); повесть Ф. ЯРУЛЛИНА «Непутевые» (продолжение); рассказ Ф. ГАЙНУЛЛИНА «Гостинец»; стихи Г. МУРАТА, М. МИРЗЫ, Р. РАХМАН, Ф. ФАТЫХОВА.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (окончание).
«Литературная критика»: «Как оживить литературную критику?» («Разговор за круглым столом»).
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ХУЗИН. «Сколько лет Елабуге?»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение); статья Х. МИННЕГУЛОВА о журнале «Яңа япун мөхбире»; статья Ф. ВАЛИЕВА «Изгнание татарского языка из науки».
«Искусство»; статья Л. ХАМИДУЛЛИНА «Сокровища национального наследия».
«Память»: Б. ЗИЯТДИНОВ. «Каждый музей—продолжение жизни»; Р. Марданов. «Журналу «Тәрбияи этфаль»—100 лет».
«Наши юбиляры»: в номере отмечаются 170-летие В. Радлова, 100-летие М. Амира, Г. Тагирова, 80-летие М. Ахметзянова, 50-летие Г. Гильманова.
«Юмор-сатира»: рассказы И. ХАЙРУЛЛИНА.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Старая Казань. Сенный базар», работа А. ТИМЕРГАЛИНА; писатель Хабир ИБРАГИМ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Prose and poetry: novel by J. ILYASOV "Snake charmer" (beginning);
Story by F. YARULLIN "Bad lots" (continuation); story by F. GAYNULLIN "Gift"; verses by G. MURAT, M. MIRZA, R. RAHMAN, F. FATYHOV.
Publicism: R. HAKIM. "Metamorphoses of spirit" (ending).
Literary criticism: How to recover literary criticism? (Conversation at a round table).
Science: A. TIMERGALIN. "Dictionary of nation" (continuation); F. HUZIN. "How old is Elabuga"?; F. GARIPOVA. History of our villages (continuation); article by H. MINNEGULOV about magazine; article by F. VALIEV Exile of Tatar language from science.
Art; article by L. HAMIDULLIN "Treasure of national heritage".
Memory: B. ZIATDINOV. "Every museum is continuation of life";
Peoples celebrating their jubilee: in issue is celebrated 170th anniversary of V. Radlova, 100th anniversary of M. Amir, G. Tagirov, 80th anniversary of M. Ahmetzyanov, 50th anniversary of G. Gilmanov.
Humour-satire: stories by I. HAYRULLIN.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: old Kazan. Hay market, work by A.TIMERGALIN;
Writer Habir IBRAHIM.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.01.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-73. Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.



Газинур
Морат

# КИҢЛЕКЛӘРГӘ ДӘШӘ ДАЛА ҖИЛЕ

## Төнге Кояш иле

**Дөньяның да чите бар бугай ла,
Дөньяның да чиге бар бугай.
Таш өстендә үсә кара каен,
Таш өстендә үсә карагай.**

**Таллары да бүтән, таңнары да
Бездәгечә атмый бу якта.
Фиордларны[1] поляр йокысыннан
Альбатрослар елап уята.**

**Сулар белән каймаланган бу җир,
Кыя-ташлар белән чигелгән.
Ак чалмалы таулар оеп тора,
Күшеккәндәй котып җиленнән.**

**Яланнарда болан утлап йөри—
Җилдәй җитез котып атлары...
Саумы, Норвей, төнге Кояш иле,
Бөек сәях җаннар Ватаны.**

**Сәяхләрең ил-кыйтгалар ачкан,
Юл сораган йолдыз, кошлардан.
Харитаң да синең
Викинглар
Корабына шундый охшаган.**

---

[1] Фиорд—диңгез култыгы.

Газинур МОРАТ (1959)—*шагыйрь, публицист; "Мин дөньяны тыңлыйм", "Түбә", "Төнге әверелеш" һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Гаярь варягларың варисларга
Юл күрсәткән—булган юламан.
Тарих кәрваннары йөри бүген
Викинглар үткән юллардан.

Дөньяның да чиге бар бугай ла,
Чите аның, ахры, бу якта.
Фиордларны поляр йокысыннан
Альбатрослар елап уята.

## Үзеңнеке булсын

*Безнең җиребез зур һәм бай,*
*әмма анда тәртип юк.*
IX гасырда славян илчеләренең
варягларга язган хатыннан.

Нигезеңне ятлар корып бирсә,
Үзеңнеке булмас ил-эргәң.
Кай кавемнәр, әнә, патшасын да
Җир читеннән дәшеп китергән.

Җиребез бай, имеш...
Үзебезне
Үзебездән кирәк якларга.
Үз-үзеңә хуҗа булалмасаң,
Баш орасың килеп ятларга.

Нигезне шул үзең кору кирәк,
Тараладыр—ятлар корганы.
Бәрәкәтсез илнең иләте дә,
Милләте дә аның кол бары.

Үзеңнеке булсын ишек-капкаң,
Үзеңнеке—тәрәз, бусагаң...
Ә варяглар, әнә, үз йортыннан
Гасыр могҗизасы[1] ясаган.

Кимлек-хурлыгын да күргән халык,
Сау саклаган әмма үзәген.
Ә бит, бер уйласаң, бу дөньяда
Татардан да азрак үзләре.

Санда түгел, җандадыр шул зурлык,
Хурлыгы да каннан киләдер.
Иң зур илдә яшәп,
Зурлыклар да
Кечерәя бара нигәдер.

Буйда түгел, уйдадыр шул хикмәт,
Безнең уйга кырау тигәндер.
Иң бай илдә яшәп,
Иләте дә
Фәкыйрьләнә бара нигәдер.

---

[1] 2005 елда бәйсез Норвегия дәүләте төзелүгә 100 ел тулды.

Җире дә бай, әйе, иле дә зур,
Чоры үзгә, үзгә заманы.
Мең ел үткән юкса...
Ә тәртип юк,
Тәртип ягы һаман чамалы.

## Тишек акча

Нумизматны нәүмиз итмик әле,
Шигыремә керсен сәмән дә.
Варягларда борын-борынгыдан
Тишек акча йөргән гамәлдә.

Мәгәр берни үзгәрмәгән: казна
Тишек акча суга бүген дә.
Шул тишектән күккә бактың исә,
Алтын тәңкә—Кояш күренә.

Ил-көнеңә бәхет иңә, имеш,
Шул тишектән баксаң Кояшка.
Шундый ырым булган.
Ышанганнар...
Ышаныч шул кирәк иң башта.

Ышаныч шул кирәк...
Сәгадәтле
Хәят корыйм дисәң илеңдә,
Үз Кояшың күренерлек кенә
Тишек акчаң булсын кимендә.

Ышаныч шул кирәк...
Үз эргәңдә
Ятим икәнеңне белсәң дә.
Идел-йортка кот, бәрәкәт иңсен—
Тишек акча йөртәм кесәдә...

## Тромсёда Руаль Амундсен һәйкәленә эндәшү

Ерак бабаларың
Америка
Ачып йөргән мең ел элгәре.
Әмма сәер: кыйтга хәтерендә
Сакланмаган никтер эзләре.

Дөнья ганимәтен эзләгәндер—
Ушкуйник ич булган алар да.
Ә үзләре кыйтга күкрәгенә
Онытканнар казык кагарга.

Казыкны шул юлбасарлар түгел,
Илбасарлар кага, дисеңдер.
...Тарих үзе казык башындагы
Чәрдәкләнгән чүлмәк ишедер.

Баскын каккан казык башларында
Оеп тора әле күп серләр.
Чүлмәк кыйпылчыгын имла итеп,
Үз тарихын яза үксезләр.

Баскынлыкка бәя үзгәрмәстер,
Үзгәрсә дә сулар агышы.
Хәбәр булып хәрабәләр калка—
Үксезләрнең рәнҗеш, каргышы.

Син үзең дә казык какмый гына
Яңа кыйтга ачкан гаярьсең.
Ил-халкыңны ганимәтле итеп,
Күк биргәндер гадел бәясен.

Һәр кавемнең Күкләр бүлеп биргән
Иманасы бардыр, ил-җире...
Баскынлыкка өйрәтмидер ләса
Китаплар да—Тәүрат, Инҗиле...

Күпме кавем әле илен, җирен
Хәтерендә яшреп саклыйдыр.
Үксезләрнең бу Җирдәге хакы
Коръән кәлимәсе чаклыдыр.

## Татарча ит

*Гәрәй Рәхимгә*

Дөнья әдипләре мәҗлесендә
Вәкаләтле вәкил бүген без.
Туган илдә үги саналсак та,
Күк астында үги түгелбез.

Дөнья әдипләре мәҗлесендә
Һәркайсыбыз табын түрендә.
Чәркәләрне чәкештергән чакта
Шәраб түгел, шигырь түгелә.

Тел белү дә юкса ташка үлчим,
Ә татарча беркем аңламый.
Ә аңлашыйм дисәң, сүз дә кайчак
Хаҗәт түгел бугай әлләни.

Кәлимәсен, әнә, белмәсә дә,
Үзен белә Мәгъриб татарның.
Татарча ит... Авыз итеп карыйк,
Шундый тәгам-сые бар аның.

Мәгъриб юкка татарланып тормас,
Бардыр бер-бер дәва-име дә,—
Без дә менә татарча ит уртлап
Утырабыз Норвей илендә.

Җир читенә килеп, үзебезчә
Сыйланабыз—менә галәмәт!

Көяз Мәгъриб татарча ит ашый—
Халкы, ахры, шуңа сәламәт.

Җир читенә килеп, үзебезчә
Янә яшәп алдык бүген без.
Туган илдә үги саналсак та,
Күк астында үги түгел без.

## Иңрәү

*Әхәт Мушинскийга*

Үзгәртепләр булмый
Гомерләрнең
Күкләр язган аять-сүрәсен.
Дөньялыкта адәм баласына
Иңрәп яшәү язган, күрәсең.

Җан үзе дә
Гүя
Иңрәп яткан
Бер нарасый бала биләүдә.
Бу дөньяга кыеп әйткән сүз дә
Әверелә бара иңрәүгә.

Күкләр иңри—безне кисәтәдер,
Калебләр шул шактый өшәнгән...
Эдвард Мунк. «Иңрәү». Ялгыз мәхбүс.
Иңрәү ишетелә төсләрдән.

## Чатыр

Өнсез чагы әле чатырымның,
Көйсез мәле әле көемнең.
Гази кылычы да кисә алмас
Бер чуалган гомер төенен.

Бөгәрләнеп ятам чатырымда,
Карындагы сабый шикелле.
Үкси-үкси бу дөньяга кабат
Кайтуларым гына икеле.

Нарасыйдай ятам бөгәрләнеп,
Дала карынында—чатырда.
Ә кылганнар гүя гөслә кылы—
Киңлекләргә мине чакыра.

Киңлекләргә дәшә Дала җиле...
Күгем—биек, түбәм—тәбәнәк.
Дуңгәләктәй үтеп бара гомер,
Җилләр уңаена тәгәрәп.

Дуңгәләктәй үтеп бара дәвер,
Җилләр гүя чаптар аңарга.
Чатыр булып тын курганнар гына
Тамырланып калган далада.

Тамырланып калган хәрабәләр,
Исем-атамалар, дагалар...
Шул дагалар мәллә
Дала җанын
Ялалардан торган аралап?

Шул дагалар мәллә, дога булып,
Чал Даланың серен саклаган?..
Атамалар гына кала икән,
Бер егылып төшкәч атлардан.

Иярләргә иярәсе икән,
Бер мәтәлеп төшкәч иярдән.
Үксез Дала җиле исә...
Аңа
Өнсез дуңгәләкләр ияргән.

Нарасыйдай ятам бөгәрләнеп,
Дала карынында—чатырда.
Ә кылганнар гүя гөслә кылы—
Киңлекләргә мине чакыра...

*2006*

Фәнис
Яруллин

# КЫЙБЛАСЫЗЛАР

ПОВЕСТЬ

* * *

Без, ир-атлар, хатын-кызның нәфис зат икәнен онытып җибәрәбез. Аларны үзебезгә караганда икеләтә күбрәк эшләтәбез. Эштән кайткач керен юа, ашарга пешерә. Ни генә эшләмә—химия. Көзге чистартсаң да, тәрәзә юсаң да химиядән ясалган порошок. Бәлки, әнә шул порошокның берәрсе аңа ярамагандыр.

Гыймай хатынын шулай үзенчә акларга тырышты. Заһит тугач, Фатыйма күбрәк вакытын бала карауга бирде. Анда-монда чыкмады, ят кешеләр белән очрашканы сизелмәде. Димәк, азгынлык түгел, белмәгән-күрмәгән килеш гөнаһлы булырга ярамый. Дөрес, балага бишекле арба алырга дип, теге вакыт биргән акчаларны сорагач, Фатыйма кинәт коелып төште, ләкин үзен тиз кулга алды: акчаны шкаф тартмаларыннан, сандык төпләреннән эзләп маташты. Аннары исенә нидер төшергәндәй: «Әй, бөтенләй онытып торам икән: беркөн өйгә көтүләре белән чегәннәр кергән иде. Берсенең кечкенә баласы бар иде. Ул баласын диванга салды да: «Баланың асты юешләнгән икән, алыштырырга бирәр чүпрәгең юкмы?»—диде. Мин теге якка чүпрәк эзләргә чыгып киттем. Кабаланганда тиз генә әйбере табыламы соң анын?! Байтак эзләнеп йөргәч үземнең иске халатны чыгарып бирдем. Шул чакта актарганнардыр инде. Югыйсә, өйгә ят кешеләр кергәне юк.

—Рәзе чегән өерен өйгә кертергә ярый,—диде Гыймай кызмый гына.

—Балалары да булгач, керткән идем шул.

—Бигрәк кин күнелле инде үзен. Минем кебек «мунча пәрие»нә кияүгә чыгуын гына да сине барлык хатын-кыздан югары күтәрә.

Сүз шунын белән бетте, ләкин Фатыйманың күнелендә бер уй яктырып китте: «Бу бит бик шәп дәлил, бөтен нәрсәне чегәннәргә сылтарга була».

Һәм ул сикереп торып үзенең алтын әйберләре саклана торган кечкенә тартманы диван астыннан тартып чыгарды. Билгеле инде, анда берни дә юк иде. Фатыйма кычкырып еларга тотынды: «Ах, кабахәтләр. Минем бөтен алтын әйберләремне чәлгәннәр. Син алып биргән муенса гына калган булса да бу кадәр йөрәгем янмас иде».

Гыймай бер сүз дәшми идән уртасында басып торды. Күнелендә ниндидер давыл кузгалам-кузгалам, дип торды. Беренче мәртәбә хатынына ышанып бетмәде. Әмма Фатыйма шулкадәр гөнаһсыз төстә елый, күкрәгенә кысып юатмый һич мөмкин түгел.

—Ярар,—диде ул,—дөнья малы—дуңгыз каны. Алтынсыз яшәрбез. Ә балага бишеккә әҗәткә керергә туры килер.

---

*Ахыры. Башы 1нче санда.*

Давыл кубар дип көткәндә жил дә исми калгач Фатыйма күнеленнән тантана итте. Заһит ул алтын муенсаларны, йөзекләрне сатып эчкәндер инде. Бик жайлы котылды бит әле бу бәладән.

Ә бала арбасы алырга әжәткә керергә туры килмәде. Фатыйма ире өйдә юк көнне үзе эшләгән кибеткә китте. Туры директор кабинетына узды.

—О-о,—диде директор ачык йөз белән,—безне искә төшерүең өчен рәхмәт. Әйдә, диванга рәхим ит. Кайчандыр без аны икебез яхшы ук йомшарткан идек.

—Әллә кайчандагыларны искә алып тормыйк әле, Сәгыйть абый. Үпкән-кочкан—жилгә очкан, диләр бит.

—Дөрес, йомшагым, үткәннәрне искә алмыйча яңа танышкан кешеләр булып бер сөялеп алыйк әле яраткан диваныбызга. Аннары йомышыңны әйтерсең. Болай гына яныма килмәгәнеңне күзләреңнән күреп торам.

Фатыйма Сәгыйтьнең һәрвакыт тирләп тора торган олы корсагыннан, йон баскан күкрәгеннән бик туйган һәм Гыймайга чыккач бераз болардан котылып торган иде. Козгынны үләксә ымсындырган кебек нигәдер күңеле тагын шушында тартылды. Күрәсең, пычраклыкның да үзенә тарту көче бардыр.

Сәгыйть Фатыйманың зифа гәүдәсенә сокலануын белдерде.

—Бала тапкач тагын да сылуланып киткәнсең,—диде ул Фатыймага сасы сулышын өрә-өрә. Хатын аның сасы тынын суламас өчен башын читкәрәк борды.

—Нәрсә, әллә миннән җирәнәсеңме?

Фатыйма дәшмәде. Сәгыйтьнең барлык кыланышларына сабыр гына торды.

—Суына башлагансың син,—диде Сәгыйть бераз канәгатьсезлек белдереп.—Нәрсәгә килгәниең?—диде.

—Балага бишекле арба кирәк иде. Арбага дигән акчаны чегәннәр урлап чыккан.

—Бала арбасы дисең инде алайса?

—Әйе.

—Арба дүрт тәгәрмәчле була бит.

Фатыйма Сәгыйтьнең тел төбен аңламады.

—Тәгәрмәч санынча килеп китәрсең,—диде Сәгыйть һәм хатынның йөзенә карады.

Фатыйманың ниндидер мизгел эчендә бит тиресе тартышып куйды. Сәгыйть моны күрде, ләкин аны-моны әйтмәде.

—Арбаны алып китәрсең, ләкин декреттан соң монда эшкә чыгасы барын онытма.

—Онытмам.

Сәгыйть сатучы кызларны үз кабинетына чакырып кертте.

—Менә нәрсә, кызлар. Фатыйма апагызга бәби арбасы кирәк икән.—Сәгыйть «апагыз» сүзенә юри басым ясап әйтте.—Һәрберегез үзегезнең зарплаталарыгыздан күпме кирәк акча туплагыз да менә бу гүзәл апабызның малаен арбалы итик әле.

Сатучылар һәммәсе Фатыймага борылды. Аларның күзләрендә ачу чаткылары чагыла иде. Фатыйма үзе дә эшнең мондый юнәлеш алырын һич көтмәде. Директор кабинетыннан чыккач алар элеккеге ахириләренә ташландылар.

—Кәнтәй! Аны директор аша соратмыйча, үзебезгә генә әйтеп булмый идемени?

—Мин Сәгыйть абый алай эшләр дип уйламаган идем.

Кызлар арасында шактый тарткалаш булып алды. Чөнки моннан өч атна элек кенә директор үзенең бер сөяркәсенә кыйммәтле тузан суырткыч бүләк

иткән иде. Аның акчасын да сатучы кызларның хезмәт хакыннан тотып калды. Әмма никадәр тузынмасыннар, хужа әйткәнне эшләми хәлләре юк.

Фатыймага бишекне үзенә сайлап алырга куштылар. Фатыйма арбаның ин кыйммәтлесен сайлады. Аннары ул кызларга:

—Кызлар, мина үпкәләмәгез инде,—диде.—Ә бу бишекле арбаны сез үзегез безгә китерсәгез әйбәт булыр иде. Сезнең бүләк бит бу. Шунда безнең тормышны да күреп китәрсез. Сөйләшеп утырырбыз. Малайның тәпиен «юарбыз».

Кызлар тәпи һәм тагын әллә нәрсәләр «юарга» остарып җиткәннәр иде, Фатыйманың чакыруын шатланып кабул иттеләр.

Алар дуслар булып аерылыштылар.

Заһиттан туган Заһит ай үсәсен көн үсте. Тәпи баса башлауга бишекле арбаны этеп йөри торгач, арба әле тегендә, әле монда бәрелеп ватылып бетте. Аннан ана өч тәгәрмәчле велосипед алып бирделәр. Малай аны да бик тиз ботарлап атты. Әтисе ана:

—Сина, улым, биш яшең тулган көнне ике тәгәрмәчле шәп велосипед алып бирермен,—диде. Ләкин Заһитка биш яшь тулар алдыннан төрмәдән өлкән Заһит чыккан дигән хәбәр Фатыймага килеп ирешә. Фатыйма эчке бер тынгысызлык белән Заһитны көтте. Хыялында аның элекке Заһит яшәде: чиста, матур, таза гәүдәле. Котырып назлый белә. Аның куллары кагылуга тәндәге бөтен күзәнәкләр уяна. Кайчак ул әллә кай җирләрне чәбәкләп, чеметеп, каергалап ала, тәнеңнең бөгелмәс җирләрен бөгә. Фатыйма авыртудан кычкырып-кычкырып куя: «Үтерәсең бит, дурак!»—ди. Ләкин Заһит: «Аңардан хатын-кызның үлгәне юк әле»,—дип тагы да ныграк газаплый. Заһит килеп киткәннән соң берничә көн Фатыйма сызлана, ләкин ул шушы сызланудан рәхәтлек табып эчтән елмаеп йөри. Ә Гыймай, тисәм ватылыр, дигән сыман Фатыймага сак кына кагыла. Башта аның ефәктәй чәчләрен сыйпый, тәненә тидерер-тидермәс кенә кулларын йөртеп чыга. Матур сүзләр әйтә. Иренең озак мыштырдавы Фатыйманың ачуын чыгара. Тиресендә каз йоннары кабара. «Ah!»—дип куя ул ачудан. Ә Гыймай моны үзенең назлары хатынының җанына барып җитте дип аңлый һәм шунда гына төп вазыйфасына керешә. Ләкин газаплы наз Фатыймага һәркөн эләкми. Гыймай эштән арып кайта. Ашапэчкәч бераз ял иткәләп ала да мастерскоена чыгып китә. Хатынын ул йөрәк җылысы җитмәүдән түгел, артык иркәләү аны туйдырадыр, дип уйлаудан гына бик еш назламый. Юкса ул Фатыйма идән юган яки көзге алдында әле бер, әле икенче күлмәген киеп караган чакларда үзен чак тыеп тора.

Хатын-кызның мондый кыланышы тәннәрендәге барлык күзәнәкләре ират назына сусап «кычкыра башлавы» икәнен Гыймай каян белсен! Ул үзенең тәнендәге бөтен әгъзаларын акылга буйсындыра килде. Моңа Гыймайның гомер буе авыр эштә эшләве, әбиләренең «хатын-кызга текәлеп карау да гөнаһ. Ул—күз белән зина кылу»,—дип тукып торулары да өстәлгәч, хатынының теге яки бу җире «ялгыш» ачылып киткән чакларда карашын читкә бора иде. Ә хәйләкәр Фатыйма аны барыбер үз кармагына эләктергәләп торды. Бервакыт Фатыйма урындыкка басып тәрәзә пәрдәләре элеп торганда ниндидер кинәт хәрәкәт ясады һәм стенадагы кадакка эләгеп күлмәге ертылды. Тәрәзә яңагының буявы кибеп җитмәгән икән, Фатыйма «ялгыш» буяулы янакка тотынды. «Бөтен нәрсәне буяп бетерәм инде, пәрдәләрне иртәрәк элгәнмен»,—диде ул һәм иренең кочагына сикереп төште. Ертыла башлаган күлмәк тагын каядыр эләкте.

—Бар,—диде ул,—мина әнә тегеннән халатымны алып кил.—Гыймай эчкәрге яктан халатны эзләп табып алып чыкканчы хатын идәндә торган буяу савытына бармагын тыгып тәненең бөтен җирен буяп бетерде.

—Син бөтенләй буялып беткәнсең икән,—диде Гыймай,—тәнеңне спирт

белән сөртергә кирәк.—Ул шкафтан спирт алып Фатыйманың тәнен сөртә башлады. Шунда ул үзен тыеп кала алмады, көпә-көндез Фатыйманың кочагына ауды. Аннан соң, гөнаһ эшләгәндәй, хатынына туры карарга оялып йөрде.

* * *

Инде уллары Заһит та аякка басты. Ул бик кызыксынучан малай булып чыкты. Бервакыт ул мунчага әнисе белән генә барды. Ләүкәдә әнисе киерелеп-киерелеп чабынган чакта малай әнисенә карап-карап торды да: «Әни, нигә минә бу әйберләр миндә юк?»—дип, әнисенең чабынганда сикереп-сикереп куйган тулы күкрәкләренә күрсәтте.

—Син бит малай кеше, улым. Ә малай кешеләрдә андый нәрсәләр булмый.

—Мондый нәрсәләр генә буламыни?

—Күп сорашырга сиңа иртәрәк әле. Чистый Заһит.

—Соң, мин Заһит бит инде.

—Әйе, улым. Син—Заһит.

Мунчадан кайткач, Фатыйма улының кызыксынуларын Гыймайга сөйләде.

—Моннан соң мунчага үзем белән барыр, болай ярамас,—диде Гыймай.

—Минем арканы кем ышкыр?

—Малайны кайтарып куйгач, үзем ышкырмын.

Йоклаганда өнәп бетермәсә дә, Фатыйма ире белән мунча керергә ярата иде. Гыймай Фатыйманы ләүкәдә тәгәрәтә-тәгәрәтә чаба. Чаба-чаба кызып китә, мондый чакларда ул Заһитка охшап китә: кайнарлана, житезләнә, кагылсаң, ватылыр дип тормый.

Мунчада күнелләре якынаеп алган чакларда Гыймай:

—Әллә Заһитка иптәшкә тагын берәр малай апкайтыйкмы, әнкәсе,—ди.

Тик иренен соравын Фатыйма күпвакыт ишетмәмешкә салыша яки: «Бусы да икегә торырлык әле»,—дип жавап бирә.

—Бер бала—юк бала, диләр бит,—ди Гыймай.

—Халык нәрсә әйтмәс. Сигез сыер асраганчы—симез сыер асра,—дигән сүзләр дә халыкныкы.

—Сүз сыер турында бармый бит әле.

—Халык маңгайга бәреп әйтми. Балага да кагыла бу сүзләр.

Фатыйма күнеленнән тагын бер малай яки кыз табарга каршы түгел. Ләкин ул: «Гыймай кебек берәр урод туып куйса,—дип уйлый да куркып куя.—Житмәсә, ул кыз бала булса. Тфү, тфү! Әстагъфирулла тәүбә. Аяклары бигрәк этнеке кадәр генә. Утырып торганда кеше төсле, торып басса—маймылның маймылы. Ярый әле, Ходай «теге» нәрсәне жәлләмичә чәпәгән. «Бурычын» еш үтәмәсә дә, анысына зарланырлык түгел.»

Тик барыбер Заһит истән чыкмый. Хәзер Фатыйма эчке киеренкелек белән Заһитны көтә. Кайда да булса очрашырга тиеш бит инде алар. Өйгә генә килеп чыкмасын. Гыймай аның белән очрашканны белсә, мәңге кичермәячәк. Ә Фатыймага Гыймай бик кирәк. Чөнки ул аның бөтен гөнаһларын каплый.

Заһит белән Фатыйма бөтенләй көтелмәгән жирдә очрашты. Фатыйма кибеттән мәктәп аша кайтып йөри иде. Мәктәп капкасын керүгә, аны бер кул эләктереп алды: «Фатыйма!»

—Заһит!—Алар бер-берләренә карашып тордылар. Заһит әйбәт костюм-чалбардан. Муенына галстук тагып жибәргән.

—Әллә берәр начальник булдыңмы?

—Мин һәрвакыт үземә үзем начальник.

—Сине төрмәдә дигәннәр иде бит әле.

—Кеше ни сөйләмәс.

—Ә монда нишләп йөрисең?

—Яшим.

—Кайда?

—Әйдә, күрсәтәм.—Заһит Фатыйманы житәкләп мәктәп гаражына таба сөйрәде.

Йозак өстән эленеп кенә куелган икән. Заһит йозакны элмәгеннән алды да, гаражның кечкенә капкасын ачты. Ут кабызды. Ике машина сыярлык итеп эшләнгән гаражның подвалы бик зур иде. Заһит подвал капкачын ачты: «Әйдә, гүзәл королева, минем апартаментларга да кереп чыгыйк».

—Юк, мин куркам,—диде Фатыйма.

—Мин барында беркемнән дә курыкма,—диде Заһит күкрәк кагып.—Мин паханның үзеннән фәлән жиремне ялаткан кеше.

Заһит Фатыйманы этеп диярлек төшерде. Утны кабызып җибәрүгә Фатыйманың күзе дүрт булды. Әйтерсең бу подвал түгел, кибет склады. Монда жаның ни тели—шул бар.

Заһит нindидер дегетле капчыктан алтын алкалар, йөзек һәм беләзекләр тартып чыгарды.

—Мин бурычымны түләргә яратам: мә, ал үзеңә ошаганнарын.

Фатыйманың күзләре янды.

—Каян болар?

—Син аның каян икәнен сорама. Бирәләр икән—ал!

Фатыйма йөзекләрнең әле берсен, әле икенчесен киеп карады. Кайсын алмый калдырсаң да жәл. Хатынның комсыз карашын күргән Заһит: «Ярар, ал барсын да,—диде.—Өеңә алып кайтып берәр жиргә яшереп куй. Кирәге чыгар».

Заһит алтын әйберләрне чистарак чүпрәккә төреп, Фатыйманың сумкасына чумдырды. Байлыкка табынучы хатын шатлыгыннан сикеренде.

—Рәхмәт, Заһит, мәңге онытмам.

—Рәхмәтен теге вакытта өеңдә әйткәнчә әйтерсең.—Заһит чишенә башлады. Фатыйманың өстендә жиңелчә күлмәк кенә иде. Аны салып ыргыту озакка бармады.

—Һаман чибәр үзең,—диде Заһит хатынның бар жирен капшап.—Әйдә, менә монда минем йоклый торган урын. Синең караватың түгел—түгелен, ләкин шунсы шәп: моннан егылып төшмисең.

Бер почмакта кыйммәтле кием-салымнардан жәелгән урын бар икән, Заһит Фатыйманы шунда күтәреп салды. «Шундый кыйммәтле кеш туны өстендә йоклыйсыңмы син? Димәк, син чынлап карак»—диде Фатыйма.

—Әйе, кешеләрнең «артык» әйберләрен алып чыккалыйм. Менә бу тун әле бер дә киелмәгән. Хәтта яка астында этикеткасы да бар. Шкафта аны көя кисеп ятар иде, ә монда мин аның өстендә ауныйм.

—Әллә нинди хатын-кызлар алып керәсеңдер әле.

—Әллә нindиләрен түгел, шәпләрен генә.

—Әле син миннән шәбрәкләрне таптыңмыни? Мин иремә хыянәт итә-итә сине өемә кертәм. Ә син...

—Сиңа бит иреңә хыянәт итү ошый. Син Гыймайны мыскыл итүдән тәм табасың.

Фатыйма Заһитка каршы әйтә алмады. Дөрестән дә ул Гыймайга этлек эшләүдән тәм таба. Гыймайның көне буе таш кисеп кайтканнан соң рамнар ясарга чыгып китүе, кулына бераз акча керсә, алтын кош тоткан баладай сөенә-сөенә акчаларын Фатыймага тоттыруы һәм кечкенә сумма өчен дә эчке горурлык кичерүе хатынга һич ошамый. Менә ичмасам Заһит! Алтын өстендә ауный. Урлаган икән—урласын. Бөтен кеше урлаша.

Заһит белән кыйммәтле тун өстендә котырганда Фатыйма шулай уйлады.

Алар кинәнгәнче, арыганчы әүмәкләштеләр. Затлы туннын йомшак мехы Фатыйманың тәнен иркәләде. Бу иркәләү хәтта Заһитның назларын күмеп китте. Хәер, Заһит иркәли белми иде: ул эт кебек ырлый, мәче кебек тырный, усал тәкә кебек сөзә, Фатыйманы елан кебек итеп бөгәрли. Ә Фатыйма мона шат. Аны һәрвакыт кайнарлап тору кирәк.

«Эшләп» арыгач алар икесе ике якка тәгәрәде. Бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч Фатыйма: «Ничек яшәргә уйлыйсын?»—дип сорады.

—Мин уйламый гына яшим,—диде Заһит.—Мине уйларга өйрәтүче булмады. Һәркем үзенә буйсындырырга теләде. Ә хәзер мин буйсынмыйча, уйламыйча яшим. Әнә минем бер дустым бар иде. Университетны кызыл дипломга бетерде. Нәрсәдер уйлап тапты. Ләкин анын уйлап тапкан әйберен алучы булмады. Эш табалмыйча йөрде-йөрде дә, Америкага китеп барды. Хәзер анын уйлап тапкан машинасын Америкадан безнен ил сатып алган. Минем дустым анда байлыкка күмелеп яши.

—Синен бу подвалын да ярлы түгел,—диде Фатыйма.—Кем бирде сина моны?

—Бу мәктәптә минем дядя завхоз булып эшли. Шәп мужик. Яши белеп яши. Мәктәпкә ни кайтса да яртысы аныкы. Әллә син бу подвалны болай гына бирделәр дип уйлыйсынмы? Тоттырырлар. Монын өчен мин ана гомерлеккә житәрлек түләдем. Бушка бирсә дә була иде бит. Барыбер җәй көне монда эт тә керми. Җәй генә түгел, кыш көне дә буш тора бу гараж. Мәктәпнен тракторын директор үз малаена алып бирде. Бер алама «Москвич»лары бар иде, ансы минем абзый кулына күчте. Талау, урлау заманы бит. Беркем сүз әйтми. Чөнки беләләр: күрүеннән күрмәвен яхшы.

Фатыйманың дөньяга үз карашы булмаганлыктан, ул Заһитның кочагында иркәләнеп ятуны гына белде. Дөньяның башка яклары анын өчен кызык түгел иде. Гомумән, ул кешедә тән барлыгын белә, калганы анын өчен түгел. Дөрес, кайвакытта ан дигән нәрсә уянгалап куя. Ләкин андый мизгел яшен кебек тиз узып китә. Заһит анын шундый икәнлеген яхшы анлый: Фатыймага хайвани тупаслык ошый. Ныграк интектергән саен ул күбрәк ләззәт алачак. Ләкин хәйләкәр Заһит аны назлаштырып, сыйпаштырып озак котырта. Фатыйманың бөтен тәне калтырый башлый, түзәрлеге калмый. Ә Заһит инде ана якынаям дигәндә генә сикереп торып, озаклап су эчкән була, йә аркам кычыта, кашы әле, дип, озак юынмаудан купшаклаган аркасын Фатыймага бора. Фатыйманың түземе бетә: ул тычканга ташланган мәчедәй үз кирәгенә ташлана. Аннары инде ятакта «акулалар» сугышы башлана.

Фатыйма ул көнне өйләренә сон кайтты.

—Нигә бик озакладын?—диде Гыймай.

—Мәскәүдән товар кайтты, шуларны берәмтекләп кабул итәргә кирәк. Безнен хужаны беләсен бит: безгә генә ышанмый, бөтенесен үзе саклап тора.

—Мин эштән кайтышлый кибетегезгә сугылдым,—диде Гыймай,—икенче смена кызлары сине өенә кайтып китте, диделәр.

—Без бит товарны икенче складка бушаттык,—дип тиз арада хәйләсен тапты Фатыйма.

—Малай сине көтә-көтә йоклап китте.

—Бик әйбәт.

—Балага ана назы да кирәк бит.

—Атаннар сүзен сөйлисен.

—Минем атамнар сине начарлыкка өйрәтәмени?

—Аларның фикере искерде инде. Бала барлык кыенлыкларны күреп үсәргә тиеш. Аны назлап утырсан, үзен-үзе яклый алмый торган мәми авыз булып үсәчәк ул. Тормышның ни икәнен белсен.

Ир белән хатын ул көнне шактый кызышып алдылар. Гыймай балага

күбрәк игътибар, наз кирәклеген төшендерергә тырышты. Йомшаклык, иркәләү бала күнелenә мәрхәмәт орлыклары сибә. Киләчәктә без балалар кулына калачак кешеләр, диде. Гыймай хатынына күптән әйтеп килә торган үпкәсен кабатлады:

—Кайчан үзебезнең балабыз була инде?

Фатыймага шул җитә калды:

—Заһит үзебезнеке түгелмени? Яхшы булып кыланыр өчен генә син аны үз исемеңә яздырдыңмыни?

—Заһит үзебезнеке, ләкин бер бала...

Фатыйма Гыймайның авызын тиз томалады.

—Бездә хәерчеләр болай да хәттин ашкан. Табасың килсә—үзең тап. Ә син киләчәктә безне балаларыбыз карар, дип өметләнмә. Безнең киләчәгебез—картлар йорты. Хәер, дөньялар болай барса, картлар йортында да урын калмас әле.

Гыймай бәхәсләшүнең мәгънәсе юк икәнлеген аңлап ятарга җыена башлады. Хатын икенче бүлмәгә кереп Заһит биреп җибәргән алтын әйберләрне тиз генә диван астына тыкты да, йокы күлмәген киярга дип көндезге киемнәрен салды. Шулвакыт шыпырт кына Гыймай пәйда булды. Фатыйма тиз генә утны сүндермәкче иде, Гыймай аның кулларыннан эләктереп алды: «Ояласыңмыни?»—диде ул.

—Оялам шул. Гомумән, мин бәләкәй чактан оялчан булып үстем. Хәтта кызлар белән су коенырга да ояла идем.

—Шуна күрә үзеңнән олы малайлар белән ерак күлгә барып коена идегезме?

Заһит янында шактый гына коньяк чөмереп кайткан Фатыйма кинәт кыюланды һәм ире каршына килеп басты: «Әйе шул. Житкән егетләр белән төнлә су коендым. Шуннан?..»

—Шуннанмы?—Гыймай көрәктәй кулы белән Фатыйманың янагына чабып җибәрде. Һич моны көтмәгән Фатыйма очып барып бүлмә почмагына ауды.—Бусы телең өчен, ә бусы...

Гыймай хатынының тәнендәге тешләнгән, күгәргән, кызарган җирләренә төрткәләп: «Бусы азгынлыгың өчен»,—дип тагын берне өстәде. Аннары ынгырашып яткан хатынын тартып торгызды да, нидер уйлап тиз генә ишегалдына чыгып китте. Кергәндә аның кулында бер учма кычыткан иде. Фатыйма өстенә кимәгән килеш һаман аңгыраеп басып тора иде. Гыймай аны диванга бәреп екты да Фатыйманың гел кычытып торган җирен кычыткан белән чабарга тотынды. Хатын үрле-кырлы сикерде, ләкин кычкырмады. «Авыртмый, авыртмый, авыртмый»,—дип үртәде ул ирен.

—Азуың житкән икән, оятсыз,—дип, Гыймай хатынын бүлмәсендә калдырып чыгып китте.

Фатыйма:

«Заһитка әйтеп монын иманын укыттырмасаммы?»—диде ул тешен кысып. Кычыткан чапкан җирләр үтереп сызлый иде. Хатын ул җирләрен одеколон белән ышкыды. Гыймайның ачуын чыгара алуына хәтта шатланды ул. Бераздан Фатыйма торып, кием шкафының ишегенә ябыштырылган көзге каршына килеп басты. Заһит үпкән эзләрне кычыткан кызарткан, хәтта кайбер җирләре чабырып чыккан иде.

«Заһит чын-чынлап ярата мине,—дип уйлады ул.—Никадәр алтын әйберләр биреп җибәрде. Гыймай көне-төне рамнар ясап картайса да, монын кадәр байлык туплый алмаячак. Заһит урлаша икән—урлашсын. Безнең кибет хуҗасы урламый гына баеганмы әллә? Бай кешегә беркем берни әйтә алмый. Кибеттә сатучы булып эшләүче күпме кызларны мыскыл итте. Дәшмибез, чөнки эштән куачак. Байлыгы арткан саен әшәкелеге арта. Хәзер ана гыйффәтле кызлар гына кирәк. Кибеткә эшкә керергә килгән кызларны иң беренче үз кабинетына алып кереп дапрос ясый. Алдашканыңны белсәм эштән куам, дип куркыта.

Гыйффәтле кызларга ул тиз генә кагылмый. Алар янына чыгып эшләгәннәрен күзәтә һәм кызлар бераз уяулыкларын югалтып алсалар, берәр кыйммәтле әйберне чәлеп үз кабинетына яшереп куя. Күпмедер вакыт үткәч: «Кызлар, безнең теге кыйммәтле әйберебезне сатып алмадылармы әле?—дип сорый.— Алмаган булсалар үземә кертегез, берәү шалтыратып шуны сораган иде»,—ди.

Әнә Сөмбел белән ни булды. Шундый чибәр, чәчләрен күрсәтмичә ак яулык бәйләп килгән иде беренче көнне. Сәгыйть Хәмитович ана: «Бу мәчет кибете түгел, син озын итәкле кулмәген, муеныннан урап бәйләнгән яулыгын белән минем клиентларымны куркытып бетерәчәксен. Бездә эшләргә теләсән, киеменне алыштырырга туры килер, матурым»,—диде.

Сөмбел бик озак эзләп, таныш кызлары аша гына тапкан иде бу эшне. Ә ак яулыкны ул әнисе кушуы буенча иптәш кызларына ияреп бәйләгән иде. Кыз аны ничек тиз бәйләсә, шулай салып та атты: «Ходай кичерер. Кием алыштырганга карап кына минем күнелем үзгәрмәс. Аллага шөкер, иманым нык, аны яулык кебек кенә алыштырырлык түгел»,—дип үз-үзен юатты Сөмбел. Ул әле таудан төшә башлагач тукталып калу мөмкин түгеллеген анламый иде. Башка кызлар кебек киенеп килгәч Сәгыйть Хәмитович: «Менә бит, ә! Нинди чибәрлекне яулык астына яшереп йөрисен. Матурлык бит ул Ходай тарафыннан сирәк кешеләргә генә бирелә торган байлык».

Сөмбел жинелчә киенеп йөри башлагач,дөрестән дә, анын товарын сатып алучылар күбәйде. Хәтта күптән сатылмый яткан кыйммәтле суыткыч, савыт-саба юу машиналары да хутка китте.

—Менә бит, матурым,—диде хужа кызны хуплап,—бездә кешене киеменә карап бәялиләр.

Һәм Сәгыйть Сөмбелгә: «Бусы лично минем үземнән премия,—дип ана зур гына сумма бирде.—Теге сатучыларга әйтмә, юкса көнләшү китәчәк. Ә мин коллективнын тату булуын телим».

Сөмбел бу акчаларга бик сөенде. Эшләр шулай әйбәт кенә барганда Сөмбел эшли торган бүлектән бер кыйммәтле әйбер югалды. Сәгате-минуты белән моны хужага житкерделәр. Сәгыйть кызны үз кабинетына чакыртты.

—Йә, нишлибез инде,—дип, хужа Сөмбелгә текәлде.

—Белмим, абый.

—Ничек белмисен? Үзен сата торган һәр нәрсәне барлап торырга тиеш син. Иртән килгәндә бар идеме?

—Белмим, абый.

—Димәк,белмисен. Белмәгәннен беләге авыртмый, дисендер.

Сөмбел дәшмәде.

—Алай, алай. Син белмисен.

Сәгыйть бүлмә буйлап йөренә башлады. Йөзенә бик уйчан кыяфәт чыгарды, аннары кызнын жилкәсенә үзенен кулын куеп: «Нишләргә икән сон инде синен белән?—дип кызнын күзләренә карады.—Бик яшь, бик чибәр үзен. Ә чибәр сатучылардан әйберне күбрәк алалар. Хезмәт хакын әйбәт булыр иде. Ләкин берни эшләр хәл юк. Чыгарырга туры килә...»—Ул өстәл тартмасыннан кәгазьләр алып нидер язарга тотынды.

Сөмбелнен коты очты. Эш табып, өйгә акча кайтара башлагач әнисе белән сенелләре ничек сөенгәннәр иде. Теге көнне хужа биргән акча ике айга фатирга түләргә житте. Житмәсә Сөмбел иптәш кызлары алдында күп акча алуы белән бераз мактанып та алган иде.

Кыз хужанын каршысына килеп башын түбән иде. Анын күзләрендә яшь иде.

—Сәгыйть абый, үтенәм сездән, мине эштән чыгармагыз. Әнием жыештыручы булып эшли. Ә жыештыручыга, үзегез беләсез, күпме генә түлиләр. Ике сенлемне укытасы бар.

—Мин кибетемдә караклар тота алмыйм,—диде Сәгыйть Хәмитович.—Читтәге карактан котылып була, өйдәгесеннән—юк.

—Мин карак түгел!—диде Сөмбел күз яшьләрен сөртеп.—Ә югалган әйберне эш хакымнан тотып калырсыз.

—Ничә ай бушка эшләп йөриячәгенне күз алдына китерәсенме соң син?

—Китерәм.

Сәгыйть йомшаган булып кызның башыннан сыйпады.

—Күнелең сафлыгына ышанам.—Сәгыйть кызның иягеннән тотып башын югары күтәртте.—Шундый матур күзләр алдамаслар, дип уйлыйм. Йә, ярый, үзен әйткәнчә, товар бәясен эш хакыннан тотып калырбыз. Ә хәзер, марш! Үз урынына бас. Эшлә!

Сөмбел шатлыгыннан хуҗасының бит очыннан үбеп алды да йөгереп чыгып китте. Сәгыйть исә бу кызны ничек кулга төшерергә икән дип баш ватты.

Оясын яшереп саклаган сандугач кебек, Сөмбел үзенең сафлыгын сакларга тырышты. Сәгыйть Хәмитович аны үзенә ияләштерер өчен еш кына кабинетына чакырып алды. Бергәләп чәй эчкән чаклары да булды. Ләкин Сәгыйть Хәмитович «ялгыш» кына кызның ботына кулын куйса, яки кәнәфидән торганда кулын иннәренә салса, Сөмбел корт чаккандай сикереп тора. Андый чакларда Сәгыйть Хәмитович: «Гафу, матурым, гафу»,—дип куя һәм эше турында сораштырырга тотына. Исәбе: кызның сизгерлеген оету, кулга ияләштерү.

—Йә, ничек соң?—дип сүз башлады ул бер көнне,—Безнең кибеткә ияләшеп буламы? Кызлар обижать итмиләрме? Гаиләдә эшләр көйлеме?

—Рәхмәт, Сәгыйть Хәмитович. Кибетегез миңа бик охшый. Сатучылар да әйбәт. Ә гаилә хәлләре...—Кыз җөмләсен тәмамлый алмады, тамагына кайнар төер утырды. Күзләреннән яшьләр тәгәрәп төште.

—Нәрсә, матурым, гаиләгездә берәр бәхетсезлек бармы әллә?

—Әйе, Сәгыйть абый.

—Әниен чирлиме? Сенелләрен берәр бәлагә юлыкканмы?

—Юк, әни исән-сау, Аллага шөкер. Сеңелләр дә әйбәт кенә.

—Алайса, мин берни аңламыйм.

—Әнине эштән чыгарганнар.

Сәгыйть тозлап-борычлап сүгенеп куйды. Аннары:

—Әниең җыештыручы дигән идең. Нәрсә җыештыра иде ул?

—Теге «Олимпия» кибетен.

—Хуҗасы кем әле анын?

—Мин аны ныклап белмим. Ниндидер хатын-кыз.

—Алай!—Сәгыйть уйланып идән буйлап йөренде, аннары кинәт бер карарга килеп:—Әле әниен өйдәме?—дип сорады.

—Өйдә!

—Әйдә, алайса сезгә киттек.—Сәгыйть Хәмитович машинасын чакыртты. Шәһәр зур түгел, Сөмбелләргә тиз барып җиттеләр.

Сөмбелнең әнисе аларны бераз гаҗәпләнебрәк каршылады. Сөмбел ашыга-ашыга:

—Бу безнең хуҗабыз, Сәгыйть Хәмитович була,—дип кунак белән әнисен таныштырды.

—Рәхим итегез,—диде ана.—Хәзер чәй әзерлим.

Ләкин ана Сәгыйть Хәмитович:

—Без озакка түгел, чәйләр куеп тормагыз, ханым—диде.

—Сөмбел миңа сезне эштән алганнар, дигән иде. Шул дөресме? Мөмкин булса, сәбәбен аңлатыгыз әле.

—Сәбәбен кем белгән инде анын. Пычрак көн иде. Кибеткә кешеләр күп килде. Мин җыештырып өлгерә алмаганмындыр ахрысы. Октябрина Николаевна үзенә чакырып алды да: «Миңа ташбака кебек: «кыймшаныймы-

юкмы»—дип йөргән эшчеләр кирәкми. Документларынны ал да, үзеңә башка урын эзлә»,—диде.

—Алай, алай,—диде Сәгыйть Хәмитович.—Сезнен хужа Октябрина Николаевна бит әле, исемә төште. Әйе, кызу канлы хатын. Тик бер ягы әйбәт: тиз кыза, тиз сүрелә. Шалтыратып карыйм әле, бәлки кире алыр. Ярамый бит инде артыгын кыланырга.

Сәгыйть Хәмитович кесә телефоныннан Октябрина Николаевнага шалтыратты.

—Алло, алло, Октябрина Николаевна, исәнмесез. Сезгә Сәгыйть Хәмитович шалтырата иде. Нинди Сәгыйть Хәмитович дисезме? Оныттыгызмыни? Предпринимательләр жыелышында бергә утырган идек. Әйе, әйе, хәтерегез яхшы икән. Мин «Алдым-бирдем» кибете хужасы. Нинди йомышмы?

Сәгыйть Хәмитович телефоннан сөйләшкәндә өйдә хәтта йөрәк типкәне дә ишетелерлек тынлык урнашты. Ә Сәгыйть сөйләшүне юри озаккарак сузарга тырышты.

—Йомыш, дип, әлләни йомыш юк инде. Хәлләрегезне беләсем килде. Хәлләр әйбәт дисез инде алайса. Ансына мин шат. Тик сезгә бер кечтеки генә үтенеч барые. Нindиме?—Сәгыйть Сөмбелнең әнисенә карады:—Исемегез ничек әле, апа?

—Хәтимә.

—Сездә жыештыручы булып Хәтимә ханым эшләгән икән. Сез аны эштән чыгаргансыз.—Телефонда тавыш яңгырап торды, тик аны аңларлык түгел иде. Сәгыйть сүзен дәвам итте:—Ну, һәрберебез кеше бит. Кайсыбызда андый гына гонаһ юк, Октябрина Николаевна. Бәлки кире алырсыз, ә? Мин аларның гаиләсен беләм. Эшчән, тәртипле гаилә. Әле менә бер кызларын үземә эшкә алдым. Нәрсә? Ансы инде әйтмәсәгез дә билгеле. Буш итмәм, әлбәттә. Йә, ярый алайса, килештек. Бик зур рәхмәт сезгә, Октябрина Николаевна. Хәзергә хушыгыз. Бер килеп чыгармын әле сезгә.

Сәгыйть Хәмитович бик зур эш эшләгәндәй үзеннән канәгать калып: «Иртәгедән эшкә чыга аласыз, Хәтимә ханым,—диде.—Ә син, Сөмбел, бүген кибеткә барып тормасаң да ярый. Эш вакыты бетеп килә.

—Сезгә нинди рәхмәтләр әйтсәм дә әз булыр инде,—диде Хәтимә. Алар сөйләшкәндә кухняда чәй кайнап утыра иде, Сәгыйть Хәмитовичны көчләп диярлек табынга утырттылар. Ул үзенең телефоныннан шоферына әмер бирде: «Ибрай, очып кына «Тәм-том»нан бер торт апкил.

—Кирәкмәс иде инде, Сәгыйть Хәмитович,—диде Сөмбел.—Болай да безнең өчен бик зур эш эшләдегез.

Шофер торт алып килгәнче табындагы сыйлар белән чәй эчә тордылар.

—Киләсегезне белгән булсам, коймак пешереп торган булыр идем,—диде Хәтимә өстәлдәге сыйның сыеклыгына кыенсынып.

—Кыенсынмагыз, Хәтимә ханым. Ипи белән май—шул ук коймак инде ул. Без үзебез дә әлләни ашап үсмәгән.

Чәй эчеп утырганда Сәгыйть Хәмитовичның шоферы зур каплы торт һәм берничә шоколад алып керде. Үзе шунда ук чыгып китте.

—Мин шоферымны алдан ук кисәтеп куйдым: әгәр мин бер эш кушсам, икеләтә итеп үтә, дидем,—диде Сәгыйть Хәмитович.

Болар чәй эчкән арада ике кыз да кайтып керде.

—Болар минем сеңелләрем,—дип таныштырды Сөмбел.

—Нәселегез белән чибәрләр икән,—диде Сәгыйть Хәмитович.

—Тәүфикълары булсын инде,—диде Хәтимә. Ә кызларның күзе табындагы тортка төште.

—Сездә утыру күңелле булса да, миңа китәргә вакыт,—дип Сәгыйть хужаларга рәхмәт әйтеп урыныннан кузгалды.

—Нинди әйбәт кеше!—диде Хәтимә.

—Корсагы менә бу табак хәтле,—дип калды кечкенәләр һәм корсакларына табак каплап Сәгыйть Хәмитович кебек итеп йөреп күрсәттеләр.

—Көлмәгез кешедән,—диде әниләре.

—Без бит шаярып кына,—диде кызлар һәм өстәлдәге тортны ботарларга тотындылар. Кызларны кухня ягында калдырып, Сөмбел белән әнисе олы якка чыкты. Алар икәүләшеп Сәгыйть Хәмитовичны мактадылар.

—Байларның бер-берсенә сүзе үтә шул,—диде ана.

—Әйе, Сәгыйть абый бик әйбәт кеше,—дип раслады әнисенең сүзен Сөмбел.

—Син тырышып эшлә инде, кызым. Хәзер эш табулары ай-һай авыр.

Ана белән кыз Сәгыйтьне мактаганда хуҗа үзенең машинасында эчтән генә елмаеп бара иде. Ул Сөмбелне кулга төшерер өчен тагын ниләр эшләргә икән, дип уйлана. Бу эш шәп барып чыкты. Октябрина Николаевна Сәгыйтьнең үтенечен кире какмады: Сәгыйть соравы буенча Хәтимәне эшеннән чыгарды һәм шул ук кешенең үтенече буенча хатынны эшенә кире кайтарды. Бу кәмитнең Сәгыйть Хәмитовичка нигә кирәген сорап тормады.

Сөмбел иртәгесен эшенә очып баргандай барды. Ул Сәгыйть Хәмитовичка рәхмәт әйтеп чыгарга уйлады. Кыз ишектән күренүгә үк: «Нишләп кабинетым яктырды дисәм, Сөмбел кергән икән»,—дип кызны каршылады.

—Сәгыйть абый, сезгә барысы өчен дә рәхмәт инде.

—Кунак ашы—кара каршы диләрме әле.—Сөмбел хуҗаның сүзләреннән сагаебрак калды. Төлкедәй сизгер Сәгыйть кызның сагайган күзләренә карап: «Мина нигәдер ышанып житмисен, ә мин тырышып йөргән булам...»—Сәгыйть үпкәләгән кыяфәткә керде. Сөмбелдән читкә борылып кәгазьләрен актара башлады. Сөмбел хуҗаның хәтерен калдыруына үз-үзен битәрләде. Аның сүзсез генә чыгып китәсе килмәде.

—Сәгыйть абый, мин сезне рәнҗетергә теләмәгән идем, гафу итегез инде. Ә кунак ашы дигәнегез безнең кулдан килә торган эш булса, без әзер.

Сәгыйть Хәмитович кызга нидер әйтергә теләде, ләкин шулвакыт телефон шалтырады. Аны каядыр чакыралар иде бугай, ул торып басты. Сөмбел дә чыгып китәргә кирәклеген аңлады. Ишектә алар ничектер бергә туры килделәр. Сәгыйть Хәмитович ботинкасына иелгән булып, ялгыш кына кагылгандай кызның калку күкрәгенә битләре белән ышкылып алды. Сөмбел аны-моны уйлап өлгергәнче битеннән үпте һәм яшьләрчә житезлек белән кабинетыннан чыгып китте.

Сөмбел моны аталарча ярату дип кабул итте, ә күкрәкләргә ышкылу—ансы тыгыз жирдә була торган хәл. Әнә, автобуста ничек кысмыйлар! Иртәнге сәгатьләрдә бигрәк тә.

Кыз үзен шулай тынычландырып эшкә керeште. Көне буе күтәренке күңел белән эшләде. Хуҗа каядыр китеп, юкка чыкты. Сатучы кызлар: «Сине хуҗа кая алып барды?»—дип сорашканнар иде, Сөмбел дөресен әйтмәде: «Складка!»—дип кенә куйды.

—Безнең хуҗа төлке кебек ул, син саграк бул,—дип кызны кисәттеләр. Сөмбел үзе дә ниндидер эчке киеренкелек халәтендә йөрде. Ләкин Сәгыйть Хәмитович берничә көн Сөмбелне бөтенләй күрмәгән-белмәгәндәй йөрде. Бер атналап вакыт үткәч кенә болай гына сорагандай: «Теге әйбер табылмадымы?»—дип кызыксынып алды. «Юк!»—дигән җавап ишеткәч, аны-моны әйтми китеп барды.

Ниһаять, хәйләкәр төлкенең түземлеге бетте: Сөмбелне кабинетына чакыртты. Сөмбел кабаланып кергәч, юри башын калкытмый утырды. Сөмбел ике тапкыр: «Исәнмесез, Сәгыйть Хәмитович!»—дип кабатлагач кына: «Ә-ә, Сөмбел матурым, син икәнсең,—дип әйтеп куйды һәм:—Мин сине ике айга сынау шарты белән алган идем. Сынауны бик әйбәт уздың дип булмый...—

Сәгыйть күзлеген күтәреп кызга карады.—Нишләргә инде синен белән. Килешү төзергәме—юкмы?»

Сөмбелнең йөрәк тибеше ешайды. Ул ни дияргә белми хуҗага карады. Хуҗаның йөзе кырыс, карашы ачулы кебек иде.

—Сәгыйть абый, үзегез күрдегез бит безнең тормышны.

—Күргәнгә аптырап утырам менә, юкса, бүгеннән куып чыгарыр идем,—диде Сәгыйть Хәмитович.

—Сәгыйть абый, әйбәт кенә эшлим бит инде.

—Начар эшләсән, сөйләшеп тә тормас идем.

—Калдырыгыз, зинһар, Сәгыйть абый, ни кушсагыз, шуны үтәрмен,—диде кыз.

Сәгыйть озак кына уйланып утырды. Аннары бер карарга килеп сикереп торды.

—Йә ярар, әниен, сенелләрен хакына эштә калдырам. Менә бу килешү кәгазенә кул куй.

Сөмбел кәгазьгә язылган сүзләрне укып та тормыйча кул куйды.

—Нишләп укымаган килеш кул куйдың?—дигән булды Сәгыйть.

—Мин сезгә ышанам, Сәгыйть абый,—диде Сөмбел. Артык киеренкелектән аның тамагы кипте. Ул иреннәрен ялап куйды. Сәгыйть Хәмитович суыткычны ачып бер шешә минераль су алды.

—Бирәр стакан эчеп куй әле менә бу шифалы суны,—диде.—Хәл кереп китәр үзенә.

Стаканга салганда ук күбекләнеп, чыпырдап торган су ачкылтым тәмле иде. Кыз тын да алмыйча стаканны бушатып куйды. Тәне буенча рәхәт салкынлык йөгерде. Ул инде чыгып китәргә уйлаган иде, ләкин бер адым атлауга башы әйләнеп чайкалып китте. Шуны гына көткән Сәгыйть Хәмитович аны кочаклап алып кәнәфигә утыртты.

—Шатлыктан бу, шатлыктан,—дип сөйләнде үзе.—Бераз хәл җыеп ал. Стрессың үтсен.

—Сез миңа аракы эчердегез ахры, Сәгыйть абый. Мин исердем бугай.

—Миңа мондый яла яксаң договорны ертып ыргытам.—Сәгыйть Хәмитович килешү кәгазен алды.—Ертып ыргытам да куып чыгарам.

Сөмбелнең аны аракы кушылган газлы судан бераз томаланган булуга карамастан хуҗаның ачулы сүзләре акылның бормалы юлларын узып тормыйча йөрәгенә барып җитте.

—Гафу итегез, Сәгыйть абый,—диде ул.—Сез әйткәнчә, шатлыктан исеребрәк киттем бугай.

Сәгыйть газлы су шешәсен циркта гы фокус күрсәтүче тизлегендә икенчесе белән алыштырып куйган иде. Ул Сөмбелнең сүзләренә һаман үпкәләгән булып кыланды.

—Минем бернинди гөнаһым юклыгына сине ышандыру өчен хәзер мин бер кызны чакырам. Ул эчеп карагач ни әйтер икән. Шиген калмасын өчен менә әле генә үзең суын эчкән шешәне тотып теге якка чыгып тор. Мин аны синең кулыңнан алып аңа эчерермен.

Сөмбел:

—Мин болай да ышанам сезгә,—дисә дә, Сәгыйть Хәмитович бер сатучы кызны алып керде. «Менә бу суны эчеп карагыз әле. Агу дип шикләнсәң, башта үзем эчеп карыйм».

Сәгыйть Хәмитович Сөмбел кулыннан сулы шешәне алып ике стаканга салды. Берсен үзе, икенчесен сатучы кыз эчте.

—Ну, ничегрәк?

Кыз җилкәләрен сикертеп куйды.

—Миңа калса, газландырылган шифалы су.

—Ярый, алайса,—диде хужа,—эшегездә булыгыз. Әгәр башыгыз әйләнгәнен тойсагыз, шундук миңа кереп әйтегез.

Сатучы кыз чыгып китте. Сөмбел хужаны кыен хәлгә куюыннан унайсызланып кабинетка чыкты. Аның инде баш әйләнүе узган, күңеле күтәрелеп, моңарчы татып каралмаган җиңеләю халәтенә күчкән иде. Ул тиктомалдан көләргә тотынды. Сәгыйть Хәмитович «җимеш» өлгереп җитте, дип Сөмбелнең чәчләреннән сыйпады.

—Мин сине үз кызым кебек яратам,—диде ул кызны куллары белән капшап.

—Мин дә сезне әтием кебек яратам,—диде кыз.

—Кил әле, алдыма утыр. Бер ратыйм үзеңне.

—Ярамый, гөнаһ була.

—Әтинең алдында утыру гөнаһмыни?

...Сәгыйть Хәмитович юмалый-юмалый кызны алдына утыртты. Башта аталарча чәчләреннән сыйпады. Әти кочагы күрмәгән кызга назлау ошады. Ә карт төлкенең калын иреннәре әкрен-әкрен кызның муеннарына барып җитте. Түштәге ике төймәнең ничек чишелгәнен дә сизми калды Сөмбел. Иреннәр оядагы сандугачка килеп җиткәч кенә айнып китте ул.

—Юк, ярамый, Сәгыйть абый, бу гөнаһ, бик зур гөнаһ.

—Гафу, сеңлем, гафу, син газлы судан исереп киткән кебек, мин дә синең исеңнән исердем.

Кыз инде айнып килә иде. Ул кинәт ыргылып Сәгыйть Хәмитовичның кочагыннан чыкты. Сумкасыннан кечкенә көзге белән тарагын алып чәчләрен төзәткәләде. Сәгыйть исә, каймакка тел очын гына тидереп алган мәче сыман, чыгып киткән кызга карап калды.

Сөмбел үз урынына чыгып баскач иптәшләренең йөзендә ниндидер үзгәреш сизде. Аларның күзләрендә кызгану чагыла иде сыман. Ләкин кыз үзен гаепле тоймады.

Сәгыйть берничә көн Сөмбелне эзәрлекләми йөрде. Ләкин аның түземе озакка җитмәде—кызны чакыртты.

—Кызымны сагындым,—диде ул.—Кил әле, теге көнге кебек бер иркәлим үзеңне.

—Юк, юк, Сәгыйть абый, ярамый. Гөнаһ!

—Синең бар сүзең шул—гөнаһ. Ә бит мин сине бәхетле итәргә генә телим. Ходай ир белән хатынны яраткан икән, димәк, гөнаһ түгел.

—Мин бит сезнең хатыныгыз түгел. Никахка кадәр мин чит-ят ирләргә карамаячакмын. Сафлыгымны никахлы ирем өчен саклыйм.

Шулвакыт Сәгыйтьнең башына бик кыю бер фикер килде.

—Әйдә алайса никах укытабыз,—диде ул,—минем дә гөнаһлы буласым килми.

Сөмбел югалып калды. Сәгыйть кызның халәтеннән файдаланып, булдыра алган кадәр матуррак сайрарга тырышты.

—Мин сине байлыкта йөздерәчәкмен. Әниеңне дә, үзеңне дә кирәк җиргә машинада гына йөртерләр. Сеңелләреңне престижный мәктәпкә бирербез. Алар укып зур кеше булырлар. Ярлылыктан мәңгегә котылырсыз.

Сөмбел, ниһаять, кирәкле сүзне тапты.

—Сезнең бит хатыныгыз бар, Сәгыйть абый.

Сәгыйть Хәмитович бу сүзне көткән һәм аның җавабы әзер иде.

—Мин мөселман лабаса. Ә мөселманга ике-өч хатынга өйләнү дә харам түгел. Аллага шөкер, ике хатынны гына тотарга хәлемнән килә.

Кыз болай гына котылып булмаячагын аңлады. Ул Сәгыйть Хәмитовичның күлмәген ярып чыгам-чыгам дип торган корсагына, тамчы-тамчы тир бөртекләре тәгәрәгән битенә карап алды. Хәйләкәр һәм сизгер Сәгыйть Хәмитович гүя ки кызның фикерләрен укып барган. Ул гади генә итеп:

—Карама йөзенә—кара йөрәгенә, диләр түгелме? Ә йөрәк минем Аллага шөкер—аракы чөмереп, наркотик кадатып йөргән яшьләрнекеннән шәбрәк!

Сөмбел бу «ит тавы» белән яшәүне һич күз алдына китерә алмады. Кабинеттан тизрәк чыгып китәр өчен генә: «Әни белән киңәшсәм ярыймы?»—дип сорады.

—Әлбәттә,—диде Сәгыйть Хәмитович,—рәзе мондый олы эшне әниләр белән киңәшмичә эшлиләр. Уйлашыгыз, киңәшегез. Ризалык бирмәсәң дә үпкәләмим. Тик бер нәрсә...

Сәгыйть чишеп булмаслык мәсьәлә алдында калган укучы кебек бер ноктага карап торды. Аннары авырлык белән генә:

—Минем тәкъдим кире кагылган очракта безгә аерылырга туры килер. Чөнки синең кояшка тиң йөзеңне күреп тә янына якын бара алмау, ефәктәй чәчләреңнән сыйпый алмау минем өчен зур газап булачак.

Киткән чакта Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә бер төргәк бирде. «Бусы әниеңә күчтәнәч. Теге көнне сездә эчкән чәйнең тәме һаман телемнән китми. Гаиләгезнең татулыгы, гади генә ризыкны да олылап табынга куюм—мине сокландырды,—диде ул.—Димәк,  ризыкның кадерен беләсез. Ә бит әле бездә бер сынык ипигә тилмереп яшәүчеләр белән бергә, икмәк кадерен белмичә, аны туптай типкәләп йөрүчеләр дә бар».

Сөмбел ул көнне өйләренә уйга батып кайтты. Әнисе аның йөзен күреп куркып китте.

—Әллә эштән чыгардылармы, кызым?

—Юк, аннан да начаррак.

Ана аптырашта калды. Сөмбел әнисен озак көттереп интектермәде, барысын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ана башта бик нәфрәтләнде. «Мин аны юньле кешегә санап калган идем, ә ул азгын җан икән»,—диде. Әнисе эчендәге бөтен ачуын чыгарып бетергәч, Сөмбел: «Онытып торам икән, Сәгыйть Хәмитович сиңа ниндидер күчтәнәч биреп җибәргән иде, менә»—әнисенә төргәкне сузды. Ана ана озак кына кагылмады. Ниндидер эшләр эшләп, күңелен бераз баскач кына төргәкне ачты. Ачты да, авып китә язды.

—Нәрсә булды, әни?—диде Сөмбел әнисенең куркулы йөзен күргәч.

—Үзең кара!—Ана төргәкне кызына сузды. Төргәктә бер чүмәлә акча иде. Ана белән кыз бер-берсенә карашып уйга баттылар.

—Сине сатып алырга уйлаган бу!—диде ана нәфрәтләнеп.—Байлар бөтен нәрсәне акча белән сатып алып була, дип уйлыйлар, ахры.

Сөмбел әнисен сүзсез генә тыңлап утырды. Акчаларга карап аптырашып утырганда кече кызлар—Нәсимә белән Рәсимә кайтып керде. Нәсимә инде сигезенче сыйныфта укый, акчалы классташларына көнләшеп карый иде. Бу кадәр акчаны күргәч, аның күзләре яна башлады.

—О-о!—диде ул.—Әллә берәр банк башлыгызмы?

—Юкны сөйләмә әле,—диде әнисе.

—Әллә күктән фәрештәләр төшердеме безгә бу байлыкны?—диде Рәсимә.—Фәрештәләр бүләге булса—миңа бер сотовый алып бирәсез. Фотоаппаратлысын.

—Сотовыйны башта миңа,—диде Нәсимә.—Безнең класста бер мин генә сотовыйсыз.

—Монда икебезгә дә җитә,—диде Рәсимә.—Бу акчалар чынлап та безнеке булса, мин обедта каткан булка белән салкын компот чөмереп утырмас идем.

—Сиңа, ач тәрегә, ашарга гына булсын.

—Ашау—самый главный!

—Матур киенергә, өйгә компьютер алып куярга. Компьютерны интернетка тоташтырырга. Интернетта шундый кызык әйберләр бар. Әнә, Гүзәлләрнең нәрсәсе генә юк!

—Һы, анын әтисе бизнесмен бит.

Кызларнын күнеле хыялга бай иде. Әллә нәрсәләр «алып» бетерделәр. Әгәр әниләре:

—Атмаган куяннын тиресен бүлешмәгез әле,—дип туктатмаса, Нәсимә белән Рәсимә байлар кибетендәге яхшы әйберләрнен бөтенесен өйләренә ташып бетергән булырлар иде.

Өйдә бераз тынлык урнашкач, бу акчаларнын каян килгәнлеген һәм артында нәрсә торганлыгын кечкенәләргә дә анлатып бирергә туры килде. Кызлар башта кычкырып көлделәр, аннары апаларын үртәп алдылар. Бу гаиләдә һәркем тигез хокуклы булганлыктан, тормыштагы барлык мәсьәләләр уртага салып хәл ителә иде. Сүзне Нәсимә башлап җибәрде.

—Ә нигә? Начар идея түгел бу. Хуҗанын яшь хатыны булып, карт хатынга приказ гына биреп ятасын.

—Үзенә машина алдыр,—диде Рәсимә.—Безне мәктәпкә машинаң белән илтеп куярсын, барып алырсын. Әтиләренен машиналарында түш киереп утыручы Чулпаннарнын, Ринатларнын күзләре мангайларына менсен әле!

—Сезгә әйбер генә булсын,—диде Сөмбел ачуланып,—минем турыда уйламыйсыз да.

—Әле никах укытып алганга рәхмәт әйт. Әнә, безнен Рәмзиянен апасы үзенен хуҗасына сөяркә булып яши,—диде Нәсимә.—Картларга кияүгә чыгу хәзер модада. Беренчедән, алар байлар, икенчедән, озак яшәмиләр. Байлыклары сиңа кала.

—Сезнен күнелегездә мондый уйлар бардыр дип башыма да китерми идем,—диде ана.—Апагызны байлыкка сатабызмыни?

—Хәзер кызлар гына түгел, ярлы егетләр дә байрак кызларны сайлый.

Бәхәс озак барды. Әниләре:

—Актыккы сүзне Сөмбел үзе әйтергә тиеш,—диде.

—Юк, әни, син әйт. Мин гомер буе синен сүзеннән чыкмадым. Дин юлына бас дигәч, башыма ак яулык бәйләдем. Догалар өйрәндем. Тик дөресен әйтергә кирәк, дога укый башласам минем уйларым әллә кая еракка китә. Догамны ялгышып бетәм.

—Күнелендә Аллага ныклы ышаныч булмаганлыктан ул, кызым.

—Ышанырга бик тырышсам да барыбер күнелгә шикләр килә бит. Башка ак яулык бәйләп кенә кара уйлардан котылып булмый икән.

—Моңа озак вакыт кирәк, кызым.

—Менә син Аллага чын күнеленнән ышанган кеше, әни. Турысын гына әйт: үзеннән ике тапкыр олы кешегә икенче хатын булып баруны син хуплыйсынмы?

Хәлимә ни әйтергә белмәде. Әлбәттә, һәр ана кебек, анын да кызын бәхетле итәсе килә. Сөмбел үзе кебек яшь егеткә чыгып, матур-матур балалар үстерсә, ире гаиләне туйдырып тора алса ни әйтер иден дә бит. Ләкин хәзерге яшьләр өйләнергә атлыгып тормый шул. Рәтләп эшләүчесе дә юк: кайсы эчкече, кайсы наркоман. Акыллыраклары чит илгә китәргә тырыша. Дөньясы болганды шул, дөньясы. Кызы бозык юлга басса нишләрсен? Андыйлар әзмени хәзер. Яхшылык белән яманлык буталган заман.

Ана шундый уйлар тезмәсен күнеле аша үткәргәннән сон, Сөмбелгә болай диде:

—Кызым, жаным тартканга түгел, бозылып китүеннән куркып ризалыгымны бирәм. Никах белән яшәсәгез, ичмасам гөнаһы булмас. Менә минем сүзем шул, калганын үзен кара. Байлыгына кызыгып ризалыгын бирде дип уйлама. Мин ипи белән бәрәнге ашап яшәсәм дә, риза. Ә сез—яшьләр, үзегезнен дусларыгыздан ким буласыгыз килмәгәнне анлыйм.

Ана сонгы сүзләрен көчкә генә әйтте. Анын тамагында кайнар төер,

күзләрендә яшь иде. Ул бозык дөньядан бераз чистарыну өчен намазлыкка басты.

Бөтен җаваплылыкны үз өстенә алгач, Сөмбелгә авыр булып китте. Армиягә озатып җибәргән егете хезмәт срогын тутыргач, шул хезмәт иткән шәһәрендә маржа кызына өйләнеп, маржасын кунакка алып кайткач, шундый авырлык кичергән иде инде ул. Хәзергесе тагын да авыррак булыр сыман. Әгәр хуҗаның тәкъдименнән баш тартса, Сәгыйть Хәмитович аны эзәрлекләячәк, буйсынмасан, куып чыгарачак.

* * *

Иртәгесен Сөмбел эшкә кәефсез килде. Төне буе йокламыйча уйланып яту үзенекен итте, курәсен. Сәгыйть Хәмитович кыздагы үзгәрешне шунда ук күреп алды. Ул Сөмбелне кабинетына чакырып: «Минем матурыма нәрсә булган? Кемнәр рәнҗеткән аны?»—дип, кыз тирәсендә бөтерелде. Сөмбелнең күзләреннән яшь тамчылары чыгып, керфекләренә эленде. Әлбәттә, хәйләкәр төлке кызның халәтен аңлый. Тик җавапны кызның үз авызыннан ишетергә тели иде. Ул Сөмбелне ашыктырмады. Кәнәфиенә утыртты, су тәкъдим итте, ләкин кыз сулы стаканны читкәрәк этеп куйды да елап җибәрде.

Сәгыйть Хәмитович бу елауның артында ни ятканлыгын яхшы аңлады. Йомшак күңелле кызлар үзләренең иң кыйммәтле байлыклары белән хушлашканда сабыйларча елап җибәрәләр. Аларның бу күз яшьләре ясалма булмый. Сәгыйть Хәмитовичның яшь чагында моны аңламыйча авызы пешкәне булды. Ул бер кызны яратып йөри, кыз да аңа битараф түгел иде. Бервакыт, алар йолдызлы төндә шәһәрдән кайтышлый, кинәт кенә янгырга очрадылар. Ышыкланырга бер салам эскерте янына килделәр. Сәгыйть тиз-тиз генә эскерт эчендә чокыр ясады, кызны да үз янына алып керде. Алар бер-берләренә терәлеп җылынып утырдылар. Ләкин яшь тән, яшь җан бер-беренә тартылмый каламыни?! Сәгыйть ныграк кочкан саен кызның каршылыгы кими барды. Ул инде Сәгыйтьнең учында өлгергән җимеш кебек иде. «Йотып» җибәрер вакыт җиткәч, кыз мышык-мышык елап җибәрде. Сәгыйть аптырап кызны кочагыннан ычкындырды. Ә күпмедер вакытлар үтеп, ул чибәркәй тормышка чыккач, аларга тагын бер очрашырга туры килде. Шунда кыз Сәгыйтькә: «Пешмәгән егет идең син,—диде.—Кызларның елавы—яшьлеге белән саубуллашу, ул ризалык билгесе».

Димәк, Сөмбел аның тәкъдименә риза. Ләкин кыз аны үзе әйтергә тиеш.

—Ни булды, матурым?—диде Сәгыйть «пешкән җимеш» тирәсендә бөтерелеп.

—Әни риза,—диде Сөмбел пышылдап.

—Нәрсәгә?—дип сораган булды Сәгыйть.

—Сезнең белән никахлашырга.

Сәгыйть Хәмитовичның шатлыктан күзләре ялтырады, йөрәк тибеше ешайды.

—Синең әниең бик акыллы шул. Мин аны бер күрүдә аңладым. Акыллы анадан акыллы бала туачагы билгеле.

—Тик, Сәгыйть Хәмитович, мин сезнең карт хатыныгыз белән бергә торырга риза түгел...

—Әлбәттә, матурым. Кем инде былбыл баласын карга оясына ябa?! Без синең белән, сандугачым, аерым фатирда яшәрбез. Син шәһәрнең кай тирәсеннән алырга теләр идең фатирны?

—Әниләргә якынрак җирдә булса...

Сәгыйть Сөмбелнең фикерен күтәреп алды.

—Әлбәттә, матурым. Әниләргә якынрак яшәү яхшырак. Сагынганда йөгереп кенә кереп чыгасың. Әниләр белән киңәшеп эшләү, аралашып яшәү

зур бәхет бит ул. Менә минем үземә андый бәхет тәтемәде. Әни мине бик авыр тапкан, авырып киткән, шуннан терелә алмаган. Миңа ана назы күрергә туры килмәде. Гомерем буе аналы балалардан көнләшеп яшәдем.

Сәгыйть авыр сулап куйды. Сөмбел Сәгыйть Хәмитовичны кызганып, аның эш өстәлендә ниндидер кәгазьләр өстендә яткан кулын сыйпап алды. Сәгыйть Хәмитовичның эченә жылы йөгерде. Шатлыктан жаны күкләргә ашардай булып бәргәләнде.

Алар никахны Сөмбелләрдә укыттылар. Фатир алуны да бик тизләтте Сәгыйть Хәмитович. Сөмбелләр яши торган микрорайонда биш катлы йорт төзелеп бетеп килә иде. Сөмбелне шул йортка алып кереп:

—Менә шушы йорттан кайсы фатир сиңа охшый—шуны алырбыз,—диде. Сөмбелгә ике бүлмәле фатир бик ошаган иде, ләкин ул: «Моны әйтсәм, артык комсызлану булыр»,—дип бер бүлмәлене күрсәтте.

Сәгыйть Хәмитович аны тиргәп алды.

—Син нәрсә, матурым! Шушы сыерчык оясына кереп утырыр идеңме? Син хан сарайларын бизәрлек кеше. Аннары киләчәгебез турында да уйларга тиешле без. Син миңа тупырдап торган ике малай табып бирерсең.

Бу сүзләрдән соң Сөмбел кызарып куйды. Ул әле һаман акылы белән бу хәлләрне кабул итеп бетерә алмый иде. Сәгыйть Хәмитович аны житәкләп өч бүлмәле, ике зур балконлы фатирга алып кереп: «Менә шушында булыр безнең оябыз»,—диде. Сәгыйть Хәмитович Сөмбелнең бу микрорайоннан фатир сайлавына икеләтә сөенде. Беренчедән, шәһәр читендә фатирлар арзан, икенчедән, беренче хатыныннан шактый ерак. Сөмбел белән никахлашуны ул яшертен эшләде. Эш пешкәч, алма авызга төшкәч, карт хатынны ризалату авыр булмас. Ул тиктомалдан тәртә жимерә торган хатын түгел. Фатирны Сәгыйть Сөмбел исеменә яздырды. Әйдә, күңеле тыныч булсын.

Фатирның эчен ул үз зәвыгы белән эшләтте. Жиһазларны бергәләп сайладылар. Оя корылып беткәч Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә:

—Матурым, сине һәркөн эшкә машина белән килеп алырлар, илтеп куярлар. Ә миңа беренче хатыным янына да кайткаларга туры килер. Ничек кенә булмасын, мин аны ташлый алмыйм. Анда минем ике кызым үсә. Синең яныңа еш килә алмасам, үпкәләмә.

Кая үпкәләү! Бу сүзләр Сөмбелне сөендерде генә.

Сәгыйть Хәмитович яңа фатирда яшь бикәч белән берничә көн яшәүгә, ике атналык ял алып Төркиягә киттеләр. Сөмбелнең моңа кадәр чит илләрне түгел, Мәскәүне дә күргәне юк иде. Акчаның нинди көчкә ия икәнен ул шунда аңлады. Сәгыйть Хәмитовичның жонлы түше, гел тирләп торган маңгае да элеккечә ачу китерми, ничектер гадәти булып күренә башлады. Акча, жинел тормыш, әйтергә теләгән фикереңне ярты сүздән аңлау һәм һәр теләгеңне үтәргә әзер торучы барлыгын тою кешене тиз үзгәртә икән.

Сөмбел Төркиядән бөтенләй икенче кеше булып кайтты.

Сәгыйть Хәмитовичның беренче хатыны малай тапмады. Сөмбел авырга узып, малай таба калса, Сәгыйтьнең фамилиясен дәвам иттерүче һәм торабара эшен үз кулына алып, аның мирасчысы булыр иде. Кыз тапса, өч тапкыр «талак» әйтәсең дә, аерылыша аласың. Ә хәзергә әле Сәгыйть бәхетле. Ә Сөмбел яшьтәшләре, кияүгә чыгып та кеше фатирында яки аждаһадай кайнаналары белән бергә яшәгән дуслары алдында мактанырлыгы барлыгын уйлап йөрәк яраларын ямады.

* * *

Заһит гараж подвалын торган саен ныграк баета барды. Төнгеауга ул гел ялгыз йөрде. Артык кеше—артык шаһит. Кешеләрнең берсе сатмаса, икенчесе сата. Үзе озын булса да гәүдәсе ябык, нечкә иде. Шуна күрә форточкадан

жайлы гына кереп-чыгып йөрү ана берни түгел. Күп кенә кешеләр форточкаларын төнлә ачык калдырып йоклыйлар. Ә ярлы кешеләр, гадәттә, булган акчаларын яшереп маташмыйлар. Күбесенен булган байлыгы шкаф тартмасында саклана. Ә кайбер карчык-корчыклар бармаклары шешенмәсен дип йөзекләрен салып куеп йоклаучан. Әлбәттә, Заһит башта берничә көн үзе төнге «кунак» булып барасы йортны күзәтә. Хужаларнын кайчан йокыга ятуларын һәм торуларын күнеленә беркетә, шуннан сон гына «аугa» чыга. Шулай да, ул бервакыт каба язды.

Бер яшь ханымны шактый озак күзәтте. Урамдагы малайлар белән шаярган булып, ул ханымнын ире бармы-юкмы икәнлекне сорашты. Ире юклыгын белгәч, сулышы жиңеләйде. Ханым бай күренә. Муенында алтын чылбыр, колакларында ярымай рәвешендә ясалган алтын алкалар, бармакларында калын-калын балдаклар. Заһит анын уты кайчан сүнәсен күптән өйрәнеп куйды.

Заһит гадәттә иртәнгә, кешеләр тирән йокыга талгач «эш»кә чыгарга ярата. Бу юлы анын нишләптер озак көтәсе килмәде. Әмма форточка ачык түгел иде. Ишекне иплэп кенә каерырга туры килде. Йорт яна булганлыктан, ханым әле тимер ишек ясатып өлгермәгән, төзүчеләр куеп киткән ишекне үсмер малайлар да жиңел ача. Заһит ишекне ачканда «шылт» иткән тавыш та чыкмады. Хатын ике бүлмәле фатирда яши икән. Заһит залны актарып берни тапмагач, йокы бүлмәсенә чыкты.

—Ханымнын бөтен байлыгы үзендә ахры,—дип уйлап куйды Заһит һәм караваг янына килде.—Аһ, чукынды, сөяркәсе бар икән. Әнә, ничек матур итеп йоклап яталар!

Йокы бүлмәсе... Тәгәрмәчле кечкенә өстәлдә шампан шешәсе, ашалып бетмәгән тәм-томнар. Заһит шешәне күтәреп карады, шешә буш. Димәк, йоклар алдыннан сыйланып утырганнар. Йокылары каты булырга тиеш. Заһитнын башында бер уй туды: чукынып китсен байлыгы, кызык ясап карарга кирәк! Ул чишенде дә, хатын янына юрган астына чумды. Ир гырылдап йоклый. Заһит юрган астында таралып йоклаучы ханымны иплэп кенә кочагына алды. Кайнар тәнгә куллары тиюгә анын бөтен күзәнәкләре уянды. Заһит үзен тыя алмаслык хәлгә килде һәм тәвәккәлләде. Хатын йокы аралаш: «Житте инде, Радик, алай комсызланма»,—диде, әмма йокысыннан уянмады. Заһитка бу мажара бик ошап китте. Ханымнын иреннәреннән, муеннарыннан үбә башлады.

—Ну, Радик, нишләвен бу?—диде ханым.

—Тс-с!—диде Заһит ханымнын авызын учы белән каплап.—Радик түгел әле бу, Бишмунча егете.

Ханым шунда гына ныклап уянды.

—Ой, нәрсә бу?—Хатын сикереп тормакчы булды, ләкин Заһит аны караватка кысты: «Тс-с! Шаулама»,—диде ул, хатыннын колагына пышылдап. Хатын караватка сенде. Заһит хатынны шактый аунатканнан сон, пышылдавын дәвам итеп: «Ә хәзер бөтен алтын әйберләренне салып бир. Тик тавыш кубарырга уйлама. Юкса, сөяркәң белән икегезне берьюлы «кых» итәм».

Хатын Заһитка сүзсез буйсынды. Бармагындагы балдакларын салып бирде.

—Тагын, тагын,—дип ашыктырды аны Заһит. Хатын өстенә халат элмәкче иде, Заһит аны тартып алып Радик өстендәге юрганга ыргытты.

Радик гырылдап йоклый иде. Карават селкенүгә ул икенче якка борылып ятты.

—Акчаларын кая, акчаларын?—диде Заһит хатыннын колагына. Хатын залга таба китте. Заһит аны бик яраткан кешеседәй кысып кочаклап барды. Хатын тавыш кубармасын дип бер кулы белән анын авызын каплады. Ләкин хатын тавыш кубарырлык хәлдә түгел, ул сөяркәсе Радикка чиктән тыш

ачулы. Әгәр икесе генә калырга туры килсә, ничек итеп аннан үч алырга икән, дип баш ватты. «Ваемсыз дуңгыз»,—дип сүкте ул аны эченнән.

Залга чыккач, Заһит иркенләбрәк сулап куйды. Юкса, ул үз нервыларының артык киеренкелегеннән зуррак җинаять эшләп ташламагаем, дип курка иде. Хатын исә, тәмам роботка әйләнгән. Заһит кая ымласа шунда бара, ни кушса шуны үти. Акча уенчык аюның эченә яшерелгән икән, бар байлыгын Заһитка тоттырды. Болар акча белән мәш килгәндә нәрсәдер шапылдап төште. Тавышка Радик дигән бәндә уянып китте. Янында сөяркәсе юклыгын күргәч: «Иркәм, син кайда?»—дип сикереп торды. Утны кабызды. Заһит хатынның колагына: «Бу минем беренче мәхәббәтем, дип әйт, юкса...»—дип хатынның касыгына берне төртеп алды.

Радик хатынны эзләп залга чыкты һәм телсез калды. Аның иркәсе бер ят ир белән кулга-кул тотынышып тора. Хәтта өсләренә дә кимәгәннәр. Оятсызлар.

Радикның каушап калуын күреп Заһит батыраеп китте: «Бу кем? Нишләп синдә кунып ята ул? Әле син ике сөяркә тотасыңмыни?»—дип хатынга бәйләнә башлады. Хатын:

—Радик, ул бер карак, тизрәк милиция чакыр,—дигән иде, Заһит хатынның яңагына чалтыратып чабып җибәрде.

—Әле син күзгә карап алдаша да беләсеңме?—Заһит хатынны диванга төртеп екты. Хатын Радик аны яклашыр, дип көткән иде. Әмма Радик: «Аһ оятсыз, кабәхәт! Мин сиңа күпме бүләкләр ташыдым. Үз хатыныма алмаган алтын-көмешләр алдым. Сиңа берни дә җитми икән: байлык та, ирләр дә. Комсыз фәхишә!»—дип диванда үксеп ятучы хатынның артына чалбар каешы белән берне сылады да, ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Заһит хатынны җәлләп куйды.

—Синдә бүтән акчаң калмадымы?—дип сорады.

—Ю-у-ук,—диде хатын үксүен тыя алмыйча. Заһит теге аю эченнән чыккан төргәкне сүтте. Анда шактый күләмдә долларлар күреп: «Оһо,—дип куйды,—әллә чит илгә китәргә җыена идеңме?—Хатын дәшмәде. Заһит аның янына утырып куе йомшак чәчләрен сыйпады.—Ярый инде, тукта. Елак хатыннарны яратмыйм мин. Ә байлык өчен кайгырма. Синең кебек чибәр хатыннар байлыкны момент җыя аны. Яна сөяркәләреңнән ике тапкыр күбрәк сора. Ә бу,—ул Радик чыгып киткән якка ымлап,—бу синең бер тырнагыңа да торырлык түгел. Куркак! Хәзер ул синең фатирның ишеген кагарга да куркачак».

Заһит сөйләнә-сөйләнә төргәктән бер яшел йөзлекне суырып алды да:

—Бусы яши торырыңа,—дип хатынның тирләгән корсагына чәпәде. Икенче йөзлекне хатынның кендек астына сылады.—Бусы кочагыңда яткырган өчен. Ә менә монсы чибәрлегең өчен.—Заһит яшел йөзлекне төкреклән ханымның түшендәге алмалары арасына ябыштырды. Аннары Заһит киемнәрен киенеп алды һәм хатын каршына басып:—Әйдә, дуслар булып аерылышыйк. Саубуллашу йөзеннән бер үп тә—мин китәм.—Заһит хатынга битен сузды. Рухы сындырылган хатын Заһитның әмерен үтәде: иреннәрен аның битенә тидереп алды.

—Бездә аны менә болай итеп үбәләр,—дип Заһит хатынны кочагына кысып озаклап үпте. Һәм чыгып киткәндә:

—Син миңа бик ошадың, бу безнең соңгы очрашу булмас, дип уйлыйм. Артык чибәр син. Мондый чибәрлек күпвакыт хатын-кызга бәхетсезлек китерә. Чөнки матур чәчәкне һәркем өзәргә тели. Шунсы да бар: чибәрлек гомерлек түгел. Аны алтын әйберләрне саклагандай саклап булмый. Шуңа күрә хатын-кыз шушы байлыктан күбрәк файдаланып калырга тырыша, ягъни-мәсәлән үзенең матурлыгын алтын-көмешкә әйләндереп сандыкка сала.

—Сез психологмы әллә?—диде ханым.

—Башында мие булган кеше—уйланмый яши алмый, уйларын тормыш тәҗрибәсе белән кушылгач психолог та, философ та буласын.

—Төрмәдә акыллы кеше белән утыргансыз сез.

Заһит шаккатты.

—Минем төрмәдә утырганны каян белдегез?—диде ул гаҗәпләнеп.

—Бусы инде минем сер,—диде ханым.—Мин дә үзенә күрә психолог.

—Ярый,—диде Заһит,—җәйге төн тиз үтә. Сездәй чибәрләр янында бигрәк тә. Китәргә кирәк мина. Ә сез, теләсәгез, ун минут үткәч милиция чакыра аласыз.

Бу чибәр ханымны Заһит озак оныта алмый йөрде. Ләкин Фатыйманы йөрәктән һич куып чыгарып булмый. Әллә өйләренә барырга микән? Шунда бәлки малаен да күрер. Үскәндер инде. Кемгә ошады икән: минамы, Фатыймагамы?

Мона кадәр малае турында уйламаган Заһитнын күнелендә аталык хисләре кузгалып куйды. Егерме биш яшькә житеп, ул инде күп кенә кызлар белән булды. Бәлки ул кызларда да анын малае яки кызы үсәдер?! Хәер, юктыр. Бөтен кызлар Фатыйма түгел бит, бала табарга ашкынып тормыйлар. Ә Фатыйма хәйләкәр генә түгел, дәртле дә булып чыкты. Заһит унынчы класста укыган чакта Фатыйма әле тугызынчыда гына укый иде. Аларнын мәктәбе янында укытучылар өчен дип салына башлаган, ләкин бетеп житмәгән бер йорт бар иде. Кайбер малай һәм кызлар нинди дәрескә керергә теләмәсә, шул йортнын берәр бүлмәсенә кереп кәрт сугалар яки башка уеннар уйныйлар. Беркөнне Заһит белән Фатыйма бергә туры килделәр. Фатыйманын Заһитка күптән күзе төшеп йөри икән. Ул егетне үртәргә тотынды: «Син мине тоталмыйсын, тоталмыйсын»,—диде дә икенче бүлмәгә качты. Озын сыйраклы Заһитка аны куып житү авыр булмады. Ул Фатыйманы тотып алыйм гына дигәндә кыз кинәт тартылды да стенадан чыгып торган арматурага күлмәген эләктереп ерттырды. Кызнын түшеннән кендегенә кадәр тәне ачылды. Егет кызнын тулышып килгән күкрәкләреннән, ап-ак тәненнән күзен ала алмады. Фатыйма тәнен капларга ашыкмады. Фатыйма кебек кызларны аулаграк жирдә «кыскалап» өйрәнгән Заһит Фатыймага ташланды. Ул кыз тарафыннан каршылык көткән иде, ләкин Фатыйма күптән Заһитнын кочагына кереп әвәләнәсе килгәнлектән, егеткә каршылык күрсәтмәде. Заһит корбанын ботарлап ташларга теләгән бүредәй кыланды: үпте, тешләде, куллары белән кызнын бөтен жирен капшады. Фатыйманын күп кенә иптәш кызлары үзләренен егетләре белән ни кыланганнарын сөйләп мактаналар. Кызнын шушы яшькә житеп егетләр кочагы татып карамавыннан көләләр, ә Фатыйма дусларынын күп сүзләре уйдырма, бары тик аны аздырыр өчен генә әйтелгән икәнлеген күнеленә дә китерми иде. Анын әнә шундый кәттә-«текә» кызларга ошыйсы, аларга үзенен «мажараларын» сөйләп мактанасы килә иде. Менә, ниһаять, җае чыкты. Кем белән диген әле? Мәктәптә уннарча кызларнын кумиры—Заһит белән бит. Хәзер менә мактанырга була.

Кыз шундый уйлар киеренкелегендә йөзгәндә, Заһит аны катгый кисәтеп куйды:

—Кара аны, кызый, бу турыда ләм-мим. Әгәр берәрсенә сөйләсән, ботарлап ташлармын үзенне.

—Ботарла!—диде Фатыйма Заһитны котыртып.

Заһит кыздан мондый сүз көтмәгән иде, бераз аптырабрак калды. Аннары ул:

—Мин сине әкренләп ботарлармын. Ә бүгенгә өенә сыпырт.

—Шушы килешме?—Фатыйма үзенен тагын да ертыла төшкән күлмәгенә күрсәтте. Заһит озак уйлап тормастан, ана үзенен спорт костюмын салып бирде.

—Бар, кеше-кара күргәнче тай!

Фатыйма егетнең битеннән үбеп алды да, арткы сукмактан гына сыпырды. Шушы көннән башлап әле төзелеп бетмәгән өй аларның мәхәббәт оясына әйләнде.

Шушы хәлләрне хәтер күпере аша үткәргәннән соң, Заһит Фатыймаларга яшеренми-нитми барырга карар кылды. Гыймае өйдә икән—өйдә булсын. Ул бит малайның үзенеке түгеллеген белә, бәлки әле Фатыйма миннән икәнен әйткәндер. Әйтсә, тагы да шәбрәк, теге «мунча пәри»енә аңлатып маташудан котылыр.

Һәм Заһит әйбәт костюмнарын киеп, галстуклар тагып көпә-көндез Фатыймаларга китте. Фатыйманың кайчан ял көне икәнлеген ул кибеткә бер малай җибәреп белешкән иде. Әлбәттә, төрмәдән янарак чыккан кешенең башын югары күтәреп шәһәр урамыннан баруы башсызлык. Аны күзәтүләре мөмкин. Чөнки ул элекке «эшен» янадан башлады. «Эш алымын» да юри үзгәртмәде. Кайвакыт ул: «Милициянең аңгыралыгымы, халыкның куркаклыгымы бу?— дип уйлана иде.—Нишләп кешеләр шулкадәр куркак? Милиция үз участогында карак йөргәнлеген начальствога әйтүдән, ә халык милициядән курка. Шушы курку чылбыры бөҗра булып бер-берсенә тоташкан, һич өзелерлек түгел». Беркөнне Заһит урам уртасында бер кызга бәйләнә башлады. Башта сумкасыннан кесә телефонын алды, аннары кызның кендегендәге алкасын тартты. «Үзең салып бир»,—диде ул аңа, ә кырыеннан кешеләр үтә башласа, кызны кочаклап үбәргә тотынды. Үткән-сүткән кешеләр әйтерсең сукыр һәм чукрак, күрмәмешкә салышалар. Кыз кендек алкасын салып Заһитка бирде. Заһит аны тагы да ныграк сынар өчен: «Ә хәзер минем арттан бар, берәр подвалга кереп чыгарбыз»,— диде дә, үзе алдан китте. Кыз качармы-юкмы, дип тикшерүе иде аның. Бераз баргач артына борылса—кыз да аның артыннан килә. Шунда кырыйдан бер милиционер да үтеп китте югыйсә. Заһит кызга борылып: «Ярар, бар кит инде. Аппетитым бетте»,—дип китеп барды.

Заһит милициянең борын төбендә җинаять эшләргә ярата. Чөнки ул милициядә шактый ук тунбашлар утыруын белә. Алар җинаятьчеләрне каяндыр читтән эзли. Тумыштан ук кеше психологиясенең нинди борылышларга сәләтле икәнлеген белүчеләр, үсә барган саен, моны ныграк үзләштерәләр. Заһит кебек төрмә мәктәбен узганнар дошманыңа никадәр якынрак булсаң, шулкадәр куркынычсызрак икәнен аңлый. Өстәвенә Заһитның кесәсендә «аеруча куркыныч җинаятьләрне ачучы» дигән бик шәп документ бар. Төрмәдә алар «Академик» кушаматлы бәндә белән бер камерада утырганнар иде. «Академик» компьютер белгече. Берәр документны кулга төшерсә, теләсә кем исеменә ясап бирә ала. Мөһер ясаучы дусты «Тәгәрмәч» белән алар бергә эшли. Ике дус шактый ялган документлар ясап, зур байлык туплый. Ләкин ике кеше белгән нәрсәне өченче берәү белми калмый. Боларны да каптыралар. Тик тупланган байлык үзенекен эшли: бернichә айдан «Академик»ның адвокаты аны төрмәдән коткаруга ирешә. Заһитка әлеге документны шул дусты эшләп бирә.

Фатыймаларга ул бик батыраеп барып керде. Подвалдан соң хатын моны көтмәгән иде. Гыймай аның бот араларын кычыткан себеркесе белән чапкач ул үкенү хисе кичермәде, киресенчә, иреннән үч алу турында уйлана башлады. Заһитның һич көтмәгәндә көпә-көндез килеп керүе аны гаҗәпләндерде дә, шатландырды да. Әмма шатлыгын тышка чыгарырга ашыкмады.

—Синең аркаңда мин ничә көн салкын су салынган таста утырдым,—диде ул үпкәләгән сыман кыланып.

—Нинди салкын су? Нигә утырдың?—дип Заһит төпченә башлады.

—Минә бу җирене кычыткан белән чапсыннар әле, син нишләрсең икән?

—Әллә мунча пәрие кычыткан белән чапты?—Заһит кычкырып көләргә

тотынды.—Башлы адәм икән. Кая, бик нык авырттымы?—Заһит Фатыймага үрелде, тик тегесе аның кулына сукты.

—Кармаларга гына торма әле. Сина кызык. Ә мина бер дә кызык булмады.

—Әйдә, алайса тагын бер кызык ясыйк.

—Гыймай кайтып керсә?

—Кайтып керсә, тагын да кызыграк булыр.

—Син, куркак, чыгарсын да качарсын.

—Качмыйм! Мин малайны күрергә килдем.

—Малайны? Синен малаен бармыни?

—Кыланып маташма, югыйсә мин дә кызык ясармын.—Заһит Фатыйманы бөтереп алды. Түшендәге төймәләрен берьюлы сыдырып төшерде. Күлмәк ертылды. Фатыйма теге вакытта мәктәпнен төзелеп бетмәгән йортында нәкъ шушының төсле иде. Заһит хатынның киемнәрен бөтенләй ертып ыргытты. Ничек кенә сәер тоелмасын, Фатыймага Заһитның шушы кыргыйлыгы ошый иде.

—Малай кая?—диде ул хатынны караватка ыргытып.

—Малай синеке түгел инде ул. Аны Гыймай туу белән үз исеменә яздырды. Ул бит синен кебек куркак түгел.

—Мин куркакмы?—Ул ерткычларча Фатыймага ташланды. Ләкин Фатыймага мондый «жәза» тансык кына иде. Юкса Гыймай сыйпаштырып, назлаштырып ярты сәгать кыштырдый. Хатынына ул, саксызрак кагылсан, ватылыр дип карый. Дөрес, Фатыйманын яратмавын белә, ләкин вакыт һәм йомшаклык үзенекен итәр, хатыны аны ярата башлар, дип өметләнә. Наз белән кулга ияләштереп булмый торган жанварларның барлыгын белми иде шул Гыймай. Кайбер жанварлар бары камчыга гына буйсына.

Фатыйма белән Заһит ике ерткыч кебек караватта тәгәрәшеп ятканда Гыймай кайтып керде. Башта ул берни анламый торды. Анлагач, иң беренче хатынын караваттан сөйрәп төшереп, һәрвакыт «кычытып» торган жиренә көрәктәй кулы белән берне чәпәде. Фатыйма почмакка барып сыланды. Чират Заһитка житте. Гыймай аның «мактаныч»ыннан умырып тотты да: «Йолкып ыргытам, кабәхәт!»—дип үкерде. Ләкин төрмә «мәктәбе»н үткән Заһит югалып калмады: яшен тизлегендә Гыймайның ияк астына тезе белән китереп бәрде. Имән төбедәй Гыймай чайкалып китте, аңы томалангандай булды. Шушы мизгелдән файдаланып Заһит ана тагын берне чәпәде. Гыймай гөрселдәп ауды.

—Үтерәсең бит,—дип Фатыйма арага кермәкче иде, Заһит ана акырып жибәрде: «Кит! Урам себеркесе! Юкса үзенә дә эләгер».—Заһит киенә башлады. Гыймай аңына килгәнче чыгып таюың яхшы. « Мунча пәрие»нен кулы каты. Гыймай аңына тиз килде.

—Алып чыгып кит кәнтәенне.—Ул Фатыймага борылды.—Бар, эзенне югалт. Бүтән бу өйгә борылып карыйсы булма.

—Мина синен себеркең кирәкми. Үзендә калсын. Урам себерергә тотарсын. Мин малаемны күрергә генә килгән идем. Кая минем малай?

Гыймай югалыбрак калды. Ләкин бик тиз исенә килеп мич алдында өелеп торган бер утын яркасы алып: «Менә синен малай»,—дип Заһитның йөзенә кулындагы утын яркасын атты. Читкә тайпылып калмаса, Заһитның маңгае ярылачак иде. Ул тизрәк таю ягын карады. Гыймайның кышын өеннән куалап чыгарылган аю хәлендә икәнлеген анлады ул.

Заһит чыгып киткәч, Гыймай Фатыйманың киемнәрен өстенә атты: «Бар, өстерәлчек, калма үзеннен төрмә кандалаңнан. Бергәләп төрмәдә кандала симертерсез».

—Син кумасаң да бүтән өенә аяк атламаячакмын,—диде Фатыйма.—Синен тәненә сеңгән дуңгыз исен иснәп яткан мин дурак.

Гыймай хатынының сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын аңлый, әлбәттә. Эштән кайткач ныклап юынырга күпвакыт өйдә җылы су булмый. Һәркөнне әниләренә мунчага бармассың бит инде. Хәер, күпме генә юынма, тәнеңнән килә торган әчкелтем ис бетми. Баштарак Фатыйма: «Син әллә фермада дуңгызлар арасында тудыңмы?»—дип Гыймайның җен ачуларын чыгара иде. Аннары ул иренә кибеттән төрле дезодарантлар алып кайта башлады. Тик нәселдән үк килгән ул исне дезодарантлар гына басмый, киресенчә, тагын да яманрак ис барлыкка китереп Фатыйманың күңелен болгата һәм бер якынаеп алганнан соң аерым караватларга күчәргә мәҗбүр булалар иде.

Гыймай беренче мәртәбә Заһиттан көнләште. Иснәп карасаң, бәлки анардан тагын да яманрак ис киләдер, ләкин чибәр. Шәһәр егете. Ә Гыймай чынлап та бәләкәйдән дуңгызлар арасында үсте. Әти-әниләре монардан барыбер әллә кем чыкмас дип, аның укуына да битараф карадылар. Гыймай үзенең дуңгыз караучы булачагына күнегеп килгәндә, шәһәрдә яшәүче балалары кинәт кенә үлеп китте. Карчыгын моннан бер ай чамасы элек кенә җирләгән карт ялгызлыкны күтәрә алмый карчыгы артыннан китте. Ушлы карт үзенең өен әллә кайчан улына, ягъни Гыймайның әтисенә яздырган булган икән.

Колхозлар таркалып, авылга төрле яклардан әллә нинди әтрәк-әләмнәр кайта башлаган чак иде. Гыймайның әтиләре Кыргызстаннан кайткан, ни кыргыз, ни татар түгел бер бәндәгә йортларын сатып, шәһәргә күчтеләр. Гыймай русчаны бик үк әйбәт белмәгәнлектән, укуын дәвам итмәде. Әтисе янына таш чыгаручы булып эшкә керде. Авылдагыга караганда монда акча күп төшә, өстәвенә ташны үзенә алып кайтырга яки кирәк кешегә сатып җибәрергә дә мөмкинлек табыла. Әкренләп Гыймайга да йорт тергезделәр. Башта ул кечкенә генә иде, тора-бара зурайттылар. Шәһәр үсә башлагач, өйгә газ һәм су кертергә дә мөмкинлек туды.

Ләкин, шәһәрдә яшәүгә карамастан, Гыймай күңеле белән авыл кешесе булып калды. Фатыйманың сүзләрендә хаклык бардыр күрәсең. Кем белә, бәлки күңелдәге авыл, төшләргә кереп интектерүче пычрак дуңгыз фермасы аның күзәнәкләре аша тышка чыгадыр. Күңелнең сафлыгын исбатлау кыен, ә начар ис тотен кебек тышка бәреп чыга. Өч буыннан күчкән дуңгыз исен шәһәр сабыннары гына юып төшерә алмый шул.

* * *

Фатыйма бер чемоданга сыярлык кына әйбер алды. Аның Заһит биргән теге алтын әйберләре генә дә Гыймайның бөтен байлыгыннан күбрәк иде.

—Баланы алып китәргә җыенма,—диде Гыймай.—Син бала үстерә ала торган хатын түгел. Бу тирәдә күренмәвең яхшы.

—Бала кирәк булса, орлыгы Бохарада түгел, табармын. Заһитны сиңа калдырам. Минем баласыз, сөрсегән ирсез яшәп карыйсым килә.

Фатыйма ишекне шартлатып ябып чыгып китте. «Ярый әле малай өйдә булмады»,—дип сөенде Гыймай. Әлбәттә, әнисен сорашачак: әнисенең нинди икәнен белми бит ул. Белгән очракта да бала өчен ана дөньяда иң кадерле, иң әйбәт кеше.

Гыймай терсәкләре белән өстәлгә таянып, учлары белән башын кысты. Күңеленнән уйлар дулкыны узды. Тормышның таркалуына кем гаепле соң? Фатыйманы корсаклы килеш хатынлыкка алып үзе ялгыштымы? Ә бит авылдагы туганнары Гыймайга менә дигән кызлар яучылап карадылар. Берсе белән Гыймай бераз якыная да башлаган иде. Кыз фермада эшли. Бәлки ул Гыймай тәнеңнән килгән искә игътибар итмәгән булыр иде. Ләкин Гыймай аны әниләренә күрсәтергә алып кайтып ялгышты. Дөрес, әниләре кызны бик әйбәт кабул иттеләр. Кыз матур ук булмаса да ягымлы иде. Тик бөтен эшне Гыймай үзе бозды. Кызны берничнди бүләксез озатып җибәрүне

яхшысынмыйча, аны бер кибеткә алып керде. Бу Фатыйма эшли торган кибет иде. Гыймай беренче кат Фатыйманы шунда күрде. Фатыйма ана фәрештә булып күренде. Ул хәтта кибеткә ни өчен кергәнен онытып торды.

—Бу чибәр парларга ни кирәк икән, белик әле,—дип Фатыйма болар каршына килеп баскач, Гыймай кесәсендәге бөтен акчасын чыгарып:

—Шушы акчаларга берәр әйбәт туфли киләме?—дип сорады, чөнки кызның аягындагы туфлиләре нык тузган күренә иде. Аяк киемнәре сайларга кызны эчкә алып кереп киттеләр. Ул аннан өр-яңа туфлиләр киеп чыккан иде. Ул Гыймайга рәхмәт әйтеп автовокзалга юл тотты. Ә Гыймай Фатыймадан күзен алалмыйча озак карап торды.

—Кәләшеңне бер үзен җибәрдеңмени?—диде Фатыйма.—Авыл кызы шәһәрдә адашырга мөмкин.—Гыймай Фатыйманың күзәтүчәнлегенә шаккатты.

—Каян белдегез аның авыл кызы икәнен?—диде ул.

—Авыл кызларын кояшта янган битеннән, әйбер сайлавыннан һәм тагын әллә нәрсәләрдән белеп була.

—Кызык!—диде Гыймай.

—Кызыгын кызык. Ләкин синен кәләшеңне ялгызын чыгарып җибәрүең бер дә егетлек түгел.

Гыймай үзенең мәгънәсезлегеннән кыенсынып хатасын төзәтергә ашыкты. Тик күпме генә эзләсә дә кызны тапмады. Ә Гыймай шушы керүдән соң Фатыйма эшли торган кибеткә эзне суытмады. Фатыйманың кешеләр белән сөйләшкәнен, аккош муеныдай кулларының хәрәкәтен күзәтүдән ниндидер ләззәт алды. Ул инде авылдагы теге кызны онытkан иде, тик бермәлне ана посылка килеп төште. Анда Гыймай алып биргән туфлиләр һәм усал итеп язылган хат бар иде. «Шәһәр егетләрен оятсыз дип әйтәләр иде, дөрес икән. Мине бөтен авыл алдында хур иттең. Ә мин—юләр, ул туфлиләремне иптәш кызларыма күрсәтеп мактанып өлгергән идем. Сина актык сүзем шул: мине кимсеткән кебек үзеңне дә кимсетсеннәр, хур итсеннәр. Хуш!»

Гыймай шушы хәлләрне исенә төшергәч: аның каргышы төшкән мина, дигән нәтиҗә ясады һәм: «Шул кирәк сина! Шул кирәк сина!»—дип үз-үзен кыйнады.

Ул шулай бәргәләнеп утырганда кечкенә Заһит кайтты.

—Уф, ашыйсым килде, әти.

—Хәзер берәр нәрсә әзерләп бирермен, улым.

—Ә әни кая?

—Ә-әниеңме?

—Әни дим бит инде,—диде малай кайнарланып.

—Әниең, улым, командировкага китте. Кибетләренә чит илдән товар апкайтырга.

—О-о,—диде Заһит,—чит илдән әни мина бер малайда да булмаган берәр шәп нәрсә апкайтачак инде алайса, әйеме, әти?

—Әйе, улым.

—Ә беләсеңме нәрсә апкайтачак ул мина?

—Юк шул, белмим, улым.

—Ул мина роликлы коньки апкайтачак.

—И-и, алар бит бөтен малайда бар диярлек.

—Аларныкы чит илнеке түгел. Подшипниклары тарала. Бурсыкныкы гына шәп.

—Кем соң ул Бурсык?

—Бурсык Бурсык инде. Әтисе аның гел чит илләргә йөри ди. Машинасы гына да безнең бабайларның мунчасы хәтле бар. Үскәч мин дә машина алам, әти.

—Алырсын, улым, алырсын. Ә хәзер аша, колбаса белән ипи бар. Соңыннан берәр нәрсә пешерермен.

Малай колбасаны пычак белән кисеп тормастан, сындырып кына алды да умырып ашый башлады.

Гыймай улының комсызланып ашаганын карап торды.

—Фатыйманы куып чыгардым чыгаруын. Тик ул бит: «Ник һаман әни кайтмый?»—дип аптыратачак. Куып чыгармый да мөмкин түгел иде. Гыймайда ирлек горурлыгы дигән нәрсә бар лабаса. Ичмасам сиздерми эшләсеннәр иде. Хәер, сиздерми эшләгәннәре дә күп булды инде. Кемдер ана бише белән арттырып сөйләгәндә жир тишегенә кереп китәрдәй буласың. Ә малайны әнисеннән бөтенләй читләштерергә ярамас. Әнисенең эшләгән кибетен белә ич ул. Әйдә, әниләр кибетенә барыйк, дияр. Ә Фатыйма аны күрергә теләмәсә? Ул бит Заһит дип үлеп тормый. Хәер, нинди ана үзенең улын күрергә теләмәс?! Йөгереп кайтып житәр әле. Тик, кайтса нишләргә?

* * *

Гыймай белән чәкәләшкәч, өлкән Заһит абыйсы Сәгыйть янына китте. Сәгыйть үз кабинетына килеп керүче Заһитны күргәч сагаеп калды.

—Нишләп йөрисең монда?

—Сине сагынып килдем.

—Мин сине бер дә сагынмаган идем әле. Кеше күрсә?..

—Күрсә соң? Син бит минем әтием урынына калган кеше. Аның бертуган энесе. Үз абзаң янына килү гаепмени?

—Төрмә кандаласы белән аралашып пычранасым килми минем.

—Аһ, паразит, күрсәтермен мин сиңа төрмә кандаласын!—Заһит абыйсының якасына барып ябышты. Сәгыйть буыла башлады: «Жи-и-бәр, үтерәсең».

Заһит кулын бушатты.

—С-син нәрсә? Абзаңны үтерергә килдеңме монда? Кулыңны бик озайтсаң—кыскарттыру юлларын табармын мин.

—Сине үтерүдән миңа ни файда?

Алар тынычрак тонга күчтеләр. Заһит абыйсының кабинетына күз йөртеп чыкты. Жиһазлар гади. «Хәйләкәр төлке. Байлыгын күрсәтергә теләми. Яна импортный машинасында да сирәк йөри». Заһит ят уйларын читкә куеп, төп мәсьәләгә күчте.

—Менә нәрсә, абзыкай...

—Нәрсә?

—Миндә артык әйберләр күбәеп китте, шуларны үз кибетең аша саттыр әле.

—Каян килде әле сиңа ул артык әйберләр?

—Дусларым китерде.

—Дусларың үзләре сатсын. Нигә сиңа китерәләр? Күңелем сизә: син тагын теге элеккә «эшенә» керешкәнсең. Кара аны, сак бул!

—Син үзенне бел,—диде Заһит кыза башлап.—Әллә синең менә бу клуб хәтле кибетең күктән төште дип уйлыйсыңмы?

—Минем бөтен байлыгым—законлы, хәләл.

—Әкият сөйләмә, абзыкай. Иң беренче әтине талаудан башладың син. Әти авариягә эләккәч, аның ларегын жайлы гына үзеңнеке итеп куйдың. Мин бәләкәй идем, берни анламый калдым.

—Мин сиңа йөз кат күрсәттем инде ул документны!

—Нинди документ?

—Әтиеңнән ул ларекны сатып алуым турындагы документ. Әтиенә, үзең беләсең, кыйммәтле дарулар күп кулланырга туры килде. Даруны бушлай бирмиләр. Менә шунда әтиең үзе миңа ялынды: ал инде ларегымны, дип.

—Хәзер син теләсә ничек алдый аласың. Әти юк, әни Үзбәкстаннан килгән килмешәккә кияүгә чыкты. Өйләрен крепость итеп куйдылар. Керә дә алмыйсың аларга.

—Хатын-кыз байлыкка кызыгучан шул, берни эшләр хәл юк. Ә ул әниеннән «килмешәгә» бик хваткий булып чыкты. Хәзер, әнә, ашханә ачып ята. Әниен балда-майда йөзәчәк.

Заһитның үзеннән-үзе тешләре кысылды.

—Ух! Яратмыйм шул хатын-кызларны. Барысы да бер б...әт.

Сүз икенче темага күчкәч, Сәгыйтьнең нерв киеренкелеге кими төште. Ул астыртын елмаеп Заһитка бармак янады.

—Берсен яратасың, үлеп яратасың...

—Фатыйманымы?

—!

—Ачуымны китермә. Мин, гомумән, ярата белмим. Мин аларның барсыннан әни үчен алам. Ерткалап, өзгәләп бетерәсем килә шуларның кайбер җирләрен.

Заһит сүгенеп куйды.

—Ярар,—диде ул аннары,—баштагы сүзгә күчик: аласыңмы минем әйберләремне?

—Син нәрсә? Минем башымны төрмәгә тыгарга телисеңме әллә? Синең документсыз-нисез әйберләреңне сатарга дурак түгел лә мин.

—Мин сиңа теләсә нинди документ ясап бирермен.

—Андый фальшивкалар тагы да куркынычрак.

—Кем әйтте сиңа фальшивка, дип.

—Син ясагач фальшивка була инде ул.

Заһит кесәсеннән кызыл таныклык алып абыйсына сузды:

—Менә моны кара әле. Берәр хәрефендә фальшивка табарсыңмы?

Сәгыйть Заһитның «Аеруча куркыныч җинаятьчеләрне тикшерүче» дигән таныклыгын төрле яклап тикшерде һәм гаҗәпләнеп тел шартлатып куйды.

—Да-а, егеткәй, төрмәдә юкка гына ятмагансың икән! Үзең эшләдеңме?

—Анысы синең өчен не важно.

—Минем өчен бөтенесе важно, энекәем. Мин хәзер шәһәрдә танылган кеше. Югалтыр әйберең булмаганда гына бөтенесе не важно, ә минем югалтыр нәрсәләрем күп. Хәзер минем исемемә тап төшерергә ярамый. Минем исемем үзе кыйммәтле байлык.

—Мактанма әле, яратмыйм шапырынучыларны.

—Ярар, конкрет эшкә күчик. Нәрсәләрең бар?

—Радиоаппаратура, кыйммәтле савыт-саба, алтын-көмеш һәм башка вак-төяк шунда.

—Әгәр тиешле документларны менә бу таныклыгыңдагы кебек пөхтә эшләтеп ала алсаң—товарларыңны әзләп-әзләп китерерсең. Ләкин бер шарт белән.

—Нинди шарт?

—Табышы бермә-бер булса гына.

—Ай-һай, комсыз да син, абзыкай. Энеңә үзең ярдәм итәр чагында.

—Менә бит ярдәм итәргә торам.

—Ярар,—дип кул селтәде Заһит,—утыз процентың алып калырсың.

Энесенең бу тәкъдименнән Сәгыйть бик канәгать иде. Алар, ниһаять, тынычланып калдылар. Ләкин Заһитның сүзе бетмәгән иде әле.

—Тагын бер йомыш бар әле сиңа, абзыкай,—диде ул.

—Нинди йомыш? Акча кирәкме?

—Юк, мин үзем акча. Сүз Фатыйма турында.

—Фатыймага ни булган?

Заһит Фатыйманың ире Гыймай белән сугышулары, Фатыйманы ире куып чыгаруы турында сөйләп бирде.

—Куса, анда синең ни эшең бар. Ир белән хатын бүген сугыша, иртәгә

татулаша. Кибеттә Фатыйма әйбәт эшли.

—Эшлидер, ләкин аны берәр жиргә олактырырга кирәк.

—Бу ни дигән сүз тагын?

—Хәзер иреннән аерылгач, Фатыйма миңа сыланачак.

—Сыланса, бик яратыша идегез бит.

—Әйтмә әле шул сүзне. Нинди яратышу булсын?! Миңа аннан тизрәк котылу хәерле. Ире белән торганда ул куркыныч түгел иде, хәзер—куркыныч. Мин бер ялгышлык эшләп ташладым.

—?

—Үземнең яшеренеп яткан жиргә алып кердем. Шунда минем әйберләр. Ә хатын-кыз авызында сүз тормаганны үзең беләсең.

—Да-а, егеткәй. Ахмаклык эшләгәнсең шул. Болай булгач, Фатыйманы эштә калдырырга һич ярамый. Ләкин эштән куу гына да проблеманы хәл итмәячәк.

—Синең танышларың күп, бәлки үзең кебек бабник берәр бизнесменга сөяркә кирәктер. Ләкин үзебезнең шәһәрдә түгел.

—Шәп идея бу. Башың эшли, егеткәем.

Алар уртак тел таба алуларына шатланып аерылыштылар.

* * *

Фатыйманың бүген нигәдер эче пошып, күнеле тынычсызланды. Юк, бу Гыймай куып чыгарганнан гына түгел. Әлегә кадәр андый пошыну хисе кичергәне юк иде бугай. Нәрсәдән соң бу? Эше әйбәт бара.Хужа аңардан бик канәгать. Башкалар алдында аны гел үрнәк итеп куя. Тик менә Сөмбел эшли башлагач, хужа аңардан суына төште. Әмма нишләмәк кирәк? Һәр нәрсә вакытлы була, күрәсең. Боларны гына аңлый Фатыйма, ләкин эчкә йөгергән тынгысызлык дулкыны нилектән барлыкка килгәнен генә аңламый. Югыйсә бөтенесе элеккечә кебек. Заһиты Фатыйма дип үлеп тора.

Заһит аны бәхетсез итәр өчен көпә-көндез өйләренә килүен, тату гына яшәп яткан гаилә учагына күкерт салып, үз казанында талгын кына кайнап уртак ботка пешерүчеләрне пыран-заран китерүдән тәм табуын Фатыйма каян белсен. Заһит оста артист кебек, үз ролен ышандырырлык итеп башкара. Тышкы кыяфәт, кинәт үзгәрүчән йөз, нинди дер китаплардан ятланган сүзләр күнелендәге үчне, явызлыкны каплап тора. Дөрес, вакыт-вакыт аңарда кешелек сыйфатлары уянгалап куя, әмма мондый халәт жил өреп сүндергән шырпыдай тиз сүнә.

Фатыйманың бүгенге эч пошуы әллә Заһитны аңлап бетермәүдәнме? Заһит серле. Фатыйманы өзелеп яратуга карамастан, усал кылана. Бәлки улын Гыймайда калдыргангадыр? Малайны авылга әбисе янына илтеп куярга микән әллә? Юк, монда әтисе янында аңа яхшырак. Гыймай аны үз улыдай ярата. Ә Фатыймага ул әллә бар, әллә юк. Барлык иркә-назларын Заһитка бирә ул. Әйе, Заһитка. Заһитның өлкәненә.

Заһитны уйлау Фатыйманың күнелен күтәреп жибәрде. «Теге жиренә зыян килмәде микән? Гыймай бик умырып тоткан иде бит. Күрергә иде үзен».

Фатыйма эше беткәч кибеттән чыкты да Гыймайларга таба атлады. Бераз баргач: «Кая барам мин жүләр? Гыймай мине хәзер бусагадан да атлатмаячак».

Фатыйма туктады һәм Заһитның яшеренеп ята торган подвалына барырга ниятләде. Тик адымнары әкренәйгәннән әкренәйде. Заһит бит ана үз янына килеп йөрмәскә кушты. Нишләргә?

Шулай уйланып торганда аның янына бер машина килеп туктады.

—Сезгә кайсы якка?—дип сорады шофер егет машина тәрәзәсеннән башын ярым чыгарып.

—Бәхет кайда—мина шул якка.

—Алайса икебез бер якка икән.

Машина кузгалып китте. Ирек Фатыйманың кибеттән чыкканын ярты сәгатьләп көткән иде. Сәгыйть Хәмитович Ирекне Заһит чыгып китүгә үзенә чакырган һәм Фатыйманың документларын тоттырган, ни эшләргә кирәклеген аңлаткан иде. Ирек Фатыйманың кибеттән чыгуын борчылып көтте. Ничегрәк итеп Фатыйманы машинама утыртырмын икән дип баш ватты. Ә асыл кош читлеккә үзе очып керде. Эшләр шулай әйбәт кенә барса, Ирекка шактый зур калҗа эләгәчәк. Аның күңеле шуны уйлап сөенде.

Ә Фатыйма, йомшак машинага кереп утыргач, бар дөньясын онытты. Машина хуҗасы сүзчән кеше түгел. Эч пошканда машина утыргычында тирбәлеп үз уйларына чуму рәхәт. Бу тирбәлеш күңелне тынычландыра, аңны йоклата. Фатыймага кая барса да барыбер иде. Хәер, ул әле үзенең эшеннән куылганлыгын, Заһитның анардан котылырга тырышуын белми, бары тик эчке тоемлау нәтиҗәсендә генә ниндидер күңелсезлеккә тарыганын сизә һәм шушы билгесезлектән качарга тели иде.

—Кайтып җиттек, туташ-ханым,—диде Ирек.—Әйдәгез, өйгә керәбез.

—Минем өй башка яктарак иде, сезгә кайтканбыз икән—кереп чыгыйк инде. Байлар ничек яши икән—күрик.

—Байлык дигән нәрсә әлегә безгә койрыгын тоттырмый. Шулай да бер эләктерергә өмет бар.

Алар өйнең эченә уздылар.

Дөрестән дә, монда бай кеше яши дия торган түгел. Җиһаз юк дәрәҗәсендә. Йортның өске каты эшләнә генә башлаган. Бары тик аш пешерү бүлмәсендә генә бөтен нәрсә бар.

Егет Фатыйманы шунда алып керде.

—Нәрсә ашыйбыз?—диде хуҗа. Фатыйма юри генә:

—Кызыл балык,—дигән иде, Ирек өй диварының чокырына кертеп куелган ике суыткычның берсеннән пешереп туңдырылган кызыл балык алды. Ул аны микродулкынлы мичтә тиз арада кайнарлады. Табын уртасына бер шешә ят эчемлек менеп утырды.

—Сез каршы булмасагыз, ашар алдыннан бераз гына тамак чылатып алыйк,—диде егет һәм Фатыйманың рөхсәтен дә көтмичә, юан корсаклы фужерларның төбенә берничә йотым эчемлек тамызды.

—Әйдәгез, танышу хөрмәтенә!

Фатыйма каршы килмәде. Эчемлек тәмле иде, йотып куйды. Аннары өстәлдәге кызыл балыкның тәмен белеп карарга уйлады. Ләкин хуҗа әллә ни арада аның авызына конфетмы-ниме каптырып өлгерде. Аннан алар күптән күзне кызыктырып торган кызыл балык ашадылар. Табында ризыклар күп иде, егет ашау белән мавыкты, ә Фатыйманың тагын бераз теге тәмле эчемлекне эчеп карыйсы килә иде. Хуҗаның күңеле сизгер икән, ул: «О-о, мин каршымда гүзәл ханым утырганны онытып җибәргәнмен ләбаса»—дип, фужерларга тагын бер-ике йотым эчемлек салды. Фатыйма белән чәкештерсә дә, үзе авыз гына тидереп алды.

—Сез бик тәти егет икән, хәтта үз өегездә эчәргә куркасыз. Мин көчләр дип шүрлисезме?

—Юк, мин алай ук изгеләрдән түгел,—диде Ирек.—Ләкин минем рульгә утырасым бар. Ә юл инспекторлары бик бәйләнчек халык бит.

—Шулайдыр,—диде Фатыйма,—минем бит машинам юк. Булмаячак та.

—Алай кырт кисәргә ярамый, Фатыйма туташ.

Фатыйма аңа гаҗәпләнеп карады.

—Сез минем исемемне каян беләсез?

—Сезнең кебек чибәрләрнең исемен белмәгәч, мин нинди егет булам, ди. Сез бит Сәгыйть Хәмитович кибетендә эшләдегез.

—Ничек инде эшләдегез?! Мин хәзер дә шунда эшлим.

—Ә-ә, әйе. Ә минем исемем Игорь.

—Игорь? Сез бит татар баласы.

—Әйе, чеп-чи татар. Ләкин без—татарлар—үзебезгә кем ничек дәшә—шуна күнегәбез.

Әнгәмә белән вакытның үткәне сизелмәде. Алар күптәнге танышлардай һәр нәрсә турында ачыктан-ачык сөйләштеләр. Фатыйма авылда әнисе барлыгын, аңа ай саен акча салып торганлыгын, атасыз бала буларак, шәһәр интернат мәктәбендә укуын, укуы беткәч сатучы булып эшли башлавын сөйләде.

—Ул яктан без почти туганнар икәнбез, мин дә балалар йортында үстем,—диде Ирек. Билгеле, Фатыйма моңа ышанып житмәде. Балалар йортында үскәннәрнең күбесе сукбайлар төркеменә кушыла. Чибәррәк кызлар фәхишәлек юлына кереп китә. Безнең илдә картлар белән балалар—иң хокуксыз затлар. Алар җәмгыятькә кирәкми. Әнә, Фатыйманың әнисе алган пенсия бер кибеткә чыгып керерлек кенә. Өйләре җимерелеп бара. Ә Фатыйма җибәргән акчалар тишек-тошыкларны гына ямарга житә. Бу илдә сыртыңа сукканга да рәхмәт әйтеп яшәмәсәң, гомер җебең бик тиз шартлап өзелә. Фатыймадагы горурлык хисен эшкә кергәннең икенче атнасында ук таптап юк иттеләр. Ул вакытта әле Фатыйма башка кибеттә эшли иде. Кибет хуҗасына чибәр яшь кыз бик ошады. Ул Фатыйманы һәр җирдә эзәрлекли башлады. Кызның югалтыр байлыгы булмаса д, хуҗаның үз артыннан чабуы, кыйммәтле бүләкләр алып бирүе аның күнелеленә хуш килә һәм бу хәлнең озаккарак сузылуын тели иде. Хуҗа әле яшь, кибете дә зур түгел. Әмма ят кешеләр алдында үзен президенттан ким тотмый. Әллә кемнәргә тау-тау вәгъдәләр бирә. Фатыйманың әнисе авылда иске йортта торуын белгәч, бер көндә аңа «өй салып» бирде. Алдашудан, алдын-артын уйламыйча вәгъдә бирүдән ул ниндидер тәм таба. Зуррак вәгъдә биргән саен үзен зуррак итеп тоя. Фатыйма белән мактанчык хуҗаның мөнәсәбәтләре ничек бетәр иде, билгесез. Тик көннәрдән бер көнне аны кулга алдылар, кибетен яптылар.

Фатыйма Игорь-Ирекккә боларны сөйләп тормады. Бүген Фатыйманың, ни өчендер, бар нәрсәдән иркле буласы, хәтта эчеп исерәсе килде. Шуна күрә егет теге якка чыгып киткән чакларда шешәдәге эчемлекне үз фужерына тутырып салып эчеп куйды. Хуҗа моны күрмәмешкә салышты. Хатынның исерә башлавын күреп, женси хисләре уянды.

Ирек Илсур Мансурович дигән кешенең шалтыратуын көтә иде.Шул ук вакытта Фатыйма белән бераз кети-мети уйнап аласы да килә. Фатыйма моңа үзе дә каршы түгел шикелле. Әмма иң кирәкле вакытта телефон шалтырап куйса?

Фатыйма исеребрәк китте, аның йокысы килә башлады. Ул изүләрендәге төймәләрне чишеп җибәрде.

—Ярдәм кирәкмиме?—диде Ирек һәм хатынга чишенергә булышты. Егет аны урынга күтәреп салмакчы иде, шулвакыт Фатыйма аны муеныннан кочып алды.

—Неужели жаныгыз юк сезнең?

Һәм алар икәүләп караватка аудылар.

«Тәне кайнар чукынмышның,—дигән фикер үтте егетнең башыннан.—Шәп!..»

Эшнең нәкъ кызган чагында телефон шалтырады. Егет мендәр кырыена куйган кечкенә телефонын алды.

—Тыңлыйм, Илсур Мансурович.

Телефонда калын тавыш яңгырады:

—Игорь, миңа баярак Сәгыйть Хәмитович шалтыратты. «Сайрар кошны» син эләктерә алмадыңмы әле?

Ирек Фатыйманың иреннәреннән бер үпте дә: «Мин хәзер»,—дип икенче бүлмәгә чыкты.

—Әлү, Илсур Мансурович, сез әйткән сандугач кулга төшәргә тора. Сезгә аны кайчангарак китерергә?

—Иртәгә көндезге икедә минем кулда булсын.

—О-кей, Илсур Мансурович.

Ирекнең эченә җылы йөгерде. Ул Илсур Мансуровичның талканы коры икәнлеген белә, шуңа күрә: «Немедленно табып китер»,—дип әйтүен көткән иде. Болай булгач, «Сайрар кош» белән төне буе сайрашып чыгарга мөмкин икән.

Ул өстәлдә калган эчемлекне фужер тутырып эчте, үзенең кыяфәтен көзгедән карады һәм Фатыйма яткан караватка чумды.

—Тагын бераз телефоннан аерыла алмый торсаң, миннән җилләр искән булыр иде,—диде Фатыйма үпкәсен белдереп.

Ирек аңа җавап биреп тормады,кочагына алды. Караватта юрган асты көрәше башланды.

Иртән торгач, Фатыйма эшкә барырга җыена башлаган иде. Ирек:

—Син кая җыенасың?—дип аның каршысына басты.

—Кая булсын, эшкә!

—Кичә бит сине Сәгыйть Хәмитович эшеннән алды.

—Юк белән башымны катырма әле,—дип Фатыйма Ирекне юлыннан этеп җибәрергә теләде.

—Туктале, кызый, ашыкма.

—Ашыгам, кит юлдан. Әллә син минем белән йоклагач, миңа хуҗа булдым дип уйлыйсыңмы? Чыгар хәзер үк!

Фатыйма йодрыклары белән Ирекнең күкрәген төяргә тотынды, ләкин Ирек—көчле егет, аның ике кулыннан эләктереп алып, кәнәфигә утыртты.

—Ә хәзер мине тыңла. Без хәзер Ч. шәһәренә барабыз. Анда безне Илсур Мансурович көтә.

—Миңа синең Илсур Мансуровичларың артымны сөртергә дә кирәкми. Мин үз эшемә барам.

Шунда Ирек түш кесәсеннән документлар чыгарып Фатыймага күрсәтте. Анда Фатыйманың барлык документлары һәм Сәгыйть Хәмитовичның: «Килешүне бозып, үз эшенә салкын каравы, сатып алучыларга тупаслык күрсәтүе өчен Кадыйрова Фатыйманы бүгеннән эшеннән алам» дигән язуына имзасы белән мөһере сугылган. Фатыйманың телен әйтерсең корт чакты. Ул бер сүз дәшә алмады. Менә ни өчен кичә көне буе җаны бәргәләнгән икән. Бу Игорь дигән татардан туган урыс аны очраклы рәвештә генә юлда туры китереп утыртып алып кайтмаган. Алар Сәгыйть Хәмитович кебек бер чыбыктан куалаган кабахәтләр. Бу ирләрнең бөтенесе икейөзле, оятсыз. Эчләре тулы ялган. Аларның тамырларында кан түгел, пычрак судыр. Кеше язмышы белән ничек уйныйлар...

• • •

Фатыйма язмышына буйсынырга мәҗбүр булды. Ул башына төшкән көтелмәгән вакыйгаларны артык тирән кичерми. Киресенчә, аның күңелен тормыштан ниндидер маҗаралар эзләү, шул маҗараларда үзе төп катнашучы булу теләге гел кытыклап тора. Тормышка ул отышлы уен итебрәк карый, ә андый уенда кемдер ота, кемдер оттыра. Бәлки әле Илсур Мансурович дигәннәре берәр бай кешедер. Ә байларга һәрвакыт сөяркә кирәк. Фатыйманың инде сөяркә булып караганы бар. Тик менә Заһит кына аны эзләп бәргәләнер инде. Бик ярата бит ул Фатыйманы.

Фатыйма юл буе шулай уйланып барды. Күз алдына улы Заһит килеп

басса: «Анын әтисе, әби-бабалары бар. Ятим итмәсләр. Бәлки, акылына килеп үз атасы алып китәр. Хәер, кая инде! Ул улы турында сүз чыкса, ишетмәмешкә салыша. Матур кызларның итәк асларын капшарга гына кыю ул. Бүтән эш кушсаң, калтырап төшә. Әй, нигә соң әле алар турында баш ватарга? Башта үз язмышыңны хәл итәргә кирәк, аннан күз күрер!»

Юл шактый озын булса да, вакыт үткәне ничектер сизелмәде. Фатыйманың йокымсырый башлаганын күргәч, егет машинасын туктатып чибәр ханымны саф һавалы чәчәкле болыннар тирәсенә алып чыкты. Анда бераз шаярышкалап, арыганлыкларыннан арындылар, капкалап алдылар.

Илсур Мансурович аларны үзләренең капка төбендә көтеп тора иде. Фатыйманың аны күрүгә күңеле күтәрелеп китте. «Кырык яшь тә юктыр әле монда»,—дигән сөенечле уй йөгереп үтте башыннан. Фатыйманы Илсур Мансурович та ошатты. Ул егетне читкәрәк алып китеп: «Товарның шәбен алып килгәнсең, молодец!»—дип куйды. Алар тагын нидер сөйләштеләр. Күрәсең, сүз Фатыйманың язмышы турында баргандыр. Озакламый Илсур Фатыйма янына килде. Ирек-Игорь боларга кул болгап алды да, машинасына утырып сызды.

—Йә,—диде Илсур Мансурович,—ныклап танышыйк. Мин Илсур Мансурович Әптериев булам. Урыслар Андреев дип атый. Эшем турында сөйләп тормыйм. Хатын-кыз өчен ул бик ялыктыргыч нәрсә. Ә сезнең хакта мин бераз беләм. Тик үз авызыгыздан ишетү кызыграк булыр дип уйлыйм.

—Үзем турында сөйли башлаганчы, минем бер нәрсәне беләсем килә иде.

—Ягъни?

—Мине монда нигә китерделәр? Сезгә кол итепме, сөяркә итепме, әллә бөтенләй мин белмәгән сәбәп бармы?

—Сорауны турыдан куюыгыз әйбәт. Тик монда кем булуыгыз күбрәк үзегездән торачак, Фатыйма ханым. Сез миндә эшләячәксез.

—Мин Сәгыйть Хәмитович кибетенә өйрәнгән идем. Анда дуслар, ирем, улым калды.

—Ирегез белән араларыгыз ничек булганын беләм. Улыгызны үзегез калдырып чыгып киттегез. Сез әле, Фатыйма ханым, иң зур бер нәрсәне белмисез.

—Нәрсә ул?

—Сезне китерүнең төп сәбәпчесе—Заһит.

Фатыйманың йөзенә шатлык чаткылары йөгерде. Димәк, Заһит монда! Бәлки ул мина өйләнергә телидер.

—Әйе, Заһит,—дип дәвам итте Илсур Мансурович.—Ләкин әле мин сезгә иң мөһимен әйтеп бетермәдем. Сәгыйть Хәмитович сезне ни өчен һич көтмәгәндә эштән куды дип уйлыйсыз?

Фатыйманың нервлары бер учка сыярлык булып төйнәлде. Ул сүзнең дәвамын көтеп Илсур Мансуровичка текәлде.

—Җан атып йөргән Заһитыгыз кудыртты сезне.

—Ышанмыйм, бер сүзегезгә дә ышанмыйм. Качачакмын мин сездән. Мине Заһит килеп коткарачак.

—Әгәр Заһитка ышанычыгыз зур икән, ышанып яшәгез. Ә хәзергә сез миндә эшләп торачаксыз.

—Нинди эш?

—Эш дип, эш тә түгел инде ул. Әнигә иптәш кирәк. Ялгызы гына өйдә калырга курка. Ә мин өйгә гел-гел кайтып йөри алмыйм. Кыскасы шул, әйдәгез өйгә. Шунда барысын да аңларсыз.

Алар ак мәрмәр баскычтан менеп өйгә керделәр. Өйнең идәненә паркет җәелгән. Бассаң таеп егылырлык шома. Диварларында картиналар. Алар борынгы булса кирәк. Хәзерге заман рәссамнары ясаганга охшамаган. Хәер, Фатыйма мондый нәрсәләрне аңламый. Картиналарның бик кыйммәт икәнен

генә чамалый. Бервакыт әллә Мәскәү, әллә Санкт-Петербургта ниндидер картинаның урланганын һәм аның өч миллион доллар торганлыгын телевизордан әйткәннәр иде. Фатыйманы шаккаттырганы картинаның урлануы түгел, ә аның бәясе булды. Телевизордан ул картинаны күргәч:

—Мин моны өч тиенгә дә алмас идем,—дип куйды.

Болар керүгә икенче бүлмәдән 60-65 яшьләр тирәсендәге бер ханым чыкты. Ул күлмәгенең алдын артка кигән, күзләре төрле якка уйнап торган, бик хәрәкәтчән ханым иде.

—Бусы нинди кәнтәй тагын?—диде ул Фатыймага ымлап.

—Ул синең якын дустың—Фатыйма, әллә танымыйсыңмы, әни?

Фатыйманың йөрәге дерт итеп куйды. Менә ул нинди җиргә килеп капты. Димәк, шушы җүләрне карар өчен монда китергәннәр аны.

Хатын Фатыйма янына килеп аны иснәй башлады.

—Тәмле хушбуй сөртәсең икән. Зәвыгың бар.—Һәм ул шап итеп Фатыйманың җилкәсенә сугып куйды. Шулвакыт Илсур Мансуровичның телефоны шалтырады. Аны каядыр чакырдылар, күрәсең. Ул бераз кабаланып, Фатыймага тиз-тиз сөйли башлады:

—Сез, Фатыйма ханым, үзегезне өегездә кебек тотыгыз. Монда сез үзегез генә түгел. Аш пешерүче, өйләрне җыештыручы һәм бакчачы бабай бар. Тора-тора танышырсыз. Ә мине эшкә чакыралар.

Илсур Мансурович чыгып китте. Фатыйма юләр хатын белән икәүдән-икәү калды. Ул инде моннан җиңел генә ычкынып булмаячагын аңлаган һәм тормышның билгесез карурманына кереп китәргә әзер иде.

—Арыган күренәсең, ашыйсың да киләдер,—диде хатын. Һәм кесәсеннән кечкенә кыңгырау алып, бер зеңгелдәтте. Ашыга-ашыга аш пешерүче кайсыдыр яктан килеп чыкты.

—Күрәсеңме, өемдә кунак бар. Аның ашыйсы килә,—диде хуҗа хатын.

—Хәзер, Әминә апа,—дип пешерүче китеп бармакчы иде.

—Тукта!—диде Әминә ханым.—Сиңа: мин Әминә апа түгел, Әминә Хөрмәтовна булам дип күпме кабатларга була?

—Гафу итегез, Әминә Хөрмәтовна, мин сезне артык якын иткәнгә «апа» дидем.

—Хәзерге заманда беркемнең апасы, сеңлесе юк. Бөтен кешегә акча—апа, акча—сеңел, акча—хуҗа.

Фатыйма бу хатынның үзе уйлаганча ук юләр түгеллеген аңлады. Улы әйткәнчә, ялгызлыктан да интегерлек түгел. Өйләрендә аш пешерүче, җыештыручы булгач, кирәк чакта алар белән сөйләшә алмыймыни?! Хәер, ул авырудыр. Әнә бит нинди затлы күлмәкнең алдын артка кигән. Пешекче чыгып киткәч ул: «Әминә Хөрмәтовна, сез күлмәгегезнең алдын артка кигәнсез. Рөхсәт итсәгез, мин сезгә булышыр идем»,—диде.

—Бөтен дөньясының алды артка килде бит. Дөньясына карап җайлашабыз инде.

Әминә Хөрмәтовна шулай дисә дә, Фатыймага карышмады. Күлмәген дөресләп киде. Фатыйма Әминә Хөрмәтовнаның чәчләрен тарамакчы булган иде. Ләкин Әминә Хөрмәтовна: «Мин кеше тарагы белән чәчемне тарамыйм. Иренә кызартылган, битә агартылган чибәр кәнтәйләрнең башында ни булмас. Минем үз тарагым бар»,—дип тузынып алды.

Әминә Хөрмәтовна Фатыйманы үз бүлмәсенә алып керде. Бүлмә бик пөхтә җыештырылган. Карават өстендә кул белән чигеп эшләнгән гаҗәеп матур җәймә һәм эреле-ваклы берничә мендәр. Аларның тышлары да кулдан чигелгән. Гомумән, монда бар нәрсә кулдан эшләнгән. Карават үзе генә дә сәнгать әсәренә торырлык. Ләкин Фатыйма мондый матурлыкны аңламый, аңа кибет әйбере—фабрикада эшләнгән келәм, фабрикада тукылган җәймә

булсын. Кулдан эшләнгән эшне ул зәвыксызлык, дип саный иде. Әбисе белән дә еш кына бәхәс куба иде.

Фатыйманы әнисе кул эшенә өйрәтергә күп тырышты. Кул белән эшләнгән эштә кешенең күз нурлары була. Ул нурлар караган саен җанны иркәли, ди торган иде. Әмма Фатыйманың андый нечкә эшләргә күнеле ятмады. Аңа урамда малайлар белән уйнау кызык иде. Малайлардан ишеткән әшәке сүзләрне үз-үзенә кабатлап рәхәтләнеп көлә иде. Әнисе шәһәргә интернат мәктәпкә җибәргәч, ул бөтенләй иркен сулыш алды. Аңа иң матур нәрсә—үзе, чишенеп ташлап үзен көзгедән озаклап карап тору күнеленә ял бирә иде.

Әминә Хөрмәтовна Фатыймадан үз бүлмәсенә карата берәр сүз көткән иде. Тик сүз ишетелмәде, бары тик күзләрендә бераз сәер, бераз аптырашлы караш кына күрде.

—Йә ничек?—дип сорарга мәҗбүр булды ул.

—Дөресен әйтсәм, ачуланмассызмы?

—Юк, юк, ачуланмыйм. Мин монда дөрес сүзгә сусап яшим.

—Улыгыз, минем белүемчә, бай кеше, бүлмәгезне кибеттән алынган затлы әйберләр белән бизәсә дә харам булмас иде.

Бу сүзләрдән Әминә Хөрмәтовнаның төсе үзгәрде, күзләре элпәләнде. Ул үз-үзенә сөйләнә башлады.

—Зәвыксыз, талымсыз, надан кешеләр басты дөньяны.—Билгеле, бу сүзләрне Фатыйма үзенә карата әйтелә дип башына да китермәде.—Хәзер барсына да акча гына матур. Кодрәтемнән килсә, дөньядагы барлык акчаларны яндырып бетерер идем. Кәнтәйләр, урам себеркеләре, оят җирен иң матур нәрсәгә санаучы азгыннар, караклар, юлбасарлар дөньяда акча булмаса үзеннән-үзе бетәр иде.

Фатыйма каршы төшеп нидер әйтергә теләде, тик пешекче аларны ашарга чакырды.

—Кемне ашарга?—диде Әминә Хөрмәтовна.

—Аш ашарга,—диде пешекче, ләкин хуҗабикә аның сүзләренә колак салмады.

—Кешеләр бер-берләрен ашаудан тәм табалар. Кыргыйлыкка таба барабыз. Дөньяны укыган кешеләр боза.

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, караватына ауды. Фатыйма бу күренешне битараф кына күзәтте. Аш пешерүче тагын бер кат:

—Ашарга иде бит, Әминә Хөрмәтовна, ашым суына,—дип әйтеп караган иде, тик хуҗабикә: «Мин беркемне дә ашарга теләмим. Әнә, бер-берегезне үзегез ашагыз»,—дип аларны бүлмәсеннән куып чыгарды. Фатыйма күнеленнән: «Бу юләрләр йортыннан тизрәк качарга!»—дигән катгый карарга килде.

Ләкин Әминә Хөрмәтовнаның вакыт-вакыт «юләрләнеп» алуы аның ачуын китерми, ничектер тынычландыра иде.

—Без начар кешеләргә «хайван» дибез. Хайваннар кешеләрдән акыллырак. Кеше бит ул нәфес корбаны. Башта акчалы буласы килә, акчасы күбәйсә—властька үрмәли, властька үрмәли алса—азгынлык юлына баса. Хәер, азгынлык өчен власть кирәкми. Хатын-кызларның ирләр белән уйнавы хәзер спорт уенына әйләнде. Кем күбрәк...

Фатыйма бу сүзләрне ишетмәде, аның уе Заһитта иде.

* * *

Заһит китергән әйберләрне арзан бәягә алып, кыйммәткә сатып җибәрә башлагач, Сәгыйтьнең кереме күзгә күренеп артты. Ул бу товарларны махсус Сөмбелдән саттырды. Тегеләй-болай тикшерү була калса, Сөмбелгә «талак» әйтеп, бар гаепне аңа аударырга була. Аласын алды бит инде ул Сөмбелдән.

Дөрес, Сөмбел ана бик якын. Карт хатыннан соң сандугач баласы кебек яшь кыз кочагына керү барлык байлыклардан кыйммәтлерәк югыйсә. Ләкин Сәгыйть инде байлыкка күнеккән, байлык булмаса, «сандугач баласы» да аның кочагында сайрамас иде.

* * *

Сөмбел Сәгыйть Хәмитович белән никахлашып, аерым фатирда яши башлагач үзендә зур үзгәреш сизде. Башын горур чөеп, элекке дуслары белән аралашмаска тырышты. Сәгыйть Хәмитович анарга: «Син иске дусларың белән аранны өзәргә тырыш. Һәр хәерче байдан көнләшә. Сине әкренләп үзебезнең мохиткә кертеп җибәрергә кирәк. Тормышта һәркемнең үз урыны булырга тиеш, ә урынны байлык билгели»,—дип тукый торгач, Сөмбел Сәгыйть Хәмитовичның шушы фәлсәфәсен тиз үзләштерде. Шәп машинада өйгә кайтып туктау, тегенди-мондый алган әйберенне үзең түгел, шоферың күтәреп кертү дөнья күрмәгән, бәхетне бары тик матди байлыкта гына дип аңлаган кыз өчен аның тормышы җәннәт булып күренде. Рухи байлык аның өчен бөтенләй юк иде. Мәктәптә көчкә «өч»кә укып йөргән кыз театрларга йөрүне, китап укуны башына да китермәде. Тегенди-мондый хәбәр кирәк булса, өйдә телефон бар. Үз эшләрең белән дә рәхәтләнеп гайбәт сат. Рухи гарип яки сындырылган кешеләр өчен кеше гайбәте сатудан, шул ук вакытта үзеңнең яңа әйберләрең белән мактанудан шәбрәк ни бар тагын?! Сәгыйть Хәмитович ана атнага ике-өч килеп куныш китә. Беренче хатыны белән үзара мөнәсәбәтләре ничектер, Сөмбел аны белми. Белергә дә теләми. Кибеттә ул хәзер үзен хуҗаларча тота: элекке хезмәттәшләренә кычкыргалап алуны, күрсәтмәләр бирүне үзенең бурычы дип саный. Сәгыйть Хәмитович яшь бикәченең кыланышларын хуплап тора. Ә беркөнне ана кайчандыр дус булып йөргән, мәктәптә укыганда кача-поса үбешкән Руслан шалтыратты.

—Ниһәл, байбикә, акчалар минем кочактан җылыракмы?

—Синең кочагың беркайчан да җылы булмады һәм булмаячак,—диде Сөмбел.—Йоны коелган куртка белән кызлар җылыта алмаячаксың син.

—Синең дә бервакыт иске куртка кебек кирәген бетәчәк. Байлык—бер айлык.

—Ә синең үз гомереңдә берәр ай бәхетле булып караганың бармы?

—Мин бәхетсез түгел. Бәхет ул ефәккә төренеп әйбәт машинада йөрү генә түгел. Мин ирекле булуым белән бәхетле.

—Нәрсә соң ул ирек?

—Аны сиңа аңлатып булмый. Көннәрдән бер көнне ефәк күлмәкләреңне салдырып урамга куып чыгарылгач аңлый башларсың син аны. Ул чагында синең ефәк күлмәкләрең генә түгел, үзең дә койрыгы йолкынган тутый кош кебек булачаксың. Байлык кешене тиз картайтып кына калмый, аның акылын да ала. Шуны исеңдә тот.

—Акыллы хәерче булуга караганда, юләр бай булуың яхшырак. Әллә син власть башында утыручылар бик акыллы дисеңме? Акыллы хәерчеләр аларның кабул итүен сорап еллар буе ишек төпләрен сагалый.

Сөмбел телефоннан сөйләшкәндә Сәгыйть Хәмитович кайтып керде. Ул Сөмбелнең соңгы сүзләрен ишетеп калган иде.

—Нәрсә, былбылым, әллә күңеленне рәнҗетерлек сүз әйттеләрме?

—Мәктәптә бергә укыган егет шалтыратты.

—Нәрсә ди?

—Байлык бәхет түгел әле ул,—ди.

—Аныңча бәхет нәрсә соң?

—Ирекле булып яшәү.

—Ярлы кеше ирекле була аламыни? Иң мөһиме—җан ирекле булырга

тиеш. Ә жанны иреккә чыгаручы ике нәрсә бар: берсе аның байлык, икенчесе—власть,—диде Сәгыйть Хәмитович.—Менә шулар гына кешене ирекле итә ала. Без инде бик озак еллар ярлы коллар булып яшәдек. Үзебезне ирекле дип санадык, ә бәхетле идекме соң? Әлбәттә байлык белән власть бетәргә мөмкин. Әмма кулында власть яки байлыгы барында кеше күпмедер хөрмәт казанып өлгерә. Байлыгын югалткан очракта да аларга ихтирам бетми. Ә күнелендә коллык, хәерчелек яткан кеше байый да, властька да күтәрелә алмый. Беркөн әле бер язучыны күрдем. Өлкән яшьтәге танылган язучы. Мин бер роман язган идем, өч ел инде чыгара алмый йөрим, ди. Өйдә ашарга бетте, хатын ташлады. Шул китапны чыгарырга ярдәм итмәссезме, ди. Минем базада йөк ташучы кирәк, әгәр шунда әйбәт кенә эшләсәң, китабынны чыгартырмын, дидем. И шатланды инде, бичара. Ә бит ул начар язучы түгел. Әгәр хөкүмәт талантларга ярдәм итсә, ул кешеләр безгә сәлам дә бирмәсләр иде. Дәүләт башында утыручыларның әнә шундый кешеләргә ярдәм итмәве безнең дәрәҗәне күтәрә. Без шушы болганчык елларда алтын балык эләктереп калырга тиеш. Ләкин, матурым, син шуны исеңнән чыгарма: югарыдагыларга бервакытта да начар сүз әйтмә. Аларны гел мактап торырга кирәк. Мактау—кешенең акылын томалау өчен иң шәп чара.

Бераз вәгазь укыганнан соң алар иркәләшеп алдылар. Беренче көннәрдә Сөмбелгә Сәгыйть Хәмитович ит чүмәләсе булып күренгән иде, хәзер инде ул ана күнегә бара.

«Кибән астында тычкан үлми»,—дигән сүзләрнең хаклыгын Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә үз мисалында раслап килә. Сөмбел инде аның белән шаяра, төрле җирләрен кытыклап Сәгыйть Хәмитовичның йоклый башлаган күзәнәкләрен уята. Сәгыйть моның өчен Сөмбелгә бик рәхмәтле. Сөмбелнең сенелләренә кесә телефоны алып биргәч, Нәсимә белән Рәсимә дә бу «ит бүкәне»нә башкачарак карый башладылар. Сөмбел бер көнне кыюланып китеп: «Әнине бераз җиңелрәк эшкә урнаштыра алмассызмы икән, Сәгыйть Хәмитович? Гомер буе пычрак җыештырып бик арыды инде ул бичара»,—диде.

—Нинди эшкә урнаштырып булыр икән соң аны?

—Бәлки берәр ашханәгә. Безнең әни заманында поварлыкка укыган. Бераз эшләп тә алган.

—Уйлашырбыз, матурым. Ләкин син моның өчен мине бик-бик каты яратырга тиешсең.

—Яратам бит инде, Сәгыйть Хәмитович.

—Юк әле. Бик үк яратып бетермисең.

—Мин бүтәнчә ярата белмим, Сәгыйть Хәмитович.

—Өйрәтермен.

* * *

Заһит сонгы вакытта үзендә нindiдер үзгәрешләр сизә башлады. Төнге йокысы саташуларга әйләнде. Бигрәк тә аның тынычлыгын алган кеше Радик исемле сөяркәсе белән яткан чибәр ханым булды. Аның иңнәренә таралып төшкән озын кара чәчләре, утлы күмер кебек янып торган күзләре Заһитка һич тынычлык бирмәде. Подвалындагы кыйммәтле туннар өстенә менеп йокларга ятуга саташа башлады. Менә подвалның караңгы идәне буйлап кара елан шуышып килә. Заһит анардан куркып башын тун белән каплый. Ләкин кара елан тун астына шуышып керә. «Кит!—дип куалый аны Заһит,—яныма килмә. Юкса пычак белән кискәләп ташлыйм». «Ха-ха-ха!—дип көлә башлый елан.—Син бит мине бик яраткан иден».

—Мин сине белмим. Мин мондый хәшәрәтләр белән аралашмыйм.

—Мин хәшәрәт мени?—ди елан һәм кара чәчле, күмер күзле чибәр ханымга әверелә.—Таныдыңмы инде?

—Син?—ди Заһит гаҗәпләнеп.—Теге көнне сине күргәннән бирле уемда гел син.

—Һәм оныта да алмаячаксын?

—Нигә?

—Чөнки мин—синен намусын.

—Юк, юк, син сихерче.

—Сихерче түгел, Иркә исемле мин.

—Иркә?

—Ә нигә ана аптырыйсын?

—Алайса, үзеннен Радигын янына кит.

—Анын янына да китә алмыйм, чөнки син мине йоклап яткан килеш көчләден.

—Кочагыма үзен шуышып керден.

—Мин йокы исереклегеннән айнымаган идем. Менә хәзер мин синен иркендә, дөресрәге син минем иркемдә.

Хатын озын кара чәчләрен туздырып Заһит өстенә ташлана. Аны изә, таптый, нәзек урыннарын тарткалый. Заһит еш-еш сулый, авыртуга түзә алмый кычкырырга тели, тик тавышы чыкмый, чөнки елан хатын әллә нинди сасы исле, лайлалы чүпрәк белән авызын каплый. Заһит бәргәләнә, чәбәләнә. Бик озак бәргәләнгәннән сон гына уянып китә. Уянуга ук утны кабыза. Тезләрен кочаклап уянып утыра. Ул инде төнге хәлләрнен бер саташу гына икәнлеген анларлык хәлгә килә.

—Ни өчен сон үзен Иркә дип атаган хатын керә төшемә? Житмәсә, мин синен намусын, ди. Гомумән, намус нәрсә сон ул? Хатыннар—ирен, ирләр—хатыннарын алдый. Ә бәлки бу Иркә атлы хатын Радигы белән кавышырга уйлаган булгандыр? Кавышканчы бер-берләрен сынашып йөргәннәрдер. Хәзер шулай бит: егет белән кыз бераз яшәп карыйлар да, ошашмыйлар икән, ике якка таялар. Әйтерсен, кием сайлыйлар. Кием сайлаган кебек үзенә яраклы ир сайлаучы Иркәләрне «намус» дип атап буламы? Юк, монда нәрсәдер анлашылмый. Мин синен намусын, дип Фатыйма керергә тиеш иде төшемә. Ә ул төшкә керми, югалды.

Дөрес, Заһит үзе дә Фатыйманы сирәк искә ала. Анын уенда гел Иркә. Берничә мәртәбә Иркә янына барырга да жыенды, әмма йөрәге житмәде. Шунысы гажәп: Заһит анын янына барырга жыенып та бармый калса, ул төшкә керә. Бу юлы ул жиде башлы аждаһа булып килде.

—Син килергә курыккач менә үзем килдем,—диде жиде баш берьюлы,—әйдә без сине аждаһалар утравына илтеп ташлыйбыз. Анда төрле илләрдән урланган ин матур кызлар яши. Алар сина каршылык күрсәтмәсләр, без аларнын рухларын сындырдык. Теләсән, йоклатып алдына китерәбез. Син бит йоклаганнарны яратасын.

Шулай диде һәм жиде авыз берьюлы күк күкрәгән тавышлар чыгарып көләргә тотынды:

—Ха-ха-ха!

Һәм жиде авызы көлүдән туктагач, аждаһа койрыгы белән Заһитны урап алды да билгесез тарафка очып китте. Карурман аша үткәндә: «Шушында аю-бүреләр арасына ыргытыйкмы?»—дигән сорау ишетте Заһит. Бу теге чибәр ханым Иркә тавышына охшаган иде.

—Юк, юк!—диде Заһит.

Аждаһа карурманны үтеп дингез аша оча башлады.

—Дингезгә ыргытыйкмы? Бәлки шунда бераз гөнаһларынны юарсын.

Заһит дингезгә дә төшәргә теләмәде.

Ниһаять, аждаһа бер утрауга килеп житте. Аждаһаны төрле карчык-корчыклар каршы алды. Алар шундый ябыклар, кабыргалары тиреләрен төртеп

чыгар төсле. Аждаһа Заһитны жиргә кую белән карчыкларның кармактай бармаклары егетнең төрле жиреннән тарткалый, чеметкәли башлады.

—Син минем соңгы акчаларымны урлап качтың. Әҗәлем житүгә карамастан, үлемтеккә житәрлек акчам булмагач, үлә алмый интегеп йөрим,—диде берсе. Икенчесе лачкылдатып Заһитның битенә төкерде.

—Бу сиңа оятсызлыгыңның тамгасы. Аны су белән юып булмый.

Заһит боларны күрмәс өчен күзләрен йомды. Ләкин озын тырнаклы бер карт аның күз кабакларын ачып, ниндидер чәнечкеле агач ботагы белән терәтеп куйды.

—Үз корбаннарыңны күр!

Заһитның күз аллары караңгыланды. Утрауга томан төшкәндәй булды. Ул аягосте йоклап алгандай итте. Күзе тирә-юньдәге хәлләрне аера башлаганда карт-карчыклар таралышкан, алар урынына яшь кызлар килеп баскан иде. Кызлар күбесе таныш кебек, ләкин күбесенең йөзе кара.

—Сез кемнәр? Нигә сезнең йөзегез кара?—дип сорады Заһит. Берсе алгарак чыгып:

—Танымыйсыңмени?—диде кыз.—Син мине дусларың алдында мәсхәрә иттең. Мин шунда: мәхәббәт ул олы сер, аны тик ике генә кеше белергә тиеш, дидем. Ә син: күрсеннәр, нигә куркырга?—дип үзеңнең батырлыгың белән мактанырга теләдең.

—Мин бит сине көчләмәдем.

—Әйе! Ләкин синдә ниндидер Иблис тылсымы бар. Мине шул тылсым хурлыкка сөйрәде. Шуннан соң йөзем карала башлады.

Кызлар Заһитны уратып алдылар. Ни өчендер болар арасында Фатыйма юк иде. Шул уй Заһитның миеннән чагылып үтүгә, каяндыр ерактан Фатыйма тавышы яңгырагандай булды: «Мин үзем сине шул юлга тартып керттем. Чөнки сине дөньямны онытып яраттым. Синең өчен утка да, суга да керергә әзер идем».

—Их, Фатыйма,—диде Заһит.

—Фатыйма дип көрсенмә, син үзең мине коллыкка саттың,—диде бер тавыш. Тик бу тавышны Заһитны божрага алган кызлар ишетмәделәр. Ул һава дулкыннары аша Заһитның гына йөрәк яраларына килеп бәрелде. Ә божра торган саен ныграк кысылды. Егетнең өстендәге киемнәрен умырып-умырып алдылар. Заһитның кызлар кагылган һәр жире кара көеп чыкты.

—Менә хәзер син дә безнең кебек була башладың.

—Мин бит сезнең күбегезне белмим дә.

—Әйе, белмисеңдер. Чөнки мине син бер кибеттә карашың белән көчләдең. Иң беренче баштан аяк чишендердең, аннары күзләрең белән оят жирләремне айкадың. Мин йөгереп өйгә кайтып сабынлый-сабынлый юындым. Ләкин жаныма сеңеп калган пычрак карашыңны юып бетерә алмадым. Мин синең карашыңнан балага уздым. Менә ул бала.—Кыз әллә нинди жан иясен Заһитның кулына тоттырды: бала дисәң бала түгел, бака дисәң—бака түгел. Жирәнгеч бер нәрсә.—Бу синең әшәкелегеңнең бер төре.

Заһит ул жирәнгеч нәрсәне жиргә ыргытмакчы булды, ләкин әлеге жан иясе ялт кына егетнең куенына чумды.

—Син аннан котыла алмаячаксың,—диде кыз,—чөнки ул синең жаның пычраклыгы.

Кызлар Заһитны егып өстенә менеп атландылар. Безнең каралык сиңа да йоксын дип төрлечә мыскылладылар. Бу күренешне карап торган Ай болытлар арасына кереп качты. Шаһит итеп милициягә чакыртуларыннан курыккандыр ахыры.

Заһит тәмам хәлсезләнде. «Жибәрегез, китегез. Әнә теге карчыклардан оялыгыз»,—дип көчсез тавыш белән ялварып карады. Ә кызлар: «Безнең

оятны син алдын, хәзер без җен балаларына өйләндек»,—дип Заһитнын ин авырткан җирләрен боргычладылар. Заһит авыртуга түзә алмый кычкырып җибәрде һәм үз тавышына уянып китте. Подвал караңгы булганлыктан озак кына бу хәлләрнен өнме, төшме икәнлеген аңламый ятты. Стенаны кармап утны кабызгач кына үзенен кайда икәнлегенә төшенде. Ул чынбарлыкта көчләнгән кеше кебек еш-еш сулый, торып су эчәрлек тә хәле юк. Житмәсә нәзек җире үтереп сызлый. Заһит анда кан күрүгә куркып китте. «Әллә соң бу төш кенә булмады микән?»—дигән фикер ми сырлары буйлап йөгереп үтте. Ул озак уйланып ятты. Барсы да теге сөяркәсе белән ятучы чибәр хатыннан башланды. Ана каләр үзе талап чыккан өйләр, юха теле белән үзенеке иткән кызлар ике ятып бер төшенә дә керми иде. Бу Иркә—сихерче булды ахры. Күпме изалана—күз алдыннан китми. Елан кебек үзенә суыра. Заһит шул еланнын эченә үк кереп бара түгелме? Намусны уятыр өчен бәлки әнә шундый Иркә кебек намуссызлар кирәктер! Әшәкелекне әшәкелек чөе белән кагып чыгарырга! Әйе, әйе, бу мөгаен шулайдыр. Юкса уянгач та шул Иркә күз алдыннан китми тормас иде. Әнә бит почмакта озын кара чәчләрен таратып ташлаган да, чәч учмалары белән Заһитны урый. Уф! Нинди хәл бу? Житмәсә әкияттәге убырлы карчык кебек Заһитнын бармагын суыра. Егетнен көче беткәннән бетә бара. Ул көч хәл белән урыныннан кузгалып су эчә. Иркә дигәне зур күсе икән, ул кружка шалтыравыннан куркып каядыр кача. «Теге» җирен күселәр тешләгән ахры. Болай ярамый, больницага барырга кирәк.

Заһитнын шушы урынына ятып үләсе килде. Ләкин ничек үләргә?

Ул урынына барып ятмакчы булды, ләкин егылып бетон стенага башын бәрде. Анын югалтып күпме яткандыр, билгесез. Уянгач: «Тизрәк врачларга күренергә кирәк»,—дип пычрак киемнәрен алыштырды, канаган җирен бәйләде. Больницада анын анализларын тикшергәч:

—Сезгә әле шактый ятарга туры киләчәк, сезне котырган күсе тешләгән,—диделәр.

* * *

Фатыйма Илсур Мансурович белән сирәк очрашты. Ул гел эштә. Өенә кайткан чакларда әнисе янына кереп утырырга ярата. Әминә Хөрмәтовна вакыт-вакыт «ычкынгалап» алса да зыянлы кеше түгел икән. Аны ин нык интектергән нәрсә—ялгызлык булган. Фатыйма башта качам-качам, дип яшәсә дә әкренләп Әминә Хөрмәтовнага ияләште. Бу йорттагы мохит тәэсир иттеме—көнеләндә кешеләрне кызгану хисе уяна башлады. Илсур Мансуровичнын әнисенә карата булган мөнәсәбәте торып-торып Фатыйманын исен китерә. Ул эштән кайтып юынуга әнисенен бүлмәсенә керә дә: «Уф, арыдым, әнием, алдына башымны куеп ятып торыйм әле»,—дип кәнәфи янына тезләнә һәм башын әнисе алдына сала. Әнисе улынын чәчләреннән сыйпый, битләрен чәбәкләштереп ала. Фатыйма моны «төчеләнү» дип кабул итә иде. Ләкин ана һәм улнын бер-берләрен чынлап ратуларын аңлагач, аларга хөрмәте артты. Фатыйманы бервакытта да әнисе үзенен алдына яткырып башыннан сыйпамады. Фатыйма әнисенә килеп сырпалана башласа, тегесе: «Кит әле, сине сыйпап утырырга вакытым юк, арып кайттым»,—дип этеп җибәрә. Кыз үпкәли. Ә инде шәһәргә укырга җибәргәч, әнисенә карата бөтенләй суынды. Вакыт-вакыт әнисенә акча җибәрүләр генә бөтенләй аралары өзелүдән саклап торды.

Илсур Мансурович әнисе алдына ятып үзе генә иркәләнми, әнисенә дә үзенен җан җылысын сала.

—Арыйсын инде, балам. Нигә шулкадәр акча артыннан куасындыр,—дип шелтәли ана.

—Акча артыннан түгел, дөнья куабыз, әни. Дөньяда һәр адәм баласы нидер эшләргә тиеш. Менә мин ателье ачтым. Кешеләрне киендерәм. Кешеләрнең төрлесе бар бит: кайберләре үзләре заказ биреп тектергән әйберне алмый. Алынмаган киемнәрне өеп яткырып булмый. Сатарга кирәк. Шуннан кибет ачарга туры килде. Менә шулай, әни, ә кибеткә килүчеләргә күп нәрсә кирәк: көлмәге дә, чүлмәге дә. Кешеләрнең хаҗәтен үти алсаң, җан рәхәтләнеп китә. Күпләр бизнесменны акча капчыгы өстендә утыручы дип күз алдына китерә. Андыйлар безнең кесәдә кайвакыт җилләр уйнаганын белми бит.

Әнисе белән эш турында шундый итеп сөйләшеп утырулары, уй-фикерләрен уртаклашуы—анага хөрмәт һәм тынычландыру чарасы. Фатыйма баштарак Илсур Мансуровичны эченнән «робот» дип йөри иде. Хәзер аңа карата фикерләре үзгәрде. Илсур Мансурович Фатыйманы да игътибарсыз калдырмый:

—Әни белән бик кыен түгелме? Тотарга акчаң бармы?—кебек сорауларны биреп тора. Ә беркөнне: «Син авылда әнием бар дигән идең. Авылда бит хәзер хәлләр мөшкел. Әниеңә акча җибәрергә кирәктер».

Илсур Мансурович Фатыймага бер төргәк акча бирде: «Әниеңә сал. Әгәр мин онытып җибәргәләсәм—исемә төшер. Бушка эшли торган заманнар үтте».

Акча шактый иде. Ә Фатыйма акчаны ярата. Акчалар күбрәк җыелса, бәлки моннан таяргадыр? Ләкин кая барырга? Авылга әнисе янына кайтсынмы? Элек эшләгән кибеткә керә алмый, анда аны Сәгыйть Хәмитович тотып ашаячак. Гыймайга кайтсам, бәлки куып чыгармас иде. Анда улы нишләп йөри икән? Сагына микән? Гыймай өйләнгәндер. Үги әни Заһитны кыерсытмый микән? Кыерсытадыр, туйганчы ашатмыйдыр да әле. Ана назы күрми үскән баладан кем чыгар? Үзем дә аңа карата кырыс булдым. Мине оныткандыр да инде. Бер кайтып күрәсе иде үзен. Улымнан бигрәк Заһитым сагынгандыр. Ул бит минем өчен үлеп тора иде. Мине юксынудан тагын начар юлга кереп китмәде микән? Ир-ат бик түземсез зат бит ул. Бер читтән икенчесенә ташланырга гына тора.

Мондый уйлар Фатыйманың күнелен торган саен ныграк борчый башлады. Ә Гыймай белән кечкенә Заһит аны бер генә минутка да онытмады. Заһит һәркөнне: «Әни! Әни кая?»—дип уяна. Гыймай улына ни дип җавап бирергә белми.

—Кайтыр, улым, кайтыр. Әниең дә сине сагынадыр.

—Сагынгач нигә кайтмый?

—Эшкә еракка җибәргәннәрдер.

—Әйдә, әти, әни эшләгән магазинга тагын барып сорыйк. Андагы апалар әнинең кайда икәнлеген беләләрдер.

—Бардык бит инде, улым,—дип Гыймай улын күтәреп ала.—Менә бит син нинди зур үстең, башың түшәмгә тия.

—Кибеткә,—ди малай әтисенең мактавына исе китмичә.

—Бүген минем эшем күп. Өченче көн кергән бабайга тәрәзә рамнары ясап бетерәсем бар. Юкса бабай мине ачуланыр. Тәрәзәсе булмагач аларның өйләренә суык керә. Ә карт кешегә җылы кирәк.

—Мина әни кирәк!

—Миңа да кирәк, улым, тик нишлим соң инде.

—Соң, кибетче апалардан сорыйк.

—Йә, ярар алайса, матур күлмәгеңне ки. Бу чалбарыңны алыштыр, тезләре тишелергә тора.

—Әти, мин бу чалбарны алмаштырмыйм, яме?

—Нигә, улым? Яңа чалбарың матуррак бит.

—Юк, бусы матур, моны әни алып бирде.

—Сатучы апалар: «И-и, бу Гыймай абзый бигрәк саран икән, шундый матур улына яна чалбар да алмый»,—димәсләрме соң?

—Дисеннәр.

Малай кулмәген алыштырды, ләкин әни чалбарын салырга теләмәде.

Ата белән ул кибеткә житәкләшеп киттеләр. Гыймай улыннан башка да кибеткә кергәләп йөри. Фатыйма турында берәр хәбәр ишетсәгез, менә бу адрес белән миңа килеп әйтегез, зинһар, юкса малай әнисен бик сагына, дип адресын да калдырып киткән иде. Әмма Фатыймадан хәбәр-хәтер булмады.

Бу юлы да ул Заһит өзелеп-өзелеп сораганга гына кибеткә барырга булды. Сатучылар аларны күптәнге танышлары кебек каршыладылар.

—О-о, менә безгә кемнәр килгән?—дип кайберләре Заһит тирәсендә бөтерелде. Малайның кесәсе кучтәнәчләр белән тулды.

—Әни кая?—диде Заһит еламсырап.

—Фатыймадан хәбәр юкмы?—диде Гыймай да.

—Юк шул,—дип көрсенде сатучы кызлар.

—Сез, кызлар, нәрсәнедер яшерәсез бугай,—диде Гыймай.—Берәр кая китсә сезгә шалтыратыр иде.

—Юк, шалтыратканы юк. Фатыйманың кайда икәнлеген хужа яки Заһит кына беләдер.

—Мин белмим,—диде кечкенә Заһит сүз үзе турында бара дип уйлап.—Белсәм, сездән сорамас идем.

—Сез хужа янына кереп карагыз әле, ул белми калмас,—дип кинәш итте арадан берсе. Гыймай үзе дә шулай уйлый иде. Улын житәкләп хужа кабинетына юнәлде. Сәгыйть Хәмитович кайчан да булса Гыймай килер дип көтә һәм бу очрашуга әзер иде. «Ниһаять!—диде ул, Гыймайның кулын кысып.—Үзем сезгә барырга дип тора идем. Кая булды безнең Фатыймабыз?»

Иң яхшы саклану чарасы, башлап үзең хөжүм итү икәнлеген белгән Сәгыйть Гыймайга авыз ачарга ирек бирмәде. Ул Заһитның башыннан сыйпап: «Әниенне без дә һәркөн көтәбез.—Ул ниндидер папка алып:—Менә бит документларын да сорап кермәде. Ә без аны бик яраткан идек»,—дип папканы кире урынына куйды. Әгәр Гыймай аны ачып караса, анда бөтенләй башка кеше документлары икәнлеген күрер иде. Сәгыйть Гыймайның аптырашлы карашын күреп: «Ә-ә, сезгә әйтергә онытып торам икән. Фатыйма соңгы ай өчен зарплатасын алмаган булган. Мин беркөнне бухгалтердан Фатыйманың акчасын алып, үзем илтергә уйлаган идем. Башка эш килеп чыкты да сезгә бара алмадым».

Сәгыйть сейфын ачып бер конверт алып күпмедер уйланып торды да конвертны Заһитка бирде.

—Миңа акча кирәкми, әни кирәк, әни,—дип өзгәләнде малай һәм конвертны идәнгә ыргытты. Гыймай идәндәге конвертны алып:

—Бу бит әниеннең кучтәнәче, улым. Ул аны сиңа берәр нәрсә алырга дип калдыргандыр. Нәрсә алыйк икән, улым?

—Миңа бернәрсә дә кирәкми,—диде Заһит күзендәге яшьләрне сөртә-сөртә.

Кибеттә эченә кереп утырып, педаль белән йөртә торган машина бар икән, Гыймайның күзе шуңа төште.

—Карале, улым, нинди матур машина. Әллә сиңа шуны сатып алып жибәрәбезме?

Сатучы кызлар «эһ» дигәнче машинаны малайга китереп тоттырдылар. Заһитның күзләрендә очкыннар кабынды. Малай ике уйлаганчы дип, Гыймай акчасын түләп куйды.

—Әти,—диде Заһит,—бу машинага утырып мин әнине эзләргә китәм.

—Ярар, улым, ярар. Баегач машинаның олысын алып жибәрербез әле.

Хәзергә монысы белән йөри тор.

Малайга машина бик ошады.

—Бабайларга да күрсәтик, әти, яме?!—диде Заһит.

—Күрсәтербез, улым, күрсәтербез. Безнең ясаткан оныгыбыз машинада гына йөри икән,—дип шатлансыннар.

—Нәчәлник булам мин, әти.

—Ярар, улым.

Малай кибеттән чыгуга ук машинасы эченә кереп утырды. Велосипедта йөреп өйрәнгән малайга педаль әйләндерү авыр булмады.

Алар бабаларына кереп машиналарын күрсәттеләр. Бабалары: «Машина тикле машинаны котламый ярамас. Менә бу солдат каешын бүләк итим әле үзенә». Бабасы озак билдә йөреп кыршылып беткән солдат каешын үзенең фронт әйберләре саклана торган сандыгыннан алып бирде.

—Бу, улым,—диде ул,—синең машинаң ватылса, буксирга тагарга да ярарлык, бөтен Европаны әйләнеп кайткан шәп каеш!

—Минем машинам ватылмый, бабакай,—диде Заһит.—Выр-выр, выж-выж!

Урамга чыккач та сүз машина турында барды. Әнисен беразга гына булса да оныттыра алуына Гыймай бик шатланды. Заһит рухланып әтисенә машинасы турында сөйләде.

—Әти, моның руле матур, менә монда тормозы да бар.

—Машина бит ул, улым.

Заһит авызыннан төрле-төрле авазлар чыгарды: «чыж-чыж, выр-р, выр-р!». Бу аның үзенчә машинага җан кертүе. Аларның күршесендә Артур исемле бер абый яши, ә аның бер иске «Москвич»ы бар. Артур абый машинасын кабыза башласа бөтен күрше-тирә уяна. Чөнки яшәсен яшәгән, күрәсен күргән бу «Москвич» кабыза башлауга салкын тигән сарыктай озаклап төчкерә, аннары өне беткән эт тавышлары чыгарып гырлый, һаваны янгыратып төчкергәннән һәм гырлаганнан соң гына кабынып китә. Аның кабынуы малайларга зур вакыйга. Алар «ура» кычкырып шатланышалар. Урамга чыккач сүнсә—этеп кабызалар. Артур абыйлары малайларны машинага төяп бер урам урый. Күрше тирәләрдә, юкса, өр-яңа импортный машиналар бар, ләкин малайлар никтер Артур абыйларының иске «Москвич»ын яратарак төшә. Дөресен әйткәндә, Артур абыйлары малайлар яратканга гына иске машинасын чүплеккә ыргытмый. Малайларны шатландыру аның җанына рәхәтлек бирә.

—Артур абыйга да машинаны күрсәтеп чыгабыз, яме, әти.

—Ярар, улым.

Артур абыйлары Заһитның машинасын күргәч: «О-о, безнең Заһитыбыз өр-яңа машина алган икән. Моны котларга кирәк бит, дип Артур тәрәзәсен тышкы яктан ачты:—Әнкәсе, анда пәрәмәч пешереп маташа идең, бер-икесен чыгар әле.

Хатын тәлинкә тутырып пәрәмәч чыгарды. Ул Гыймай белән Заһитны күреп: «Күршеләр кергән икән, әйдәгез өйгә, чәй эчеп чыгарсыз»,—дигән иде, Заһит: «Юк, апа, безнең машинада йөрисе бар. Менә миңа әни машина җибәргән»,—дип машинасын күрсәтте. Боларның тормышларын яхшы белгән хатын «әни» сүзен малайның күңеленнән чыгарыр өчен бөтен игътибарын Заһитның машинасына юнәлтте.

—Бигрәк шәп машина булган бу!

—Әллә безнең «Москвич» белән алышабызмы?—дип хатыны сүзенә Артур кушылды.

—Юк, алышмыйм. Әни машинасын алышмыйлар.

Заһитны күрше-тирәдә яшәүчеләр ярата һәм кызгана иде. Чөнки Заһитың телендә гел әнисе. Кайвакыт ул әтисенең рамнар ясый торган мастерское түбәсенә менә дә: «Әни, менә мин зур үстем. Кайт инде!»—дип кычкырып

утыра, кычкырып арыгач елап җибәрә. Мондый чакларда Гыймай үзен гаепли: «Катырак кыланып ташладым бугай, йөрер-йөрер дә басылыр иде әле. Заһит ничек сагына. Йөрәге телгәләнә балакайның. Чынлап та бу Фатыйма кая китте икән. Моны белсә, бары Заһит беләдер».

Һәм Гыймай өлкән Заһитны эзләп карарга булды. Тик ул аның кайда, кем белән яшәвен белми, бары тик Фатыйма белән бер мәктәптә укыганнарын гына белә иде. Ләкин әле мәктәп ябык, укулар башланмаган. Ә бәлки милиция идарәсенә барыргадыр. Заһит—утырып чыккан кеше, анда белми калмаслар.

Начальникның үзенә керә алмады Гыймай. Кабул итү бүлмәсендә бер яшь кыз утыра иде, ул тупас кына: «Без беркемгә бернинди информация бирмибез»,—дип җавап бирде.

—Минем ни өчен килгәнемне белмисез бит әле сез...

—Дежурный!—дип кычкырды кыз. Тавышка бер сержант йөгереп керде.—Чыгарып җибәрегез минә бу зоопарктан качкан маймылны.

—Туктагыз әле, тукта!..—Сержант Гыймайны өстери башлады. Ләкин Гыймай тамырлары җиргә ябышкан төп кебек урыныннан кыймшанмады. Ул арада кулына портфель тоткан пөхтә адәм шәүлә кебек кенә ишектән кереп теге кыз янына килде. Портфеленнән ниндидер бүләк алып кызга тоттырды. Кыз аны яшен тизлеге белән өстәл тартмасына чумдырды. Шунда ук бу адәмне начальник бүлмәсенә кертеп җибәрде. Шул мизгелдән файдаланып Гыймай да ишеккә ыргылды һәм: «Начальник!»—дип кычкырып җибәрде. Аның тавышына начальник кабинетыннан чыкты.

—Что за шум?

—Минә бер хулиган сезгә керергә тели. Чыгып кит дим, чыкмый.

—Сержант!—диде начальник.—Менә бу кайнар башны «теге бүлмәгә» кертеп бераз суытып чыгарыгыз.

Әллә ни арада тагын бер милиционер кереп җитте. Алар Гыймайны өстерәп диярлек каядыр алып китеп ябып куйдылар.

—Тавышыңны чыгарма,—дип бераз типкәләп алдылар.

Менә ни өчен халык милициягә барырга курка икән. Караклар, хулиганнар, юлбасарлар халыкның соңгы тиен акчасын талап ала. Кешеләр башкаларга күрсәтми кан-яшь түгә, ләкин милициягә бармый. Чөнки белә: милиция хулиганнан яманрак булуы мөмкин. Әнә, машинист Миркасыймның машинасы урлангач шаһит булып Госман барган иде, сорау алып йөрттеләр-йөрттеләр дә, үзен дә ябып куйдылар,—дип уйлады ир.

Гыймайны берничә сәгать тоткач чыгарып җибәрделәр. Шуннан соң ул Заһитны да, Фатыйманы да эзләмәскә булды. «Чукынышып бетсеннәр!»—дип бу эшкә нокта куйды.

Ә кечкенә Заһит әнисен озак сагынды. Тора-бара сагыну, юксыну хисләре малайның йөрәгенә ачу булып утыра башлады. Аның йөрәген ниндидер элпә каплады. Вакыт үткән саен бу элпә калынайды, катыланды. Әби-бабаларының назлары, әтисенең гел кайгыртып, ни теләсә—шуны алып бирүе дә ташбака кабырчыгыдай катыланган бу элпәне кубарып алып ташлый алмады. Малай керпе кебек үз эченә йомылды.

Гыймай авылдан килеп фатир таба алмый йөрүче Дамира исемле кызга өйләнде. Ни гаҗәп: бу кыз да авырлы булып чыкты. Гыймай эчтән генә сукранып: «Күрәсең, хәзерге кызлар тумыштан авырлы булып туалардыр. Бәхетең кимерелгән сөяктән булса берни эшләр хәл юк»,—дип язмышына буйсынды. Гыймайның әнисе: «Без сыер алсак кысыр, кызлар алсак буаз була»,—дип авыз эченнән сөйләнеп алгалады.

Кечкенә Заһит үсте, үсә барган саен анарда әтисенең гадәтләре ныграк чагылыш тапты. Ул үзеннән көчсезләрне елатудан тәм тапты. Аеруча кызларга ачулы иде ул. Үги әнисе Дамираның бала табар вакыты җиткәч Заһит ана:

«Әгәр дә мәгәр кыз тапсаң, кызыңны әнә теге сазлыкка батырып үтерәм»,—дип кисәтеп куйды.

Дамира чынлап та кыз бала тапты. Баласының кыз икәнен белгәч ул бик курыкты. Гыймай да Заһит бирәр нәрсә эшләп ташламагае бу, дип улын күз уңыннан ычкындырмады. Кызны Заһит барында бик иркәләмәскә тырыштылар. Ә Заһитның яңа туган баланы бер дә күргәне юк иде. Ул бишектә төрелеп яткан кызга гаҗәпләнеп карады.

—Син хәзер абый булдың, улым. Абый булу бик җаваплы эш. Сөйләшә башлау белән ул сиңа «абыем» диячәк. Ә инде тәпи йөри башлагач үзен берәрсе кыерсытса: «Абыема әйтәм»,—дип кыерсытучыны куркытачак. Менә бит, улым, сеңлең туу сине никадәр үстерде. Көчле булу, сеңлеңне яклый алу бәхете бөтен кешегә дә эләкми.

Заһитка әтисенең сүзләре тәэсир иттеме, ул бишектәге кызга карап озак-озак уйланып тора башлады. Аның күңелендә нинди хисләр кайнаганын беркем белмәде.

* * *

Фатыйманың җитез машинасы Н. шәһәренә якынайганнан якынайды. Юл буендагы агачлар, машина тизрәк алга барган саен җәһәтрәк артка чигенгән кебек күңелдәге хатирәләр дә үткәннәргә таба йөгерде. Хәтер күгеннән балачак дигән чор соры болыт булып агылып үтте. Соры болыт артыннан күкрәп-яшьнәп яшьлек яшеннәре ялтырады. Күктәге болытларга ут кабызып йөрүче Заһит күренеп калды. Фатыйма Заһитка кулларын сузды, ләкин аның учларына утлы яшен ташлары гына төште. Тик ни өчендер учка төшкән ташлар кулны түгел, йөрәкне яндырды. Хатирәләр җебе Илсур Мансуровичларга барып ялганды. Әминә Хөрмәтовна үләр алдыннан улы Илсур белән Фатыйманы чакырып кертте.

—Улым,—диде ул,—соңгы көннәрдә өянәгем бик ешайды. Сиңа шуны әйтергә телим: күктән йолдыз эзләп йөрмә. Өйлән. Күпме тырышып җыйган байлыгыңны мирас итеп алырлык малай тап.

—Малайны мин үзем генә таба алмыйм бит, әни.

—Менә Фатыймага өйлән.

Илсур аптырап әнисенә карады.

—Саташып әйтмим, улым. Әйе, Фатыйма фәрештә түгел. Мин аның бөтен тормышын беләм. Тик кеше кайчан да булса чистарына башларга тиеш. Күпләр пычраклыктан ялгыз гына чыга алмый. Фатыймага күңелен пакьләндерә башларга вакыт.

—Ни өчен мин, әни?

—Чөнки син аның сазлыкка батуына күпмедер гаепле. Кеше тикле кешене үз дөньясыннан умырып алып, бер белмәгән җиргә алып кайту зур гөнаһ.

—Ярату дигән нәрсә дә бар бит, әни.

Әминә Хөрмәтовна улына бармак янады.

—Беләм-беләм. Хәйләкәрләнеп маташма. Фатыймага күз атып йөрүләреңне күрмәскә мин сукыр түгел ләбаса. Фатыйманың да син кайтып кермичә йокларга ятмавын, телефон шалтыраса да сикереп торуларын күреп торам. Озын сүзнең кыскасы шул, балалар, көн—озын, гомер—кыска, гөнаһлардан арынып матур итеп яши башларга вакыт.

Әминә Хөрмәтовна берничә көннән мәңгегә күзләрен йомды. Илсур Мансурович сабый баладай үксеп-үксеп елады.

—Якты күңелле кеше иде,—диде Фатыйма. Ул да бу югалтуны авыр кичерде.—Авыр туфрагы җиңел булсын.

Әминә Хөрмәтовнаны җирләгәннән соң Илсур Мансурович озак вакыт җанына урын таба алмый йөрде. Ул имезлеген югалткан баладай көйсезләнде,

берәрсе ялгышрак сүз ычкындырса, кызып китте. Шушындый чакларда әнисенең алдына башын куеп, йөрәктәге сызлауларын баса торган өрлектәй ир тамырын давыл кубарган имән кебек кайсы якка аварга белми чайкалып торды. Фатыйма боларның яшәү рәвешен күргәч үзен бөтенләй башка дөньяда хис итте. Ана белән өрлектәй улының үзара самими мөнәсәбәте, Илсур Мансуровичның һәр эшне кинәшеп эшләве Фатыйманы гаҗәпкә калдыра иде. Әминә Хөрмәтовна күпвакыт улы сөйләгәннәрне аңлап та бетерми, өянәге ешайган чакларда ул берничә көн аңкы-минке йөри. Әнисен шушы халәттән чыгарырга да улы ярдәм итә. Назның, бере-берәнә ышанып йөрәгеннә ачуның никадәр кыйммәтле нәрсә икәнен Фатыйма төшенә башлады. Килгәнрәк мәлне ул авызы ныклап тегелгән капчык сыман мөмкин кадәр әзрәк сөйләшергә, үткәннәрне хәтер төбендәге учакта яндырырга тырышты. Ләкин хәтергә сеңгән вакыйгалар янарга теләмәде. Алардан котылыр өчен бушанырга кирәк иде. Әкрен-әкрен Фатыйма үзенең тормышын Әминә Хөрмәтовнага сөйли барды. Әминә Хөрмәтовна аны гаепләмәде дә, хупламады да.

—Безгә һәрвакыт тыелган алма тәмлерәк кебек шул. Синең сүзләреңә караганда, Гыймаең әйбәт кеше булган. Ә Заһитың сине аздырудан тәм тапкан. Гыймайга тормышка чыккач анының синә килеп йөрүләре сине ярәтудан түгел, азгынлыктан, кешеләрнең арасын бозудан үзенең бозык җанына рәхәтлек эзләүдән булган. Күпләр хәзер алдашуны, урлашуны, ата-бабаларыбыздан калган әхлакъ кагыйдәләрен аяк астына салып таптауны батырлыкка саный. Без хәзер авыр заманда: яхшылык белән яманлык буталган чорда яшибез. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман икәнен акылыбыз белән төшенгәч кенә без туры юлга чыгачакбыз.

Әминә Хөрмәтовнаның сүзләре Фатыйманың күңеленә сеңә барды. Илсур Мансуровичның үз-үзенә урын тапмый бәргәләнүләрендә Фатыйма үзен күпмедер гаепле сизде. Беркөнне диванда телевизордан «Җәнлекләр дөньясында» дигән тапшыру караганда боланнарның бер-берләрен ничек назлашуларын күрсәттеләр. Шунда Фатыйма үзе дә сизмәстән башын Илсур Мансуровичның иңенә салды. Фатыйманың чәчләре Илсур Мансуровичның битләрен кытыклады. Менә шушы бер кагылу Илсур Мансуровичның күңелендә яшеренеп яткан наз чишмәсен ачып җибәрде. Ни Фатыйма, ни Илсур авыз ачып бер сүз әйтмәде. Әмма йөрәкләрдән чыккан хисләр дулкыны бер-берләренә кушылып аларны нindидер тирән кичерешләр дөньясына алып кереп китте. Бу—икесе өчен дә яңа дөнья. Монарчы татылмаган саф чишмәләрдән, үрләре үзенә чакырып торган урманлы таулардан, таҗларын чыкларда юып утыручы чәчәкле болыннардан торган дөнья иде.

Илсур Мансурович белән Фатыйманың тормышлары шулай башланып китте. Илсур әнисенең алдына башын куеп ял иткән кебек, арып кайткач Фатыймага сыенды. Фатыйманың тән җылысы аны тынычландыра һәм ул хыялга бирелеп:

—Кайчанрак бер малай алып кайтабыз инде?—дигән сорауны кабатлый.— Бала тавышы яңгырамаган өй—телсез кыңгырау. Баласыз өй—чәчәксез болын...

Мондый сүзләр ешрак кабатланган саен хатынның күңелендә элекке Фатыйма калкып чыга һәм Гыймайны искә төшерә. Ул да гел тагын бер бала апкайтыйк дип тәңкәгә тия иде. Ләкин Фатыйма Илсурга дөресен әйтергә курка, ә дөреслек: Фатыйманың балага уза алмавы иде. Ул инде врачларга да барып карады. Кайсы врачка гына бармасын, һәммәсе сүз берләшкәндәй аңардан Фатыйма монарчы исемен дә ишетмәгән чир табып: бала таба алмаячаксың, дип тәкърарладылар. Фатыйма врачларны аңлый: ул җенси тормышка бик иртә кереп китте. Анда да гадәти итеп түгел, нindидер бозыклык, азгынлык юлын сайлады. Болар, билгеле, эзсез калмагандыр. Ә

Илсурга мирасын калдырыр, эшен дәвам иттерер кеше кирәк.

Шулчак Фатыйма улы Заһит турында уйлап куйды. Шәп фикер бит бу шайтан алгыры! Аны Илсур яратыр, үз улы итәр. Ләкин бу фикерне маңгайга бәреп әйтергә ярамас, хыялны эшләтергә кирәк. Һәм Фатыйма бер төш уйлап чыгарды. «Узган төнне бер төш күрдем. Имеш мин киң бер елганың бер ярында басып торам. Елга ургылып-ургылып ага. Шул ярсып аккан елганың икенче ярында бер малай агымсуга ташланырга тора. «Батып үләсең бит, ярдан читкәрәк кит»,—дип кычкыруыма ул: «Батсам коткарырсың, мин синең улың Заһит»,—диде малай һәм суга ташланды. Мин аңа каршы сикердем. Шунда елга агуыннан туктап торгандай булды. Мин Заһитымны күтәреп ярга чыгардым. Аны җиргә бастыруга улым: «Әни, анда тагын бер малай бар, ул әле йөзә белми. Аны да алып чыгарга кирәк»,—диде. Кабат елгага ташланыйм дигәндә генә уяндым. Төшем шунда бүленде».

Илсур Мансурович төшләргә ышана, аларга югарыдан килгән бер хәбәр дип карый иде.

—Улыңны алып кайтырга кирәк сиңа, шуны алып кайтсаң Ходай үзебезгә дә бер малай бирәчәк. Төшең бик хикмәтле синең, Фатыйма.

Фатыймага Илсур кебек акыллы ирләрнең дә уйлап чыгарылган төшкә ышануы кызык тоелды. «Акыл ягыннан ирләр хатын-кыздан нык калыша»,—дигән фикер башына килгәч ул үзен чын акыл иясе итеп тоя башлады. Машинага утырып юлга чыгуга ук Әминә Хөрмәтовналар гаиләсендәге мөнәсәбәт ниндидер ялганга корылгандыр кебек тоелып, һәркем үз мәнфәгатен кайгырта, дигән фикергә килде. Илсурның Фатыйманы ашыктырып юлга чыгаруы да аның күнеле олылыктан түгел, Заһитны алып кайткач үз уллары туар дигән өметтән чыгып эшләнгән эш түгелмени? Дөрес, ул: «Заһитны алып кил»,—дип элек тә әйтә иде. Әйтә, ләкин бик тиз оныта иде. Ә бу төшне сөйләгәч әнә ничек кабынды.

Һәркемнең матур сүзе артында ялган яшеренеп ята дигән фикерне күнеленә сендереп үскәнгәме, Әминә Хөрмәтовна, Илсур Мансуровичларның күңел сафлыгын, беренче карашка кырысрак күренгән йөрәктә салават күперендәге кебек төрле төсләрнең табигый кушылуыннан барлыкка килгән гүзәллек ятканын аңлый алмады шул Фатыйма. Яшьтән үк җанына оялаган шайтани хис: «Беркемгә ышанма. Дөнья ул пычрак сазлык. Кешеләр бер-берләренең өсләренә басып, шул сазлыктан чыгарга тели. Мөмкинлек барында син дә Илсур Мансуровичының иңнәренә басып югарырак күтәрелеп кал. Улыңны син күптән алып кайта ала идең, ләкин моңа кадәр ул сиңа кирәкмәде. Син үзеңне генә яраттың»,—ди иде.

Фатыйма күнелендәге Иблис белән килешергә теләмәде.

—Юк, мин үземнән артыграк Заһитны яраттым.

—Заһитны да яратмадың син. Ул чибәр һәм аның артыннан күп кызлар чаба иде. Башка кызлар өлгергәнче бу калҗаны үзем эләктерим дип син аны салынып бетмәгән йортның караңгы бүлмәсенә сөйрәдең.

—Дөрес түгел, Заһит мине үзе алдан алып керде. Бер кызык әйбер күрсәтәм, дип.

—Ул «кызык әйбер»нең нәрсә икәнен белеп кердең бит син.

—Белсә соң! Бөтен кызларның да аны беләсе килә. Заһитны яратмасам мин ул «кызык әйбер»не башка җирдә бүтән кешеләр белән күрер идем.

—Атасын яраткач, улын да яраталар.

—Мин улымны яраттым.

—Яратмадың. Яратсаң, син аны Илсур Мансуровичларга алып килә ала идең. Син Илсур Мансуровичны үзенә карату уе белән яшәдең. Әминә Хөрмәтовнага үзеңне тормыш тарафыннан рәнҗетелгән кеше итеп күрсәтергә тырыштың. Син молодец! Максатыңа ирештең.

Фатыйма юл буе үзе белән үзе бәхәсләшеп кайтты. Н. шәһәренә килеп житкәч йөрәге ешрак тибә башлады. Иреннәре кипте. Ул су алырга дип бер кибеткә керде. Керү белән кайчандыр бергә укыган, шәһәрнең бөтен гайбәтен белә торган Гөлфияне күрде. Гөлфия сатучы булып эшли икән. Ул ахирәтен күрүгә: «О-о кемне күрәм! Син кай тарафлардан? Ирдәме? Ирен кем? Заһитын турында беләсеңме?»—дигән сораулар белән Фатыйманы күмеп ташлады. Ләкин Фатыйма авызын ачарга өлгергәнче тагын тел пулеметын хутка җибәрде.

—Ишеткәнсеңдер инде, Заһитың җүләрләнде. «Менә мин сезнең алтыннарыгызны китердем. Аларны мин урлаган идем»,—дип кешеләргә кереп йөри икән. Ә кешеләргә алтын дип алып кергән нәрсәсе йә берәр тимерчыбык кисәге, йә ялтыравыклы шешә бөкесе була, ди. Инде үзен әллә ничә тапкыр кыйнап та ташлаганнар. Барыбер йөри, ди. Беркөнне әле аны кемнәрдер ыштансыз күргәннәр, ди.

Гөлфия бер сүзен өзмәстән икенчегә күчә:

—Теге син эшләгән кибет хуҗасы Сәгыйть Хәмитович турында ишеттеңме? Ул бит бер яшь кызны икенче хатын итеп алган. Ак яулыклы, гыйффәтле кыз булган, ди. Алтын күргәч фәрештә азган, диләр бит. Гыйффәтле кыз да ак яулыгын салып ташлап бик тиз «ит бүкәне» астына кереп киткән.— Гөлфия хихылдап көлеп алды һәм сүзен дәвам итте:—Гыйффәтле кызның аппетиты шәп икән. Тиз арада үзенә кибет ачтырган, элитный йорттан ике бүлмәле фатир алдырган. Сәгыйть Хәмитович аның күзләренә генә карап тора имеш.

Фатыйманың бик эчәсе килә иде, Гөлфиянең бер мизгелгә авызы йомылудан файдаланып су сорап алды да тизрәк китү ягын карады. Ә Гөлфия аны ишеккә кадәр озата барган булып тагын берничә хәбәр әйтергә өлгерде:

—Теге «мунча пәрие»—Гыймаеннын өйләнгәнен әйткәннәрдер инде. Бер авыл кызына өйләнгән. Ансы да корсаклы булган. Тисә дә тия бит бәхет кешегә. Тагын әле...

Фатыйма аның соңгы сүзләрен ишетмәде. Тизрәк машинасына утырып Гыймайларга таба элдертте. Ләкин өйгә якынайган саен машинасының тизлеге кимеде. Заһитның юләрләнүе турындагы хәбәр аны тетрәндерде. «Мине югалту хәсрәтен күтәрә алмагандыр, бичара. Бигрәк нык ярата иде шул. Ә Гыймайның өйләнүе әйбәт. Яшь хатынга минем Заһитым артык кашык кына. Артык кашыктан һәркем тизрәк котылырга тели».

Шундый уйлар белән Фатыйма Гыймайлар капка төбенә килеп җитте. Урамда берничә малай туп тибә иде. Туп тәгәрәп Фатыйманың машинасы астына кереп шартлады. Малайлар Фатыйманы сырып алдылар.

—Апа, сез бу тупның нинди туп икәнен беләсезме?

—Футбол тубы.

—Шулаен шулай, ләкин безгә бу тупны чемпион Инсаф абый бирде.— Малайлар машина астыннан тишелгән тупны тартып алдылар.—Менә монда Инсаф абыйның автографы.

—Әйе, сезнең өчен бик кадерле нәрсәне таптаганмын икән. Сезне ничек бәхилләтергә соң инде? Яна туп бирсәм риза булырсызмы?

Фатыйма машинасыннан өр-яңа туп алып һавага чөйде. Малайлар тупны, ә Фатыйма малайларны күзәтте: «Бу малайлар арасында аның улы Заһит булырга тиеш. Кайсы икән? Әнә теге озын торыклысыдыр, мөгаен». Фатыйма шулай дип уйлауга Гыймайларның капкасыннан бала күтәргән бер хатын чыкты да: «Заһит, Заһит, аш пеште, ашарга кер»,—дип кычкырды. Малайлар арасыннан йөреше белән Гыймайга ошаганрак, нык бәдәнле, тәбәнәгрәк буйлы берәү ачык капкага юнәлде. Фатыйманың күңелен нидер чеметеп алды.

—Әстәгыфирулла, неужели минем Заһит бу? Нәкъ Гыймай.

Малайга ияреп ачык капкадан Фатыйма да керә башлаган иде, бала күтәргән хатын:

—Сез кемгә?—дип аны туктатты.

—Гыймайларның өе шушы иде кебек.—Фатыйма теге хатынның җавабын да көтмичә кыю рәвештә өйгә юнәлде. Бала күтәргән хатынның йөрәгенә ут йөгерде: Фатыйма! Гыймайның Фатыймасы кайткан. Гөнаһ шомлыгы: Гыймайның өйдә чагы.

Фатыйма килеп кергәндә Гыймай күкрәгенә терәп ипи кисеп тора иде. Ишектән Фатыйма килеп кергәч аның кулыннан пычагы төшеп китте.

—Фатыйма?!

—Әйе, синең яраткан Фатыймаң, әйдә күрешик.—Гыймай кулындагы ипине өстәлгә куеп Фатыйма белән күреште. Бала күтәргән хатын Фатыйманы өзгәләп ташлардай булып боларның һәр хәрәкәтен күзәтте.

Өйдә ниндидер авыр тынлык урнашты. Дамира кулындагы кыз шыңшымаса бу тынлыкның озаккарак сузылуы мөмкин иде.

—Кызыңның исеме ничек?—диде Фатыйма Дамирага төрттереп.

—Кызыбыз Чәчкә исемле.

—Матур исем кушкансыз. Ә безнең Заһитыбыз кая соң әле?

—Сезнең Заһитыгыз кайдадыр, ә безнеке үзебездә.—Хатын ишекне ачып карады.—Бәй,—диде ул,—артымнан кереп килә иде бит. Мәле, атасы, кызынны тотып тор, Заһитны эзләп керәм.

Хатын баласын Гыймайның кулына тоттырып чыгып китте.

—Нәрсәгә кайттың?—диде Гыймай кырыс кына.

—Курыкма, синең янда калырга дип түгел, улым Заһитны алырга кайттым.

—Синең улың бармыни?—диде Гыймай.

—Акыллыланып утырма сана. Сезгә бит хәзер минем улым кирәкми. Әнә Дамираның Чәчкәсен үстер. Кеше балаларын үстерергә яратасың бит син.

Гыймайның чиктән тыш ачуы кабарды. Ул үзен тыяр өчен өстәл почмагына тотынган иде, өстәл почмагы шартлап сынды. Фатыйма Гыймайның ярсыган чакларда нәрсәгә сәләтле икәнлеген яхшы белгәнлектән, өй эчендә дулап кубарга торган буранны басарга теләп сүзен йомшарта төште.

—Мин ачуланышырга дип кайтмадым, Гыймай. Әйе, мин сине рәнҗеттем. Сиңа мине кичерүе кыендыр. Ирләр хатыннарын ташлап киткәндә хатыннары кичерә ала, ә хатыннары ташлаган ирләр—гафу итә алмый.

Фатыйманың сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын аңласа да, Гыймайның күңеле йомшамады.

—Ташлау белән ташлауның аермасы бар,—диде ул.—Син минем күңелемдәге иң изге нәрсәләремне (Гыймай: «хисләрне» диярргә теләгән иде дә, мондый сүзләр төчелек була дип хис сүзен кулланмады) мыскыл иттең, таптадың.

Гыймай бик нык ярсуга карамастан, Фатыйманы кимсетерлек сүзләр әйтмәде. Юкса, мин сине авырлы килеш алып, дусларыңның мыскыллы карашыннан коткардым. Заман нинди генә якка үзгәрмәсен кияүгә чыкканчы ук корсак тутыруны беркем дә хупламый, дип әйтә ала иде. Шулай ук, минем йөзем ямьсез булса да күңелем чиста, син минем пакъ күңелемә үзеңнең пычрагыңны йоктырдың. Синең арканда мин кешеләр күзенә туры карый алмый башладым, дип әйтә ала иде. Күрәсең, Фатыймага әле аның күпмедер мәхәббәте сакланып калган булгандыр.

Гыймай белән Фатыйма сүзсез генә «сөйләшкән» арада Заһитны житәкләп Дамира кайтты. Фатыйма тиз генә машинасы янына чыгып китте, аннан бер кочак кием-салым күтәреп керде. Ул киемнәрен Заһитның каршысындагы урындыкка куйды.

—Улым,—диде Фатыйма,—мине таныйсынмы? Мин кем?

Заһит аны ныклап танымаса да, күнеленен ниндидер күзәнәге белән бу хатынның үз әнисе икәнлеген тоемлый иде. Ләкин ул әнисенең кочагына ташланырга ашыкмады. Аның күнелендә хисләр өермәсе башланды: әтисе белән аны кибеткә барып сорашулар, кайтканда күзләреннән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртә-сөртә күлмәк җиннәренең чыланып бетүе, сатучы кызларның, Фатыйманың кайда икәнлеген белмибез шул, диюгә әтисенең кин җилкәләре асылынып төшүе, таныш-белешләре сорашмасын өчен урау тыкрыклардан кайтулары Заһитның күнеленнән чөй белән дә бәреп чыгарырлык түгел. Бигрәк тә усал малайларның: «Синең әниең фәлән, синең әниең төгән»,—дип кабәхәт сүзләр әйтүе, шул сүзләрне әйттермәс өчен канга батканчы сугышуы онытырлыкмыни?

—Йә, улым, нигә бер сүз дә эндәшмисең? Мин бит синең әниең—Фатыйма.

—Минем әнием юк, әтием генә бар,—диде Заһит.

—Менә мин сина матур киемнәр алып кайттым. Киеп кара әле, таман микән?

—Минем үз киемнәрем дә җитәрлек. Әти мина бөтен нәрсәне алып бирә.

Фатыйманың кире малайга ачуы чыга башлады. Заһитның кулыннан тотып үзенәрәк тартты. Киемнәрен салдырырга маташты. Ләкин малай әнисен читкә этеп җибәрде.

—Юк инде, улым,—диде Фатыйма,—мин сине бу хәерчелектә калдыра алмыйм. Әнә капка төбендә «Форд» машинасын күрәсеңме, ул минем машина. Берничә елдан анда син йөри башлаячаксың.

—Безнең үзебезнең машинабыз бар,—диде малай.—Әти мине гел үз машинасында йөртә.

Фатыйманың түземлеге бетә башлады.

—Никадәр генә киреләнмә, барыбер мин сине хәерчеләр арасында калдыра алмыйм.

—Без хәерче түгел. Минем әтием акчаны күп ала.

—Кем соң синең әтиең? «Мунча пәрие» Гыймаймы? Алайга киткәч, соңгысын әйтәм: Гыймай синең әтиең түгел. Синең әтиең...

Фатыйма синең әтиең озын буйлы, чибәр Заһит, дип әйтергә авызын ачкан иде дә Заһитның юәрләнүен күз алдына китереп тыелып калды. Ул инде болай гына улын алып китә алмаячагын аңлаган иде.

—Сез аны мина каршы котырткансыз,—дип ул Гыймай белән Дамирага ташланды. Әнисенә Заһитның шундый каты торуы аларны тынычландырган иде. Шуна күрә алар Фатыйманың кыланышларын сабыр гына карап тордылар. Гыймай Фатыйма килеп керүгә үк Заһит әнисе кочагына ташланыр дип курыккан, чөнки малай юк-юк та әнисе турында сораштырып куйгалый, хәтта бер фоторәсемен китап арасында йөртә иде. Беркөнне ничектер сумкасын актарганда малайның китаплары таралды һәм берсеннән эченнән әнисенең алсу ефәк күлмәк киеп, чәчләрен җилдә җилфердәтеп төшкән фотосурәте килеп чыкты. Фотосурәтне Гыймай алып озак кына карап торды. Заһит үзен гаепле сизеп: «Мин аны әнинең альбомыннан алдым, үзе күрмәгәндә»,—диде.

—Ярый, улым, мин берни дә әйтмим бит, әниеңне онытмавың әйбәт. Ничек кенә булмасын—әни әни инде ул.

Шунда Заһит: «Әтием, Дамира апаны «әни» дип әйтмәсәм ярыймы?»—дип сорады. Гыймай улын күкрәгенә кысып: «Ярый, улым, ярый. Әни бер генә була»,—дигән иде.

Фатыйма бу гаиләнең шактый нык икәнен аңлады һәм хәйләгә күчте.

—Ярый, улым, син минем белән китәргә теләмисең икән инде, һич югы минем машинага утырып шәһәрне карап йөрик. Алты ел буе читтә яшәп үз

шәһәремне оныта башлаганмын. Әйдә, улым, иптәш малайларыңның күзләре янсын әле. Заһит менә нинди машиналарда гына йөри дисеннәр. Йә, киттекме?

Заһитның шәп импортный машинага утырып шәһәр әйләнәсе бик килә. Берәрсенең капка төбенә ятрак машина туктаганын күрсәләр дә, алар шунда җыелышып, нинди маркалы икәнен укыйлар иде. Улының ул гадәтен Гыймай белә һәм әнисенең машинасына да утырырга теләвен ул яхшы аңлады. «Мәхәббәт нәфрәткә әйләнсә, аны янадан кайтарып булмый шул»,—дип фикер йөртте Гыймай. Гыймай тагын шунысына шат: бөтен мәсьәләне Заһит үзе хәл итте.

—Әти белән әнине дә алсаң гына утырам,—диде ул.

—Нинди әни?! Менә мин бит синең әниең.

—Юк, минем әнием менә!—Заһит Дамираның беленнән кочаклады. Дамираның күзләреннән яшьләр килде. «Рәхмәт, улым!»—диде ул йомшак тавыш белән. Моңа кадәр Дамирага «апа» дип кенә дәшкән Заһитның үзен «әни» дип атавы яшь ананың күнелен йомшартты. Дамира күзләрен алъяпкыч итәгенә сөртте. Ул арада калкандай булып Дамира белән Заһит янына кызын күтәргән Гыймай килеп басты. Фатыйма бу күренешкә түзеп тора алмады, улына дип алып кайткан әйберләрне таптап:

—Жир тараканнары, кадерне белмисез икән—яшәгез шунда пычракка аунап. Ә синең, Заһит, бервакыт исеңә төшәр, ләкин соң булыр. «Әтием» дип атаган мунча пәрие кебек надан, ангыра, киребеткән нәрсә чыгачак синнән. Укырга теләрсең, әмма хәерчеләргә уку йортларында урын булмас,—дип чәрелдәде.

—Сүзең бетсә, чыгып китәргә мөмкин,—диде Гыймай ишекне ача төшеп.

—Кумасагыз да китәм, сезнең сөрсегән өегезнең исен иснәп торасым килми.

Фатыйма ярым ачык ишеккә китереп типте дә, дулап чыгып китте. Ул итәгеннән «давыл» күтәреп машинасына менеп кунаклады. Фатыйманың «җененнән» курыккан машина алга ыргылды. Машина астында ике каз ял итеп яткан икән, алардан канлы эз генә калды.

Фатыйманың кайтканын тыкылдык Гөлфия шәһәргә таратып өлгергән, хәтта бу хәбәр юләр Заһитка да барып ирешкән иде. Ул сәләмә киемнәрен жилфердәтеп Гыймайларга юнәлде. Шулвакыт юл чатыннан уктай атылып бер кара машина килеп чыкты да Заһит юеш борынын җиңенә сөртеп маташканда аны бәреп тә китте. Заһит юл читендәге бетон баганага сыланды. Кеше таптатканын күргәч, Фатыйма машинасының тизлеген тагын да арттыра төште. Аның күзе-башы тонды. Кул-аяклары акылга буйсынмый башлаган иде. Шулчак кинәт әллә күк күкрәде, әллә Фатыймага гына күкрәү тавышы ишетелде, аның куллары рульдән ычкынды һәм ул текә борылышта упкынга очты.

Әле җаны чыгып җитмәгән Заһитны да, кем икәнлеге танымаслык хәлгә килгән Фатыйманы да «Ашыгыч ярдәм» машинасы больницага алып китте.

Алда аларны нәрсә көткәнлеген бер Алла гына белә иде.



Мөхәммәт
Мирза

# АДӘМ БАЛАСЫНА

БИШӘРЛЕКЛӘР

## I

* * *

...Тәннең китәсе юк,
Җанның каласы юк...
Адәм баласының
шуны үзгәртерлек
һичбер чарасы юк...

* * *

...Данлау, мактау—бары
шайтан имезлеге
Адәм баласына—
дулап дауламасын
өчен тигезләгән...

* * *

...Барысы буйсынган
көтү Анасы бар...—
Адәм баласына
карусыз бүредән
гыйбрәт аласы бар...

* * *

...Ялган дәрәҗә, дан—
салпы якка сәлам...
Адәм баласына
масаеп азсынга
шайтан сузган харам...

* * *

...Бозлык чорында да
тәнне тән җылыткан...
Адәм баласына
Ана сөте белән
керерен җен йоткан...

* * *

Алашага—тышау...
айгырга—арата,
Адәм баласының
башында бармы уй
шул хәлгә карата?

* * *

Хөрмә һәм Хур кызы—
Оҗмах җимешләре...
Адәм баласының
күңле шайтан коткы...-
сында килеш әле...

* * *

Кешелек—чоңгылда:
бик астан менәре...
Адәм баласының
җан кыюдан ары
юк оста һөнәре...

* * *

Хәләл гомер иткән
тәмугта янмаган...
Адәм баласының
нәфсе мәңге чикмәс
тыелган алмадан.

* * *

...Хатадан хали зат—
кул кушырып утырган...
Адәм баласының
басып торганы да—
йөз егылып, йөз торган.

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; «Турайгыр», «Киек каз юлында» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

...Туган туганыннан
йөз чөергән заман...
Адәм баласына
бәхет чит-ятлардан
явар сыман һаман...

* * *

...Таңнар атып торыр,
Кояш батып торыр...
Адәм баласының
әрәм гомеренә
Күк шаккатып торыр...

* * *

...Сөю—канның, җанның
шашып котыруы...
Адәм баласының
шул татлы газаптан
юктыр котылуы...

* * *

Нәфесен тыялган—
күңеле камил зат.
Адәм баласына
гап-гади хакыйкать
нилектән шулай ят?

* * *

Һәркемнән шикләнгән—
үзенә бикләнгән...
Адәм баласының
килере-табары
учында чикләнгән...

* * *

Урман, дала, кырда
кыргый эт көтүе...
Адәм баласын да—
көтеп йөриме алар—
мур кырып бетүен?

* * *

Туган туфрагыннан
көчләп кубарылган
Адәм баласының
юк кайтыр Ватаны,
аты тугарылган...

* * *

Хәер акчасын да
алыр иде күрәп...
Адәм баласының
чүпле бакчасында
сынык саплы күрәк...

* * *

...Нәфесе чигенгән
һәр адым җаваплы...
Адәм баласының
чамасы чигеннән
чыкмавы саваплы...

* * *

Вөҗдан мыскалында:
явызлык, игелек...
Адәм баласының
уе корсагында
шул әле—иң элек...

* * *

Эт—дус, бүре—дошман,—
һич юктыр бутасы...
Адәм баласының
эт тиресеннән бит
бүреге, унтасы...

* * *

Козгын тавышында
фаразның шомлысы...
Адәм баласының
җирдә шүрләп үтә
бер карыш тормышы.

* * *

Хәерче илнең дә
үзенчә бае бар...
Адәм баласының
бер-берсе әҗерен
чәлергә җае бар.

* * *

Көтеп килмәс—бәхет,
көтми килер—кайгы...
Адәм баласының
үтәрме бер көне
шул хәленнән айры?

## II

* * *

Вакыт—матдәнең беренчел
Сан, сыйфат бирәмлеге...
Галәмнең тирән төбеннән,
Үткәннән—килер көненә
Сузылып кергәнлеге...

* * *

Ут-матдәнең кайчан да бер
әвереләчәк хәле—
Вулкан-таулар эчләрендә,
күкнең чиксез чикләрендә
дөрләп яначак мәле...

* * *

Беркем берни белмәс,—димә,
беркем берни күрмәс,—димә...
Кемдер белеп, күреп торыр:
каптырырга кармагына
форсат кына көтеп торыр...

* * *

Гөнаһлардан арала, Бер Ходам,
нәсел ыру, бала-чаганы...
Саклаганны саклаганың беләм,
белә торып,
онтып җибәрәм шул чаманы...

* * *

Кяферлек—шайтан бакчасы,
чәчелсә бер уч орлык,
күкрәп үсәр имансызлык;
оныкларның оныклары
мең ел тәгам кылырлык.

* * *

Май чүлмәге, диләр,
тышыннан билгеле...
—Бу күмер чүлмәгең
күршеңнән
алган идеңме?..

* * *

Үҗәт тырышлык кирәктер
ни булса майтарырга...
Тама-тама таш ярып та—
булмый икән, булмый икән
яшьлекне кайтарырга...

* * *

Мәхәббәттә арадашчы нигә,
хөкемдар ник кирәк хисләргә?
...Олылыгын ваклау өчен генә,
хыянәтне аклау өчен генә
кирәк алар иблисләргә...

## Ветеран агитатор

*Г.Афзалга ияреп...*

Элек нотыклар сөйләдек
сулар йота-йота...
Бүлмә салкын, тамак та ач.
Әллә инде шул елларның
ялганнары тота?..

* * *

*Куштанга*

Түрәләр янәшәсендә
йөререм кем юраган?
—Шунда бул, килешә сиңа,
аккан-тамганны чәлергә
тиеш кулын юмаган!

* * *

Бер киткән килми—
үткән гел артта...
Көн үткән саен—
гомерләр кими,
үкенү арта...

* * *

Сүрелде дә... сүнде учак,—
өелеп калды көле...
Җил себереп үтәр берчак:
кучеп киткән авыл кебек
караеп калыр төбе...

* * *

Ишенә куш булалган—
бәхетенә кинәнгән...
Ишенә борын чөйгән—
үрелеп өзә алмаган
чикләвеген иманнан...

* * *

«Дөнья куласасы—
әйләнеп басасы...»—
Адәм баласына
әллә шуны язып,
муйнына асасы?!

* * *

Тугры юл—савапка,
кыек юл—газапка...
Адәм баласының
кыйбласызлыгы—
газаплы азакка...



Җәүдәт
Ильясов

# ЕЛАННАР ӘФСЕНЛӘҮЧЕ

РОМАН

**Беренче бүлек**

## Игезәкләр йолдызлыгы

1048 елның 18 маенда шыксыз Газнада хурлыклы әсирлектә фикер иясе, күп газаплар күргән Әбу-Рәйхан Беруни каты авырый башлады. Ул инде үзенең көннәре санаулы икәнен тоя, әмма үзе кабызган гыйлем утын кем дәвам иттерәсен генә белми иде.

Шул ук көнне, таң атканда, Нишапурда чатырлар остасы Ибраһимга олы шатлык килде: хатыны аңа малай бүләк итте. Малайга матур һәм җыйнак Әбелфатыйх Гомәр дигән исем куштылар.

Ул туган сәгатьтә Кояш белән Меркурий Игезәкләрнең өченче градусында булып, Меркурийның Жиргә озынлыгы Кояш озынлыгына туры килгәнлектән, ә Юпитер аларга нисбәттә өчпочмак ноктасында торганлыктан, Гомәргә байлык, күп бала, эшендә уңышлар фараз иттеләр.

Әле балачагында ук Гомәр өлкәннәрне үзенең зирәк акылы һәм, әйтергә кирәк, гаҗәеп зиһене белән шаккатыра.

Хәер, кайдадыр әйтелгәнчә, шаккатырырлык зиһен юләрләрдә дә була.

Ябык, ак чырайлы, киң маңгайлы, оялчан һәм хәлсез була ул. Еш авырый. Аның каравы искитмәле үҗәт, хыялый һәм үтә сизгер. Рәнҗетсәләр, бигрәк тә нахакка булса, үз эченә бикләнә. Нык ачуы килгән чакларда, кинәт кызып китеп, үзеннән күпкә зуррак малайларга да ташлана, сүзен өскә чыгару өчен кулына эләккән теләсә нәрсә белән кыйный башлый.

Котылу өчен сугыш чукмарын типкәлиләр, таяк белән сугалар, әмма бу да ярдәм итми. Узып баручы берәр өлкән кеше килеп аермаса, канга баткан хәлдә, күз яшьләренә тыгылып, сугышуын дәвам иттерә.

Ул барысын да тизрәк белергә, барысы белән дә кызыксынырга ярата. Тышта кар явамы, әллә яңгыр коямы—Гомәр җылы мич янында тыныч кына утыра алмый, әтисенең калын чапанын бөркәнә дә сиздермичә генә

Роман кыскартып бирелә.

Җәүдәт ИЛЬЯСОВ (1929–1983) – *Үзбәкстанда яшәгән татар язучысы; «Согдиана», «Ук һәм Кояш», «Тылсымлы үләм» һ. б. китаплар авторы.*

тышка чыгып шыла. Бер нәрсә турында да уйламыйча, салкынга һәм янгыр тавышына бирелеп, бакчада юеш, шәрә агачлар арасында йөри. Аннары юан кәүсәләр тирәли үскән вак чияләр чытырманлыгына керә дә, өстән койган янгырда чыланып, дәшми-тынмый гына сәгатьләр буе шунда утыра.

Берни турында да уйламый ул. Шул чагында, кемнендер тонык һәм боерулы тавышы булып, күнел түрендә шигъри юллар барлыкка килә. Кемнекеләр? Билгесез. Бәлкем, үзенекеләр, кайчан да булса язачак шигырьләредер?

Малайны беркем эзләми, беркем дәшми, өйгә чакырмый. Әнисе инде ана кул селтәде.

Җир тетрәсә яки, давыл чыгып, Нишапурдагы черегән агачларны аудара башласа, Гомәр кыргыйларча шашып шатлана. Кискәләп, өйләргә ташып бетергәнче, ауган агачларның куе яфраклары арасына кереп яшерена дә яшел энгер эчендә хыяллар дөньясына чума.

—Юләркәй!—дип көлә аннан әти-әнисе.

Башка балалардан сораган кебек, кем буласын килә, дип сорагач, ул, ата-анасын хафага салып: «Сукбай!»—дип җавап бирә. Анын язуы матур. Ул киная белән сөйләгәнне яки әйтеп бетермәгәнне сөйми, бар нәрсәдә—фикердә, сүздә һәм эштә—төгәллекне ярата. Җан дуслары юк анын. Ни өчендер Гомәрне беркем дә яратмый. Хәтта әнисе дә.

Төн урталарына таба китабын кочаклап йоклап киткән улын күреп, Ибраһим: «Ул, мөгаен, китап тотып үләр дә»,—ди.

Һәм вакыты җиткәч, бу шулай була да.

Җиде яше тулып, мәхәллә мәдрәсәсенә илткәнче үк инде Гомәр укый-яза белә, шунлыктан башкалар белән бергә уку ана кызыксыз була. Ул еш кына дәресләргә керми, тирә-яктагы бакчаларда ялгызы кангырып йөри. Шуна да карамастан, ун яшендә инде грамматиканы, тел белеме теориясен, стилистиканы белә, һиндчә исәпләүгә, алгебра һәм геометриягә күчә.

Гомәргә 10 яшь. Хеопса пирамидасына 3880 ел тулды. Ашшурбанипалның язмалары моннан 1670 ел элек юкка чыккан. Аристотель 1380 ел элек үлгән. Олыгбәк 336 елдан сон туган. 542 елдан сон Джордано Бруноны утта яндырачаклар.

Ун яше тулгач, Гомәр беренче тапкыр Нишапурдан Астрабадка барды. Аннан ерак түгел, Баге-Санг дигән авылда әтисе—шактый бай оста Ибраһим җәй көне ял итәр өчен йорт һәм бакча сатып алган иде.

—Йөрмәскә иде, вакыты бик хәвефле.

—Ходай мәрхәмәтле,—диде Ибраһим. Әмма шулай да, кирәк булса-нитсә дип, биленә кылыч такты, ә үзенең әзмәвердәй өч хезмәтчесен үзләре кебек үк зур күсәкләр белән коралландырды.

—Ходайның кодрәте кин!—дип шатланды Ибраһим юлда.—Быел хурдад (май ае) искитмәле. Кайбер елларда инде бу вакытта үләннәр көя, агачлар калын тузан белән каплана, селкетсән, үзенне күмәрлек була. Ә хәзер? Көн саен кич яшен дә янгыр, көндезен—кояш. Һава чиста, һәркайда чисталык.

Шатлыгы ана файда турында да уйларга комачауламады, киресенчә, күнелле һәм эшлекле фикердән анын бу шатлыгы арта гына барды: «Җәй янгырлы булса, чатыр сорап килүчеләр артачак»,—дип уйлады ул.

Кәрваннан аерылып, алар Фирүзгән тавы юлына борылдылар. Өсте юешләнгән каты юл кара кыя артына таба сузылган. Һәм ул, әле күтәрелеп, әле аска төшеп, тыныч кына көй уйный кебек.

Гомәр өчен һәр бирмеш көн бәйрәм, ул инде уянгач ук белә: хәзер нинди дә булса бер гаҗәеп нәрсә булачак. Кояш чыгачак, кар яки янгыр явачак.

Жил булачак. Тәмле кайнар ипи. Китап. Ак гөләп—эсседә аннан шундый рәхәт салкынчалык бөркелә. Сер сөйләшүләр булачак. Нидер булачак! Һәм бу бит инде үзе үк могҗиза!

Бар нәрсәне янгыр юып узган, зәңгәр тау өстендәге һава, ташлар, яфраклар—барысы да ялтырап тора! Әгәр бу мизгелдә Гомәр кичергәннәр могҗиза белән чынга ашса, ул шундук очып китәр иде дә, юл читендәге куакларга кунып, башка кошлар белән бергә чыркылдашыр иде.

—Бүген синең туган көнең,—дип елмайды әнисе.

—Ходай кушып, бөтен тормышың бүгенге бәхетле иртә кебек якты һәм искитмәле булсын, Аллаһының кодрәте киң!—диде Ибраһим. Һәм, атларны чыбыркылап, олауны туп-туры талаучылар өеренә китереп чыгарды.

Алар, атларыннан төшеп, тау битеннән юлга килеп тоташкан яшел уйсулыкта төркем булып торалар иде. Кысык күзләрендә—рәхимсезлек, комсызлык һәм миһырбансызлык. Куллары—тимер. Мангайлары—бакыр. Йөрәкләре—таш. Шәфкать көтмә үзләреннән.

—Тукта!—дип кычкырды зур йөнтәс бүрек кигән яшь төрекмән.

Гомере буе ат өстендә йөреп, кәкрәеп беткән аякларында алпан-тилпән атлап, кара һәм кыргый бу кеше туктап калган арба янына акрын гына әмма дәһшәтле кыяфәттә килде. Ибраһимның хезмәтчеләре кулындагы күсәкләргә усал караш ташлады. Үзенекеләр ягына борылды (алар унбишләп кеше иде) һәм карлыккан тавыш белән көлә башлады:

—Күрегез әле боларны! Коралланганнар, һа-һа!..—Ул якындарак торган хезмәтчегә акырды:—Кемгә дип әзерләдең инде син бу күсәкне, эттән туган нәрсә?! Безнең өчен түгелдер бит, ә? Хәзер тондырам бит шуның белән тинтәк башына!—Ул күсәкне алмакчы булды, әмма башта аптырабрак калган Әхмәт, кызып китеп, читкә сикерде дә күсәкнең очлы башын сөңге кебек итеп төрекмәннең күкрәгенә китереп терәде.

Төрекмән чинап җибәрде. Берникадәр вакыттан соң инде Ибраһимның иң яхшы хезмәтчесе Әхмәт куллары артка каерылып бәйләнгән һәм тезләнгән хәлдә тора иде.

—Син безгә... кизәндең,—дип карлыккан тавыш белән әйтте яшь төрекмән, күкрәген ышкып.—Йөз динар да өч фельс![1] Әҗерең алачаксың син моның!

—Хуҗам!—дип коты очып кычкырды Әхмәт таш булып катып калган Ибраһимга.

—Акырма,—дип мыгырданды талаучы-юлбасар.—Монда мин хуҗа.—Ул озын тар пычак тартып чыгарды һәм, арттан килеп, бармаклары белән Әхмәтнең борыныннан тотты, каты итеп башын югары күтәрде. Әхмәт, тыны бетеп, тәкерәеп йотарга тырышты, бугаз төере чарасыз селкенде.

Коты очкан Гомәр төрекмәннең пычак очы белән кытыклавын күрде.

—Карама!—дип калтыранып пышылдады әнисе.

Малай анын аркасына яшеренде, учлары белән күзләрен каплады. Әмма ишетү һәм сизү әгъзалары ачык иде. Ул кыска гырылдауны, янгыр яугандагы кебек үлән кыштырдавын ишетте, күңел болгаткыч кан исен сизде...

—Күрдегезме?—Төрекмән гадәтенчә канлы корычны ялап алды.—Йә, ташлагыз утка ахмак күсәкләрегезне!—Ул юеш ботаклар пыскып яткан мескен учакка күрсәтте. Мыскыллы гына елмаеп куйды:—Рәхмәт, утын алып килгәнсез. Юкса юньлерәк учак тергезерлек нәрсәбез юк иде.

Учак тернәкләнеп китте. Усал карашлы төрекмәннәр дә җанланды. Төркем башлыгы әле һаман да исенә килә алмый торган Ибраһимга:

[1] Динар һәм фельс—акча берәмлекләре.

—Арбаны да ватарга туры килер,—диде.—Учак дөрләп янсын өчен. Төшегез. Нәрсәләр ул капчыкларыгызда, шулпа пешерерлек берәр нәрсә бармы?

Гырылдык усал тавыш белән төрекчә сөйли иде ул, әмма Хорасанда төрекләр басып алуның беренче елларында ук аңлый башладылар дала телен.

—Оят түгелме?—диде Ибраһим тыныч кына, хатыны белән улына арбадан төшәргә булышып.

—Нәрсә?—дип дорфа гына сорады юлбасар. Кысык кара күзләрендә—аптырау галәмәте. Күрәсең, «оят» һәм «намус» кебек сүзләрне еш ишетергә туры килми иде аңа.

—Мөселманнарны талау оят түгелме?—Ибраһим үксеп елап җибәрде.

—Ә-ә...—Төрекмән бүрекен маңгаенарак төшереп куйды, муенын кашыды.—Мөселманнар...—Һәм шундук аңлатып бетерә алмаслык ярсуга күчте:—Йөз динар да өч фельс! Ә без кемнәр?!—Ул кем алдындадыр (бәлкем Ибраһим алдындадыр) акланырга ашыккандай, кызып-кызып һәм тотлыга-тотлыга, сүзләр ташкыны яудыра башлады:—Без... безнең бәхетсез кабиләбез... Сәйхун[1] буенда яшәгәндә... ишеткәнең бармы шундый елганы? Хаким Җөндә... ни өчен дип безгә ябырылды соң? Алла белсен! Бөтенебезне талады. Терлекләрне куып алып китте. Минем сигез мең кардәшемне үтерде. Алар кяферләр идемени? Барысы да мөселман иде, авыр туфраклары җиңел булсын. Каһәрләргә түгел, кызганырга кирәк безне! Хорасанга качарга туры килде. Шуннан? Йөз динар да өч фельс! Бирегә безнең төрекмән каныбызга сусап... тиле солтаныгыз Мәсүд Газнави килеп чыкты. Ярый ла безнең булдыклы Тугрылбәгебез аны тар-мар итте. Хәзер инде бөтенесен таларга һәм җимерергә безгә чират җитте. Беләсеңме—яраланган юлбарыс өчләтә куркыныч. Менә шулай. Әй, капчык һәм чүлмәкләрне җиргә ташлагыз!—дип кычкырды ул үзе кебек үк каракучкыл йөзле усал ярдәмчеләренә.

Әниләре мыштым гына үкседе. Ибраһим белән Гомәр агарынып, сүзсез басып тордылар. Баш шаулый, аяклар калтырый, ә эчтә—кайнар ачу. Әмма юлбасарларның берсе арбадан зур яшел төенчекне җиргә ташлагач, Гомәр түзмәде, аңа ташланды.

—Кагылма!

—Авыр,—дип гаҗәпләнде төрекмән.—Ни бар анда? Бәлкем алтындыр, ә?

—Алтын?—дип алар янына килде башлыклары һәм төенчекне бушатты. Агач тавышы чыгарып, юлга тоныграк юка кирпечләр коелды.

—Нәрсә болар?—дип сорады сәер кирпечләрнең алтынга бик үк охшап бетмәвенә кәефе киткән юлбасар.

—Китаплар.

—Китап?! Ә-ә,—дип исенә төшерде төрекмән.—Без аларны Марвәдә күп яндырдык.—Иелеп, бәкам тышлы китапларның берсен кулына алып ачты.—Исе тәмле! Ә нинди шайтан нәрсәсе соң бу? Таяклар, сызык-мызык, почмак, түгәрәкләр. Ни турыда бу китап?—Аннары Гомәрдән сорады:—Җеннәр чакыра торган сихерләрме?

—Эвклид геометриясе ул.

—Кем соң ул Эвклид, мөселманмы?

—Юк,—диде Гомәр, Әхмәтнең үле гәүдәсенә карамаска тырышып.—Ул бик күптән яшәгән, пәйгамбәр туганчы ук әле. Византия кешесе булган ул.

—Ә син шул чүп-чарны укыйсыңмы?

—Укыйм. Әмма чүп-чар түгел ул. Дөньяда иң акыллы китапларның берсе.

—Әй син, көчек, каһәр төшкере мәҗүси язмасын мактарга ничек җөрьәт итәсең?! Утка ташларга кирәк синең алласыз китабыңны! Коръән укырга кирәк.

---

[1] Сәйхун—Сырдәрья.

—Мин Коръәнне дә укыйм,—диде Гомәр, югалып калмыйча.—Яттан беләм мин аны!

—Бөтен Коръәннеме?—дип аптырап сорады төрекмән.—Алдыйсың.

—Мин беркайчан да алдамыйм.

—Алайса, укы аннан ни дә булса.

Гомәр, исенә төшереп, күзләрен йомды да көйләп укый башлады. Әмма һәр сүздә тотлыкты һәм аять дөрес яңгырамады. Болай ялгыш укысаң, мәдрәсәдә остаз чыбык белән сыйлар иде. Әмма юлбасар мондый нечкәлекләрдә томана, гарәп телен гомумән белми иде.

—Безнеңчә ничек була инде бу?

—«Кеше байлыгына күз атма, ул байлык дөнья тереклегенең зиннәте» . Егерменче сүрә, йөз дә утыз беренче аять.

—Э-э...—төрекмәннең маңгаена тир бәреп чыкты. Аякларының кинәт хәлсезләнүен тоеп, чүгәләде. Аны иң гаҗәпләндергәне агарып калган малай укыган аятьнең мәгънәсеннән бигрәк малай үзе, аның кыюлыгы, хәтере һәм зирәклеге иде.

Малайдан чыккан гыйлемлелек яктысы көчсез генә булса да юлбасарның кара күзләрендә чагылды. Һәм, күрәсең, әлеге яктылыкның түзеп тора алмаслык кечкенә генә нуры аның миенә үтеп керде дә анда буталыш тудырды. Аның күнелендә нидер булды, анда нидер чак-чак кына ачылды. Ул сугыша белә. Ул сөнге һөҗүмен кире кайтара ала. Әмма сүз һөҗүмен ничек җинәргә белми иде.

—Бу китапларның барысын да укыдыңмы?

—Укыганнары өйдә калды. Боларын яңа башладым гына әле.

—Читенме соң?—дип сорады төрекмән балаларча беркатлылык белән.

—Нәрсә?

—Ни... укырга өйрәнү?

—Бер дә читен түгел.

—Һм... Исемең кем синең?

—Гомәр.

—Ә мин—Ораз. Бәлкем син кайчан да булса бөек кеше булырсың, ә?

—Ходай кушса,—дип ялагайланыбрак әйтте Ибраһим, котылуга булган иң кечкенә генә өметне дә кулдан ычкындырмаска тырышып. Аның һәр тамыры менә-менә өзелергә торган кыл сыман киеренке чыңлый иде.

—Ходай, Ходай…—дип уйчан гына авыр сулап куйды төрекмән.—Анда ничек әйтелгән дисең әле: «Күз атма»мы? Ул читкәрәк төзеп куелган капчык, төен һәм чүлмәкләргә тонык кына караш ташлады да кинәт, үзендәге нәрсәнедер җиңәргә тырышып, әмма җиңә алмыйча, үкереп җибәрде: «Йөрисез шушындый вакытта! Өегездә генә утырсагыз ни булган, йөз динар да өч фельс?! Гомәр дус, әниеңне минем чатырга, әтиең белән синең үзеңне һәм куркак хезмәтчеләрегезне базарга озатасы, атларыгызны тартып аласы иде дә... Йә, сыпырт әле моннан яхшы чакта! Авырмаган булсам... Алыгыз китапларыгыз белән бу нәрсәләрегезне. Әй!—дип кычкырды ул дусларына.—Бөтенесен кире төягез! Бер капчык ашлыкны алып калыгыз.—Ул Гомәрнең чиста күзләренә карады, күнелсез генә аңа күз кысты.—Зур кеше булгач, минем турыда онытма. Хәтереңдә тот: Тугрылбәк патша белән бер нәселдән булган кынык кавеменнән Ораз! Ә сезнең,—ул Ибраһим хезмәтчеләренә борылды,—саубуллашу хөрмәтенә арт сабагыгызны укытырга иде дә... Йә, ярый инде. Юкка ашатасың син бу әрәмтамакларны?!—диде ул остага.

—Нишлисең инде, әфәндем! Һөнәрле кешеләр. Тыныч халык.

—Тыныч халык…—Төрекмәннең күз карашы аның биленә төште.—Кылычыңны чиш, монда бир. Сиңа кирәге юк аның.

* * *

Күнелсезлекләр күнелсезлекләр белән, тик тау кояшы, һавасы, тау чишмәләрендә коену шулай да Гомәр өчен файдалы булды. Өйгә ул ныгып, үсеп, каралып кайтты. Шәһәр шау-шуын, ыгы-зыгысын сагынган иде, әтисеннән тәнкә алып, беренче көнне үк йөрергә чыгып китте. Нишапурда кырык мәхәллә бар, бөтенесен дә урап чыгасы килә. Әмма иң элек—базарга!

Инде капкадан кергәндә үк ул сорнайның чакырулы әче тавышын, барабан дөбердәвен һәм таныш, татлы балдай тавышны ишетте. Улмы? Йөрәк еш-еш тибә, баш шаулый башлады. Ялгышуыннан куркып, ул үҗәтлек белән төркем арасына кысылды һәм келәмдә үзенең күптәнге яшерен мәхәббәтен күрде.

Иягендәге бәләкәй генә яра—әнә шул күз яшьләрен чыгарганчы әсәрләндерә Гомәрне! Гөлмохтар! Сәйәр җырчы-музыкантлар гаиләсе кызы. Әллә көрдләр, әллә сәлҗүкләр, ә чыны чегәннәрдер әле. Алар Нишапурга еш килеп чыгалар, базарда тамаша оештыралар: башаркан алга-артка мәтәлчек аталар, бер-берсе аша сикерәләр, аякларын өскә күтәреп, кулларында йөриләр, төрле мәзәк-әкәмәт белән халыкны көлдерәләр, җырлыйлар-бииләр һәм, әлбәттә инде, ал иренле, кара күзле, алтынсу-кучкыл йөзле Гөлмохтар барысына караганда да яхшырак җырлый.

Тавышы нәкъ менә җиз инде—көчле, яңгыравык. Гомәргә ул әкияттәге чибәр булып тоела, бу кызны еш кына төшләрендә күрә. Их, аның белән бергә китәсе иде дә, базар-ярминкәләрдә бергә йөреп, кешеләрнең исен китерәсе иде!

—Бәндә нәрсә хакына дустын ташлап китә ала?—дип аларда урнашкан гадәт буенча тамаша соңында үгет-нәсихәтен башлады төркем башлыгы-карт, халыкка мөрәҗәгать итеп. Һәм, бу башваткычка беркемнең дә шундук җавап таба алмаячагын белеп, үзе үк әйтте:—Гаилә хакына.

Һәм дәвам иттерде:

—Ә гаиләсен? Авылы хакына. Ә авылын? Иле хакына. Ә илен?

—Аллаһы хакына,—дип кычкырды кайсыдыр бер диндары. Әмма карт, аны сынап, юри бераз көтеп:

—Үзе хакына!—диде.

Тамаша бетте. Сакаллы башлык, җиз савыт тотып, үзен әйләндереп алган кешеләр рәтеннән китте. Тәнкәләр чыны ишетелде. Гомәр чын күңеленнән үзенекен салды. Ул Гөлмохтардан күзен алмады, әмма тегесе ана хет бер борылып карасын! Ул тәэсирләнгән тамашачыларга илтифатсыз, әйтерсең лә, ялгыш, үзе дә сизмәстән, өстеннән бурычын төшерер өчен генә карап елмайды да чатырга кереп югалды.

Гомәрнең тәкатьсез төстә, орлык чүпләргә ашкынган әтәч төсле, чатырга керәсе килде. Һәм түзмәде, ишек урынына калган пәрдәне аз гына ачты. Кулларын тезләренә куеп, башын кулларына салып, Гөлмохтар идәндә утыра иде. Гомәр катып калды. Үз-үзен белештермичә, ул кинәт авыр итеп сулап куйды. Гөлмохтар башын күтәрде, сискәнеп китте һәм:

—Рой!—дип кычкырып җибәрде.

Гомәрнең яланаяклары шундук җирдән күтәрелде. Көчле яшь егет, малайның якасыннан алып:

—Ни кирәк сиңа? Югал!—дип пышылдады.

Гомәр биш-алты адым ераклыкка канауга барып төште, кемнендер шаркылдап көлүен, кемнеңдер:

—Нидер чәлдерергә йөридер...—дигәнен ишетте.

Күз яшьләренә тыгылып, оятка калып кайтты Гомәр өенә. «Чәлдерергә йөридер!» Җир ярылса, җир тишегенә кереп кит! Коточкыч! Каһәр төшкере, Рой! Кемдер, сикереп, синең муеныңны сындырсын иде. Мескен йолкыш-

кәмитчеләр! Ахмаклар! Караңгы гына төшсен әле, базарга кереп, эт яламас чатырыгызны яндырмасаммы?!

Өч көн бармады ул базарга. Кирәкми! Кирәге юк ана тинтәк Гөлмохтарның! Исең киткән икән. Әллә кем, имеш. Әмма дүртенче көнне түзмәде, тагын бер генә тапкыр күрү нияте белән базарга китте. Тик тегеләренең, кем әйтмешли, эзләре суынган иде инде.

—Киттеләр, балакаем. Кичәгенәк. Чатырларын, бөтен нәрсәләрен төяделәр дә—әллүр! Кайгырма, тагын килерләр. Болары булмаса, башкалары.

—Башкалары?..

Һәм бервакыт, иртә язда, ишегалдында нидер эшләп йөргәндә, ачык кече капкадан:

—Ярдәм итегезче!—дигән мескен тавыш ишетте ул. Ертык күлмәк, пычрак озын ыштан кигән (кая матур киемнәре?) Гөлмохтар мескен кыяфәттә капка янында басып тора һәм хәлсез, кызганыч тавыш белән каядыр бушлыкка:

—Бер телем икмәк бирегезче...—дип пышылдый иде.

Гомәр үзен акылдан шашкандай хис итте. Үз-үзен белештермичә аш бүлмәсенә атылып керде. Аллага шөкер, ипиләре күп иде аларның. Әмма, дөньяда иң саран кешеләр Хорасанда яши, дип белми әйтмәгәннәр шул.

—Кемгә ул ипи?—дип кычкырды әнисе.

Гомәр кыз ягына ымлады. Иреннәре дерелдәде. Менә-менә елап җибәрер кебек иде.

—Бирмә! Күбәйделәр алар. Бөтенесен туйдырып бетерә алмассың.

Гөлмохтар авыр сулады һәм яланаяк килеш язгы пычракны ерып китеп барды. Кайдадыр урамда аның:

—Ярдәм итегезче...—дигән гаҗәеп тавышы тагын ишетелде.

Ә шулай да, әнисе читкә борылган җайлы вакытны табып, Гомәр кайнар көлчәне куенына кыстырды да урамга атылды. Гөлмохтар куркып калды. Ни кирәк яшел күзле бу малайга? Ходай күрсәтмәсен—букчасын ала күрмәсен тагын. Анысын алмаса, тик торганда кыйнап китүе дә бар. Ул мескен букчасын кысыбрак тотты да, янга борылып, курка-курка каранып, тиз-тиз атлап китте.

Ни булган аңа? Ата-анасы кая киткән? Ходай белсен. Алсу иреннәре күгәргән-агарган. Кайчандыр янып торган шат күзләре тоныкланып, гомерлеккә төссезләнеп калган.

Көлчә Гомәрнең күкрәген көйдерә. Ул кулын куенына тыкты. Тик җөрьәт итмәде. Юк! Кыюсызлык туктатты аны. Әйтерсең лә, бөтен кеше күз алдында ниндидер ярамаган бер эш эшләргә теләде. Оялып кына түшеннән ал да суз. Кемгә? Анамы? Мөмкин түгел эш бу. Оятсызлык. Гомәр аны башка бер тапкыр да күрмәде, әмма гомере буе хәтерендә калдырды. Тормыш дигәнең әкренләп ана да кырын карый башлады. Күз яшьләренә тыгылып өенә кайтканда, ул көлчәне башка хәерчегә—мескен бер карчыкка бирде.

Дулкын юеш комга ябырыла да алдагы дулкыннар ясаган бизәкне юкка чыгара һәм үзе үк башка, элеккесенә охшамаган яңа бизәк төшерә. Иске ярага ятып, яңа яра аның төсен үзгәртә.

Югалтуларны кире кайтарыр чара юк! Һәрберсе йөрәктән үзенекен, кабатланмасны алып китә. Табыш та, югалтуны тулыландырмастан, йөрәктә үз урынын, бәлкем әле мөһимрәк тә урынны ал. Әмма югалту—бөтенләй үк мәхрүм калу түгел. Һәрбер югалту күңелдә эз калдыра. Һәм яңа эз, аның өстенә ятып, башка берсен, өченчесен тудыра. Тормыш тәҗрибәсе әнә шулай арта бара.

Бәлхтән яңа мөгаллим, шәех Нәзир Мөхәммәт Мансур килде. Тыныч холыклы һәм сүзгә саран, әмма җор телле ул. Искиткеч акыллы. Бүгеннән башлап Гомәргә аның гаҗәеп тирән акылы хәзинәсеннән тарихка күмелгән сөякләрне казып алырга, тел белеме энҗе бөртекләрен өйрәнергә, мөселман

кануннары зирәклекләрен әләктереп калырга тырышырга туры киләчәк.

Мәдрәсәдә Гомәргә, әтисенен һөнәрен искә алып, Чатырчы дигән кушамат тактылар («хәйям» гарәпчә чатыр дигәнне аңлата). Һәм бу сүз аңа бөтен гомеренә берегеп калды.

Улын укытырга акча кызганмыйча, Ибраһим оста ни нәрсәгә ирешергә теләде соң?

Ул аны хокук белгече итәргә теләде.

Ул аны дин белгече итәргә омтылды.

Ул аны мөхтәрәм дин әһелләре арасында күрергә хыялланды.

Әмма ул аның астрология белән шөгыльләнүенә дә каршы килмәде. Аллам сакласын, йолдыз белгечләре—абруйлы кешеләр. Кайчан да булса Гомәрнең нинди дә булса вилаятнең[1] (патшаныкы турында уйлау да гөнаһ) бай сараена эләгүе ихтимал. Беркемгә билгесез чатырчы, күр дә тор, көнче күршеләренең күз алдында күккә күтәрелер әле... Алгебра, геометрияме? Ходаем, үзең ярлыка! Ярый соң, мөгаен, алары да файдалыдыр. Мирас турындагы буталчык бәхәсләр, җир кишәрлекләрен бүлү вакытында, салымнарны, бурычларны һәм башка түләүләрне исәпләгәндә, зур биналар һәм каналлар төзегәндә, мөгаен, аларсыз да булмыйдыр. Тик... монысы инде аның акылына сыешып бетми, артык томанлылар. Кирәкләре бар иде! Акчаң булса, аны алгебрасыз да исәпләп, тотып була. Һәм тагын... табигать фәннәре. Алары ниемә кирәк инде? Ходаем, үзең ярлыка. Икмәк икмәк инде ул, таш—таш. Шулай да әйтегез әле, зинһар, нишләп шундый мөхтәрәм аталардан шундый тинтәк уллар туа? Гомәр барыннан да бигрәк математика белән, җисемнәрнең ачык һәм яшерен сыйфатлары белән кызыксына.

Тарих, хокук, тел белеме?

Их, хөрмәтле әти кеше! Аларны Гомәр көч сарыф итмичә дә үзләштерә. Алар үзләреннән-үзләре аңлашыла. Әйтерсең лә, алар аның миендә туган чагында ук булган да, менә хәзер кирәкле китапка күз төшерүең була—шундук хәтердә яңаралар. Аның каравы ак таплы гадәти соры ташта күпме сер бар! Яисә язын шул ташларны тишеп чыккан кечкенә бер үсентедә?! Аз гына уйласаң, әлеге алгебра күпме серләрне ача ала! Соңыннан ул «Исбатлаулар турында трактат»ында коры гына болай дип язачак: «Алгебра һәм альмукабала сәнгате—төп асылын абсолют сан һәм үлчәм тәшкил итүче фәнни сәнгать ул».

Балачагында (балачагында гынамы соң—гомере буе!) Гомәрне алгебраның тышкы ягы, саны түгел, ә эчке, поэтик-сихри асылы җәлеп итте, сихерләде. Аңа иң гади формула да куәтле җеннәр көтүен буйсындырырга сәләтле тылсымлы әфсен яки Архимедның Җирне кучәреннән кузгата алырлык таяну ноктасы булып тоелды.

Әйе, фән—сәнгать. Сәнгать—фән. Аларның нигезе бер—иҗади фикерләү. Мәдрәсәдәге кайбер уҗым бозаулары кебек аларны капма-каршы кую аның башына да килмәде. Геометрия белән дә шул ук хәл.

Кушылган ике дивар—ян һәм арт дивар—һәм ерактагы аз гына чыгып торган керу урынын күргәч, бөтен бина күренешен күз алдына китереп була. Әйтерсең, аны үтәли күрәсең. Бөтен дөньяны ачык сызыклар призмасы аша күрде ул. Мәсәлән, бакчаны әйләндереп алган балчык диварның ничек кирәк алай гына сыланган почмагын күрсә, ачуы килә, җаны әрни—почмак түгел, ә нинди дер кәкре-бөкре, шыксыз бер нәрсә. Геометрик нәфислекне боза торган һәр нәрсә аңа гарип, күңел кайтаргыч булып тоела, җанын әрнетә.

Әмма анда сәнгатьчә тою сиземлелеге дә бар. Ул шәрә, кәкре ботаклы, ямьсез булып кәкрәйгән һәм тырпайган агачның диварларның, капка, гөмбәз, манараларның дөрес һәм тигез өлеләренә матур булып кушыла алуларын күрергә сәләтле.

[1] Вилаят—өлкә.

Ә инде йолдызларга һәм планеталарга килгәндә, жиде яшьтән үк беренче караудан ук аларның теләсә кайсысын таба ул.

—Син үзеңне алар арасында үз өеңдәге бакчачы кебек хис итәсең,—диде шәех Нәзир, аның бу эшен хуплап.

Астролябия—искитмәле инструмент! Карышмый һәм төгәл эшли. Аны хатын-кыз уйлап табуына ышанмассың да! Әйе, грек хатыны Ипатия чын мәгънәсендә табигать могжизасы була. Берүзе мең иргә торырлык! Нәкъ шуның өчен үтермәделәр микән әле аны?!

Сүз дә юк, шәехнең башка сәләтле шәкертләре дә житәрлек, әмма ул Гомәргә генә ышана. Остаз үзе дә мөселман кануннарын өйрәнергә бик үк атлыгып тормый (бер тапкыр бирелгән бит инде, күпме генә казынма—яңаны аз гына да таба алмыйсың), иртәнгә чаклы йолдызларга карап утырырга әзер. Ул Гомәрне астролябия, квадрат белән эшләргә, кояшның биеклеген билгеләргә, градусларны исәпләп чыгарырга, таблицалар белән эш итәргә өйрәтте. Изге тарих, дин һәм астрология белән шөгыльләнәләр дип исәпләнсәләр дә, математика һәм күк жисемнәре турындагы житди фәнгә бирелсәләр, сәер мөгаллим белән сәер шәкерт ашау-эчүләрен онытталар. Әйе, исәп-хисап алып барыла торган такталарга сибү өчен юл тузаны аз тотылмады.

Дөрес, йолдызлар буенча фаразлауга да игътибар бирелде. Кайчандыр кирәк булачак! Шушы безнең гасырда ук. Беруни да әйткән бит: «Астроном исеме алу өчен, телисеңме, юкмы, астрологияне дә белергә кирәк»,—дигән.

Мисалга Үгезбозау йолдызлыгыннан кызгылтрак Альдебаран йолдызын алыйк. Үзенең табигате буенча ул Миррихка (Марска) туганрак, тискәре йогынты ясый. Саксызлык күрсәтеп, әлеге мәкерле йолдыз астында туган бичаракай гөнаһ эшләү түгел, як-ягына карамыйча түкерергә дә курыксын! Ә юкса бит ниндидер бер ташландык планетада мәгънәсез яшәп ятучы ике аяклы бөжәкләрдә йолдызларның ни эше бар инде?!

...Йолдызлы төннәрдә мәдрәсә түбәсендә куркыныч та, кызык та. Күк йөзе кристаллар сибелгән гаять зур кара-зәңгәр пыяланы хәтерләтә. Йолдызлар һәрвакыт хәрәкәтсез Котып йолдыз тирәли сәгать саен сулдан уңга, астан өскә, уңнан сулга, өстән аска хәрәкәтләнәләр. Үтә күренмәле салкын төпсезлектә югалып калган Гомәр калтырана. Каян һәм кая баралар бу йолдызлар? Ни өчен? Алар артында ниләр бар? Йолдызлар кәкре сызыктан чиксезлеккә таба баралар һәм элеккечә үк якты жемелдиләр. Әмма аларны барыбер тотып булмаганлыктан, йолдызлар турында онытып, Гомәр жирдә кеше башкара торган эшләр белән шөгыльләнергә булды. Моңа аны эчке халәте мәжбүр итте. Син ничаклы гына укымышлы һәм акыллы булма, хайвани хисләреннән барыбер беркая да китә алмыйсың.

Ундүрт яшендә танымаслык булып үзгәрде ул. Жилкәләре киңәйде, колга кебек озынайды. Ул инде бөтенләй башка Гомәр иде. Түзеп тора алмаслык оятсыз, рәхимсез сугыш чукмары һәм хәтта ахмаклык та бар үзендә. Егет күрше кызларына, бигрәк тә өлкәнрәк хатыннарга, аларның корсак һәм билләренә күз ата башлады. Битендә кызгылт тимгелләр барлыкка килде.

Эссе көннәрнең берсендә ул, үзенә урын таба алмыйча, әтисенең остаханәсенә керде. Алачык тәбәнәк, кысан бүлемтекләрдән тора, аларда өлкән яшьтәге ирләр, карчыклар, ә аерым бүлмәләрдә яшь хатыннар һәм кызлар эшли. Биредә буйлы-буйлы, ак, кара, жәй өчен—киже-мамыктан көрдләр, гарәп, бәлжүк, чегәннәр өчен—йоннан, күренекле кешеләр өчен хәтта ефәктән чатырлар тегәләр.

Ул нишләптер хатын-кызлар ягына керде. Эшләүчеләр шундук йөзләрен капладылар. Тик егерме жиде яшьләрдәге тол хатын Фәйрүзә генә ачык йөз белән калды. Ул моңа хокуклы: әле кыз вакытында, Фәйрүзә хужаның улын кулларында күтәреп йөрткән иде.

Анар кебек кызгылт-алсу йөз, искитмәле кыйгач кара каш, өске иренендә кара йон бөртекләре. Ул, шундук шатланып:

—Гомәр!—дип кычкырды.—Бездә күптәннән булганың юк иде. Бөтенләй укуга бирелдең син! Кара инде, ничек үскәнсең, чын егет булгансың!

Ана кара-коңгырт, акыллы күзләре белән карады да, малайның тиле, комсыз, таләпчән туп-туры карашын күреп, кызарып, башын иде. Калын иреннәре дерелдәп, тулы күкрәге селкенеп куйды. Күрәсең, иртәдән бирле аякларын бөкләп, иске киез астындагы тигезсез җир идән катылыгын тоеп утыру туйдыргандыр.

Булды! Инде алар болай гына аерыла алмыйлар. Нидер көтеп, ул аның тирәсендә чуалды, алар шундук сүзсез килештеләр. Фәйрүзәнең куллары калтырый. Зур энә белән бармагына калады.

—Кала хакиме атлас чатыр тегәргә кушкан иде,—диде ул әкрен генә, сәер уйчанлык белән һәм үз-үзен тыңлагандай. Аннары ягымлы пышылдауга күчте.—Бүген иртән без аны тегеп бетердек.—Аннары кинәт карлыккан тавыш белән:—Күрәсең киләме?—дип сорады.—Чоланда ул.

Тәкате калмаган үсмер:

—Тизрәк, тизрәк!—диде.

Менә шулай. Йолдызлар алар җирдә дә бар. Эзли белсәң, әлбәттә.

Фәйрүзәнең теш эзләре Гомәрнең кулбашында озак төзәлмәде, аның караве йөрәктә яралар калмады. Яратты ул Фәйрүзәне. Үзенчә яратты. Ана үзенчә тугрылыклы да булды. Ягъни башбирмәс һәм тәкәббер кыяфәттә гомерлеккә ташлап чыгып китте дә, озак та үтми, гаепле кыяфәттә кире килде.

Уналты яшендә Гомәр инде чын ир иде. Өстәвенә яхшы табиб, пешекче һәм музыкант. Астрономиянеме? Беләбез аны. Математикамы? Анысына да теш үтә. Көнчыгыш фәлсәфәсе? Таныш ул безгә. Шулай ук Коръән дә, әлбәттә.

Шактый шигъри ул Коръән. Аның теле ритмлы, көйле, әмма үксүле, күңелне әллә нишләтә. Коръәннең аятьләре ярсулы, куркыта. Гомәр күңеленә шагыйрьләр шагыйре Рудаки шигырьләре, бигрәк тә аның ялкынлы дүртьюллыклары якын.

Мәдрәсә шәкертләре каяндыр җәтмә таптылар һәм шәһәр читендәге елгада балык сөзәргә, бер үк вакытта чинар агачы астында мәҗлес оештырырга сүз куештылар.

Гомәрне дә үзләре белән барырга күндерделәр. Кызыгып, ул алар белән бер-ике тапкыр барган иде инде. Хәтта шәраб та эчте, ә аннары авыру карт кебек ни үле, ни тере йөрде. Аның ашказаны шәрабне кабул итми. Ә бу юлы ул җиңел генә риза булды. Ә ник карышырга?! Бар да әйбәт—өйдә дә, мәдрәсәдә дә. Саулыгы менә дигән. Ул инде зур, чибәр егет. Һәр яңа көн аңа уңыш алып килә.

Күңел ачу турындагы мавыктыргыч гәп уңаена хуш исле кыяр кетердәтеп, яшьләр төркеме шәһәр капкасына якынлашты. Аларның күзләрендә иртәләгән җәй күге төсе чагыла иде.

Әмма капка янында Гомәргә кемдер дәште:

—Әй, кайда югалып йөрисең син?—Аның янына күрше малае килде.—Өеңә йөгер, әниеңә әллә ни булган анда.

—Нәрсә?—Гомәргә эсселе-суыклы булып китте.

Һәм тагын теге вакытта, Фирүзгән юлында Әхмәт һәлак булгандагы кебек, башы сәер шаулый, аяклары калтырый, җаны әрни башлады. Ул өеннән өченче көн үк киткән иде, һәм аның күз алдына яшел үләндәге кызыл күлдәвек эчендә хихахайлап көлеп торучы кара шайтан пәйда булды.

—Акылыннан шашкан бугай. Чәчләрен йолка. Битен тырнап бетергән. Кулларын тешләгән, күлмәген ерткалаган. Үзе һаман саен «Икта» дип кычкыра.

—Икта?—дип очкылык тотып сорады Гомәр. Ул әле генә кыяр тешләп капкан иде, авызындагы шул таш кебек әче кисәкне чәйни дә, йота да алмыйча басып торды.—Каян?

—Өенә йөгер, шунда белерсен.

Хуш, чинар астындагы күңелле ял урыны! Гомәр кыяр кисәген юл тузанына ташлады, авызындагы әче тәмне түкерде һәм, дусларына берни дә әйтмичә, хәтта саубуллашып та тормастан, мескен кыяфәттә өенә йөгерде.

Зур ишегалды капкасы янында җыелып торган күршеләрен күрде. Алар зәһәрлек белән пышылдашалар иде. Аны күргәч, тындылар. Мәет озаткандагы кебек. Гомәрнең аркасыннан салкын калтырану йөгереп үтте. Кемнендер кулында сеңлесе акырып елый. Бер ел элек аның сеңлесе туды, һәм, Гомәрнең үтенечен искә алып, аңа Гөлмохтар дигән исем куштылар. Кыз аңа үрелде. Гомәр аны кулына алды, күкрәгенә кысты һәм алпан-тилпән өйгә таба атлады.

—Бәхетсез баш, кая олактың? Күрәсең, чынлап та сукбайга әверелгәнсең бугай син.—Чәче-башы тузган, кара янган, борыны һәм йөзе тырналып беткән, әйтерсең лә, әле генә капка төбендәге төркем кыйнаган. Әнисе аны каргады, усал караш белән каршылады.—Әтиең янына бар, остаханәдә ул. Кызым, кил мина. Кил, балам, курыкма. Мин тынычландым инде.

Ишегалды ат тизәге, печән калдыклары белән пычранып беткән. Мондый хәлнең аларда гомердә дә булганы юк иде. Хорасанлылар—пөхтә халык. Улын күреп, Ибраһим урыныннан торды, аңа таба килә башлады һәм, кыенсынып кына мышкылдап, башын аның иңбашына куйды.

—Әти, ни булды?

Ибраһим якында дәшми-нитми торган эшчеләргә куркып карады.

—Аһ, улыкаем! Гөнаһларыбыз өчен Аллаһы каргады. Остаханәне... иктага алалар.

Гомәр белә: икта—яхшы хезмәте өчен кемнең дә булса бирәүнең хакимияттән алган бүләге. Иктага гадәттә чәчүлек җирләрен бирәләр, һәм аның хуҗасы—иктидар—элек җәмәгать казнага керткән акчаны яки азыктөлекне үз файдасына ала. Әмма иктага төрле сәүдә һәм һөнәр биналарыннан—мунча, тегермән, базардагы кибеттән, кәрван-сарайлардан, остаханәләрдән һәм хәтта тулы бер каладан яки вилаяттән керә торган керемнәр дә бирелә. Күрсәткән хезмәткә карап.

—Иктадар бит... ул үзе.—Ибраһим куркып тагын тирә-ягына каранды,—ул... үзе теләгәнчә эшли. Безнең иктадар—күрекле сәлҗүк түрәсе. Ничек әле? Рыс... Рысбәк. Иртәнге якта бер төркем башки.. кыю сугышчылары белән килде. Ходаем, ярлыка! Мина камчысы белән сукты. «Өйне бушатыгыз!»—дип таләп итә. Янәсе, карт анасын һәм калада яшәргә теләгән туган-тумачасын безнең йортка кертмәкче. Ә без дүртәүләп остаханә чоланында яшәргә тиеш булабыз.

Гомәр иренен тешләде: менә ничек?! Сократ, Платон һәм Аристотельнең өчесен бергә кушып, алардан өч тапкыр акыллырак булсаң да, йолдызлар турында барысын да белү генә түгел, аларны йөз тапкыр әйләнеп кайтсаң да, Веганы үз борыны астында ялтыраган манкасыннан аера белмәгән бер пычрак йолкыш, барыбер өенә бәреп кереп, сине аннан куып чыгарырга хаклы.

—Йә Хода!—дип авыр сулады Ибраһим.—Өстәвенә әле ул иртәнгә мең алтын әзерләп куярга куша. Каян алыйм мин аны? Мин кем—бай сәүдәгәрме, йә булмаса кенәзме? Алла кушса, биш йөз динар җыярмын, ә мөнне—юк. Аллаһының рөхсәте бар икән—башымны киссен. Берни эшләп тә булмый, улым, язмыш шундыйдыр инде, түзәргә кирәк.

—Бәлкем әле башыңны кистерер өчен түмәр дә әзерләп куярсың?—диде Гомәр, аның куркаклыгына, хайваннарча күндәмлегенә гаҗәпләнеп.—Балтасын да алдан кайрап бирерсең?!

—Аларның балталары үзләренеке...

—Шәһәр башлыгына бар, ярдәм сора.

—Бардым инде, улым, бардым!—Баш очындагы элмәккә карагандай, Ибраһим, коты очып, күзләрен акайтты.—Баш казый сәлҗуккә минем остаханәне шунын коткысы буенча атаган да инде. Рысбәкнең солтан мөһере сугылган кәгазе бар. Безне әнә шул каһәр суккыры кәгазьгә язганнар. Көнчеллек ниләр генә эшләтми?!

—Ничә елга?

—Ун.

Әйе, эшләр хөрти. Монда чәченне йолкып, күлмәгенне ертып кына калмассын, ачуыннан йөрәгенә чаклы күкрәгенне ярып ташларсын. Иктавакытлыча бүләк, кулында хакимият барда комсыз иктадар остаханәдән мөмкин булганның барысын да сыгып калырга тырышачак. Һәм төрле ысуллар белән. Ун елда ул табышлы остаханәне бөлгенлеккә төшерәчәк һәм Ибраһимнын гаиләсен кабергә кертәчәк.

Гомәр күнелсезләнеп тирә-ягына карады. Эшчеләр күзендә—аптыраш. Ибраһим, әлбәттә, саран хужа, шулай да ул—үз кеше. Чит кешедән—сәлҗуктән—яхшырак.

—...Ә Фәйрүзә кая?—дип борчылып сорады Гомәр, аны башкалар арасында күрмәгәч.

—Алып китте, иктадар алып китте!—Ибраһим кулын селтәде.—Беренче генә көн әле, ә шулай да башланды инде...

—Ah!—Үзенекенә охшамаган ниндидер чыелдык тавыш. Гомәрнең аяклары тынламас булды. Кинәт хәле бетеп, ул остаханә баганасына тотынды һәм, анын тупас ботагына башын бәреп, аска таба шуышты. Бәрелгән баш чүмеченнән муенга кан ага башлады. Фәйрүзә югалуга, анын өчен нәрсәдер юкка чыкты.

—Улым,—диде Ибраһим авыр гына,—мин сине укытыр өчен күп акча тоттым. Хәзер инде син үз-үзенә ярдәм итәргә тиеш. Үзенә һәм мина. Хезмәткә керү турында уйларга вакыт түгел микән сина?

Ә Гомәрнен үз кайгысы:

—Ул чоланга без барыбыз да ничек сыярбыз икән?—Фәйрүзә белән ул анда ничә тапкыр булды сон? Юк, ул анда яши алмый.

—Чоланда яшәү яшәү түгел инде, әлбәттә,—дип җөпләде анын сүзен Ибраһим.—Әниен мыгырдый, сенелен шыншый. Анда ничек укымак һәм язмак кирәк! Менә нәрсә. Мәдрәсә хөҗрәсенә күч син. Юк, уйлый күрмә, мин сине кумыйм, әмма анда сина унайлырак булачак. Бераз акча бирермен, ярты елга алдан түләп куй да яши бир рәхәтләнеп. Әмма безне онытма. Ризамы?

Әйе, Ибраһим аны кумый, әлбәттә. Әмма әтисенен анын белән шулай җинел аерылышуы рәнҗетә егетне. Шул ук вакытта үзен генә яшәү, үз юлынны башлау да кызыктыра.

Оясыннан очып чыгарга әзерләнгән кош баласы кебек: куркыныч та, тизрәк канатларны да ныгытасы килә. Алда—тулы бер дөнья.

—Рәхмәт!—Гомәрнен күзләре яшьләнде.—Риза. Әйбәт булачак бу. Әмма син дә мине бәла килгәч сездән кача дип уйлама.

—Их, улым! Мин барын да анлыйм. Мин кем? Ярлы һәм томана бер чатырчы. Минем кебекләр—дөнья тулы. Ә син бөтенләй башка. Бүтәннәр кебек түгел. Күрәм мин. Башыбызга бу бәла килмәсә, чыгара идем мин сине үзеннен йолдызларына. Әмма хәзер...

Алар өстенә нинди зур бәхетсезлек килгәнен урамга чыккач кына тулысынча төшенде ул. Башы катты анын. Юлда барганда Гомәр әрем әчесен тойгандай исенә төшерде:

> Имансыз бу дөньяга өмет итү—
> Ахмак кешедән акыл көтү.

Катран бине Мансур шигыре. Шагыйрь Тәбризне нигезенә кадәр җимергән җир тетрәүне сурәтли. Иминлеге, байлыгы һәм камиллеге ягыннан аңа тиң каланы бер офыктан икенчесенә кадәр эзләсәң дә табу мөмкин булмый. Һәркем үзе теләгәнне эшли: берсе Аллага, икенчесе халыкка хезмәт итә. Өченчесе дан артыннан, дүртенчесе байлык артыннан куа, һәм бер мизгелдә җир ярыла, елгалар ярларыннан чыга, түбән урыннар югары күтәрелә, таулар ишелә. Икенче бер кешегә: «Елама!»—дип әйтерлек бер генә кеше дә калмый.

Ибраһим гаиләсе белән дә Тәбриздә җир тетрәгән кебек хәл булды.

Рухы сынган, канаты каерылган Гомәр кичен шәраб сорап танышларына үзе барды. Күп эчте. Начар йоклады. Иртән үзен кыйналган кебек хис итте.

Ни үле, ни тере хәлендә ул шәех Нәзир янына китте. Ә эчендә, әйтерсең лә, ачык яра: кайнар күмер кебек яндыра. Иске келәмгә утырып, дөресрәге, хәлсез егылып, башын тезләренә куйды һәм, телен көчкә әйләндереп, тотлыга-тотлыга, остазына өйдәге хәлләрне сөйләде. Хәзер ул үз көнен үзе күрергә тиеш.

—Әйе-е!—дип авыр сулады шәех.—Безне игелекле ислам илендә тагын ниләр көтә икән? Улым!—диде ул, хөҗрә буйлап йөренеп.—Син иң җинел фәнне—табигать белемен үзләштердең. Уртача фәнне—математиканы да һәм иң югары фәнне—метафизиканы да. Син бүгенге гыйлемнең барлык өлкәләреннән дә хәбәрдар. Син аларны хәзер кайда файдалана аласың? Мөгаллимлеккә бар. Мәктәптә җиде яшьлек балаларны теләсә кем укырга, язарга, санарга өйрәтә ала. Мин сина хезмәт урыны бирсеннәр дип әйтермен. Баюың байый алмассың, әмма иписез дә утырмассың. Минем киңәшне тот. Дөньялар рәтләнгәнчегә кадәр. Бәлкем,—ул күнелсез генә елмаеп куйды,—кайчан да булса Нишапурның баш казые булырсың да үзең теләгәнне иктага алырсың.

—Юк.—Гомәр иелгән башын какты. Аның күңеле болгана иде.—Миннән андый кеше чыкмас...

Укытырга? Котылу бу! Әмма кайгы һәм махмыр баскан Гомәр шатлану сәләтен югалткан иде. Бары тик: «Ярар»,—гына диде дә карашын караңгы почмакка текәде. Талчыккан йөзендә—битарафлык, юеш күзләрендә—сүрәнлек, корыган иреннәре әкрен генә нидер пышылдый. Әйтерсең лә, онытылган доганы исенә төшерә.

Ул авыр сулады һәм тонык тавыш белән әйтте:

Шәкерт булдык, остазга чыктык,
Белем алдык, шәкертләр күпме таптык.

—Карале, син бит шагыйрь икәнсен!—дип гаҗәпләнеп әйтте шәех.—Искитмәле. Туктале!—Һәм ул өченче юлны әйтте:

Ирештек нәрсәгә, җирдән яралып?

Гомәр күзләрен дә күтәрмичә, үз-үзен белештерми җавап бирде:

Черергә дип кабаттан җиргә яттык.[1]

Акрын кыймылдаучы малайлардан көлгән дүртьюллыкларны санамаганда, бу аның беренче шигыре иде.

—Кайгырма!—дип юатты шәех үзенең шәкертен.—Алла боерса, харап булмабыз.—Аннары якын итеп әйтте:—Мин дә шигырьләр язам. Тик аларны яндыра барам. Беркемгә дә укымыйм. Син дә укыма. Безнең заманда шигырь язу—хәтәр эш.

Махмырдан азрак айну өчен берничә көн кирәк булды Гомәргә. Нигә

[1] Робагыйларның кайберләре Н. Арсланов тәрҗемәсендә бирелә. (Тәрҗемәче иск.)
[2] Кебаб—киптерелгән ит.

дип үз-үзен агуларга иде инде ана? Чиркангыч. Ул әти-әнисенең хәлен белергә һәм шунда беррәттән сөтле аш һәм киптерелгән кебаб[2] ашарга дип килде. Файдасы тия, диләр.

Ана остаханәгә туп-туры урамнан, икенче капкадан керәсе калган икән. Әмма аяклары гадәт буенча аны зур ишегалдына алып килде. Авыр капканың кече капкасын ачып керсә, каршында колаклары һәм койрыгы киселгән сары зур эт тора.

Ярый әле Гомәр кулына юан кызыл таяк тоткан иде (хәзер бит ул мөгаллим, житдирәк күренергә тиеш), юкса ишегалдына тулган бүре аулаучы зур гәүдәле дала этләреннән котыла алмаган булыр иде.

Шунда ук корылган киез тирмәдән явыз чырайлы, кысык күзле кешеләр кычкыра-кычкыра йөгереп чыга башлады. Ходаем! Ул бит монда ят кеше. Үзенең туган йортында ят. Гомәр урам аша остаханәгә кереп китәргә чак өлгерде. Куып житсәләр, кыйнарлар яки үтерерләр үк иде.

Остаханәнең кече ишегалдына биналар арасындагы тар аралык илтә. Шуна күрә Гомәрне беркем дә күрмәде. Ул диварга аркасы белән терәлде, башын аска иде. Эчкәннән соң әле ныгып житмәгән гәүдәсе тирләп чыкты. Ятып хәл аласы килде.

—Гомәр.

Анын алдында—кем уйлаган—Фәйрүзә!..

—Син?—дип гажәпләнеп сорады Гомәр.

—Күргәненчә—мин.—Хырылдыклы түбән, ят тавыш.—Ахириләремне... башкаларны да... күрергә дип килдем.

Гомәр сәерсенеп Фәйрүзәгә карап торды. Өстендә шәһәр казые хатыннарыныкы кебек (Гомәр бервакыт базарда күргән иде аларны) кыйммәтле атлас күлмәк. Шулай ук һинд хушбуй исләре анкып тора. Менә ничек үзгәртә кешене эре түрәнең кәнизәге булу!

Фәйрүзә ябыккан—йөзе дә, инсәләре дә. Ә таз сөякләре кинәеп киткән кебек. Ак янагында (элек кызгылт иде)—зур миң. Каян килгән ул—Гомәр аны хәтерләми. Буянган, хәсис, матурланырга тырышкан. Күп үбешкән иреннәрендә—тиле көлемсерәү. Үпкәле көлемсерәү. Әмма иң әшәкесе—күзләр. Аларда башка ир рәхәтенең серләрен белгән хатынның өстенлеге, дөньяга мыскыллы карашы чагыла.

—Үтерәм!

Көньяк кешеләрендә була торган кара көнчеллек күкрәктә икмәк пешерә торган мичтәге ялкын кебек дөрләп, кайнар төтен белән бергә Гомәрнең башына китереп сукты, күзләрен томалады һәм иреннәрен очкан көл кебек күгелҗем күбек белән каплады. Ул котырынып таягы белән кизәнде.

Шундук ялварулы пышылдау ишетелде:

—Сук, кадерлем, кыйна! Һәм алып кит мине кая да булса, яшер. Син уйлама... канәгать булып кыланам гына мин. Бөтенесенә үч итеп, үз-үземә үч итеп. Оят мина, оят. Миннән бөтенесе йөз чөерә. Ә ни гаебем бар минем?

Кая алып китсен ул аны, кая яшерсен?!

—Күземнән югал!—диде Гомәр коры гына һәм, әти-әнисен дә күрмичә, китеп барды.

Фәйрүзә аның артыннан тавышсыз-нисез генә елап калды. Гаепләме соң ул аның алдында? Әлбәттә. Ә ни өчен? Үзе теләп түгел бит... Шулай килеп чыкты. Ә ни өчен болай түгел, шулай килеп чыкты соң? Моңа кем гаепле?

> Бу дөнья гел табышмак, бер чара юк,
> Хакимнәр фикерен аңларлык чара юк.
> Шәраб эч—пәйда булсын жирдә жәннәт,
> Ә үлгәч—йә кирәсең анда, йә юк.

Төнлә ул күңелләре күтәренке дуслары белән тагын күп итеп шәраб эчте. Шәраб күп азык сорамый, зәһәрлекне баса һәм тиз кызып китүче кешеләр өчен файдалы.

Тыныч тормыш әнә шулай юкка чыкты. Әмма кипкән күл сазлыгының тозлы ләменә күкрәк турыннан кереп батсаң, тагын да тирәнрәк түгелдер монда, дип уйлама. Бервакыт (Гомәр инде дүртенче елын укыта) мәдрәсәнең иркен ишегалдыннан үтеп барганда, ул биредә дин белемен укытучы ике галим белән очрашты.

Кулын күкрәгенә куеп, тиешенчә баш иеп, ул алар яныннан тыйнак кына үтеп китте һәм үз артында:

—Йә Хода! Бездә математиклар, табиб, табигать фәне белгечләре чебеннәр кебек күбәйде,—дигәнне ишетте.

Почмакка борылып, Гомәр диварга сыенды да игътибар белән тыңлый башлады.

—Барлык шәкертләр алар ягына күчте,—дип авыр сулады икенчесе.—Икмәк, май, инжир алып киләләр. Ә без мескеннәрдә беркемнең бернинди эше юк. Яшьләр изге китаптан йөз чөерде. Йолдызлар, саннар бир син аларга.—Бераз дәшми торгач, зәһәрлек белән дәвам иттерде:—Ә бит мөселман илендә яшибез.

Гомәр бу сөйләшүне Нәзиргә җиткерде.

—Яхшылыкка түгел бу!—Зур тәҗрибәле шәехнең йөзе караңгыланды.—Акыл тынычлыкны ярата һәм ул мәрхәмәтле. Томаналык исә сугыш тели һәм мәрхәмәтсез. Акыл үзенең асылы белән игелекле һәм үзен фәкать үзенең барлыгы белән генә раслый. Томаналык исә—сукыр. Рәхимсез вә шәфкатьсезлектән гайре тагын ни белән раслый ала ул үзен? Син түбәгә башка менмә. Астролябияңне әтиең остаханәсенә илтеп, яхшылап яшереп куй. Математика буенча китапларыңны, шулай ук Беруни һәм аеруча Әбугалисина китапларын да яшер. Актарыначаклар. Хөҗрәдә Коръәнне, кануннар җыелмасын, шуның ишеләрне калдыр. Үзең беләсең...

—Беләм.

—Һәм бер генә намазны да калдырма.

Бәлки шушы чара саклап калгандыр әле Гомәр белән шәех Нәзирнең гомерен. Берничә көн үтүгә, мәдрәсәгә сәлҗүк башкисәрләре бәреп керде. Аларны бирегә кыйммәтле, алтын белән чигелгән, даладагыча тоз-тир исенә баткан иләмсез зур гәүдәле, симез җайдак алып килде. Ул сугышчылар арасында тау аюы сыртланнар көтүендә күренеп торган кебек аерылып тора иде.

—Рысбәк!—дип кычкырды сугышчылардан берәү.—Бөтенесен дә алыйкмы?

—Бөтенесен дә түгел, ахмак!—диде карлыккан башлык.—Әйттеләр бит: дин белгечләренә тимәскә. Исемлек—баш шәехтә. Кемне алырга кирәклеген ул әйтер.

Рысбәк? Гомәр юан төрекмәнгә дошман итеп карады. Менә ул—талаучы һәм... көндәш. Һе!

Гаҗәп, нигә кирәк икән кешегә бу кадәр май? Симез тәкә, симез үгез—анысы яхшы. Аларның кыйммәте һәм бәһасе дә симезлектә. Ә бу ирдә—колач житмәс корсак, искитмәле арт сан... тьфу, карарга чирканыч! Дөя үркәчләрендәге кебек запасмы? Шулай булса икән! Кичкә кадәр ашарга бирми кара син аңа—акырып үлә башлаячак, мәхлук. Вакытлар үтү белән, суалчаннарга азык булыр өчен шушы кадәр май тупларга кеше хезмәтенең күпме жимешен эшкәртергә кирәк булды икән—бу хакта хәтта уйларга да куркыныч.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Рифә
Рахман

## АТЛАР ЧАБА

**Гомер аты алга чаба, дисең,**
**Әйтәм... җанда—атлар кешнәве...**
**Чөелдерек кадәр җитәлмичә,**
**Айдан, кешнәп, җиргә төшкәне...**

**Гомер аты алга чаба, дисең,**
**Күзләреңдә, җирле, сагышы...**
**Атны кире бору сүзләре бар,**
**Син туктатып кара язмышны!**

**Гомер аты алга чаба, дисең,**
**Минем атым чаба алдарак!**
**Син юыртмый гына барып кара,**
**Туктап хәл ал анда-сандарак.**

**Гомер «аты» алга чаба, дисең,**
**Атсыз да ул яхшы элдерә!**
**Эшне бүлеп йокыларга ят син:**
**Таң атармы дигән уй килә.**

**Көн җигәрме мине тагын диеп**
**Иртәгесен яңа эшләргә,**
**Ятабыз без, әйе, атлар кебек**
**Һәм кешнибез булыр төштә дә.**

**...Айга күпме генә җитәлмичә**
**Өзелерме гомер үзе дә**
**Татлы хыял кебек? Кайсыгызда**
**Шул хыялны сузу сүзе бар?!**

Рифә РАХМАН—*шагыйрә; «Керфекле тәрәзәләр», «Сиңа», «Мине уйла» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Үр арты үр

Үр артында үрләр бардыр ла ул,
Яр киткәнен көткән яр бардыр.
Офыкларда бездән качкан кояш—
Аргы якта туган бер таңдыр.

Үр артында үрләр бардыр ла ул...
Шуңа ымсындырган төн бардыр.
Төндә сиңа кайтмый калган ярың
Чит кочакта аткан бер таңдыр...

Яр киткәнен көткән ярлар китте,
Аларның да көтеп гомре үтте...
Офыкларга миннән качкан кояш
Кабат туар кебек үсендертте.

Үр артында үрләр бар икән лә,
Яр артында ярлар бар икән.
Үрдән үргә күчә бара кояш...
Бөтен сөю иле тар икән.

Ул үрләрнең бармы бер-бер чиге,
Ул ярларның бармы соңгысы?
Бер кич миннән качып киткән кояш
Инде кемгә бирә җылысын?

Инде кемгә ялган вәгъдәләрне
Биреп уза, мәңге китмәс күк?
...Гомеремнең көне кыска иде,
Гомеремнең төне үтмәс күк...

## Хәтерсезлек

Минем яшьтә хәтерсезлек
Сыядырмы кысага?
Җуела кадерле көннәр,
Җуелмас тоелса да...

Җуела тән газаплары:
Урын киң—җанныкына.

Яшәрмен моннан ары мин—
Сине яратып кына.

Уйлармын моннан ары мин
Сине—сагынып кына...
Картаям. Сөю сыямы
Картаю кысасына?

## Еламыйм

Китәсең. Еламыйм. Сагышлы
Сурәтем исеңдә калмасын.
Буранда, чилләдә адашкан
Болыт күк килмәссең аннан соң.

Килмәссең бөтенләй. Елмайган
Ирнемә: сагындым, димәссең.
Аларда—наз гына. Керфектән
Җаныма тәгәри бар яшем.

...Китәсең. Еламыйм. Озатмыйм.
Миңа бит гомерлек пар кирәк.
Синең ул парың бар. Ярың (!) бар.
Борыл бер, янына җитәрәк.

Кара бер артыңа, кул сузсаң,
Җитәрсең шикелле миңа да.
Челләдә адашкан болытлар
Кайвакыт яумыйча югала...

Челләдә адашкан болытлар
Агалар гаепле шикелле.
Китәсең. Еламыйм. Үзең дә
Йөзеңнән сагышны сөрт инде!

## Төсне яклау

Болыннарның сары яктысында
Балачакның татлы төсе бар...
Сары төс тик картлык билгесеме?
(Һәрнәрсәнең таңы, киче бар...)

Сары төс бар кояш өсләрендә,
Чәчәкләргә баткан җәйләрдә,
Йөрәгемне саклап, кич ятканда
Сыек кына эчкән чәйләрдә.

Әбиемнең матур экиятендә,
Чәчүргечтә башка үрелгән...
Балачакта төснең сарысы да
Бәхетнеке диеп күрелгән.

Картлык төсе диеп санамыйча,
Сагыш төсе диеп юрамый—
Яшәгәнбез сары төсләрне без,
Яшәгәнбез—берни уйламый...

Әти күлмәгенең сап-сарысы
Якын булган безнең күңелгә.
Бәрәңгенең агы, сарылары
Күмеп куелган бит күмергә.

Кырга чыккач, яккан учакларның
Көткәнбез без көлгә калганын.
Бәрәңгенең учак көлләрендә
Күмер төсле булып янганын.

Шул кырларның камыл яктысында
Балачакның калган төсләре...
Сары төс ул картлык кына түгел.
(Төснең дә бар таңы, кичләре!)

Арышларның сары дулкынында
Балачакның якты төсе бар.
Без учларда уган башакларның
Икмәкләрдән килгән көче бар.



Вазыйх
Фатыйхов

# БЕЗНЕҢ НӘСЕЛ СЫНМАС, СЫНАТМАС...

## Кирәк...

**Кайчак аяк чалмасыннар өчен,
Кирәк көчең, кирәк куәтең:
Көрәшләрдә җиңгән яхшы аңлый
Гаделлекнең чып-чын кыйммәтен.**

**Хисләреңдә ялгыз янмас өчен,
Кирәк дуслар, сердәш-танышың:
Авырлыгын—кичергәннәр белә
Ишек какмый кергән сагышның.**

**Картлыгыңда бер үкенмәс өчен,
Кирәк намус, кирәк гакылың...
Шулай яшәгәннәр генә белә
Бәяләрен яшәү хакының!**

## Кайчакларда

**Кайчагында, белмим, ни өчендер
Күктән төшкән бәхет кадерле.
Әллә инде үзе сайлап алып,
Ходай бирә мондый әмерне.**

**Кайчагында, һич тә көтмәгәндә
Барыр юлың кала өзелеп.
Торган кебек була шул чакларда
Алда бәхетсезлек тезелеп.**

**Кайчакларда, үзең тоймаганда
Күктән бәхет төшә ишелеп.
Нигә күктән? Җирдә туганбыз бит,
Шуннан чыкканбыз бит тишелеп?**

Вазыйх ФАТЫЙХОВ (1958)—*шагыйрь; «Яшерен Сөю», «Күз тимәсен күзләреңә», «Яфрак куләгәсе» һ. б. китаплар авторы. Балык Бистәсендә яши.*

Әле ярый, кайчак, көтмәгәндә
Бәхет төшә, төшә күкләрдән!
Шул бәхеткә килеп сыенасың,
Җирдә чикне узып киткәндә.

## Яшьлек шаяруы

Җепшек карлар ата идем сиңа,
Яратып һәм һәрчак үз итеп...
Тоя идең бугай тимәсен дә,
Куя идең серле күз сирпеп.

Ә мин ата идем алларыңа,
Озата кала иде карларым.
Тоя идем җылы нурларыңны,
Син дә сизә идең—мин барын...

Һаман язын, җепшек кардан атлап,
Киләм яшьлек үткән урамга:
Карлар атам... Әмма сиңа тияр
Карларымны—йоткан бураннар...

## Гомерләр үтә икән ул...

—Кем баласы, кемнеке син?—диеп,
Җелекләргә үтте карт-коры.
—Ничек инде белмисез ди, мин бит
Рәхиләнең бердәнбер улы?

Мыек чыккач, егет булгач та әле
Тилмерттеләр мине карт-коры...
—Танымыйсыз әллә, Вазыйх бит мин—
Бай Сәлахи мулла оныгы!

...Авыл урамнарын әйләнгәлим,
Ник күренсен берәр карт-коры?..
Бала-чага исәнләшеп уза,
Сорап калам: «Син соң кем улы?!».

* * *

Хушлашканчы белмәссез дә кебек
Җаным көчен, тәнем халәтен:
Мин яшимен меңнәр уе белән...
Ходай әйтә: бу бит сәләтең!

Ә мин риза меңнәр җаны хакына
Үз җанымны бүләк итәргә
Офыклардан тик кайтаваз килер:
Алыштырма җаның бүтәнгә!

Без килдек тә китеп барабыздыр,
Бер күргәннәр—безне онытмас!
Үлгәндә дә учларымнан тамар
Холкым-каным, гомер—үч тотмас!

* * *

Бер учымда—язмыш, Сөю,
Бер учымда—иҗатым:
Учларымны Сезгә ачам,
Бүләк итәм җыр-атым.

Бер учымда—үткәннәрем,
Бер учымда—үтәсем:
Сезгә ачам учларымны,
Килә уртак итәсем.

Учларымда, куш учымда
Шатлыгым, сагышларым.
Мин бәхетле, үз иткәнгә
Шигърият язмышларын...

Бер учымда—гомер юлым,
Бер учымда—дәвамым.
Чын бәхетнең ни икәнен
Яши-яши аңладым,
Туган якта аңладым.

* * *

Уйламагыз әле, без көчсез дип,
Әйтер сүзләр безнең алда әле.
Безнең атлар чабышларга әзер:
Бер минутлык кына ялда әле...

Кузгалырбыз, тузаннарда калыр
Бер тиенгә тормас язмышлар.
Ярый әле димен, бу, дөньяда
Акыл көчен сынар ярыш бар!

Мин көрәшәм әле, көчем җитәр,
Безнең нәсел сынмас, сынатмас.
Башын горур ияр—игәндә дә,
Дәрәҗәсен ләкин югалтмас!

♣

*Хикәяләр конкурсына*



Фәнил
Гайнуллин

# КҮЧТӘНӘЧ

Гаҗәп тә нәрсә бу Вакыт дигәнең. Ага туктаусыз, бернигә дә исе китми, беркемгә игътибар итми, барысына да битараф кебек... Ә менә син кая да булса ашыгып кара!.. Андый чакта ул машинага караганда да шәбрәк чаба. Көткән минутларда бөтенләй башка хәл—юньсез ишәк кеби—һич кузгалырга теләми.

Инде ничәнче тапкырдыр, Сәгыйт эш арасында,мастерской стенасына эленгән сәгатькә әледән-әле карап ала да аптырап куя: бигрәк тә акрын йөри инде бу! Әйтерсең лә аның уклары ябышып калган. Бераздан егет үзенең бу хәленә буйсынгандай була һәм янадан эшенә тотына. Кул эшли, ә күңелдәге уйлар дулкыны бер көчәеп, бер азаеп, эссе көндә тирләгән тәнне иркәләгән салкынча җилдәй кичерешләрне назлый, бәхетле хыяллар тарафына алып китә. Сәгать күпме генә карышса да эш көне барыбер бетә һәм көне буе уйлап, көтеп торулар инде чынбарлыкка әйләнеп, гүзәл мизгелләр килә. Бар да алда, тик көтәргә, көтәргә генә кирәк.

Мастерскойга көннең нинди булуына да карамастан беркайчан да күн курткасын салмый торган, мастер килеп керде дә житез адымнар белән туп-туры Сәгыйт янына килде.

—Икедә ундүртенче ватылды. Бераз тоткарлан инде,—диде ул егеткә.

Уйларыннан айнып бетә алмаган егет, аның сүзләренең эчтәлегенә төшенеп бетмәсә дә, нинди дер кодрәт белән кире җавап бирергә өлгерде:

—Юк, юк. Бүген булмый.

Мондый гына сүзләргә күнеккән мастер җавапка игътибар итеп тә тормады:

—Үзенә машинист ярдәм итәр,—диде дә китәргә җыенып кире борыла башлады.

Үзенең ниятләренә нинди куркыныч янаганын тик хәзер генә бөтен күңеле белән аңлаган егет кискен хәрәкәт белән аның юлына аркылы төште:

—Юк! Бүген булмый, Әхнәф абый. Теләсәгез нишләгез. Бик мөһим эшем бар.

—Ничек инде кала алмыйсың, ничек инде булмый?—Мастер бераз кызып китте,—кемгә әйтим синнән башка?—ул аларны тыңлап торган эшчеләргә ымлады.—Коля баласын ала, Ирек укырга бара, Габдулла абыенны кунаклары көтә. Нәрсә мина, установканы туктатыргамы?

Сәгыйт тагын да кире җавап бирергә җыенган иде, өлгермәде. Алар янына Ирек килде.

—Ярый, үзем калам,—диде ул тыныч кына,—укып мулла булмассың, булсаң да мәчетләре юк.

Мастер шундук җинел сулап куйды, анын күз карашы элеккегә хәленә кайтты. Ул Ирекка кирәкле күрсәтмәләрне бирде дә китеп барды.

—Ни булган коммунистик хезмәт ударнигына?—Ирек Сәгыйткә елмаеп карады. Яшькә алар бер чамада.—Беренче күрәм карышуыңны.

—Бүген күрешергә кирәк.

—Кем белән?

—Таныштым бит.

—Таныштың?!—дип сузды Ирек бөтенләй үк якын килеп,—менә бу яңалык, менә бу хәбәр. Кайчан?

—Инде бишенче көн.

—Ну, астыртын, ну эндәшмәс! Ничек соң?

—«Үзе!»—булырга тиеш.

Тойгылар тәэсире астында алар бераз икесе дә эндәшми тордылар. Беренче булып Ирек телгә килде:

—Ярый,—диде ул һәм каты итеп Сәгыйтнең кулын кысты,—котлыйм. Чын күнелдән.

«Дөнья матур, дөнья киң, минем күңел аңа тиң». Кайтырга дип урамга чыккач, Сәгыйтнең кәефе шундук күтәрелеп киттек һәм кайчандыр кемнәндер ишеткән шушы шигъри юллар исенә килеп төште. Кызу адымнар белән тулай торагына кайтып бар булган нигъмәтләрне хәстәрләп туйганчы ашады, юынды, битендәге сирәк төкләрне кырып ташлады һәм иртән үк әзерләп куйган яңа күлмәген, үтүкләнгән чалбарын киеп көзге алдында тикшеренгәннән соң, ниһаять, урамга чыгып, Әнисә яшәгән тулай торакка юл алды.

Көн инде кичкә авышса да, кояшның кыздыруы артык кимемәгән. Урам аның кебек үк үз эшләре белән каядыр баручылар, өйләренә кайтучылар белән тулы. Аларның бик сирәкләре генә ашыга, күбесе көннең матурлыгынамы, әллә башка нәрсәгәме сокланып, күтәренке күңел белән салмак кына атлый. Сыра мичкәсе янында һаман да шул зур гына чират, юл кырыендагы түтәлләргә утыртылган чәчкәләрнең хуш исе сулышларны рәхәтләндерә. Чәчкәләргә карап, Сәгыйтнең кайсыдыр кинода күргән, шулай ук очрашуга чәчәк тотып барган егет исенә килеп төште һәм ул озак уйлап тормастан, чәчәк сатучылардан иң матур бәйләмне сайлап, аны кызларга күчтәнәчкә дип инде алдан ук алып куелган кәнфитләр төргәге белән бергә тотты. Нигә тартынып торырга, күрсеннәр кешеләр, бер бәхетле кешене!..

Кызлар торагына килеп кергәндә сәгать җиденче киткән иде инде.

—Килә дә башладылар,—дип сукранды оек бәйләп утыручы вахтер хатын егетнең тантаналы йөзенә, чәчәкләренә дә игътибар итеп тормыйча,—бер тынгы юк үзләреннән.

Сәгыйт конфетның берничәсен алып аның алдына куйды:

—Ачуланмагыз инде, апа. Туфлиләремдә бер тузан юк ич.

Бүләктән бигрәк егетнең эчкерсезлегеннән үзгәргән вахтер бәйләнүеннән туктады.

—Күрәм, күрәм,—дип елмайды ул,—шәп егетсең дә. Рәхмәт.

Сәгыйтнең озын коридор буйлап ашыгасы бик килсә дә, салмак кына атлады. Очраган, ашыккан кызларга, әдәпә саклап юл бирде. Менә, ниһаять, өченче кат. Номерлары язылган бертөрле ишекләр: өч йөз унике, өч йөз ун, өч йөз сигез... Ул туктап өс-башын рәтләде дә сак кына ишекне шакыды:

—Мөмкин, керегез!

«Әкълимә»,—дип уйлап куйды егет.

Ул кергәндә Әкълимә идән уртасына баскан килеш чәчен бигудига урый, ә Нәзимә пөхтә итеп җыештырылган ятак өстенә утырып ниндидер китап укый иде.

—Исәннәрмесез?

Кызлар ана бердәм җавап кайтардылар. Әкълимә шөгыленнән туктамыйча аягы белән урындыкны ана этәрде:

—Утырыгыз!

—Рәхмәт. Хәзер,—Сәгыйт төргәктән берничәшәр конфет алып кызларга бирде, калганын чәчәк бәйләме белән өстәлгә куйгач кына утырды.

Тегеләр шундук аю сурәте төшерелгән кәгазьләрен сүтеп конфетны ашарга да тотындылар.

—Ой! Нинди тәмле. Рәхмәт.

Егет бүлмәне карап чыкты. Ул пөхтә итеп җыештырылган. Күзгә өстендә, караватт башларында кызлар үзләре теккән, чиккән әйберләр, кечкенә шүрлектә китаплар, стенада берничә артистның журналлардан кисеп алынган сурәте.

—Кәефләр ничек? Кая җыенабыз?

—Алла—гөл.—Әкълимә кин итеп елмаеп җибәрде,—культпоходка, егетләр карарга, үзебезне күрсәтергә, яна тойгылар белән баерга.

—Изге теләкләр, кирәкле уйлар. Уңышлар сезгә. Тормышка ашсыннар. Әнисә кайда?

Кыска гына тынлык туды. Әллә кызлар үзләре дә белмиләр инде?

—Чирләде ул. Бүлнистә.—Нәзимәнен тавышы акрын һәм төшенке.

—Чирләде-е?! Бүлнистә?!.—Егет көтмәгән хәбәрдән чак кына кычкырып җибәрмәде,—кайчан?!

—Бүген.

—Ни булган?

—Белмибез. Без кайтканда алып киткәннәр иде.—Һәм Нәзимә янадан китабына тотынды.

Күтәренке кәеф каядыр очты. Көтелмәгән бу хәбәр күз алларын караңгылатты, сулышын кысты, кызлар да, бүлмәдәге әйберләр дә бер әһәмиятсез, җансыз шәүләләргә әйләнделәр. Ә ул үзен ниндидер бушлыкта калгандай хис итте. Нәрсәгә икәнен абайлап тормыйча, егет урыныннан купты; каядыр бармакчы булгандай, бераз таптанып торды янадан утырды да берәр җинелрәк хәбәр әйтмәсләрме икән дигәндәй, янадан кызларга карады, алар үз шөгыльләрендә булсалар да Нәзимә аның бу уен сизеп алды булса кирәк.

—Кайгырмагыз,—диде ул егеткә йомшак тавыш белән,—үзен тиз терелтерләр. Хәзер врачлар көчле.

—Әйе, әйе,—диде егет, сүз уңаеннан аларга артык игътибар биреп тормыйча, үз кичерешләрендә булып. Килеп чыккан көтелмәгән бу хәлдән ул нишләргә дә белми. Уйлар, уйлар йөрәкне тырнап туктаусыз агалар да агалар. Өстәлдә уяту сәгате тыкылдый, радиодан чак кына ниндидер көй ишетелә. Ә күнелдә бушлык, төшенкелек. Анда тик бер генә уй: ни булды икән ана? Узган соңгы очрашуда сәламәтлек, чирләр турында бер сүз дә булмады. Икесенең дә күңелләре күтәренке, сүзләре шатлыклы иде.

Кинәт бер уй, кечкенә болыттан һич көтмәгәндәява башлаган янгыр тамчыларыдай, искә алмастан күнелгә килеп керде һәм кәефне бераз күтәрде: Әнисә янына барырга кирәк, үзен күрергә, хәлен белергә.

Ачык максат канатында Сәгыйт житез хәрәкәт белән урыныннан торды да кызларга эндәште:

—Кайсы бүлнистә микән ул?

—Бездә андые берәү генә инде. Заводныкына салмыйлар ич,—дип җаваплады әле һаман да күзгә каршында боргаланган Әкълимә.

Егет китәргә җыенып саубуллашу өчен кызларга борылган иде, өстәлдә караусыз яткан букетны күргәч, туктап калды. Өстәл янына килеп буш банканы алып, аңа су салып, чәчәкләрне шунда утыртты да, туктап берничә секунд аларга карап торды.

—Ә монысы сезгә,—диде ул кызларга конфет төргәгенә ымлап,—сау булыгыз.

Урам элеккечә үз мәшәкатендә. Шул ук шау-шу, шул ук күренешләр. Тик хәзер аларның кызыгы да, әчтәлеге дә юк. Сәгыйт кызу адымнар белән бүлнис ягына баручы автобус тукталышына ашыкты. Тукталышта кеше шактый гына. Аларның күбесе бердәм рәвештә автобус киләсе якка карап тора. Тик челтәр сумкасына әллә кайдан, ерактан күренеп торган әфлисун тутырган хатын гына икенче бер хатынга дөньясын онытып ни турындадыр сөйли. Апельсиннар! Үзенең авыр тойгылары астында барган егет аларны күргәч, үзе дә сизмәстән, туктап калды һәм аларга карап тора башлады. Күңелгә килеп кергән, әмма әлегә әчтәлеге аңлашылмаган ниндидер шатлыклы уй аның төшенке кичерешләрен бераз күтәргәндәй итте. Ул күпме шулай торгандыр, ниһаять, уйның асылы аңлашылып кабынган уттай бөтен күңелне яктыртып җибәрде. Күчтәнәч! Менә нәрсә кирәк Әнисәгә, менә нәрсә алып барырга кирәк шифаханәгә, аның янына...

Сәгыйт шатлык канатында якындагы кибеткә юнәлде, керү белән кирәкле бүлектә чиратта торган кешеләрне күрмәгәндәй сатучы янына килеп аңа эндәште:

—Апа! Күчтәнәч кирәк иде.

Сатучы, урта яшьләрдәге хатын, эшеннән туктамыйча киң ишарә белән, кибетнең буш киштәләренә ымлады.

—Теләгәненне сайла, чибәр егет.

—Апельсин беттемени?

Сатучы эшеннән туктап егеткә текәлде.

—Нинди апельсин!?

—Апа!—дип ялварды егет үзе дә сизмәстән бөтенләй икенче тавыш белән нык дулкынланып.—Якын кешем авыр хәлдә. Табыгыз инде бераз, зинһар!

—Юк бит, энем, юк. Былтыр күздән бирле.

—Ә кешеләр алган бит. Каян микән?

—Үзләреннән сорарга кирәк иде.

—Чыннан да.

Аның беркатлы сүзләреннән көлгән кешеләрнең кызганулы карашы астында ул урамга ашыкты. Чыгып тукталыш ягына караса, анда инде автобус килеп туктаган һәм кешеләр шыгрым тулы машинага утырырга тырышалар. Теге апельсинлы хатын да алар арасында.

Сәгыйт бар көченә тукталышка ташланды, ләкин өлгермәде—ул килеп җитәрәк тулы автобус көчкә ишекләрен япты да зәңгәр төтенен чыгарып кузгалып китте. Тукталышта бер үзе басып калган егетнең күз аллары караңгыланды, буыннары таралып хәле китте. Өметсез караш белән ул авыр тирбәнеп, торган саен ераклаша барган автобуска карады. Анда теге апельсинлы хатын, анда Әнисәнең шатлыгы. Берничә минуттан алар бөтенләй күздән югалачаклар. Алар белән көтелгән шатлык та, уйланган теләккә ирешү дә. Төшенке уйлар егетнең тәнен өтеп алгандай куырдылар, өзгәләделәр һәм шулар арасыннан алардан аерылып торган бер генә сорау күңелгә килеп кадалды: нишләргә? Автобус һаман бара, һаман ераклаша.

...Уй һич искә алмагандай туды: автобусны, теге хатынны куып җитәргә.

Бу башта дуамал, әкият өлкәсеннән килгән ым кебек булып тоелса да, егет моның бердәнбер өмет икәнен шунда ук аңлады һәм берничә секунд эчендә чалбар каешы бер тишеккә кыскартылды, туфли җепләре тыгызлап бәйләнде һәм ул бар көченә автобус артыннан ташланды. Бу теләкне тормышка ашыра башлау белән авыр кичерешләр каядыр югалып, алар урынына үз көченә ышану, максатка ирешү өчен барлык мөмкинлекләрне куллану тойгылары алып аның көчен арттырдылар, сулышын киңәйтеп, хәрәкәтләрен җиңеләйтеп, күнелен күтәрделәр. Урам буйлап автобус артыннан чапкан бу егеткә кешеләр гаҗәпләнеп карыйлар, кайберләре туктап карап торалар, нишләргә белми йөргән урам этләре ул якынлашу белән куркып качалар, кыюраклары өреп арттан ташланалар. Ләкин боларга игътибар итәргә вакыт та, мөмкинлек тә юк. Алга, алга! Автобустан калышмаска, ничек булса да түзәргә, тырышырга. Автобус беренче семафорны туктаусыз узса да, икенчесе янында шактый торды. Монардан файдаланып егет араны шактый кыскартты. Чапкан уңайга Сәгыйтнең күңеленә ничек итеп көчне саклау кагыйдәләре исенә төште. Аларны үтәп ул мөмкин кадәр тирәнрәк суларга, адымнарны киң һәм җиңел тотарга тырышты.

Автобус «Мәдәният йорты» янына килеп туктады. Ләкин теге хатынның төшкәне күренмәде. Бу тукталыштан соң бераздан бушлык башлана, аннан соң кечкенә инеш аркылы салынган күпердән соң юл сулга борылып озын сөзәк таудан менәчәк һәм өстә «Поселок» тукталышы. Ә моннан турыга җәяүлеләр өчен сукмак барлыгын Сәгыйт белә иде һәм ул шунда омтылды.

Сукмак тигез булса да аның ике ягын каплаган биек үләннәр тиз барырга шактый комачаулыйлар. Менә инеш, аның аркылы кечкенә басма. Сәгыйт аны бер-ике сикерүдә узды да текә ярга кайда дүрт аяклап үрмәләп, кайда куакларга, ташларга тотына-тотына өскә менгәч, киң, зур мәйданга килеп чыкты. Ерактарак бер катлы авылча өйләр, ә монда якынрак юл буенда ялгыз тукталыш будкасы. Хәзер анда теге автобус килеп туктаган һәм кешеләрен төшереп, утыртып инде китәргә җыена. Төшкәннәр таралышып өйләренә таба атлый. Шулар арасында теге апельсинлы хатын да. Егет йөгерүен акрынайтмыйча аны куып җитте дә алдына чыгып басты.

—Апа!—дип ымлады ул әфлисуннарга кулын сузып һәм еш сулаудан башка эндәшә алмады.

Каршысында һич көтмәгәндә пәйда булган, тирләп кызарган, мышнап беткән бу кешене күргәч, хатын шактый курыкты. Аның сузылган кулыннан күчтәнәчләрен читкәрәк алды да эндәшүен ишетмәгәнгә салышып, адымнарын тагын да шәбәйтеп юлын дәвам итте. Сәгыйт аны яңадан узып каршысына чыкты.

—Әйтегезче, зинһар,—диде ул мөмкин кадәр йомшаграк тавыш белән сүзләрне көчкә әйтеп,—каян алдыгыз бу апельсиннарны?

—Каян булсын, кибеттән. Әллә урлаган дип беләсезме?

—Юк, юк. Мин кайсы кибеттән дим?

—Куштирәктән.—Һәм хатын җәһәт кенә икенче якка борылды да бу сәер кеше яныннан тизрәк китәргә ашыкты.

«Куштирәк, Куштирәк»,—дип кабатлады үзалдына нишләргә белмәгән егет. Ул никадәр бу исемне хәтерләргә тырышса да булдыра алмады. Шулчак ул узып баручы бер ир-атны күреп куып җитеп ана эндәште:

—Гафу итегез. Сез Куштирәкне беләсезме?

Теге шундук туктап Сәгыйткә елмаеп карады һәм ул аның шактый кызмача икәнен абайлады.

—Беләм,—диде ул сөйләшергә зур теләге барлыгын сиздереп,—күп йөрдек без ул якларда. Тик бүген кирәкми анда барырга. Аракы монда да бар ич. Һәм ул берничә шешә күренеп торган сумкасына ымлады.

—Минем башка йомыш...

—Ә-ә, кызлар янына. Алайса әйтәм,—дип тирбәнде ул эчемлекнең татлы тәэсире астында,—авыл ул. Асфальттан җиде чакрым, ә турыга чокыр буйлап биш тирәсе.

Юлның кайдан башланганын сорагач, Сәгыйт китәргә җыенды.

—Рәхмәт ярдәмегезгә,—диде ул сүзнең дәвамын көткән бу кешегә,—сау булыгыз!

—Нурылла абыйга сәлам әйт!—дип кычкырды ул юлга ыргылган егет артыннан.

Көннәр буе үзенең ыгы-зыгысы, тузаннары, төрле исләре, туктаусыз ашыгучылары һәм башка күренешләре белән тулган, шаулап торган шәһәр урамнарыннан соң бу ике ягы да төрле зурлыктагы куаклар, текә йә сөзәк чокырлар белән чуарланган, калган өлешен төрле үлән каплаган үзән буйлап салынган йомшак сукмактан баруы җиңел һәм рәхәт. Ә тирә-якта искиткеч тынлык. Бары тик төрле кошларның сайраулары, үлән арасыннан чиксез күп бөҗәкләрнең чекелдәшкәннәре генә ишетелә. Ярым атлап, ярым чабып Сәгыйт шулай күпме баргандыр, ул моны уйлап та, исәпләп тә тормады. Бу сәфәр бәхетле уйлар белән бизәлгән тоташ бер максатка әйләнеп аны алга туктаусыз ашыктырды да ашыктырды. Чабасы, сикерәсе килә. Барлык хәрәкәтләр җиңел, һәрбер адым сулышларны киңәйтә, көч бирә. Әллә кайларга барырга әзер ул Әнисәне шатландырырга, аның хәлен җиңеләйтергә дигәндә.

Алда ялтырап яткан суы белән нindидер күл. Аңа килеп җиткәч, егет үзе дә сизмәстән матурлыкка сокланып, гаҗәпләнеп, башка уйларын онытып, туктап күлгә карап тора башлады. Офыкларга кадәр сузылган төрле иген басулары, сөрелгән җирләр һәм кеше кулы белән актарылган, үзгәртелгән дөнья арасында кысылып калган бу табигать почмагы әйтерсең лә тирәяктагы бар матурлыкны үзенә җыйган да канәгатьләнеп тынып калган. Күлнең аргы ягындагы калкулыкта үскән берничә каен, суга якынрак тал куаклары, сай җирдәге түмгәкләр һәм болар арасында төрле тавышлар белән кычкырышып үз мәшәкатьләре белән мәшгуль булган су кошлары. Бу күренешкә караган саен карыйсы килә. Әнисә терелгәч, алар һичшиксез, монда киләчәкләр, икәү бергә шушы матурлыкка карап сокланачаклар. Ә хәзер алга!

Куштирәк текә ярлы инеш буенда урнашкан артык зур булмаган җыйнак кына бер авыл икән. Машиналар кермәскә киртәләп куелган олы урамны хәтфә чирәм каплаган. Казлар кунаклаган, тавыклар тибенеп җим эзлиләр. Кайбер капка яннарында берәмләм тә, берничәшәрләп тә, күбесенчә олы яшьтәге кешеләр утыра. Бер урында малайлар кычкырыша, туп тибәләр. Тынычлык, иркенлек.

Урамга керү белән, Сәгыйт ашыгуын калдырып, дәрәҗәле салмак адымнарга күчте. Якындарак утырган апалары, абыйлары белән авылдагы гадәт буенча, исәнләшеп атларга керешге. Әмма аның күнелендәге максат—авыл кибете һәм андагы апельсиннар. Аның кайдалыгын белү өчен таяк атка атланып, кечкенәрәк чыбык белән аны камчылап кәҗәләр куып йөргән бер малайга эндәште. Теге шул малларны калдырды да урабрак, әмма шәп чабып егет янына килеп туктады.

—Тр-р, тыпырчынма!—малай башта «атын» тынычландырды.—Нәрсә абый?

—Кибетегез кая?

Малай «камчысы» белән авылның аргы башына ымлады.

—Әнә тегендә. Үзегез белән барыйммы?

—Киттек.

Ул «атын», «камчысын» атып бәрде дә, егеткә иярде. Эндәшмичә шулай бераз барганнан соң Сәгыйт артына әйләнеп караса, малайлар инде өчәү

булганнар. Берсенең култык астында зур туп. Бер эт тә ияргән.

Оешкан төркем очраган кешеләрнең кызыксыну карашлары астында бераз барганнан соң урам аркылы салынган, үзенең рәвеше белән авыл өйләреннән аерылып торган бер йортка якынлашты.

—Әнә, абый, кибет,—диде малайларның берсе, алар кинәт очып киткән чыпчыклар төркемедәй, барысы да чабышып бина янына киттеләр һәм шундук кире әйләнеп килделәр.

—Бикле, абый.

Чыннан да, кибет ишеге өч йозакка бикләнгән иде. Егет нишләргә белми туктап калды һәм аптырап бер бикле ишеккә, бер авыл ягына карап эндәшмәс булды. Малайларның да күңеле төште, тынып калдылар. Әйтерсең лә мона алар гаепле. Бераздан малайларның кайсыдыр авыр тынлыкны бозып әйтеп куйды:

—Әнә сатучының өе.

Егет берни уйламыйча сорап куйды:

—Кайсы?

—Кызыл мөрҗәлесе.

Күңелдә ниндидер әле эчтәлеге билгеле булмаган өмет уянып кәефен чак кына күтәргәндәй итте һәм аның шушы малайлар кебек чагы хәтеренә килеп төште. Ул вакытта әнисе аны кибеткә берәр кирәк-ярак алырга җибәргәндә ул бикле булса туры сатучы Галия апасының өенә керә иде. Туган өмет үзенең ачык билгеле юнәлешен алды һәм ул дусларына эндәште:

—Киттек.

Төркем кузгалды. Иң алда үзенең өмете белән канатланган Сәгыйт, аннан соң малайлар һәм иң артта кешеләрнең эчкерсез дусты—эт.

Алар сатучының өенә якынлашканда биек койма аркылы ихатадан радио җыры ишетелде.

Сәгыйт сак кына капканы шакыды. Җыр туктады, бу якка килүче аяк тавышы ишетелде һәм «урыс» капканың кечесе ачылып китеп, аның барлык киңлеген тутырып кызыл чырайлы таза ир гәүдәсе пәйда булды.

—Исәнмесез!—Сәгыйт аңа мөмкин кадәр йомшак тавыш белән эндәшергә тырышты,—миңа сатучы кирәк иде.

—Ни йомыш?

Хуҗаның сүзе кыска һәм кырыс.

Белә Сәгыйт, мондый вакытларда туры үтенечкә шундук кире җавап алуың бар. Шуңа күрә сорауны бераз йомшартып, аны ни белән булса да бизәп, башта кереш сүз әйтү кирәк.

—Кеше ул, абый, төрле хәлләргә очрый,—дип башлады егет кесәсеннән портсигарын чыгарып һәм сатучыга да сузып.—Аны берчак җылы кояш иркәләсә, икенче вакыт ачы суык интектерә.

—Анысы хак,—дип ризалашкан булды сатучы юан бармаклары белән сигаретны көчкә эләктереп, егет сүзе аны артык кызыксындырмаса да.—Әллә эшләрең яманмы?

—Шулайрак шул, абый. Якын кешем авыр хәлдә, бүлнистә. Азрак апельсин кирәк иде.

—О-о, энекәш. Туй үтте, апельсин бетте,—һәм сатучы капканы ябарга омтылыш ясарга җыенган иде, Сәгыйт уң аягын аркылы сузып мона комачаулык итте. «Бетте» дигән сүзләреннән күз аллары бераз караңгыланып киткән егет чак кына беленеп торган өмет җебен өзмәскә, барлык тырышлыгын куеп мөмкин кадәр түбәнчел тавыш белән сак кына эндәшергә тырышты:

—Бәлки бераз калгандыр?

—Калса соң!—сатучы горур кыяфәт белән башын чайкап куйды да бөтен урамга ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде.—Мин инде унҗиде ел

сатудамын. Медалем бар, грамоталарым күп. Дусларга, туганнарга кирәк нәрсәләрне калдырырга хакым юкмыни?!—Һәм ул үзенә каршы дәшәргә теләүчене күреп, аны алып ташларга җыенгандай, егеткә таба талпынып куйды.

—Мин дә бит сезгә дус була алам,—дип туктатты ул сатучыны.

Сатучының кыяфәте кинәт болыт артыннан чыккан кояш нурларыдай яктырып китте.

—Менә бу башка сүз, менә бу егетләрчә,—дип мактап китте ул егетне.—Ну тырышсын да үзең. Молодец! Яратам андый кешеләрне.

Аннан соң сатучы артка борылып ихатага кычкырды:

—Сара! Китер ачкычларны.

Эшнең нәрсә белән бетәсен бер як читтәрәк тын гына көтеп торган малайлар да җанлана төште һәм барысы да сатучы артыннан кибеткә юнәлделәр.

Ниһаять, йозаклар шапылдап ачылды, ярым караңгы кибет эченә кергәч, хуҗа каяндыр челтәр сумка алып аңа аста яткан апельсиннарны тутыра башлады. Ә Сәгыйт тартынып тормыйча киштәдән үрелеп бер шешә аракы алып прилавка өстенә уртага куйды.

—Ике кило алты йөз,—сатучы тулы сумканы үлчәде һәм чут төймәләрен шакылдата башлады. Егет ялгыз торган шешәгә ымлады:

—Монысын да кушыгыз.

—Ул миннән. Син минем кунагым.

Исәп-хисап ясалганнан соң хуҗа ике стакан янына тешләштерергә дип каты-коты куйды да, стаканнарга аракы салып берсен егеткә бирде, икенчесен үзе тотты.

—Танышлык өчен,—диде ул тантаналы тавыш белән.—Исемең ничек?

—Сәгыйт.

—Ә мин Нурылла абыең булырмын.

Тын кибет эчендә стаканнар зеңгелдәде. Аннан соң авыр сулыш һәм күпмедер тынлык. Сәгыйт аз гына капты.

Эчкәннән соң сатучының теле ачылып китте. Күп тә үтмәде, егет аның армиядә кайда хезмәт иткәнен дә, районда уңышның ничек буласын да, алдынгыларга ничә машина һәм башка нинди бүләкләр бирәсен дә белеп бетерде. Кешеләрнең шулай үзара сөйләшүләре бу дөньяның иң күркәм күренешләренең берсе. Әгәр синең әңгәмәдәшең «Кеше» дигән бөек исемгә лаек булса, ул синең эчке дөньяңны баетачак, күңелне төрле юшкыннардан, утырган чүпләрдән чистартып, үзеңне яңа биеклеккә күтәрәчәк, һәрбер тормыш билгесезлегеннән чыгарга ярдәм итәчәк. Ә инде әңгәмәдәшеңдә, киресенчә, тар карашлар, түбән омтылышлар өстенлек итсә, ул чакта булган рухи байлыгыңның да кечерәеп, саегып калуы бар.

Сәгыйт Нурылла абыйсына карый да сокланып туя алмый. Нинди эчкерсез, чиста хисле кеше ул. Инде олыгаеп башы пеләшләнә башласа да, моңа кадәр аңа һич таныш булмаган, беренче күргән бу яшь кешегә чын күңелдән бирелеп, үзенә тигез итеп рәхәтләнеп сөйли, аның тыңлаганын күреп шатлык кичерә.

Ул арада сатучы стаканнарны яңадан тутырды да, үзенекен күтәреп җырлый башлады:

Бергә яшик, бергә яшик
Бергә яшәү күңелле.
Бергә яшик буш итмәек
Чәчкә кебек гомерне.

—Дөресме, энем?

—Бик дөрес, Нурылла абый.

—Ул чакта дуслыкка.

—Бик теләп.

Тагын стаканнар зенгелдәде. Сәгыйт бу юлы да аз гына капса да, ач карынга житә калды—аракы шаукымы башка йөгереп күнелне күтәрде, уйларны кинәйтте һәм аларнын ин беренче дулкыны сатучыга юнәлде.

—Рәхмәт сезгә Нурылла абый,—диде ул ана ягымлы күзләре белән карап,—бик зур ярдәмегез өчен...

—Ничьё, ничьё,—сатучынын мона артык исе китмәде,—кулдан килгәнчә энем, булдыра алганча.

Эшләрен бетереп урамга чыкканда малайлар аларны көтеп торалар иде. Сатучы ишеген бикләгән арада егет аларга апельсин өләште. Тегеләр бүләкне бик оялып, әмма зур теләк белән кабул иттеләр.

—Рәхмәт, абый. Рәхмәт.

Ул арада эшләрен бетереп хужа да килеп житте. Табыннан сон ул шактый кызарган, кәефе күтәренке.

—Каты авырыймы?—дип сорады ул егеттән кинәт йөзенә кайгылы төс кертеп.

—Шулай шул.

Алар икесе дә бераз эндәшмичә басып тордылар. Тынлыкны сатучы бозды:

—Ярый, Сәгыйт,—ул апельсиннарга ымлады,—шифасы тисен. Исән-имән илтеп житкер. Савыккач, икәү килегез. Көтәм,—һәм ул егеткә кулын сузды.—Сау бул.

Ул чын күнелдән анын кытыршы зур кулын кысты һәм малайларга борылды:

—Сез дә сау булыгыз, егетләр,—аларнын һәркайсын сөеп чыкты—тырышып укыгыз, зур кешеләр булыгыз.

Сатучы белән тагын бер кат карашлар белән саубуллашканнан сон, Сәгыйт тиз адымнар белән кайту юлын башлады һәм күнел узачак юлны алдан үтеп Энисәгә килеп тәрәлде. Анын хәле егет анында шактый борчулы уйлар тудырса да, кулдагы күчтәнәч ничектер аларны йомшартты, кечерәйтте.

Урам буйлап бераз барганнан сон, Сәгыйт артына әйләнеп карады һәм үзенен мондагы яна дусларынын шул ук урында басып торганнарын күрде. Малайлар ана кул болгыйлар иде. Егет тә жавап итеп кул изәде.

Кулда күчтәнәч, күнелдә күтәренкелек. Рәхәт тә сон бу дөньяда күркәм уйлар белән яшәве. Синен һәр адымын, һәр хәрәкәтен жинел һәм мәгънәле. Озакламый көз житәр, аннан сон кыш килер. Хәзер яфраклары, ә кайсылары чәчкәләре белән дә матурланып торган агачлар башта саргаерлар, бераздан яфраклары коелып шәрә калгач, бөтенләй ямьсезләнерләр. Кеше дә бит шулай. Ул үзенен уйлары, омтылышлары, эшләре белән матур, шушы агачларга охшаш. Ә алар юк икән, ямьсез кышкы ботакларны хәтерләтәсен. Уйлар, уйлар. Һәр кешенен аерылмас юлдашы, анын көзгесе, кәефенен билгесе һәм эчке дөньясынын эчтәлеге.

Бүгенге мәшәкатьләрнен бер өлеше үтәлеп, кыенлыклар, дулкынланулар, билгесезлекләр беразга артта калгач, Сәгыйтнен уйлары иркенләп, ашыкмыйча үз жаена агарга кереште һәм тагын да Энисәгә күчте. Егетнен хәтеренә кыз белән мона кадәр булган очрашуларында анын карашлары, хәрәкәтләре, елмаюлары күз алдына килеп, сөйләшкәндәге күнел жылылыгынын чагылышы, хәзер егет күнелендә мәһабәт бер бәхеткә әйләнеп, хисләрен иркәләде, хыялларын яктыртты. Әмма озакламый бу уйлар Энисә тирәсендәге чынбарлыкка күчеп, егетнен кичерешләренә шөбһә билгесе керттеләр. Ә анын хәле авыр булса? Хәзер бәлки ул караватында сызланып, ынгырашып ята торгандыр. Ул һич көтмәгәндә килеп кергәч, Энисә гажәпләнеп, елмаерга тырышыр, әфлисуннарны күргәч, һичшиксез, шатланыр һәм «Каян алдын?»

дип сорар. Берничәсен аңа үзе әрчеп бирер. Алга! Тизрәк Әнисә янына. Үзенә шатлык бүләк итәргә.

Алда теге күл. Инде кичкә авышкан кояшның озын күләгәләре аны тагын да матурлап сихри бер төскә кертәннәр. Тал куакларынын берсендә тырышып-тырышып сандугач сайрый. Әйтерсең лә ул егетнең уйларын сизеп соклана, аңа уңышлар тели.

...«Шәһәрнең үзәк шифаханәсе» дип язылган капканы узгач егет башта адымнарын акрынайтты, ә аннан соң бөтенләй туктап калды. Алда төрле зурлыктагы биналар һәм аларның кайсындадыр Әнисә. Тик аны ничек табарга соң? Бүген башка мәшәкатьләр белән шөгыльләнгәндә уйга да килмәгән бу бурыч хәзер үзенең барлык зурлыгы, мөһимлеге белән каршыга килеп баскач, тырышлыклар белән чыныккан күңел тагын да күтәрелеп киткәндәй булды. Ниндидер китапта укылган бер командирның сүзләре күңелгә килде: «эзләргә, табарга һәм... өченче сүз монда «юк итәргә» иде. Ләкин егет аның урынына үз сүзен куйды: шатландырырга».

Ул якындагы ике катлы бинага юнәлде. Бу терапия бүлеге булып чыкты. Урамда ялгыз да, төркемләшеп тә чирлеләр, күбесе үзара сөйләшеп торалар. Тик кайсылары гына ялгыз үз кичерешләре белән уйга калганнар. Сәгыйть туктап тормыйча эчкә узды һәм коридорда өстенә «Авыруларга әйбер бирү 17—19 сәгатьләрдә» дип язылган тәрәзә янына килеп чыкты. Тик хәзер аның такта капкачы ябык. Ул аны сак кына шакыды, әмма тавыш-тын ишетелмәде. Тагын шакыды һәм шул чак кинәт капкач ачылып китте дә аннан урта яшьләрдәге шәфкать туташының ачулы йөзе күренде:

—Ни кирәк?—дип кычкырды ул кырыс тавыш белән.

—Авыруны күрергә иде...

—Соң инде, соң. Иртәгә килерсең!—һәм ул капкачны яба да башлады.

—Апа-а!!! Бүген кирәк. Хәзер.

Ханым егетнең тирләп кызарган, алҗыган йөзенә, өмет белән текәлгән күзләренә карап алды да бераз йомшарды.

—Кайсы палатада?—дип сорады ул инде ягымлырак тавыш белән...

—Белмим. Бүген салганнар. Бик авыр хәлдә.

Ул шундагы өстәл тартмасыннан калын дәфтәрне алып егеттән авыруның фамилиясен сорады да аны эзләргә кереште, ләкин таба алмады.

—Бездә юк, энем.

—Рәхмәт.

Икенче бина хирургия бүлеге булып чыкты. Монда да шул ук күренеш, шул ук авырулар. Тик аларның күбесенең тышкы кыяфәтләре бинтларга уралган.

Шәфкать туташы үз эшләре белән мәшгуль. Аның янында берничә яшьрәк ир-ат вакыт уздыралар. Берсе, кирәргә батырчылык итмичә таптанып торган Сәгыйтькә карап торды да култык таягын алып, титаклап аның янына килде:

—Кем кирәк?

Йомышны аңлаткач, ул кире өстәл янына китте һәм алар бергәләшеп калын дәфтәрдән кирәкле исемне эзләргә керештеләр, ләкин таба алмадылар. Сәгыйть моны шунда ук аңласа да әдәп саклап чатаннның яңадан килүен көтте.

—Бездә юк,—диде теге.

—Рәхмәт.

Аннан соң чатан-чулаклар, тәннәренең башка бәрелгән, кысылган, киселгән урыннары бәйләнгән авырулар белән тулган имгәнгәннәр бүлеге... Керү түгел якын килергә дә мөмкин булмаган, өстәмә койма белән әйләндереп алынган йогышлы авырулар йорты. Ләкин боларның берсендә дә Әнисәне табып булмады һәм бу көтелмәгән хәлдән бераз кәефе төшә башлаган Сәгыйть

нишләргә белмичә беренче очраган эскәмиягә утырды да уйга калды.

Элеккеге тойгылар, хыялдагы күркәм уйлар хәзер ничектер кысылып, сагаеп киткәндәй булып дөньяны сорылаттылар. Әйтерсең лә, бик озак тырышып барганнан соң, инде «килеп җитәм» дигәндә алдан белмәгән уза алмаслык киң һәм тирән су янына килеп чыкты. Ләкин болай югалып калып мәлҗерәп утыру инде бүгенге вакыйгаларда чыныккан егетне озак тота алмады. Омтылыш көче янадан уянып, аның өметсезләгән читкә этәреп тагын тырышырга, хәрәкәт итәргә чакырды.

Ул торып басты һәм тирә-якка карарга тотынды. Инде барлык бүлекләрдә дә булды кебек. Тагын кайда нәрсә бар? Шул чак куе булып үскән агачлар арасыннан чак кына күренеп торган бер бинаның калай түбәсенә күзе төште һәм ул артык уйлап тормыйча шунда юнәлде. Киң парад ишеге ачык. Аннардан ерак түгел үскән агач янында бер ир белән көмәнле хатын сөйләшеп торалар. Мәйданның аргы ягында шулай ук үскән агачлар янында берничә эскәмия. Алары да буш түгел.

Егет ипле адымнар белән шәфкать туташы янына килде дә аның үзенә игътибар иткәнен көтеп, ниһаять, мона ирешкәч, йомшак тавыш белән сорап куйды:

—Кәримова Әнисә сездә ятамы?

Теге «тагын да комачаулыйлар» дигән чырай белән аңа усал итеп карап алды да өстәлдә яткан калын дәфтәрне алып кирәкле исемне эзләргә керешге.

—Бездә,—диде ул тиз арада кирәк исемне табып,—сигезенче палата. Бүген килгән.

—Керергә ярыймы?

—Юук, юук!—Катгый тыела. Бераз көтегез, чакырырмын.

Көтмәгәнме соң! Аллә күпме булса да риза. Күпме эзләгәннән соң Әнисәнең табылуы егет күңелен шунда ук җилкендерде. Элеккеге гүзәл тойгылар кире кайтып дөньяны тагын матурладылар, әйләнә-тирәдәге кешеләрне ягымлы иттеләр. Һәм ул күтәренке күңел белән эш юктан стенадагы плакатларны карарга кереште. Шуларның грипптан ничек сакланырга кирәклеген укып торганда арттан тавыш ишетелде:

—Чибәр егет хатынын сагынган...

Әйләнеп караса, теге урамдагы хатын-кызлар кай арада кергәннәр дә якын ук килеп аңа елмаеп карап торалар.

—Менә бу ир ичмасам!—дип дәвам итте аларның икенчесе.—Каяндыр апельсин да тапкан. Ә безнекеләр...

—Без әле өйләнешмәгән,—диде Сәгыйт аларның сүз уңаена.

Хатыннар шунда ук җанланып киттеләр. Аларның берсе егетнең җанына керердәй булып аның күзләренә карады һәм кычкырып җибәрде:

—Өйләнешмәгәнсез! Менә монысы кызык? Ашыктыгызмыни?

—Була инде ул кайчак аванс белән дә,—дип әйтеп куйды тыныч кына икенчесе. Һәм алар шунда ук көмәкләшеп көләргә тотындылар.

Башта бу хәлне һич аңламаган Сәгыйт нишләргә белмичә бераз сабыр итеп торды да бу тамашаны үзенә кагылмаганлыгына ышану өчен яңадан хатыннарга текәлде. Ләкин аларның көлүдән тәмам кысылып беткән ялтыравык күзләре егет күңелендә ниндидер шомлы тойгы уятты. Бу тойгы зурая, үсә башлап мона кадәр урын алып торган шатлыклы хисләрне читкә этәреп үзе бөтен күңелне биләп аны болгата башлады, суларга һава җитмәгәндәй тынны кысты һәм нишләргә белмәгән егет үзе дә сизмәстән бер максатсыз яңадан урамга чыкты. Көлешү монда бераз ишетелеп торса да, кичке саф һава, дөньяның башка тавышлары авыр тойгыларны бераз саектырып бу табышмак хәлне аңлау теләген тудырдылар. Ул элеккечә сөйләшеп торган ир белән көмәнле хатынга тагын карап алды, аннан китабын укып утырган

ханым янына килде.

—Апа! Бу нинди бүлек?

Ханым китабыннан аерылмыйча гына әйтеп куйды:

—Бәби табалар, аборт ясыйлар монда, энем.

«Аборт, аборт». Соңгы минутларда «авыру», «авырулар», «бүлек» һәм башка шундый мондагы төшенчәләр белән буталып беткән баш берни анламады. Һәм ул соравын яңадан бирде:

—Нинди авыру соң ул?

Бу юлы ханым көлемсерәп китабыннан аерылырга мәҗбүр булды:

—Мәхәббәт чире. Әллә шуны да белмисез инде?

Тик хәзер генә эшнең асылы анын аңына барып житте һәм егет уйлаган уен үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде:

—Нишләп Әнисә монда?

—Аборт ясата торгандыр,—дип җавап бирде анын бу сүзләрен ишеткән ханым һәм яңадан китабына тотынды.

Сәгыйтнең күз аллары караңгыланып хәле китте, күңелдә моңа кадәр һич таныш булмаган әллә нинди ямьсез уйлар туып, йөрәкне тырный, өзгәли башладылар һәм ул нишләргә белми, якындагы эскәмиягә утырып, тынып калды. Туган бу кичерешләр арасында ниндидер ачы әрнү, кемнедер сагынып юксыну һәм тагын әллә нинди шуларга охшаш тойгылар туктаусыз кайнашалар. Дөнья ниндидер катып калган җансыз бер нәрсәгә әйләнде, бар күренешләр үзләренең төсләрен югалтып шәүләгә әверелделәр һәм егет боларга түзә алмыйча, яңадан урыныннан торды, максатсыз берничә адым ясады, ләкин кире уйлап яңадан утырды.

Күпме утыргандыр ул шул тойгылары белән. Әмма күбрәк утырган саен вакыт агышы шатлыкларны бәхет хатирәсенә әйләндерә бара, кайгыларны капларга, кечерәйтергә тырыша. Бераздан егет кичерешләреннән айный башлап, гадәттәге уйлары белән тирә-якка карап алды. Китап укыган хатын юк, күрәсең, киткән. Теге сөйләшеп торганнар да күренми. Бушлык. Тынлык. Ул да китү нияте белән торып басты да бинага карап алды. Әйтерсең лә хәзер аннан ниндидер күренмәгән уклар очып чыгалар да аңа килеп кадалып авырттыралар, интектерәләр. Анын яныннан узасы да, аңа якын барасы да килмәде Сәгыйтнең һәм шуңа күрә ул юлсыз, сукмаксыз бушлык аша гөрләп машиналар узган юлга таба атларга кереште. Төрле үләннәрне егып, алар арасында күренмәгән чокырларда сөрлегеп, калкулыкларда абынып бераз барганнан соң ул ике ягын биек үлән каплаган, ә үзен инде, күптән, йөрүче булмагач, бәбкә чирәме баскан ниндидер бер иске юлга килеп чыкты. Тынлык. Кечке чиста һава, йомшак хәтфә үлән. Болар барысы да акрынлап егетне бераз тынычландырып күңелсез хисләрне читкә этәреп, алар урынына көндәлек уйларны кайтара башлады һәм ул хәзер тирә-якка икенчерәк караш белән игътибар итте. Алда гомергә шау-шуы бетмәс шәһәр, олы юлда туктаусыз машиналар гөрелтесе. Ә бу сукмакта тынычлык, монда иркенлек. Әйтерсең лә шушы дөньяда син бер үзең. Нәрсә ул тормыш? Нәрсә ул кеше гомере? Бу, әлбәттә, синең туганнан алып үлгәнгә кадәр башкарган эшләрен, кылган гамәлләрен. Әнә үләннәр арасында күпме бөҗәкләр чекелдәшә. Алар да бит бу дөньяда үз эшләрен башкаралар, теләгәннәрен эшлиләр.

Юлдан бераз читтә түбәләре кайбер урыннарда каерылып, җимерелеп беткән, стеналары таушалган берничә сарай, склад кебек корылмалар, алардан аерымрак, бушлыкта ишеге ярым ачык, үзе бер якка кыйшайган бәдрәф. Тик анда бер җан иясе күренми. Ташландык, бушлык.

Нәрсә кирәк соң кешегә бу дөньяда? Гап-гади табигый нәрсәләр. Ашарга, киенергә, үз куышында яшәргә, балалар үстерергә. Болар һәркем өчен кирәк нәрсәләр. Ә сина бу гади хәстәрлекләрдән өстенрәк булырга, югарырак уйлар,

тырышлыклар белән яшәргә, шушы якты дөньяда исеменне, эзенне калдырырга. Менә кая омтылырга кирәк.

Кинәт егетне шушы көтелмәгән хәлләр арасында онытылып киткән әфлисуннар сискәндерде. Күнелдә тыныч кына ага башлаган уйлар шунда ук каядыр югалып, теге шифаханә янындагы хатын сүзләреннән соң булган тойгылар янадан әйләнеп кайта башлады. Дөнья тагын да карангыланды, тагын да тын кысылды. Күз алдыннан бүгенге көннең мизгелләре, матур күл, Нурылла абыйсының эчкерсез йөзе бер-бер артлы узып, аның йөрәген көйдереп алдылар. Сәгыйт тагын җимешләргә карады. Хәзер нинди дер кире этәргеч, күнелне болгата торган ис анкыган кебек булды алардан. Аларга караган саен бу тәэсир зурая, үсә. Әмма бүгенге хәлләрдә билгесезлектән чыгу юлларын инде тиз табарга өйрәнгән егет бу юлы да озак мәлҗерәп тормады: Аның уена бу әфлисуннардан котылырга, юк итеп алар белән бәйләнгән барлык хатирәләрне шунда ук онытырга теләде. Аларны атып бәрү өчен кизәнергә җыенып ул урын эзләде. Тоташ үлән баскан урын. Ниләр генә юк монда. Үзенчә матур булган ачы әрем дә, зур кызыл чәчкәсе белән чәнечкеле шайтан таяклары, мәһабәт биек әрекмәннәр, билчәннәр һәм тагын әллә нинди үләннәр, чәчкәләр. Барысы да үзләренчә матурлар, сөйкемлеләр. Нигәдер күнеле тартмады Сәгыйтнең монда ташларга. Шул чак, ташландык корылмалар арасында ялгыз калган бәдрәф исенә төште егетнең. Менә кая кирәк аларны ташларга, менә кайда аларның урыны!..

Ул әфлисуннарны сумкасы-ние белән җирәнгеч тишектән аска бәрде. Күнеле шунда ук тынычланды.

Сигарет тартылып бетте. Сәгыйт төпчекне ташлап аягы белән сүндерде дә бу сасы иске корылмалар арасыннан тизрәк чыгып, беренче утлары кабына башлаган шәһәргә таба ашыкты.

---

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яңа меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятә, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Яңа хикәяләргә ачык конкурс дәвам итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

*Әй ханиям, ханиям!*
*Җир китәрдә ни калыр?*
*Җиреннән тайган ил калыр,*
*Ил китәрдә ни калыр?*
*Ил киткәндә йорт калыр,*
*Йорт китәрдә сөт калыр,*
*Ак күкрәктән сөт имгән*
*Сүзе татлы тел калыр.*
*Тел китәрдә ни калыр?*
*Язганнан язган хат калыр,*
*Баш китәрдә ни калыр,*
*Буында типкән кан калыр;*
*Буыннан буын чабылса,*
*Ул чагында ни калыр?*
*Йорт урынында яу калыр.*
*Яу чапканда ни калыр?*
*Ялгыз башы каңгырап,*
*Куйдай булып маңгырап,*
*Чүл далада тинтерәп,*
*Дуадактай хан калыр.*

"Идегәй дастаны", XV гасыр

## "Татар Русе"

Татарлар өчен Россия—чит территория түгел, аннан аерым тору яки киртә куюның хаҗәте юк. Бу киңлекләрдә төрки-татар цивилизациясе мең елдан артык яшәп килә. Россия эчендә баштан ук ике дөнья, дөньяга ике төрле караш, ике мәдәният даирәсе яши: рус-православие һәм төрки-ислам, алар бер-берсенә янәшә, бер киңлектә яши алып та, бер берсе белән аз аралашалар.

"Татар Русе" дигән сүзтезмә мантыйкка каршы төсмердә, иҗтимагый тәкәбберлек сыман яңгырый. Күп гасырлар буена рус аңының кайбер штамплары барлыкка килгән: "рус гаярьлеге" («русская удаль»), "рус каены" («русская береза»), "рус кыры" («русское поле»), "рус игелеге һәм күңел киңлеге" («русская добрата и широта души»), "Волга анабыз—бөек рус елгасы" («Волга матушка—великая русская река»), "Изге Русь" («Русь святая») һәм башкалар. Хәтта "Киң дала" («Степь широкая») дигән гыйбарә дә саф рус символы була-

*Ахыры. Башы 2006 елның 7-12, 2007 елның 1 саннарында.*

рак кабул итела. Дала кешесе (степняк)—кыргый һәм йөгәнсез күчмә кеше булса да, Дала үзе—рус даласы, иркен һәм иксез-чиксез икән. Татарныкы дигән һичбер нәрсәне катгый рәвештә кабул итмәү иҗтимагый аңга ясалма рәвештә кертелгән, бу хәл шушы гыйбарәләрдә "рус"ны "татар"га алмаштырсаң аерымачык күренә башлый: "татарская удаль", "татарская доброта", "Волга—великая татарская река", "Русь татарская". Әллә аң үзе, әллә аңның төпкелләре карыша: татарныкы бары рәхимсезлек, комсызлык, хәйләкәрлек кенә булырга тиеш, әмма һич тә игелек түгел янәсе. Нәкъ менә шулай тәрбияләделәр безне. Татар телендә бу сүзләр, әлбәттә, бөтенләй башкача яңгырый. Гаярьлек, игелек, күңел киңлеге кебек сыйфатлар татар холкына ябышып тора. Чыннан да, татар ир-егетен тагын ничек күз алдына китерәсең ди? Әлбәттә инде, дала буйлап ярсу атта җилдергән гаярь җайдак итеп. Сөер килеп чыга ләбаса бу: татар егете гаярьлеккә гаярь, әмма "татар гаярьлеге"—мәгънәсезлек имеш. Шул ук Идел турында татар халкы күпме җырлар җырлаган, аны дастаннарында олылаган, Идел-йорт дип атап, туган-үскән йорт, туган җир символына әйләндергән. Идел, һичшиксез, "татар елгасы", русларда ул шушы мәгънәдә күп соңрак пәйда була.[1] Татарда күз күргән һәрнәрсәгә "татар каены", "татар кыры"ише "татарныкы" дигән тамга салу гадәте юк. Ә менә Россияне татарныкы дип атап була.

"Татар Русе" үз законнары, үз мәнфәгатьләре, үз кыйммәтләре булган үзенчәлекле, катлаулы һәм алга киткән аерым бер дөнья сыйфатында яшәп килә. Күп кенә россиялеләр өчен - билгесез бер кыйтга, билгесез цивилизация ул, чөнки аларның күзен татарларга карата алдан ук тискәре мөнәсәбәт пәрдәсе каплаган. Бик күпләр исә, теләпме, теләмичәме, аны күрмәмешкә салышалар. Саратов [2] үз губернасының 200 еллыгын гына билгеләп үтте, алар тарихка тирәнрәк карарга курыктылар. Чөнки тарих төпкеленнән Алтын Урда шәһәре Үкәк (Үвәк) килеп чыгарга мөмкин иде, ә аңа 2003 елда 750 ел тулды. Хәзерге Волгоград Царицын (Сарацин)[3] шәһәренең нигезендә тора. Әстерхан үзенең 400 еллыгын билгеләп үтәргә җыена, аның борынгырак шәһәр икәнен һәм урта гасыр карталарында Хаҗи Тархан дип аталганын бөтен кеше белә юкса. Ибне Батутта анда XIV гасырда барган һәм болай дип язып калдырган: "Бу шәһәрнең исеме төркиләрдәге хаҗи [изге урыннарга барып гыйбадәт кылучы], шушы якларга килеп төпләнгән изге кеше атамасыннан килеп чыккан. Солтан аңа бу җирне ясак-салымнар түләтмичә генә биргән [ягъни аны тархан иткән] һәм биредә башта авыл калкып чыккан, үсә-бара шәһәргә әверелгән".[4]

"Татар Русе" әйләнә-тирәбездә дип кенә әйтү аз, аның тормышы кайнап тора. Елга бер тапкыр ул башкалар өчен сабантуй бәйрәме рәвешендә калкып чыга, әмма анда башка вакыйгалар да җитәрлек: сәяси, мәдәни вакыйгалар, гомуммилли бәйрәмнәр; идеологиядә, әдәбиятта, музыкада хәтта үзенә күрә революцияләре дә булып ала. Рус газеталары бу хакта язмыйлар.

Совет чоры татар дөньясына шактый зыян китерде: заманында куәтле булган икътисадый төзелмәләр юкка чыкты, мәгариф системасы бозылды һәм нәширлек эшчәнлеге бөтенләй диярлек бетерелде, шуның белән бергә Россиянең күп кенә шәһәрләрендә мәгълүм татар үзәкләре җимерелде. Бүген Казан татарның бердәнбер мәркәзе булып калды.

Петербург башкаламы, юкмы дигән мәсьәләне тикшерергә мөмкин, әлбәттә, ләкин без моңа бу шәһәрнең чын гомумдәүләт вазифаларын үтәү ягыннан түгел, тарихи яктан гына карый алабыз. Ә Казанны исә татар башкаласы буларак бер генә шәһәр дә алмаштыра алмый. Мәскәү моңа дәгъва кыла алмый, чөнки анда интеллектуаль көчләр җитми, анда чын татар мәктәбе дә юк, татар мәдәнияте белән шөгыльләнерлек югары уку йортлары яисә фәнни үзәкләр турында әйтеп тә торасы юк. Гәрчә Мәскәүдә Казанга караганда күбрәк

---

[1] Вадим Трепавлов. Волга- матушка - для кого? / / «Родина». 1998, №4, сс. 41-46.

[2] Саратов "Сары тау" дигән татар сүзеннән килеп чыккан.

[3] Сарацин "сары чин"нан килеп чыккан, аны сары йөз, сары чырай дип тә әйтеп була.

[4] Золотая Орда в источниках, с. 140.

татар яши. Мәскәү татар мәдәниятен кулланучы булырга мөмкин, әмма аны җитештерә алмый. Моннан тыш, Мәскәү әле ислам үзәге дә була алмый. Екатерина II Казанга каршы куеп мөселманнарның диния нәзарәтен Уфада оештырса да, Уфа мондый үзәккә әйләнә алмый. Россия ислам дөньясының бөтен төзелмәсе табигый рәвештә Казанда ясала. Татарларның барлык төп гомуми эшләре—Бөтендөнья татар конгрессы корылтайлары, җыр конкурслары һәм театр фестивальләре, нәширлек эшчәнлеге, видео- һәм аудио-язмалар чыгару, теле һәм радио тапшырулар алып бару Татарстанда гамәлгә ашырыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә "Татар Русе" кысаларында башкала Казан дип әйтү хак.

Иҗтимагый тормышта дәүләти булмаган оешмаларның роле арткканнанарта бара. Бу—глобаль күренеш. Дәүләт күп кенә вазифаларын иҗтимагый оешмаларга, дини берлекләргә, сәяси хәрәкәтләргә һәм трансмилли корпорацияләргә тапшыра. Соңгы елларда иҗтимагый берләшмәләр халыкара оешмаларда турыдан-туры катнашалар. Казанның татарлар башкаласы дигән рәсми булмаган статусы—заманча процессларга тәңгәл килеп торучы күренеш ул. Мәсәлән, Барселона, мөгаен, дөньяга Мадрид кадәр үк билгеле шәһәрдер, гәрчә рәсми төстә Каталония башкаласы гына булса да. Татарның тар милли аңын үтеп чыгуы Каталония үрнәгендә Россия һәм чит илләр кимәлендәге проектлар эзләү дигән сүз ул.

"Татар Русе" башкаласы буларак Казанга нәрсә җитми соң? Күрәсең, башкала рухы җитмидер. Мәскәүдәге мөлкәт җыю, җиңел табыш артыннан куу рухына, анда-санда баш калкыткан империячел карашларга альтернатива булырлык, кешеләрне берләштерерлек яңа идеяләр җитмидер. Федерализмны һәм демократияне яклау, һичшиксез, гомумтатар эшчәнлегенең иң мөһим юнәлеше, әмма киләчәк үсеш җәһәтеннән түгел, башлыча үз-үзеңне яклау ягыннан гына. Безгә милли кысалардан чыгарлык яңа проектлары булган һөҗүмчән программа кирәк һәм дә совет чорыннан калган мирасны - төбәкчел аңны җиңеп чыгу зарур.

Татарлар—үз тарихларында берничә мәртәбә үлем белән яшәү арасында калган халык ул, шуңа күрә дә этник яшәешнең бар нәрсәдән дә кадерлерәк икәне аңнарына сеңгән. Ассимиляция әле дәвам итә, әмма хәзер тулаем халыкка куркыныч янамый инде. Бүтән сыйфатка—конкуренциягә сәләтлелеккә күчү чоры җитеп килә. Бу үзгәрешне хакимият тә, акча да билгели алмый, ул рухи әверелешкә бәйле.

Руслар һәрвакыт "Нәрсә эшләргә?" дигән сорауны тәкърарлыйлар. Татарда ул бүтәнчәрәк яңгыраган: "Кемнән өйрәнергә?" Дәүләтчелеген җуйганнан соң үзенчәлекле, мөстәкыйль татар фикере бөтенләй юкка чыккан диярлек. Татар фикере гади бер идеягә—этник мәдәниятне саклауга кадәр тарайды һәм үз дәүләтен тергезү турындагы хыялга әйләнде, ул татарныкы булган бөтен нәрсәне идеаллаштырды. Татарларда руслардагы шикелле "Град Божий"ны эзләү дә, Тәңре-кеше турында фәлсәфә куерту да юк. Бәхетле киләчәк бездә халыкны якларлык гадел дәүләткә бәйле. Гаделлек эзләү юлында татарлар казакълар яки кыргызлар кебек "ак патша"га өмет багламады. Бөтен өмет үз көчебездә иде, һәм вөзгыять бүген дә шундый ук.

XX гасыр башында "Кемнән өйрәнергә?" дигән сорауга татарлар, иң әүвәл рус мәдәниятен күзаллап, Европадан, дип җавап биргәннәр. Алар Европаны бөек рус мәдәнияте аша кабул иткәннәр. Революциягә кадәрге татар мәдәнияте, дини киртәләрне җиңеп, халык үсешенең дөньяви механизмнарын эшләгән, бу хәл аның кимәлен кискен күтәргән. Татар мәдәнияте дөнья хәзинәләренә ачылган, ул бик хәрәкәтчән рәвештә бөтен яңаны үзенә сеңдерә барган, яңалыкларны үз тормышына кертеп кенә калмыйча, төрки дөньяга да тараткан. Үзәк Азиядә төрки телләрдәге бөтен матбугатны һәм нәшриятны татарлар башлап җибәргән, мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә һәм университетларда мөгаллим булып күбесенчә татарлар эшләгән. Мәдәниятнең ачыклыгы бик зур өстенлеккә әверелгән, чөнки ул иң заманча белемнәрне үзләштерергә ярдәм иткән.

Революциягә кадәрге бәхәссез казанышларның тагын берсе—икътисадый төзелмәләр үсеше. Татарлар үзләренең банк системасын булдыра алмый калганнар, ләкин сәүдә өлкәсе һәм сәнәгатьнең кайбер тармакларын инде үзләштергәннәр. Революциядән соң бу төзелмәләр буржуазия, кулаклар һәм интеллигенция сыйныфлары белән бергә юк ителгән. Татарларның бүгенге менталитетына баю, мөлкәт җыю рухы зур зыян салды. Совет чоры, саф милли әхлакны какшатып, шушы вәзгыятьне өзерләп биргән. Шәхси мөлкәт туплар өчен шартлар тугач, алар милли кыйммәтләр белән тигезләндерелмәде. Татарларның күп катлы коттеджлар төзергә һәм иң кыйммәт машиналар алырга ташлануы рухның зәгыйфьлеген күрсәтә. Инстинктлар рухи башлангычтан өстенрәк булып чыкты. Имамнар, рухи башлангыч тәрбиялисе урында, үзләре дә шул ук юнәлештә киттеләр. Аларны дәрвиш дип атап булмый, алар һич тә ярлы түгелләр.

Чынлыкта исә интеллигенция катламы чамадан тыш юка булып чыкты, өстәвенә, "үзгәртеп кору" шартларында бу катлам кәтмәгәндә хәерчеләнде һәм күп кенә зыялылар хәзер дә байлардан акча тамганын көтеп, очын-очка ялгап кына яши. Язучыларның таяныч ноктасы юкка чыкты һәм алар хәзер "фикер хакимнәре" түгел инде. Совет чоры - татар тарихында иң авыр заманнарның берсе иде, әмма шул чорда татар мәдәниятен нәкъ менә язучылар һәм театр сәнгате сөйрәп алып чыкты. Алар күренекле сәнгати казанышларны саклап кына калмадылар, яңаларын да тудырдылар. Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники, Муса Җәлил, Габдрахман Әпсәләмов, Туфан Миңнуллин һәм башкалар совет язучылары сыйфатында мәгълүм булсалар да, татар рухының чын сакчыларына әйләнделәр, үз күңелләрендәге милли очкыннарны "үзгәртеп кору" заманнарына кадәр китереп җиткерделәр. Һәм кинәт кенә бушлык пәйда булды. Татар язучыларының саны елдан-ел арта бара, ә укырлык нәрсә юк. Моны татарга гына хас күренеш дип әйтеп булмый. Рус әдәбиятында бу хәл иртәрәк тә туды әле. Типик пропаганда тәэсиреннән арынып, шәплөп уйлап карасаң, Михаил Шолохов, Анна Ахматова һәм Александр Твардовскийдан соң Хәсән Туфан һәм Әмирхан Еники белән янәшә куярлык совет язучысын табуы кыен. Безнекеләргә реклама гына ясалмады. «Кече» халыкларның шагыйрьләрен күтәрү куркынычсызрак иде: Рәсүл Гамзатовны, Кайсын Кулиевны, Даут Кәгелтдиновны яисә русларны—Астафьевны, Михалковны, Евтушенконы, Вознесенскийны, Рождественскийны, Богуславскийны алга этәрделәр. Рус шигърияте һәм рус прозасы заманында мәшһүр булсалар да, дәверләрдә сакланырлык әһәмияткә ия түгел. Чын "фикер хакимнәре" Чыңгыз Айтматов белән Олжас Сөләйманов иде. Сөләймановны тыярга да тырышып карадылар, Айтматов исә цензура өчен артык зур фигура иде. Шолохов үз әсәрләрендә Гражданнар сугышы чорын гәүдәләндерсә, совет чорын гәүдәләндергән бердәнбер әдип Чыңгыз Айтматов булды. Ул совет режимының ахырда тоталитар строены һәлакаткә китергән чир нокталарын да күрә белде. Кызганыч ки, бүген андый шәхесләр юк инде... Язучы үз заманы сулышын тоеп яши. Ул әле үз дәвере тәмамлангач та яши бирә, тик бернәрсә дә иҗат итә алмый инде. Шолохов Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң бер бөек әсәр дә язмаган һәм, гомумән, язудан туктап, үзенең хуторы Вешенскийда гади генә гомер кичергән, балык тоткан. Олжас Сөләйманов исә филологик тикшеренүләргә кереп китте. Чыңгыз Айтматов илдән-илгә йөри, анда аны XX гасыр классигы буларак кабул итәләр. Моны гаепләмик. Безнең язучылар да яңа шартларда югалып калдылар бит. Димәк, бу вазифаларны үз өстенә башкалар алырга тиеш. Имамнар милли һәм рухи бурычларны аңламыйлар икән, язучылар рухландыра алмыйлар икән, милләтнең рухи үсешендә кискен борылыш килеп чыкканга кадәр моның белән галимнәргә яисә сәясәтчеләргә шөгыльләнергә туры килә. Көтәргә, сабыр булырга һәм рухи ыргылышны өзерләргә кирәк.

Бүген татар икътисадый төзелмәләре дигән төшенчә юк—һәркем үзен генә кайгырта. Бу, әлбәттә, бөтен татар дөньясын какшата һәм ыргылышлы технологияләргә өзер булмаган зәгыйфь рухны чагылдыра. Татарстанның бик үк

алда булмаган икътисадый фикере Россиядәге сүлпән теорияләрнең калдыкларын кабатлый, тегеләре исә - көнбатышның бик үк яңа булмаган концепцияләренең тупас күчермәләре генә. Татарстанда фикер сөреше чималдан килә, ул гаклый, интеллектуаль фикер сөреше түгел. Нефть кеше акылын билән алган, ә нефть исә—узып баручы индустриаль дәвер нигезе ул. Нефть сәнәгате—эчке яну двигателенең колы. Дөньяда нефть сәнәгате мәнфәгатьләрен алга сөрүчеләр водород двигателенең дөньяга таралуына каршы торачаклар, "Токомак" белән нәкъ шулай эшләделәр дә, әмма экология күптән сәяси факторга әверелде һәм аның йогынтысы нефть яклыларга каршы торырлык дәрәҗәдә көчле инде. Дөнья энергиянең күпсанлы альтернатив, чиста чыганакларын уйлап табу юлыннан китәчәк, атом энергетикасы да, энергия җитештерүче башка гигант заводлар да булмаячак. Яңа, иң заманча "акыллы" нечкә технологияләр энергияне сак тотачак. Энергияне сак тоту һәм табигатьне саклап калу кешелекнең яңа кануннарына әвереләчәк.

Кызганыч ки, Татарстанда электроника һәм компьютерлар кебек киләчәк заман технологияләре үсеше урынына чимал тәшкилиятләре колач җәя, якын киләчәктә химияне алмаштырачак биологик индустрияне үстерәсе урында химия һәм нефть химиясе үсеше хуплана. XXI гасырның өстенлекле юнәлеше булган авиация һәм космик сәнәгать Татарстанда соңгы көннәрен кичерә. Геннар инженерлыгы бөтенләй үстерелми. Мәгълүмат технологияләре турында хыялланырга гына кала. Татарстан индустриягә кадәрге һәм өлешчә индустриаль дәвердә булып чыкты, өстәвенә аның үзгәреп торучы шартларда тиз генә үзгәртеп корыла алмый торган гаять зур предприятиеләре дә бар. Бюджет ясаучы бер дистә гигант урынына берничә мең кече һәм урта предприятие булса яхшырак, әлбәттә.

Тормышның икътисадый агымын базар үзе билгеләргә тиеш дигән легенда яшәп килә. Үсеш юнәлешен үзгәртү хакында сүз барганда моннан да мәгънәсезрәк нәрсәне уйлап табу мөмкин түгел. Япония, иң ыргылышлы технологияләр буенча АКШны куып тотарга ниятләгәндә, моны дәүләткүләм максат дәрәҗәсенә күтәрде. Япония хөкүмәте милләткә кирәкле юнәлешләрне оештырды, фәнни шәһәрләрнең 19 технополистан торган бөтен бер архипелагын төзеде, Нобель премиясе лауреатлары булган алдынгы инглиз галимнәрен чакыртып алды. Мондый нәрсәләрне базар хәл итми, бу—интеллектуаллар белән дәүләт төзелмәләренең уртак бурычы. Әлеге җәһәттән Россия төзелмәләре бөтенләй өметсез, алар безнең өчен үрнәк була алмыйлар. Анда да гаклый фикерләү түгел, шул ук чималга нигезләнгән фикерләү хакимлек итә. Россия хөкүмәтенә авиация дә, электроника да, информатика да кирәкми. Мәскәү кертергә тырышкан һәр нәрсә икътисадны башлангыч индустриаль чорга чигендерә.

Базар—кешене түгел, кеше базарны үз максатларына буйсындырырга тиеш. Парадигма үзгәрүнең мәгънәсе төп кыйммәт итеп республиканың постиндустриаль җәмгыять буларак үсешен билгеләүдән гыйбарәт. Шул чакта гына нефть торбасы тирәсенә чүмәшкән бер күч эшкуарлар гына түгел, бөтен кеше дә баеп китәчәк.

Интеллектуаль-мәгълүмати дәвер ресурслары чикләнгән кечерәк илләргә дә иң алдынгы илләр рәтенә чыгу мөмкинлеге тудыра. Электроникага һәм мәгълүмат технологияләренә исәп тоткан Сингапур, Мальта, Ирландия, Гонконг менә шуннан файдаландылар да инде. Кече дәүләтләр мисалы яңа икътисадый парадигма тудырган шушы мөмкинлекләрне аермачык күрсәтеп тора. Бөтен хикмәт фикер сөрешен үзгәртүдә. Табигый байлыклар да, ресурслар да, хәтта финанслар да кирәк түгел, фәнни һәм мәгариф үзәкләре булырлык университетлар, интеллектны ил байлыгына әйләндерүче белем һәм технологияләр кирәк. Боларның барысын да Көнбатышта, Японияда, Тайваньда, Сингапурда табарга мөмкин.

Урта гасыр мәзһәбләреннән оеган Көнчыгыш тирән йокыда хәзер. Казан университетлары Азиянекеләрдән кайтыш түгел, кайбер белгечлекләр буенча күпкә әйбәтрәк тә. Көнчыгышта технологияләр уйлап табылмый, фәнни

ачышлар ясалмый. Без һичшиксез Европага йөз тотарга тиешбез. Тик ул очракта табигый бер сорау туа: Европага нәрсә белән килеп керербез икән? Бердәнбер реаль өлешебез - евроислам, ягъни либераль идеяләрне ислам хәзинәләренә яраштырган караш. Иҗтимагый фикернең бу юнәлеше татарларны милли кысадан чыгарачак һәм шуның белән бергә Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында күперләр салачак.

Татар дөньясы үз университетына мохтаҗ, ул университет Татарстан Республикасы мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә, татарлар яисә Россиянең мәдәниятләре буенча татарга якын халыкларының мәнфәгатьләрен дә исәпкә алырга тиеш. Ул заманның яңа карашларыннан читләшмәскә тиеш, шуңа күрә укыту өч телдә: татар, дөресрәге, төрки-татар, рус һәм инглиз телләрендә алып барылырга тиеш. Татар телен төрки телләр кысасында һәм аларның һәммәсенә яраштырып укытырга кирәк, чөнки асылда ул төрки телнең казакъ, үзбәк, төрек, әзәрбәйҗан һәм башкалар кебек бер диалекты гына, аны шулай дип кабул итәргә кирәк тә. Тарихта шулай килеп чыккан инде: төрки диалектларының атамалары мөстәкыйль телләргә әверелгән, әмма бу хәл мәсьәләнең асылын күрергә комачауламаска тиеш. Татарлар төрки дөньяда моннан йөз ел, ике йөз ел элек эшләгән кебек эшләргә тиешләр. Бу безнең икътисадый һәм мәдәни киштәбез, безнең өстенлегебез дә шунда.

Тагын бер мөһим нәрсә—Татар университеты кысаларында уку процессын фәнни тикшеренүләр белән берләштерү. Дөньядагы алдынгы университетларның өстенлеге үзләрендә ясалган ачышларны укучыларга, студентларга турыдан-туры укытуда. Ниндидер арадашлык рәвешендәге өзеклек булу белемнең дәрәҗәсен киметә. Ачышлар ясаучы үзе укытырга тиеш, укытучы исә фән белән шөгыльләнергә тиеш, югыйсә бу уку йорты университет дип түгел, институт дип атала. Бу мәсьәләне хәл итү Татарстан Фәннәр академисе егәрен файдалануга бәйле. Академияне Татар университеты белән тоташтыру вәзгыятьне тамырдан үзгәртергә мөмкин. Татар университеты гамәлгә куелган вакытында ук Милли китапханә һәм электрон ресурслар кебек куәтле мәгълүмат системасына тоташтырылырга, шулай ук Көнбатышның алдынгы университетлары белән дә багланышта торырга тиеш. Шул чакта ул өметләребезне аклар һәм конкуренциягә сәләтле булыр.

Революциягә кадәр татарларны алга киткән милләт дәрәҗәсенә күтәргән мөһим юнәлеш - матбугат. Типографияләрнең, нәшриятларның, газета-журналларның күп тармаклы челтәре оешкан. Казанда, Оренбургта, Уфада татарча нәшер ителгән китаплар, Үзәк Азияне дә кертеп, бөтен Россия буйлап таралганнар. Революциягә кадәрге Россиядә татарлар иң күп китап укый торган милләт булган, бу җәһәттән алар руслар белән эстоннардан калышмаган. Горурланырлык хәл, әмма ул киләчәк моделе була алмый. Чынлыкта исә XX гасырда татарлар бик соңга калып булса да Европа Реформациясе тәҗрибәсен кабатлаганнар. XXI гасырда вәзгыять үзгәрде. Бүген басма китапның тарихи вазифасын Интернет башкара. Димәк, төп басым заманча мәгълүмат системаларына ясалырга тиеш. Татарлар өчен милләтне ил чикләрен, административ киртәләрне һәм башка чикләүләрне үтеп чыгып берләштерерлек бик олы ресурс бу. Ул татар һәм дөнья мәдәниятенең барлык казанышларыннан бушлай файдаланырга мөмкинлек бирәчәк,—бу техник яктан тәэмин ителгән очракта, әлбәттә. Татар тормышының үзенчәлеге җирлелек тә, экстерриториальлек тә гамәлдә булу. Бер яктан, татарларның тормышы билгеле бер авылда яисә шәһәрдә уза, икенче яктан, татарлар дөнья буйлап сибелгән. Бер яктан - яшәргә сәләтле Татарстан, икенче яктан—бөтен татар мәдәниятенә хезмәт күрсәтү ихтыяҗы, монысы исә республика мөмкинлекләре белән чагыштырырлык та түгел. Милләтнең яшәү рәвешендәге әлеге каршылыкны иң заманча мәгълүмат системаларыннан башка җиңеп чыгармын димә.

Интернет татарга теле буенча бер-берсенә якын торган мәдәниятләрне бер метапространствода берләштерү мөмкинлеге бирә. Мондый проектны гамәлгә ашыру өчен икътисад һәм хакимият төзелмәләре ике мөһим шартны үтәргә тиешләр. Беренчесе—"Inalif" вариантындагы латин алфавитына күчү,

икенчесе—татарларга Интернетка керү мөмкинлеген тәэмин итү. Беренче мәсьәлә игелекле ниятка нигезләнгән һәм моңа бернинди дә чыгымнар кирәкми. Икенчесе чыгымнар таләп итә, ләкин телефон элемтәсе үскән саен үзеннән-үзе хәл ителәчәк. Татарстанның бурычы—элемтә чараларын үстерү генә түгел, шулай ук икътисад, мәдәният, тел, тарих өлкәсендә дә гаять куәтле сайтлар рәвешендә мәгълүмат ресурслары булдыру, тугандаш төрки культураларга мәгълүмат ресурсларын алмашу турында тәкъдим белән чыгу. Бу - татарларны тар милли кысалардан чыгаручы юнәлешләрнең берсе.

Милли рух—ихтыярны белемгә кушу ул. Әмма акча җыю белән мәшгуль кешенең ихтыяры булмый, ул һәр кичне эшләгән долларларын санап утыручы сәүдәгәр психологиясе тәрбияли торган мөнәсәбәтләргә тартып кертелгән. "Саран рыцарь"—авыру кеше, һәм бу мөнәсәбәтләргә кертелгән милләт тә чирле. Икътисадый проектлар иҗтимагый, милли максатларга хезмәт итәргә тиеш. Киң колачлы берләштергеч кыйммәтләр булмаган очракта дәүләт төзелмәләре коррупциягә бирешә. Бөек Кытай дивары дошман кучмәләр өчен үтеп кермәслек булган, әмма коррупция бу диварны татарлар өчен үтә күренмәле иткән.

Милләт үсеше формуласы, гомуми рәвештә, өч өстенлекле бурычны үтәүдән гыйбарәт: (1) заманча белем алу; (2) газеталарны, спутник телевидениесен, радионы, Интернеттагы сайтларны да кертеп, мәгълүмат ресурслары оештыру; (3) гомуммилли икътисадый проектларны гамәлгә ашыру өчен мөстәкыйль финанс чыганаклары булдыру.

Татарларга үзләренең арттa калуына сәбәпче дошманны эзләү темасыннан котылу мөһим. Россия дәүләте барлык халыкларны, шул исәптән русларны да тупикка куып кертте. Бүген бу сазлыктан үз көченә таянып кына, демократия һәм федерализмны яклап кына, империячел инстинктларга, башбаштаклыкка һәм җиңел табыш артыннан куугa каршы торып кына чыгып булачак. Гамәлдәге стереотиплардан кыенсынмыйча: "Мин—татар!" дип авыз тутырып әйтергә кирәк.

## Йомгаклау сүзе

II меңьеллыкның башында Евразиянең дала киңлекләрендә төрки һәм славян культуралары туган. Аларның юллары һәрдаим Дон, Днепр, Идел елгаларында кисешкән. Әле бер як, әле икенче як өстенлек алган. Һәркем үз хакыйкатен яклаган. Әле берсе, әле икенчесе уңыш казанган.

Татарлар, Россия империясенә килеп эләккәч, тарихтан берничә гасырга төшеп калганнар. Өстәвенә аларга рус җирләренә дәгъва итүче килмешәк баскынчылар дигән ярлык тагылган. Тарих фәне гади максатка хезмәт иткән: татар дәверен төшереп калдырырга, оныттырырга, Алтын Урданы каралтырга, татарларны кимсетергә. Рус һәм көнбатышның тарих фәне, нигездә, татар-монгол һөҗүменең коточкычлыгын тасвирлый һәм бөек дәүләтнең иҗади рухы хакында бер сүз дә әйтми. Нәтиҗәдә руслар гына түгел, хәтта татарлар да үзләренең үткәнен начар беләләр.

Русның тарихи традициясе татар белән көрәшкә корылган. Чынлыкта исә татарларның да, русларның да тарихы Алтын Урдага барып тоташа. Ошыймы, ошамыймы, әмма нәкъ менә Алтын Урда татарларның да, русларның да һәм башка бик күп халыкларның да уртак ватаны булган. П.Н.Савицкий Л.Гумилевка язган хатларының берсендә болай дигән: "Русь үзен монгол татарларының бик сәләтле "укучысы" буларак күрсәткән һәм күп кенә очракларда үзенең "укытучыларыннан" уздырып та җибәргән... Русьның бөек бөтендөнья тарихы мәйданына үз вакытында нәкъ менә "монгол изүе" тарафыннан чыгарылганын һәм бу "изү"нең Русь өчен бөек монгол-татар "мәктәбенә" әверелгәнен сукыр кеше генә күрмәскә мөмкин. Хәзерге вакытта бу ап-ачык хакыйкатьне инкарь иткән тарихчылар, бәлки үзләре дә сизмәстән, XIII-XV гасыр монгол-татарлары хакындагы күзаллаулардан, ягъни "түбән раса", ерткыч хайваннар

дигәннән чыгып фикер йөртәләрдер? Ерткыч хайваннан игелек көтеп буламыни?! Чынлыкта исә Русь монгол-татарлардан шактый күп яхшылык сеңдергән. Шул исәптән ул алардан милләтләргә һәм диннәргә тигез караш күнекмәләре дә алган".[5] Нәкъ менә Алтын Урда тарихында Россиянең дәүләт буларак бердәмлеге фәлсәфәсе салынган. "Табигый чикләр"не география түгел, илне берләштерүче мәдәният билгели ләбаса.

XX йөз - күп яктан югалган гасыр, гәрчә бөек рус мәдәниятенә, аның аша Европа мәдәниятенә кушылу татарлар өчен гаять зур адым булса да. XX гасырны Россия белән бергә узып, без яңадан юлның башына килеп чыктык. Меңьеллык азагында руслар да, татарлар да тарихны яңадан ачкан сыман һаман шул иске сызыкта торып калдылар. Яңа меңьеллык зур сынаулар алып килә, бу сынаулар каршында төрле цивилизация вәкилләренә үз көчләрен берләштерү бер дә зыян итмәс иде.

Бүген Татарстан һәм Россия тагын юл чатында. Бу юлы тарихи бәхәснең ни белән бетәсен әйтүе кыен! Мөмкинлекләр тигез түгел, тик һәркемнең үз шансы бар. Лев Аннинский язганча, "бөтен яңалык искелек куенында өлгереп җитә һәм, искелекне каһәрләп, аңа килеп төртелә, тора-бара үзе дә шул көнгә кала. Урда белән Русь Евразиядә өстенлек алу өчен көрәшә һәм ахыр чиктә Мәскәү таҗын кигән иң яхшы хаким Урда нәселеннән булып чыга..."[6] Вакыт хөкемне үзе чыгарыр, әлегә Мәскәү һәм Казан интеллектуаллары илнең киләчәген күзалларга тырышалар.

X гасырда Лейф Эриксон җитәкчелегендәге викинглар Төньяк Америкага барып чыкканнар һәм бу сәяхәтне тасвирлап биргәннәр. Колумб Американы яңадан ачкан, аның кулында бу кыйтганың XV гасырның беренче яртысында швейцар монахы төзегән картасы булган. Килер бер көн: "Тартария" исемле кыйтганы да яңадан ачарлар.

Татар ханнары үзләренең юлламаларын: "Мин әйттем!" дип тәмамлаганнар.

Сүзем!

*Сәфәр кыеннарын күп көн кичердем,*
*Килеп җиттем, ахыр, хезмәт өчен мин.*

*Ниләр күрсәм дә мин юл йөргәнемдә,*
*Тогәл йөрдем, тогәл килдем, көнендә.*

*Бик акыллы сүз әйтте миңа бер карт:*
*- Кичексәң дә килми калма—килү шарт.*

*Килүдән ошбу максат торды алда:*
*Теләгемне үтәр монда хак алла.*

*Шөкер хакка—бу максатка китерде,*
*Теләк-өмет җәясен нык киерде.*

*Котб. 1340 ел.*

---

[5] Из писем П.Н.Савицкого Л.Н.Гумилеву. – Л.Н.Гумилевның "Черная легенда" китабында, 478 нче бит.

[6] Храмом - по библиотеке?! // «Родина». №2, 1998.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕ НИЧЕК ҖАНЛАНДЫРЫРГА?

*Күптән түгел редакциядә журналыбызның даими авторлары—күренекле әдәби тәнкыйтьчеләр, язучылар—катнашында «Әдәби тәнкыйтьне ничек җанландырырга?» дигән темага «Түгәрәк өстәл» сөйләшүе булып узды. Укучыларыбызга әлеге сөйләшүдә яңгыраган кайбер чыгышларны тәкъдим итәбез.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН:**

—Җәмгыять үсешенә матур әдәбиятның тәэсир көче ни дәрәҗәдә булса, тәнкыйть, гомумән әдәбият фәне турында да шул нисбәттән чыгып фикер йөртергә туры килә. Һәммәбез белә: чын әдәбиятның кадере элгәрге гасырлар белән чагыштырганда шактый кими төште. Кеше аңына тәэсир итү чаралары күбәйде, төрләнде, баеды. Нинди чаралар икәне һәммәбезгә мәгълүм. Әле моннан 40-50 еллар элек кенә китап (бу очракта әдәби әсәрләр дип уйлыйк) Адәм баласы өчен Дөньяны танып-белүдә ышанычлы төп чыганак иде. «Китап—белем чишмәсе» дигән шигарь белән үстек ләбаса! Галәмилек, компьютерлык, клонлаштыру һәм тагын байтак галәмәтләр нәтиҗәсендә дөнья ничек кенә үзгәрмәсен, Кешелек яшәгәндә Сүз сәнгатенең мәңгелек көченә ышанам мин үзем. Адәм баласы фани дөньядагы соңгы сүзләрен, барыбер, «акыллы машиналар»ның серле төймәләренә карап түгел, кемнәрнеңдер ышаныч сыяр күзләренә төбәлеп, күңел җылысына өмет итеп әйтердер... Әмма!... Кырыс замана шигъри күзаллау белән дә, табигый мантыйк белән дә хисаплашмый кайчак. Шунысы ачык: күп яки аз санлы исәпләнәме, һәр халыкта да, Сүз сәнгате (ягъни әдәбият) хәвефле зур сынауда хәзер. Әгәр Аны сакларга телибез икән, әгәр бу эшкә алынганбыз икән, бездән бөек, ким дигәндә, камил әсәрләр иҗат итү сорала! Һәрхәлдә язучы шуңа омтылырга тиеш. Бу девиз безгә бигрәк тә кагыла, татар үзенең төп тарихи байлыгын—китабын югалтса, (ягъни телен югалтса), аның милләт буларак киләчәге булмастыр.

Инде бүгенге сөйләшүгә конкретрак килик. Темабыз: «Әдәби тәнкыйтьне ничек җанландырырга?» Тирәнрәк уйласаң, «ничек реанимациядән чыгарырга?» дигән мәгънә дә аңлашыла бу сүзтезмәдән. Хәер, әле беркайчан да «әдәби тәнкыйть гөрләп үсә» дигәнне ишеткән юк, тәнкыйть үзе гел тәнкыйть астында (кемнәрнеңдер аның бүген дә Добролюбовлар заманындагы ролен күрәсе киләдер. Мондый теләкне дә аңлап була). Бәлки, репрессия елларында тәнкыйтьне тәнкыйтьләргә базмаганнардыр, анысы да куркудан гына... Минемчә, бөтен житешсезлекләрне таныган очракта да, безнең хәлләр әлегә ул кадәр мөшкел түгел. Иң мөһиме: әдәбиятыбыз бар, аны тудыручы талантлы язучыларыбыз бар. Әсәрләрне бастырып чыгаручы нәшриятларыбыз бар. Укучыларыбыз бар. Әдәби хәрәкәтне әйдәп барырлык басмаларыбыз бар. Бу хәрәкәтнең дөрес юнәлештә баруын теләүче галимнәребез, тәнкыйтьчеләребез бар... Шул ук вакытта... проблемаларыбыз да бар. Алай гына да түгел, алар—күп. «Казан утлары», тарихи миссиягә ия төп әдәби журнал булгач, табигый, кайбер актуаль мәсьәләләрне кадәри хәл эш алып барырга тырыша. Соңгы 15-20 ел эчендә генә дә безнең карашка актуаль дип саналган дистәдән артык зур сөйләшүләр, дискуссияләр, иҗади конференцияләр уздырылды. Аларда байтак язучылар, галимнәр, сәясәтчеләр, укытучылар һәм башка фикер ияләре катнашты. Һәркем үзе аңлаганча, үзе булдыра алганча, әдәбиятыбызны үстерүгә, Сүз сәнгате аша милли идеягә чыгып, халкыбызның асыл сыйфатларын, рухи потенциалын киләчәктә ничек саклау турында тәфсилле фикер алышты.

Хәтерегезләдер, үткән ел гына «Безнен заман герое» дигән дискуссиягә йомгак ясаган идек. Ике ел чамасы барды ул сөйләшү. Зур әчке мәгънәгә ия бәхәс булды дип уйлыйм мин ул язмаларны.

Менә янәдән, тәнкыйть хәлләре белән бәйләп, әдәби киләчәгебез турында сөйләшергә җыйналдык. Журнал тарафыннан җавап алыр өчен шартлы булса да кайбер сораулар да тәкъдим ителгән иде.

Сүз унаеннан, үземнән дә кайбер сорау-фикерләрне өстәп үтим. Әйтик, тәнкыйтьнең язучы өчен кирәклек дәрәҗәсе; тәнкыйтьче—язучының укучы белән арадашчысымы яки әйдәүчесеме; традиция һәм новаторлык мәсьәләләре бүген ни хәлдә; тегe яки бу темалар бездә һәм бүтән әдәбиятларда ничек чагыла да ничек чишелеш таба; бүгенге китап ташкынында тәнкыйть юл күрсәткеч ролен үтиме; төрле жанрларга мөнәсәбәттә тәнкыйтьнең торышы ничек; Татарстанда соңгы биш-алты ел эчендә унбишләп классик язучының күптомлыклары чыкты, нигә алар турында тәнкыйтьчеләребез дәшми; әдәби тәнкыйтьнең киләчәк перспективалары нинди?... Әдәбият тарихына, аның теориясенә, көндәлек тәнкыйтькә караган бихисап сорауларның кайберләре генә болар. Һәркемнең үз сораулары бардыр. Аларга җавап рәвешендә фикерләр ишетәсе килә, хөрмәтле каләмдәшләр!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН:**

—Әдәбият дөньясына мөнәсәбәте булган берәү дә «тәнкыйть—тар өлкә, ана зур ихтыяҗ юк, ул бер төркем галим-голәмәләр генә шөгыле» кебек көфер фикерне ачыктан-ачык әйтмәс, «тәнкыйть кирәкле, файдалы шәй» дип, кулын күкрәгенә куеп, ихласлыгын белдерергә ашыгыр. Чөнки классикларыбыз, бигрәк тә кин күңелле Тукай, агымдагы тәнкыйть мәсьәләләренә дикъкатен беркайчан да киметми, аның кирәкле жанр булуын искә төшереп, үсешенә юнәлеш биреп тора. Мәгәр әдәбият тарихы үзе язучыларның (укы: җәмәгатьчелекнең) тәнкыйть торышыннан тулысынча канәгать булган бәхетле елларны хәтерләми. Чөнки һәммәбезгә яраса—тәнкыйть тәнкыйть булудан туктый инде ул. Анысының жанры башка—мәдхия, дифирамб. Тәнкыйть бәжрәсына эләккән язучы өчен усалрак күренгән чыгыш берьяклы, начар, тенденциоз, хәтта объективлыктан ерак торган яла ягу буларак бәяләнә. Профессиональ тәнкыйтьчеләрнең элек-электән бер кул бармаклары санынннан артмавы, яшәү, гаилә тормышын алып бару өчен тагын каядыр эшләү мәҗбүрияте, каләмнәрен әүвәл бу жанрда тибрәтеп тә, күбесенең башка жанрга күчүе (әйтик, М. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Мөдәррис Вәлиев) күп нәрсә турында сөйли.

XX гасырның икенче яртысында иҗат иткән, төп хезмәтләре дә язу-сызу белән бәйле ике тәнкыйтьчене генә беләм: Фәрваз Миңнуллин һәм Рафаэль Мостафин. Тәнкыйть һәм әдәбият белеме өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен ике каләмдәшебез генә Тукай исемен йөртүче бүләккә лаек булды: Нил Юзиев һәм Рафаэль Мостафин.

Дөрес, тәнкыйть жанрын язучылар үзләре дә читләтеп үтмиләр. Еш кына аларның язмалары йоклап яткан миләрне уятып җибәрә. А. Хәлимнең «Сез беләмсез кая барганны?» дигән тәнкыйди язмалары кырмыска оясына таяк тыккан эффект тудырды. Әсәрләре мактап телгә алынмаган, тәнкыйть сүзе эләккән язучылар, мирасыбызны тел-теш тидерүдән саклаган булып, мәкалә авторын төрле гөнаһларда, берьяклылыкта, субъективизмда, хәтта пычраклыкта гаепләү җаен эзли башладылар. Кайбер бәяләрендә хаталанса да, бүрәнәне балта белән генә чокып узса да, А. Хәлимне битарафлыкта, салкын канлылыкта, догматизмда гаепләп булмый.

Тәнкыйть ул футбол кырындагы тупны хәтерләтә. Ана типкәләп китүне һәркем үзенә мәртәбә саный. Ә капкада татар егете Ренат Дасаев юк. Мондый кызыктыргыч, күңел кытыгын бастырырдай (тәнкыйтькә һич югында «мине бәяләп бетермиләр» кебек дәгъва булмыйча калмый, язучы да адәм баласы ич) гамәлдән зыялы, зәвыклы сүз осталарыбыз да тыелып кала алмыйлар. А. Хәлим дә бу цех әһелләренә, бигрәк тә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына шактый йомры тәнкыйди фикерләрен индерә!

Әле кайнарлыгы суынып та җитмәгән чыгыштан яңа мисал. «Мәдәни җомга»да А. Тимергалин М. Галиевнең «Рух» китабын тирәнтен анализлап, нәзари фикерләрен инсани уйлануларына, йөрәк җылысына төреп, әдәби әсәр кебек укыла торган «Марсельезалы сәхифәләр» исемле эссе белән чыкты (3-9 октябрь, 2006). Югары

эстетик кимәлле мәкаләсендә дә автор әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр мичкәсенә бер кашык деготь салып китүне кирәк таба. «Гыйльми дәрәҗә тәхетеннән торып язылган җансыз мәкаләләр чыкмый калмас әле. Тик без аларны укырбызмы икән?» «Гыйльми дәрәҗә тәхете» нинди була икән дә, «җансыз мәкалә җанлыдан нәрсәсе белән аерылып тора?» дигән софистик сораулардан тыелып калып, М. Галиев иҗаты турында язарга алынган һәр кеше дә «бөек фантаст» дәрәҗәсендә фикерләү сәләтенә, шундый эрудициягә ия булмаска мөмкин диясе килә. Тәнкыйтьнең үз кысалары, жанрлык хасиятләре турында онытырга ярамый. Ул чәй эчкәндә яисә йоклап китү өчен укыла торган юморесканы алыштыра алмый, интеллектны эшкә җигүне сорый. Кечерәк күләмле әсәрләргә, шигырь җыентыкларына газит-журналларда күзәтүләр еш басылып, гадәттә сөйләшү үзәгендә поэзия торса, күләмле әсәрләр, саллы иҗтимагый-тарихи романнар тәнкыйть фикерен сирәк ишетәләр. Әйтик, Ф. Садриев, В. Имамов, Ф. Сафин, Ф. Бәйрәмоваларның XXI гасыр башында дөнья күргән романнары, җитмеш яшьне узгач ифрат активлашып киткән З. Зәйнуллин, М. Әмирханов иҗатлары да тәнкыйтьнең игътибарына, проблемалы мәкаләгә лаеклылар.

Әдәбият белән тәнкыйть алдында торган олуг бурычларның уртак икәнен онытырга ярамый. Ул - милләт мәнфәгатьләре белән рухланып, аңа буйсынып яшәү рухыннан, коллык психологиясеннән арынырга ярдәм итеп, горур, кирәк чакта үзен тәкәббер тотарга, кыскасы, олы тарихына лаеклы тормышка өндәүгә, шуна өйрәтүгә чакырылган. Кыскасы, тәнкыйть олы хакыйкатьләр белән яшәргә, укучының акылын һәм җанын баетырга, аны сүз сәнгатенең сурәт-тел, төсмерләр байлыгында тәрбияләргә тиеш. Тәнкыйтьче «чапанын» җилкәсенә элгән кеше яналыкка сизгер, үз-үзенә таләпчән, ялган дуслык коткысына бирелмичә, бәясендә ихлас һәм гадел булса гына каләменнән төшкән җөмләсенә ихтирам уята ала.

Мина калса, язучы тәнкыйте белән профессиональ тәнкыйть арасында аерманы танырга һәм икесенә ике төрле таләп белән килергә кирәк. Р. Фәйзуллин, А. Тимергалин, Р. Харис, Р. Батулла, Р. Гаташ, З. Мансуров мәкаләләрен образлы өслүб, йөгерек тел, һәр халыкның менталитетын билгеләүче милли хис, миллилек кебек сыйфатлар, эчтәлек белән сәнгатьлелекне илаһи бөтенлек итеп бәяләү бизи. Язучыларның әдәби тәнкыйтен хуплаган хәлдә дә, аларның күбрәк иҗади нәтиҗә, уныш, матурлык, рухи дөнья турында язып, аналитик бәя бирүгә алынмауларын, ул якны максат итеп куймауларын искәртү мөһим. Укылмый торган тәнкыйди, «җансыз мәкаләләр» язу, каймагы аертып алынган «сипарат сөте», мәгълүм мәзәктәге кебек, «укыган кешегә»—профессиональ тәнкыйтьчегә кала.

«Яшьләр бу авыр жанрны яратмыйлар, фәнни хезмәтләр язып туйгач, тәнкыйтькә берән-сәрән генә киләләр» дип зарлангалап алсак та, теоретик әзерлекле, әдәби матурлыкны, тел бизәкләрен тоеп язучы яшь көчләребез бар икән. Алсу Шәмсутова, Фәридә Хәсәнова, Ләйсән Кәшфиева, Нурфия Гафиятуллина һәм XX гасыр башы белән ахырын салават күпередәй полифоник, төрле төсмерле фикерләре ярдәмендә якынлаштырып, янача уйланулы китаплары белән туктаусыз шатландырып торган Дания Заһидуллина хезмәтләре әдәбият белеменең киләчәгенә өмет уяталар. Тәнкыйтьне Ж. Вәлиди, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Халит, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Ф. Миннуллин кебек гаярь затлар тоткан чорларны сагынып яшәсәк тә, бу синтетик жанрга ир-егетләрнең аз килүе, бәйгегә сирәк чыгуы күнелне тырнаса да, безнең чорда хатын-кыз тәнкыйтьчеләребезгә үзләрен күрсәтү мөмкинлегенең чикләнмәгән булуына шатланып та куясың. Бу сөйләшүдә төрле буын тәнкыйтьчеләре бер өстәл артына җыелуы милли тәнкыйтебезнең хәзерге торышы турында фикер алышырга, бәхәсләшергә, еллар буена җыела килгән мәсьәләләрне уртага салып сөйләшергә, ачыкларга, үстерергә булышачагына ышанам мин.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН:**

—Әдәби тәнкыйтебезнең бүгенге торышы, әдәбиятыбызның төп мөнбәре булган журналыбыз битләрендә аның урыны турында сөйләшүебез бик вакытлы. Чөнки, күреп торабыз, бу өлкәдә хәлләребез шәптән түгел. Иң беренче, тәнкыйть сүлпән. Бүген, яманмы-яхшымы, әдәби әсәрләр гаять күп, төрле-төрле. Һәм шушы хәл аны объектив бәяләүгә бигрәк тә мохтаҗ итә. Ярый, аерым әсәрләргә тәнкыйть күренмәсен дә ди. Моны: андый әсәр тәнкыйть игътибарыннан түбән, анар игътибар

итмәү шул ук әйтелмәгән тәнкыйть инде ул, дип карарга да мөмкин, әлбәттә. Ә бит үзенең фикере белән, нинди дә яңалык алып килүе белән мөһим булган, сәнгатьчә эшләнешендә кайбер килеп ук җитмәгән яклары белән тәнкыйть күзенең уңында торырга тиешле әсәрләр дә шактый иҗат ителә. Яки сәнгати ягына алай ук тел-теш тидерерлек булмаган, әмма укучыны рухи үстерә алмаган, алай гына да түгел, аны рухсызлыкка өстерәүче яки фикер тарлыгы ачык булган әсәрләр дә дөнья күрә. Әмма андыйларының кимчелекләрен укучыга да, авторның үзенә дә аңлатып бирергә тиешле тәнкыйть еш кына дәшми.

Кызганычы тагын да шунда, кайберәүләр аны гомумән дә кирәксезгә чыгарырга тырышалар, тәнкыйтьчеләрне гомумән дә хәкарәт итәргә омтылалар. Марсель Галиевнең матбугаттагы һәм телевидениедәге саксыз бер чыгышында шул ачык булып урын алды. Иҗаттагы бер өлкәне алга куеп, икенчесенә төкереп карау юлы белән китсәң, тормышта гади эш кешесенең шөгыльен, яшәешебезне тәэмин иткән профессиясен мыскыллавына кадәр барып җитәргә мөмкин. Сәнгать әһеле моны гына аңларга тиеш, югыйсә.

Шөкер, «Казан утлары» журналын югары кимәлдә яшәтеп килүче редакция хезмәткәрләре тәнкыйтьнең әдәби процесстагы ролен һәм урынын асылда дөрес аңлыйлар дип уйлыйм. Моны журнал битләрендә ике ел алып барылган дискуссия дә раслый. Нигездә ул уңышлы булды, бигрәк тә яшь һәм башлап язучылар, матур әдәбиятка битараф булмаган укучылар өчен файдалы булды дип исәплим. Дискуссия унае белән тәнкыйтьнең алга үсеше өчен урынлы булырдай фикерләр дә яңгырады. Шул унай белән әдәби тәнкыйтькә юл бирү, аны кабул итүнең дөрес юллары, фикерләр каршылыгын матбугатта чагылдыру мәсьәләләре тирәсендә бәхәсләр дә урын алды. Бәхәсләр Язучылар берлегендәге тәнкыйтьчеләр остаханәсенең бер утырышында да калкып чыкты. Кайбер мәкаләләрнең артык кискен булган, күпчелек хата дип кабул иткән урыннарын укучыларга җиткермәскә дә мөмкин иде, ягъни аны кыскартып бастырырга кирәк иде дип фикер йөрттеләр. Андый мәкаләләрне бастырмаска кирәк дигән сүзләр дә булмады түгел. Оппонентлар исә «бу элеккерәк заманнардагы яман аты чыккан цензурачылыкка әйләнеп кайту булыр. Мондый алымны кулына беренче мәртәбә каләм алган, әлегә тәҗрибәсез авторларга карата гына кулланырга мөмкин. Ә инде әдәбиятта үз урынын тапкан, тәҗрибәле авторларны кысарга ярамый, ничек язса (әгәр дә инде бик тә мәгънәсез язма тәкъдим итмәгәндә!), шулай бастырырга кирәк», дигән карашны якладылар. Монда бүгенге тәнкыйтебезгә җитмәгән сыйфат ярылып ята. Әгәр дә автор белән килешмисең икән инде, үз фикерләреңне алга сөреп җавап яз! Һәм матбугат органы анар тиешле урын бирсен. Ә кайбер газитләрдәге кебек, «бу турыда алга таба сүз алып бармыйбыз» дип кире кагып утыру булмасын. Чын, зыялы бәхәс урын алсын. (Тукайлар, Фатих Әмирханнар чорында, хәтта советның беренче унъеллыгында да ул шулай булган.) Яисә, татар милләте мәнфәгатьләре өчен гамәли эшләре белән дә җан атып йөргән, үзенчәлекле иҗаты белән дә күрәшкән олы язучыбыз Зәки Зәйнуллинның бүгенге театр һәм драматурглар иҗаты турында («Шәһри Казан», 2006, 8 сентябрь) бик тә бәхәсле мәкаләсенә шактый ук урынлы каршы чыккан укучыны редакция мөнбәреннән торып мыскыл итүләр булмасын («Шәһри Казан», 2006, 6 октябрь). А. Хәлим мәкаләсе унае белән дә шулайрак килеп чыкты. Андагы кайбер фикерләр белән тамырдан килешмәсәк тә, без аларга (тәҗрибәле каләмдәшебез Рафаэль Мостафиннан кала) тиешле бәя бирә алмадык, матбугатта дәшми калуны артык күрдек...

Әдәби тәнкыйть, әдәбият белеменең бу мөстәкыйль тармагы—бик тә кадерсез, борчулы өлкә. Шагыйрь, чәчмә әсәр авторы укучының рәхмәтен еш ишетә, бигрәк тә драматург тамашачының алкышларына күмелә—күңел рәхәтлеге кичерә. Тәнкыйтьчегә болар бик үк эләкми, аның каравы тәнкыйть каләменә эләккән авторның каһәрләвен ачыктан-ачык ишетмәсә дә, аның үзенә карата чытык йөзен күрә, исәнләшми дә, күрми дә узып китүен еш очрата. (Яшьрәк буын тәнкыйтьчеләре өчен бу хәл алай ук тәэсир итмәскә дә мөмкин, аларның нервлары ныграк, әлегә тушалмаган. Ә өлкән буын?!..) Тәнкыйтьчене шуның өчен генә, шуларга түзеп, иҗатын дәвам иткәне өчен генә булса да хөрмәт итәргә кирәк, югыйсә. Ә аны белемсезгә, әдәбиятны аңламаучыга, төшеп калганнарга чыгарып хәкарәт итмәскә кирәк...

Әдәби тәнкыйтькә яшьләрне күбрәк тартырга, аларны тәрбияләргә кирәк. Элекгә журнал тирәсендә яшьләрне оештыру бар иде. Үземнән мисал китерә алам. Менә,

әле 3 нче курста укыган вакытымда, бу эшкә редакция хезмәткәре, тәнкыйтьче Илдус Ахунҗанов тартып керткән, заказлар биреп, беренче рецензияләремне бастырган иде. Танылган тәнкыйтьчеләр Фәрваз Миннуллин, аннары Мансур Вәлиев журнал тирәсенә яшьләрне җыйнап, эш алып баралар иде. (Заманында бу эш белән «Ватаным Татарстан» газите дә актив ук шөгыльләнде.) Күренекле тәнкыйтьчебез М. Вәлиев әллә арыбрак киттеме, әллә прозага күчүне кулайрак таптымы... бу эш күз уңыннан төште. Ә бит яшьләр бар! Мәсәлән, безнең университетта «Тәрәзә» исемле студентлар газите уңышлы чыгып килә (шефы—иҗатында да, яшьләр белән эшләүдә дә яхшы мәгънәсендә тынгысыз Галимҗан Гыйльманов, мөхәррире—яшь талант Ленар Шәехов). Аның тирәсендә тупланган яшьләрнең иҗатка сәләтләре, омтылышлары ачык күренә. Ә үзем алып бара торган «Хәзерге татар драматургиясе» дип аталган махсус курста 1131 нче төркем студентлары мине бу яктан активлыклары белән сокландырды. Алар драматургия һәм театр процессына карата игътибарга лаек фикерләр дә әйттеләр, бәхәсләр дә алып бардылар, фикерләрен раслау өчен аерым пьесалардан өзекләр уйнап та күрсәттеләр... Андыйлардан файдаланырга кирәк. Күмәк рецензияләр дә, аерым-аерым кыска фикерләр дә яздырып карарга, кыскасы, үстерергә кирәк. Моның өчен журналыбыз битләрендә «кыска рецензияләр» дигән исем беләнме, «укучы фикере» исеме астындамы бер рубрика ачып җибәргәндә яхшы булыр иде.

Тагын бер тәкъдимем бар. Актуаль темага дискуссияләр уздыруда журналның тәҗрибәсе зур, моны алга таба да алып барырга кирәктер. Мәсәлән, күптән инде бездә драматургия буенча зурдан кубып сөйләшү булганы юк. Хәлбуки, кирәклеге күз алдында. Пьесалар язучы авторларыбыз күбәйде, кызыклы эзләнүләр бара. Театр тәнкыйте беркадәр җанланды. Драматургия тәнкыйте өлкәсенә дә яңа авторлар килде (Әлфәт Закирҗанов, Алсу Саттарова һ.б.). Шулай да без сәхнә әдәбиятын бәяләүне театр белгечләренә генә биреп бетердек булса кирәк. Әлбәттә, моның нигезләре бар: пьеса бар көченә сәхнәдә, режиссерлар һәм актерлар хезмәтендә тулы ачыла, һәм спектакль турында язганда тәнкыйтьче тегеләйме-болаймы әдәби материалга да кагылып уза. (А. Юнысова, Д. Гыйммранова, А. Хәсәнова, А. Габәши һ. б. рецензияләре шуның матур мисаллары.) Шулай да драматургия—мөстәкыйль әдәби төр, шуңа күрә аны иң әүвәл әдәбиятчылар анализларга тиеш. Татар пьесаны сәхнәдән карарга гына түгел, укырга да бик ярата бит. Сөйләшергә иде бер иркенләп драматургиябезнең бүгенге торышы турында. Моның зарурлыгын З.Зәйнуллинның алда искә алынган чыгышы да раслап тора...

**Рафаэль МОСТАФИН:**

—Мин «Казан утлары» битләрендә әдәби осталык турында дискуссия үткәрүне теләр идем. Минемчә, соңгы елларда безнең әдәбият бу яктан шактый аксый. Поэзия һәм прозадагы аксакалларыбыз (Х. Туфан, М. Әмир, С. Хәким, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев һ. б.) киткәннән сон, яшь буын бу якка игътибарны киметте. Төссез, урта кул әсәрләр саны шактый күбәйде. «Шуышып бара торган» реализм (ползучий реализм) хөкем сөрә. Язучы нәрсә күрә, шуны яза. Болытны күрсә—болыт, ди. Этне күрсә—эт, ди. Композиция, образ, деталь, башка әдәби алымнар турында уйлаучы юк диярлек. Әдәби осталыкны күтәрмичә торып, буыннар алмашу кризисыннан чыга алмабыз дип уйлыйм...

Минемчә, бүгенге көндә таләпчән, «тәнкыйди тәнкыйть» тә җитенкерәми. Мактаучы тәнкыйть (аеруча, юбилей уңае белән) тулып ята. Фәнни тәнкыйть тә җитәрлек (аеруча классик мираска карата). Ә менә таләпчәнлек юк диярлек.

Үткән гасырның 20-30 нчы елларын гына искә төшерик. Хәтта бүген классик дип саналган әсәрләргә карата да (Такташ, Туфан поэмалары, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир әсәрләре һ. б.) кискен тәнкыйть итә торган мәкаләләр басылып килгән. Дөрес, ул елларда социологик тәнкыйть хөкем сөрде, язучының әсәреннән бигрәк, аның сыйнфый чыгышына бәйләнәләр иде. Әмма, ничек кенә булмасын, мондый таләпчән атмосферада язучы тынычланып, булганы белән генә канәгатьләнә алмый иде. Укучы да, бәхәсләргә ияреп, үз фикерен тупларга ашкынып тора иде. Социологик хаталарны кабатламыйча, шундый таләпчән атмосфераны яңадан булдырырга кирәк.

Бераз соңрак, 40-50 нче елларда да тәнкыйтьтән шүрлиләр иде. Хәзер генә

тәнкыйтьчеләрне санга сугучы юк. Укучы да тәнкыйть мәкаләләрен кѳтеп алып, яратып укый иде. Халыкта тәнкыйтьчеләр турында шундый усал эпиграмма йѳрде:

*Хәсән Хәйри пычак кайрый.*
*Кемне суярга икән?*
*Кашшаф Газый кабер казый.*
*Кемне куярга икән?*

Хәзер эпиграмма чыгару тѳгел, тәнкыйтьчеләрнең исемнәрен дә белмиләр. Яна китапларга язган рецензияләр исә табын янында әйтелә торган тостларны хәтерләтә.

Бер якка гына ташланмас ѳчен мин тѳбәндәге рубриканы торгызырга киңәш итәм: «Бер китапка ике тѳрле караш». «Остаханә» рубрикасын да даими рәвештә дәвам итәргә иде. Рашат Низаминең 2006 ел башында басылган «Каләм алдым кулыма» мәкаләсе бик яхшы тәэсир калдырды. Шундый материаллар ешрак басылсын иде.

Тагын бер рубриканы гамәлгә кертергә була: «Тормыш һәм әдәбият». Бу рубрикада әсәрдә кѳтәрелгән проблемаларны анализлау, чынбарлык белән чагыштырып карау кѳздә тотыла.

Ә ѳзем журнал ѳчен бер бик җитди теоретик мәкалә ѳстендә эшлим. Якынча исеме: «Фән һәм сан». Билгеле булганча, һәрбер фәннен тѳгәллеге сан белән тикшерелә. Әдәбият белеме дә бу кагыйдәгә буйсына. Муса Җәлил шигырьләренең ритмик ѳзенчәлекләрен компьютер ярдәме белән тикшергәндә мин шактый кызыклы закончалыклар ачтым шикелле. Шул турыда язарга җыенам.

«Тәнкыйтьне җанландыру ѳчен беренче чиратта нәрсә кирәк?» дигән сорау куйсак,—иң башта талант кирәк, игътибарны шуна юнәлтѳ кирәк! Икенчедән, бәхәс кирәк. Хәзер теләсә кем ѳз акчасына китап чыгара ала. Елына дистәләрчә, йѳзләрчә яңа китап чыга. Без аларны кѳрмәмешкә салынабыз. Югыйсә бу турыда бик кызыклы һәм гыйбрәтле сѳйләшѳләр оештырып булыр иде.

Кабатлап әйтәм: кискен, таләпчән тәнкыйть кирәк! Ясалма чәчәкләр генә яшенле янгырдан курка. Чын, тере чәчәкләр исә янгыр астында тагы да матураеп, ѳсеп кенә китәләр.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА:**

—«Казан утлары»—дистә еллар буе әдәби процесска йогынты ясап килгән журнал, әдәбияттагы аерым тѳрләр ѳсеше хакында кѳзаллау булдырырлык әсәрләр иң беренче чиратта шушы журналда басыла, әдәби тәнкыйть ягыннан да без шуны кѳтәбез. Дискуссияләргә килгәндә, соңгы 10-15 ел эчендә дѳнья әдәбияты һәм шуның бер ѳлеше булган рус әдәбияты бик зур ѳзгәрешләр кичерә. Татар әдәбиятында бу кѳренешләр акрынрак бара, ләкин барыбер яналыклар кѳзгә ташланып тора. Шушы яналыкларга һәм соңгы еллар әдәбиятына багышланган сѳйләшѳләр бик кирәк. Ләкин булып узган дискуссия шуны кѳрсәтә: башта ук әдәби тѳрләрне аерып кую сорала (проза, поэзия, драма). Чѳнки татар әдәбиятында әдәби тѳрләр динамикасы бер-берсеннән шактый нык аерыла. Проблемалы мәкаләләр дигәндә, ел әдәбиятындагы аерым жанрларга, берничә ел эчендә пәйда булган аерым әсәрләргә аналитик кѳзәтѳләр бирѳ яхшы булыр иде. Дѳрес, мондый тѳр язмалар ел йомгакларыннан соң басыла, ләкин алар—бер кеше карашы. Елның иң кызыклы һәм әһәмиятле әсәрләрен билгеләѳ ягыннан да берничә кеше фикерен, әдәби барышны кѳзәтѳен укучыга тәкъдим итѳ урынлы. Бу, иң беренче чиратта, каләм сынаучылар, әдәбиятка килә торган талантлы яшьләр ѳчен кирәк.

Әсәрләрне бәяләѳ критерийлары турында сѳйләшѳ дә артык булмас иде дип саныйм. Бер мисал. Бѳген дә татар әдәби тәнкыйте әсәр хакында сѳйләгәндә тормышчанлыкны алгы планга чыгара. Дѳнья әдәбият белеме моннан 80 ел элек, рус әдәбият фәне 20 ел элек тормышчанлыкның әдәби әсәр бәяләѳ критерие буларак социологик метод белән бәйле рәвештә генә кулланыла алуын исбатлады. Чѳнки әдәби әсәр—марксизм-ленинизм әдәбият белемендә кабул ителгәнчә, тормыш-чынбарлыкның чагылышы тѳгел, аның кабат тергезелгән, уйлап табылган моделе ул! Мондый мәсьәләләрдә фәнни фикерләрне журнал битләрендә китерѳ кулай дип уйлыйм.

Төрле басмаларда мәкаләләрнең юбилей мөнәсәбәте белән яки «бу автор хакында күптән язма күренгәне юк» диебрәк бирелүе сер түгел. Шуна да кайчагында тәнкыйть ягыннан публицистика өстенлек итә. Моннан тыш, әсәрне читкә куеп, милли мәсьәләгә кагылып үзара гаепләшүләр «чәчәк ата». Соңгы күренеш—субъектив мөнәсәбәт белән фәнни карашның бәрелешүе ул, дияр идем. Минем бу яктан редакциягә бер тәкъдимем: татар әдәбият белемендә мәгълүматлы галимнәр бар, теге яки бу бәхәсле мәсьәләдә кинәшкәннән соң гына язманы бастыру кулай булыр иде. Чөнки аерым бер язмалардагы «ул әсәр бу метод белән язылмагандыр ул, шулай түгел микән» дигән сүзләр фәнни яктан караганда, миләш агачына карап, «каен түгел микән бу?» дип әйтү кебегрәк кабул ителә.

Әдәби тәнкыйтьнең ике төренә—«оператив» тәнкыйть, ягъни яңа басылып чыккан китап (әсәр) хакында сөйләшү һәм «объектив» тәнкыйть—әсәргә төпле анализ биреп, бер үк вакытта кимчелекләрен күрсәткән язмаларга ихтыяҗ зур төсле тоела миңа. Татар әдәби тәнкыйте милли әдәбияттагы заманча үзгәрешләр артыннан һәрвакытта да өлгереп бара алмый.

Яңа рубрикалар дигәндә, елга кимендә бер тапкыр «Яшь тәнкыйтьче фикере», ике тапкыр «Быелгы әдәбият турында галимнәр», шулай ук «Ел әсәре» кебекләрне күрергә теләр идем.

Ә үзем, әгәр кызыксыну бар икән, «Дөнья әдәбияты фонында татар әдәбиятындагы яналыклар» дигән язмамны тәкъдим итәргә әзер.

Рус әдәби тәнкыйте 90-нчы елларда фәнни-аналитик язмалар артыннан ияреп, активлашып китте. Әдәби журналлар әдәби барыштагы төп тенденцияләр, күренешләр хакында зур-зур фәнни күзәтүләр белән чыгыш ясадылар. Аннары аерым әсәрләрне гомуми барыш контекстында караган тәнкыйть мәйданга чыкты. Дөрес, мин бездә бу вариантның барып чыгачагына ышанып бетмим..

Студент яшьләр белән эшләү һәм бер әсәр хакында зур булмаган сөйләшүләр уздырып, шуны журналда бастыру, мини-дискуссияләр оештыру яхшы булыр иде дип саныйм.

**Равил РАХМАНИ:**

—Иң элек, минем карашка, әдәби тәнкыйтебездә кыйбла һәм иман ныклыгы житеп бетми. Мин моны туры—илаһи мәгънәсендә—әйтәм. Бөтен әдәби мирасыбызны, бүгенге бөтен әдәби продукциябезне нәкъ менә шушы күзлектән карап бәя бирү сорала сыман. Тирән ышануымча, әдәбият һәм шул исәптән аның тәнкыйте дә, берничек тә имансыз була алмый. Бу хакта Ф.Бәйрәмованың «Заман. Милләт. Кеше», А. Хәлимнең «Сез беләмсез кая барганны?» китапларында шактый тәфсилле әйтелде. Ни өчендер әдәби җәмәгатьчелек бу фикерләрне бөтен житдилегендә кабул итеп бетермәде шикелле. Һәрхәлдә, соңгы корылтайда тәнкыйтьчеләр бу хакта сүз башлап, ул китапларда күтәрелгән төп проблемадан шактый ерак торуларын күрсәттеләр, төп фикердән бигрәк сүзләрен авторларның үзләре тирәсендә куертып, комсомол җыелышындагыча, аларның үзләренә бәя куеп маташтылар, ә дөресе—бередә аларның үзләре адресына булган тәнкыйть сүзе күбрәк борчыганлыгы күренде. Әйе, мәсьәлә катлаулы, ул бик уйлап эшләгәнне ярата, объектив-фәнни бәя бирә белүне сорый... Әмма куелган проблема бар, аны чишү котылгысыз; ана дөрес җавап табу—безнең бурыч, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме бурычы.

Инде иманны кинрәк мәгънәсендә алып, тәнкыйтьченең турысүзлелеге, аның вөҗданы кушканча, дөресен, хаклыкны әйтеп язуын алсак, монысы да соңгы еллар әдәби тәнкыйтенең, миңа калса, иң йомшак ягы.

Әдәби тәнкыйтькә, минемчә, шулай ук фәннилек, аның әдәбият теориясе белән коралланган булуы житми. Йөрәк белән тоеп һәм янып язу яхшы нәрсә, әмма әсәргә анализ ясау өчен, аңа объектив бәя бирү өчен бу гына аз бит. Сүз монда безнең гайрәтне чигереп бетергән, әдәби әсәрләрдән ерак торган әллә нинди ясалма диссертация темалары һәм фәнни позалы язмалар хакында бармый. Сүз катлаулы, жанлы әдәби иҗат процессына алып керә алган—эшли торган теория турында бара.

Әдәби тәнкыйть чиста әдәби жанр гына түгел. Ул чынбарлык, милли тормыш һәм милли культура мәсьәләләре белән дә турыдан-туры бәйле. Соңгы елларда публицистика жанрының алга чыгуы үзе генә дә күп нәрсә сөйли булса кирәк. Бу

унайдан, мин әдәби тәнкыйтебездә милләт мәсьәләләрен тиешле дәрәҗәдә күтәрү житеп бетми дияр идем. Россиядә милли сәясәт булмаганы кебек, бу проблема бөтен кискенлеге белән республикабыз яшәешенә дә килеп кагыла. Милли идеология бездә гомумән ябык тема. Бармы безнен билгеле бер милли программабыз? Булса, без кая барабыз? Кая барып життек?.. Кая барырга җыенабыз?.. Бу сорауларга ачык җавап таба алмаган тәнкыйтьче ул инде тәнкыйтьче түгел. Менә монда инде рәсми җитәкчеләребезнен бу хактагы уй-фикерләрен белеп тору да һич комачау итмәс иде. Журналда, бу теманы даими күз унында тотардай берәр рубрика оештырганда, язучыларыбыз сукыр көйгә хәрәкәт итмәсләр иде. Бу мәсьәләдә активрак, максатчанрак булырлар иде.

Мәдәният, сәнгать проблемалары да тәнкыйть күзеннән читтә калмаска тиеш. Әйтик, бүгенге көндә татар радиоларыннан яңгыраган җырларны нормаль татар кешесенен, тынлый алмыйча, тизрәк туктатып куюын кемдер, кайдадыр әйтергә тиештер бит инде... Безне бит «Классик композиторларыбыз бар» дип, җырнын да композитор язган көе була, җырнын шагыйрь язган шигъри тексты була, җырны билгеле бер тавышы һәм әзерлеге булган җырчы башкара» дип өйрәткәннәр иде... Без шуна күнеккәнбез. Хәзер боларнын барысын да дөньяга күзе яна ачылып килгән даһи яшүсмер-дилетант үзе әвәли һәм барабанны кызганмый дөпелдәтеп, аны үзе башкара. Милләтнен зәвыгын тәрбияләүче дип зурдан кубып сүз ачмыйм инде, һич югы анын колагын саклаучы, анын җанын яклаучы берәр җаваплы кеше бармы бездә? Кем ул? Нәрсә уйлый ул? Чиле-пешле котлау, интим мөнәсәбәт хатлары укып (интим тойгыларны бар халыкка чыгарып селкүнен, гомумән, әхлаксыз булуын аңлаучы калмады, күрәсен), мәгънәсез сорау-җавап, сөйләшүләр оештырган булып милләт рухын тагын күпме изәргә була? Бәлки, бу акча эшләү белән бәйледер? Бик кыйммәткә төшә түгелме бу бизнес милләткә?!. Кемгә кирәк шулай халыкны музыкадан, сәнгатьтән, милләттән биздерү?! Минемчә, мондый проблемаларны үзәккә куйган, белгечләрнен фикерен ишеттерерлек рубрикаларнын журналда булуы һич артык түгел.

Әдәби тәнкыйтькә нәрсә житмәвен ачыклый барып, мөмкинлекләреннән чыгып, максат һәм теләктән чыгып, нинди конкрет чараны гамәлгә куюны редакция үзе карый инде. Әйтик, студентлар һәм аспирантларны тарту максатында, «яшь каләм ияләре почмагы» оештырып, «кызыклы китап күзәтүләре» биреп барырга мөмкиндер. Елнын ин әйбәт әсәре яки авторын билгеләүдә дә әдәби тәнкыйтьне эшкә җигәргә була. Әдәби-иҗат остаханәсе дәресләрен биреп бару да (әйтик, жанрларны чиратлаштырып) кызык булыр иде кебек.

**Фәридә ХӘСӘНОВА:**

—Егермеләп әдипнен, шагыйрьнен «Сайланма әсәрләр»е басылып чыгу турында мәгълүматлар ишетелде. Ләкин аларны китап кибетләреннән сатып алу мөмкинлеге юк. Шуна күрә мин журнал битләрендә «Сайланма әсәрләр»гә рецензияләрнен ачык конкурсын тәкъдим итәр идем. Дөрес, «Казан утлары» аерым рецензияләрне һәрдаим биреп бара. Конкурсның алдан ук нигезләмәсен эшләп, рецензияләргә аерым шартлар куелган очракта, әлеге ярыш, бәлки, көткән нәтиҗәне дә бирер. «Сайланма әсәрләр» турында сүз чыккач, мин Язучылар берлеге игътибарына шундый тәкъдим әйтер идем. Шигърияткә 60 елларда килгән буын вәкилләренен йогынтысы зур икәнен күпләр таный. Мина калса, әлеге шагыйрьләр арасында татар шигъриятен үзенчәлекле Көнчыгыш мотивлары белән баеткан Р. Гаташнын «Сайланма әсәрләр»е басылып чыгу нур өстенә нур булыр иде. Шулай ук М. Әгъләмнен «Сайланма әсәрләр»е чыкса да, каршы килүчеләр булмас. Язучынын иҗатын тулаем алып тикшерер өчен, гомумән, яшь буынны шигърияткә аңларга өйрәтүдә әлеге сайланма җыентыклар бик уңайлы бит.

Журналда әдәби тәнкыйтьнен һәр төренә урын бирелеп бара. Дискуссия, әдәби сөйләшү, күптөрле конкурслар, юлъязма, истәлек, иҗат портреты, публицистика аралаш тәнкыйть, мәдхия-мәрсия, юбилейлар унае белән язылган мәкалә, проблемалы һәм фәнни мәкалә, рецензия, түгәрәк өстәл, монография, аннотация, тематик анализ төрләрен очратырга була. Бигрәк тә 2004-2005 елларда барган «Безнен заман герое» дискуссиясе бик уңышлы килеп чыкты. Журнал бүгенге таләпләргә җавап бирә. Шулай да «Яна заманнын романтик герое» яки «Яна заманга «иске»

романтика сыямы?» шикелле темага мәкаләләр (Д. Заһидуллинаның бер хезмәтеннән башка) булмады кебек. Язучы-шагыйрьләр генә түгел, тәнкыйтьчеләр үзләре дә реалист булып беттеләр бугай дигән тәэсир кала.

Тәнкыйтьчеләр әдәби әсәрләргә образлар системасы аша яки идея-эстетик яктан, йә булмаса автор артыннан бару кебек анализ формалары аша якын килләләр. Тел-стиль юнәлешенә дә игътибарлылар. Шулай да, миңа калса, теге яки бу язучының ана гына хас булган индивидуаль үзенчәлеген күрсәтеп, шул рәвешле татар әдәбиятын, татар телен баету өлкәсендәге өлешен ачыклаган хезмәтләр житенкерәми әле. Нәкъ менә шул шагыйрь генә уйлап тапкан уңышлы деталь, образлы гыйбарә тәнкыйтьчеләр игътибарыннан күп очракта читтә кала. Гомер буе, әдәбиятта образлылык турында сүз барганда, Такташның «март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җиргә кар ашый» юлларын гына мисалга китереп яшәп булмас бит. Башка үрнәкләр дә соралыр. Әйтик, И. Юзеевны «яралы юлбарыс»ы, Р. Фәйзуллинны «җанын ваклыгын сылтама заманга!» афоризмы, «бәхет юрганы», «йокысызлык офыгы», «иясез шатлык», «глобаль затсызлык», «пәрәвез җебеннән нечкә язмышка кунган кигәвен» кебек шигъри табышлары аша истә калдырсак, Р. Харисны «лирик сәүдәгәр»е, «сапер кебек гомергә бер генә тапкыр ялгыша торган мәхәббәт»е, «дилбегәсез тамаша»сы, «сәрхуш әхлагы», «федераль кыршавы»; Р. Гаташны «кайгы игене чәчеп урмавы», «шигырь бавы»; Х. Әюпне «конституцион богавы», З. Мансурны «залиманә зәһәр заман»ы, М. Галиевне «тарихи черки»е; М. Мирзаны «милли арыслан», «милли фил», «бу дөньяның куркагыннан куркам» дип белдергән шигъри детальләре һәм сүз-образлары тел байлыгын кабатланмас итәләр. Бәлки, нәкъ менә шул юнәлештә бер рубрика ачып җибәрергәдер? Әйтик, сәнгатьчә осталык, герой, иҗат методы, язучының милли-индивидуаль үзенчәлеге, стиль проблемаларын үз эченә ала торган әлеге рубриканың исемен М. Галиев шигыреннән дә алырга була. Мәсәлән, «Үз тәхетен эзлим һәр сүзнең...», йә булмаса М. Әгъләмнең «Бер сүз эзләп, телемнән Күпме сүзем коелды. Уен түгел, чын бит бу. Ташлыймын бу уенны» строфасыннан файдаланырга булыр иде кебек.

**Рифә РАХМАН:**

«Казан утлары» журналында тәнкыйтьнең торышын урта бер дәрәҗәдә дип билгеләргә кирәк, әмма ул да аның хезмәткәрләре тырышлыгы нәтиҗәсендә генә дип чамалыйм. Җәмгыятебездәге яшәеш кануннары әдәбият, фән, сәнгать өлкәсенә дә үтеп керде, һәртөрле тәнкыйди сүздән саклану, бары тик мактауга йөз тоту, дусишләрне, түрә һәм «кирәкле» әдип-шагыйрьләрне мактау тәнкыйтьчеләрнең дәвалап булмаслык бер чиренә әверелде.

Еллар дәвамында сан артыннан куабыз, әмма һаман сыйфат күтәрелешенә ирешмибез. Тәнкыйтьне җанландыруның төп юллары—тормышта актив позицияле һәм әдәбиятта үз кыйбласын, стилен тапкан, кыю каләмле А. Хәлим, З. Зәйнуллин кебекләрнең язганнарына күбрәк урын бирү һәм әле дуслык элемтәләре белән тормыштагы урынын табуны максат итмәгән яшьләрне журнал тирәсенә күбрәк тарту.

Университетта көчле тәнкыйтьче кадрларның әзерләнә башлавына карамастан, аларның язганнары урын алмау, яшьләр өчен махсус рубрикалар булдырмау, ниһаять, аларны тәнкыйтьтән читләштерде. Югыйсә без журналга узган ел тәкъдим иткән язмалар гына да башкаларныкыннан фикер, жанр формасы төрлелеге, фәнни төплелек белән аерылып тора иде. Шул ук вакытта, бигрәк тә диссертация яклау алдында торган яшь галимнәр тәкъдим иткән материалларда, башкалар язганны кабатлау, кемнәрдер тарафыннан инде кайчандыр язылганны бер җепкә тезеп чыгу, бер үк авторларны мисалга китерү күзәтелә. Хәтта автор өчен материал чыгу бик мөһим булганда да, таләпләрне арттырырга, язмаларны янадан эшләү юлын тәкъдим итәргә кирәк яисә андыйларның әдәбият тарихына караган язмалары башка рубрикаларда урын алсын иде.

Мине иң борчыган нәрсә—журналга язучы тәнкыйтьчеләр даирәсенең тарлыгы, бер үк авторларның ел дәвамында берничә тәнкыйть язмасы белән катнашуы. Галимнәр биргән материаллар, аерым искәрмәләр белән, әдәбият укытучылар өчен бик кирәкле булса да, аларда җанлы рух юк, сакланып һәм сайлап язу кычкырып тора. Әйтик, мин үзем Рөстәм Зариповның күп кенә фикерләре белән бәхәскә керә

алам, әмма аның әдәбиятның сафлыгы, милли йөзе өчен борчылганы, каләменең кыюлыгы теләсә кем күзенә ташланырлык. Андыйлар каләменә урынны кызганмаска кирәк. Минем тәнкыйтькә кагылышлы фикерләрем бер «Казан утлары» журналына гына карамый. Тәнкыйтьнең объектын, жанр формаларын, шул формаларның асыл сыйфатларын аермау барлык матбугат органнарында да күзәтелә. Әйтик, нигезендә әдәби материал яткан сәнгать төрләрен аерым бер рубрикаларда ачу кирәк. Бездә сәхнә тәнкыйте белән сәхнә әдәбияты тәнкыйте дә бутала. Теге яки бу авторның фәлән пьесасына рецензия дигәнең премьерага рецензия булып чыга.

Әдәби тәнкыйть жанрларының барысын да тулысынча файдаланмыйбыз. Киләчәктә рубрикаларны жанр формаларына бәйле дә оештырырга мөмкин. Пародия, шарж, сатирик шигырь—болар да әдәби тәнкыйть төрләре бит әле. Бигрәк тә заманында зур эшләр башкарган фельетон жанрын әдәби тәнкыйтьне үткенләндерү максатыннан җанландыру кирәк.

Үткән елларда чыгып барган язмаларның әдәбиятка тәэсире сизелерлек булырмы-юкмы—әйтүе кыен, чөнки аларда күтәрелгән проблемаларга тулысынча җавап табылмады, аерым бер авторларның язмалары гына укучыларда зур кызыксыну уятты һәм безнең һәммәбезгә дә хас җитешсезлекләрне ачты. Әгәр куелган мәсьәлә кирәкле дәрәҗәдә ачыклап бетермәдек; бөтен тулылыгы белән ачылмый икән, бәхәсне туктатмаска да мөмкин, чөнки шул ук замандаш геройны иҗат итү турында без һәрвакыт уйланырга тиеш.

Бүгенге көндә хикәя һәм повестьларның хәле, аларның киңлеге, заманга бәйле кичергән үзгәрешләре турында даими рәвештә сөйләшәсе килә. Татар әдәби җәмәгатьчелегендә шау-шу куზгаткан аерым әсәрләр, иҗатлар турында укучы фикеренә конкурс игълан итәргә мөмкин.

Милли язмышның иң киеренке чагы. Мондый вакытта әдәбиятның милли эчтәлеге актуальләшә, аның реалистик нигезлесенең файдасы ныграк була. Әдипләр үз иҗатларында әнә шуны күздә тотарга тиеш. Ырым-шырымнан, хыял тудырган дөньядан, мифик затлардан һәм бигрәк тә шуларның ботка хәленә китерелгән катнашмасыннан читкә чыга алмаган әсәрләр халыкны милли проблемалардан, яшәештәге көндәлек мәсьәләләрдән генә түгел, әлегә югары интеллектлы, милли рухлы булган төп катлам укучыларны ахыр чиктә прозабызның үзеннән дә читләштерәчәк. Зур тарихлы, күләмле, үзгәртеп кору елларында читтән-читкә ташланган, төрле әдәби юнәлешләр барлыкка китерергә омтылып та очлап чыга алмаган рус әдәбияты да үз асыл ызаннарына кайтып барган, «фэнтези» жанрыннан йөз чөерә башлаган бер вакытта татар әдипләренең буш юлдан китүләре, мода артыннан куулары, иң кызганычы, кайбер галимнәрнең шул төр әсәрләргә дан җырлаулары, сәнгатьчә эшләнеше бик үк югары булмаган прозаны күтәрүләре җанны әрнетә. Ә безнең әдәби мохиттә кемнеңдер җиңел кулыннан күтәрелү, лаек булмаган югарылыкларга ирешү бер дә авыр түгел.

Әнә шуларны күздә тотып, бигрәк тә журналда басылган әсәрләргә, кайтаваз рубрикасы булдырырга кирәк. Бу бөтен төр юнәлештәге әдәбиятка, журналның гомуми эчтәлегенә тәэсир ясамый калмаячак. Икенчедән, киләчәктә кайбер авторларның чиле-пешле яисә уртакул әсәрләреннән баш тарту өчен сылтау булачак. Журналның эчтәлеген кайгыртып, безне бергә туплаган коллективка рәхмәт җиткерәм.

* * *

«Түгәрәк өстәл» сөйләшүендә кызыклы тәкъдимнәр, җитди фикерләр тагын да әйтелде. Анда катнашкан каләм әһелләре журнал битләрендә әдәби тәнкыйть чыннан да җанланып китсен өчен ихлас кайгырту күрсәтеп, бу эш өчен олы җаваплылык тоеп сөйләштеләр. Киләчәктә ул кайгыртуның тормышка ашуы расланыр—журнал битләрендә әдәби тәнкыйть җанланып китәр дип ышанабыз.

*Журналыбыз битләрендә «Безнең күргәзмә» дигән яңа рубрика ачып җибәрәбез. Бу сандагы сәхифәдә рәссам-скульптор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Альфрет Хәйрулла улы ӘБДРӘШИТОВНЫҢ бронза һәм граниттан коеп эшләнгән, әдәбият-сәнгать әһелләренә багышланган иҗат үрнәкләре тәкъдим ителәчәк.*

## Һади Такташ

(1901—1931)



Татар әдәбиятының классик язучысы Һади Такташ 1901 елның 1 январенда элекке Тамбов губернасының Сыркыды авылында туа. Заманына күрә яңачарак укытуга корылган Пешлә мәдрәсәсендә укый, гарәп һәм фарсы телләренең нигезен үзләштерә. Язмышы кушуы буенча 13 яшеннән үк ислам диненең үзәге булган Бохара шәһәренә китә. Тамак ялына төрле эшләрдә эшли, беренче шигырьләрен яза башлый. Оренбург, Ташкент, Мәскәү шәһәрләрен гизгәннән соң 1922 елны Казанга килә.

«Җир уллары трагедиясе», «Гасырлар һәм минутлар», «Алсу», «Мокамай», «Киләчәккә хатлар» поэмалары аның иҗатында күренекле урын алып тора. Нибары 30 ел яшәп калган шагыйрьнең гәүдәсе Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура паркы биләмәсенә урнашкан туганнар каберлегенә җирләнә.

Такташның рәсемдәге бюсты 2000 елда эшләнә. Ул шагыйрьнең Сыркыды авылындагы музей-йорт каршына урнаштырылган.

## Гомәр Бәширов

(1901—1999)



Күренекле татар язучысы Гомәр Бәширов 1901 елны Арча районының Яңасала авылында дөньяга килә. Остабикәдән, аннары авыл мәдрәсәсендә укырга-язарга өйрәнә, арифметика һәм география кебек дөньяви фәннәрдән азмы-күпме белем ала.

13 яшеннән тегүче бер абзыйга ияреп, ипи хакына ялланып эшләүнең бөтен ачысын-төчесен татый. Бары китаплар уку гына аның рухын чыныктырып, киләчәккә өметен ныгыта. Гражданнар сугышында корал тотып катнашкан кеше буларак, 1937 елда «Сиваш» повестен тәмамлый һәм әдәбиятта үзен талантлы прозаик итеп таныта.

Ватан сугышы көннәренә багышланган «Намус» романы исә дөньяга чыгу белән үк укучыларның мәхәббәтен казана, ике-өч ел эчендә ул украин, казакъ, үзбәк, әзәрбайҗан, кыргыз, латыш, эстон, уйгур, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. 1951 елда бу романы өчен Гомәр Бәшировка СССР Дәүләт премиясе бирелә. «Туган ягым—яшел бишек», «Җидегән чишмә» кебек соңгы романнары да аның иҗатында күренекле урын алып тора.

Рәсемдәге бюсты 1999 елда эшләнә. Ул Арчадагы Үзәк мәйданга куелган.

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТӨСЛӘРГӘ МӨНӘСӘБӘТ*** – Мөселманнарда зәңгәр һәм күк төсләр кайгы билгесе булган. Шуңа күрә, мәсәлән, Төркиядә җәзалап үтерү турындагы фәрман зәңгәр кәгазьгә язылган. Яшел киемне шигыйлар яратып кигән. Шәригать буенча ирләргә җете кызыл һәм җете сары киемнәр киеп йөрү тыела. Шулай ук кара эшләпә киеп йөрү дә (йәһүдләрдәге кебек) тыелган. Сөнниләрдә бәйрәм киеменең һәм байракларның төсе кара булган. Шәрыктә кара төстәге хайваннар үзләренә бик күп кояш энергиясе сеңдергәнгә, кара сарык итен шифалы дип исәпләгәннәр. Пәйгамбәрнең: "Сезгә акны кулланырга кушам, өммәтемнең тере кешеләре дә акны киегез һәм мәетләрегезне дә ак кәфенгә кәфенләгез",-дигән сүзләре билгеле. Фәрештәләргә дүрт төрле: ак, яшел, сары һәм кызыл төсләр хас икән.

***ТӨФӘНГ, ТӨФӘҢ*** *ф.* – Мылтык. // *Үзенең мәлгунь гаскәрен, тавышлары Фиргавен Нәмруд сурәтле,-имансыз Иван, башта булган бөтен гаскәре, сансыз туплары, тофәңнәре, чама белән сигез йөз меңлек гаскәре белән килеп, Казан шәһәренең әйләнә-тирәсен сарып, чолгап алдылар.* Кол Шәриф.
Чаг.: ***ТҮФӘК***.

***ТӨЧӨГӘН АТНАСЫ*** – Июньнең 15-25 ләрендә үткәрелә торган җыен. *Төчөгән-*төчлегән, ягъни агачның кайрысы астында барлыкка килгән йомшак, сыек катлау. Соңыннан ул, катыланып, кабыкка әйләнә.

***ТУ (ТУГ)*** *бор.* – Ат кылыннан ясалган байрак. Туның башы ай урагы шикелле ике җәпле булган. Ул бик зур булып, аны егермешәр кеше бергә күтәргән. Сабан туеның сөңгеле таягын күтәрүне дә "*ту күтәрү*" дигәннәр. Әхмәдзәки Вәлиди аны төркиләрдә гаскәрнең алдында тоткан байрак, төрки гаскәренең туг ы ак яки кара ат койрыкларыннан ясалган булган дип аңлата. Борынгы төрки телдә "ту" сүзенең "ябу" мәгънәсе дә булган. Ихтимал, "ту" ат өстенә яба торган ябынча итеп тә кулланылгандыр.

***ТУ КИҢӘШ*** *тар.* – Байраклар киңәше, хәрби шура.

***ТУАР*** *бор.* – Йорт хайваннары, терлек. *Мал-туар, терлек-туар, туар-кара* кебек гомумилек төшенчәләрендә катнаша. "Товар" сүзе дә шуннан килеп чыккан дигән караш бар, ә русча "товарищ" сүзен төркичә "товар+иш" аша аңлату да яшь. Шулай да "туар" сүзенең, әйтик, русча "тварь" яки немец телендәге "Tier" сүзләре белән формаль һәм мәгънәви охшашлыгын ничек аңлатырга дигән сорау барыбер кала. Кайбер галимнәр борынгы төрки "табург"-тоз сүзен *туар* һәм *товар* сүзләре белән бәйлиләр, чөнки борынгы заманда тоз иң таралган товар исәпләнгән (Р.Әхмәтьянов).

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

***ТУБӘ АГАЧЫ, ТУБА(Й) АГАЧЫ*** *г.* — Җәннәттә үсә (күктән аска таба) һәм җәннәткә күләгә биреп тора торган агач. Саргаймый, җимеше бетеп тормый. Төрек галиме Фуркани (XVI гасыр) "Туба агачы саф алтыннан, ул шулкадәр зур ки, бөтен җир йөзен кояштан каплый алыр иде" дип яза. Сигез җәннәттә дә бу агачның ботаклары сузылмаган урын юк. Ботакларда төрле-төрле җимешләр җитешә, җәннәт әһелләре кулларын сузуга, җимеш аларның учына килеп төшә икән.

*//Илаһи, бу асыл кошны туба агачына кундыр.* Г.Кандалый.

***ТУГРА*** *тар.* — Каллиграфик тамгадан гыйбарәт мөһер, пичәт; монограмма. Шаһ фәрманнары язылa торган махсус язу стиле дә, аннары фәрман (рескрипт) та *тугра* дип аталган. Тугра госманлы падишаһларның, Мисырда хакимлек иткән мәмлүк солтаннарның, XIV гасырдан Алтын Урда ханнарының, аннары Кырым ханнарының һәм ханзадәләренең гербы булып хезмәт иткән. Гомумән, хан туграсы һәм хаким нәселләр туграсы дигән ике төргә бүленгән. Хан туграсын куярга дүрт карачибәк һәм бәкләрбәге дә хокуклы булганнар.

Россия патшаларының да, ике башлы сәмруг кош сурәтләнгән мөһер белән бергә, гарәп хоруфатында язылган тугралары булган. Бу тугралар Шәрык илләре белән аралашканда кулланылган. Сакланып калган беренче рус туграсы 1620 елга нисбәт ителә (бу вакытта Михаил Романов патшалык иткән). Петр патшаның туграсы да билгеле (1695). Рус тугралары берсендә, мәсәлән, түбәндәге сүзләрне укыйбыз: "Тәңре Тәбарәк вә Тәгаләнең рәхиме вә гыйнайәте белән..."

Мәскәү патшаларының тугралары Кырым туграларына охшаган.

***ТУГРЫ*** *тар.* — Ау кошын (лачын, бөркет) кундырып йөртә торган агач (*тур, тургач* вариантлары да очрый).

***ТУГЫЗ*** — Борынгы төрки телдә тугыз-халык аңында зур, "түшәм" саннарның берсе. Мәс., "күкнең тугызынчы каты" дигәндә иң югары, соңгы каты күздә тотылган (әлеккә 3, 7, 9, 10, 12, 40, 60, 70, 80, 90 һ.б. саннарны "башка сыйдыру" кыенлыклар тудырган). "Тугыз сүзе" исем компоненты буларак та актив (*Тугызай, Тугызбай, Тугызбәк, Тугызбикә* исемнәре).

***ТУДУН*** — **1**.Каһанның җирле урынбасары (наместнигы, наибе), Хәзәр каһанлыгында ясак җыю өчен җаваплы кеше. Бу сүз рус теленә дә кереп, *Тиунов* фамилиясендә сакланган. **2**.Кырым йортында Алтын Урда ханы билгели торган олыс әмире.

***ТУЗНАМӘ*** *тф.* — Неологизм: тузга язылган язу, русча — *берестяная грамота*. XIV гасырга караган шундый бер тузнамә Иделнең сул як ярында Үкәккә (Увек) каршы Подгорный авылы янында 1930 елда табылган. Монгол телендә уйгур хәрефләре белән язылган бу кульязманың эчтәлеге бер ананың улын түрәгә хезмәт итәргә озаткан вакыттагы әңгәмәдән гыйбарәт.

***ТУЙ*** — Ирле-хатынлы булып гаилә корып яшәү дәверендә барысы 20 гә кадәр туй уздыру гадәте дә бар икән. *Ситсы туй* — өйләнешеп бер ел үткәч уздырыла торган истәлекле бәйрәм. Бу көнне бер-береңә ситсыдан тегелгән берәр кием бүләк итәргә кирәк. *Агач туй* — никахлашып 5 ел узгач билгеләп үтелә, бу көнне ир белән хатынга берәр агач әйбер бүләк итү яхшы. *Гөлчәчәк көне* — гаилә коруның уңьеллыгы. Бу көнне ир белән хатынга фәкать роза чәчәкләре генә бүләк ителә. *Пыяла туй* — 10 елдан соң билгеләп үтелә. Никахта яшәүчеләрнең үзара мөнәсәбәте пыяладай саф булсын өчен, аларга пыяла савыт бүләк итәләр. *Фарфор туй* — гаиләнең 20 еллыгына багышлана. Бу көнне табынга фәкать фарфор савытлар гына куела. *Көмеш туй* — 25 елдан соң бик зурлап бәйрәм ителә. Ир белән хатын бу көнне *туйге туйда* алмашкан балдаклары янына көмеш балдаклар өстиләр. *Энҗе туй* — 30 елдан соң билгеләп үтелә. *Якут туй* — 40 елдан соң үткәрелә. *Алтын туй* — 50 елдан соң, алмаз туй 60 елдан соң бәйрәм ителә. *Тимер туй* — 65 ел бергә гомер итүчеләр бәйрәме, ә *таш туйны* 67,5 елдан соң уздыралар. *Затлы туй* исә 70 ел бергә яшәгәч, ә *гомер таҗы* дигән туй

75 елдан соң билгеләп үтелә. (2002 елга татар календаре буенча.)

"Кызыл туй" төшенчәсе 1917 еллардан соң гына кергән, аның мәгънәсе чыннан да "кызыл", никахсыз һәм дини-традицион йолаларны үтәмичә уздырылганга аны шулай атаганнар. Хәер, соңрак ул үзенең бу сәяси мәгънәсен җуя төшкән.

Татарда тагын *яраш туй* төшенчәсе бар.

***ТУКАЛ*** *бор.* — Йорт хуҗасының өченче яки дүртенче хатыны. Нәкый Исәнбәт: "Тукал — кече хатын, бай бичә кулындагы кол хатын", — дип аңлата. //*Тубылгыдан өй булмас, тукалдан (яки-колдан) туган би булмас.*

***ТУЛАК*** *бор.* — **1**.Болгар чорында сыер тиресеннән эшләнгән күн капчык, күнәк. **2**.Аяк астына җәелә торган тирене да тулак дип йөрткәннәр. **3**."Аякка чорный торган калын материя", тула (К.Насыйри). Р.Әхмәтьянов аны *тулгау*-урау, чорнау сүзеннән дип аңлата (без монда "чолгау" сүзен дә өстәр идек). Бу очракта борынгы "тулак" сүзенең рус телендәге "*чулок*" сүзен хәтерләтүенә игътибар итик. Шул ук вакытта рус этимологлары "чулок" сүзенең төрки "чолгау" сүзе белән бәйләнышы булу ихтималын да кире какмыйлар.

***ТУЛПАР*** — Төрки халыклар, шул исәптән татар һәм башкорт халыклары мифологиясендә канатлы ат, дөлдөл, пегас. Халык ышануынча, ул ябык кына, юаш кына имеш. Тулпар ат күзгә күренми торган канатларын кагып, таудан-тауга сикереп очып йөри икән. Арыгач, ул берәр аулак җирдә ятып хәл җыя, канатларын да шунда гына җәеп сала имеш.

"Тулпар" сүзенең кызыклы этимологиясен Р.Әхмәтьяновта табабыз. Ул "тулпар" сүзен *тол/тул* һәм *пар/бар* өлешләренә таркатып карый. "Сүзнең тамыры гомум төрки *тул* "кеше үлгәч, аның истәлеге итеп саклана торган сын, курчак" сүзеннән булса кирәк; к. чыгтай, иске татар телләрендәге *тул* "тулпар, сугыш аты (Радлов). Элек сугышчыны күмгәндә төркиләр, бигрәк тә кыпчаклар, аның атын да бергә күмгәннәр, кайчакта атының итен ашап, баш-аягын гына кабергә куйганнар. Соңрак кабер өстенә атның тиресе генә эленеп куелган яки ат сурәтен (балчыктан h.б.) ясап кына куйганнар. Бу гадәт — ат сурәтен корбан итү — мариларда революциягә кадәр сакланган. Марича корбанлык ат сыннары аргамак дип аталган. Сугыш аты, әлбәттә, бик тиз үлә торган булган. Ул үлгәч, аның тиресеннән *тул* ясаганнар; пар өлеше борынгы төрки, монгол телләрендәге *пар, бар* "барыс, юлбарыс" сүзеннән."

Астрономиядә *Пегас* йолдызлыгы да татар терминологиясендә Тулпар дип йөртелә.

***ТУЛЫМ*** *бор.* — Елгада бусага ташлары. //*Днепр тулымнары.*

***ТУН*** — Борынгы мәгънәсендә: кием; халат; күлмәк. Р.Әхмәтьянов: "Тун сүзе башта ханнар кия торган киемне белдергән. Соңрак тун дип туй киемен генә атаганнар ("туем узды, туным туздыˮ дигән сүз дә шуннан"), — дип яза. Ләкин борынгы төрки телдә *тултон* — тол хатыннар кия торган кайгы киеме. Хәзерге Себер татарлары телендә *тун* — өс киеме, *ецке* (эчке) *тун*-костюм, *тыш тун*-толып, *айактун* — ыштан, *ә тунлык* — кәфен, кәфенлек (Д.Г.Тумашева). //*Әтләс тун* — атлас халат. *Тимер тун* — көбә күлмәк, тимер җөббә, панцирь. *Паласларин чыкариб тун кийурди, һәм тәцдән ицдерди, ат бендерди.* — Тупас кием урнына күлмәк кидерде. Дөядән төшереп, бер атка менгерде. Кол Гали. *Аяк тунын чишми килсә, янә дә таяк белән ора икән.* Кол Шәриф. *Тунын суеп* — киемен салдырып (Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында Йосыфның туганнары аның "тунын суеп [үзен] дар коюга салалар").

***ТУП*** — Гомумтөрки сүз. **1.** Эластик материалдан ясалган һәм берәр җиргә бәрелгәч яхшы сикерә торган уен әсбабы. Уенчык тупларны элек мал ябагасыннан әвәләп ясаганнар. **2.** Утлы коралның бер төре, артиллерия тубы, пушка. Электә кечерәк туплар *туфәк* дип аталган. //*Чөерен ора котуне, Костырыр адәм утене, Карынына ут төртсәң, Күккә чыгар тотене.* Табышмак (җавабы-*борынгы туп*). **3.** Шул корал көпшәсеннән атыла торган шар, ядрә (йәдрә). Аларны элек таштан һәм чуеннан ясаганнар. //*Ул нидеркем, дошманын курсә, очар, һәм җаны юк, һәм теле юк,*

*һәм күзе. Ни гаҗәптер, тән тишеп каның эчәр.* Табышмак (җавабы — йәдрә). 4.Туплам, җыелма.

***ТУПЛАН*** *тар.* — Бер туплам атлы гаскәр, эскадрилья, отряд.

***ТУРАМ*** — Җәннәткә кертелгән ун хайванның берсе. Аллаһы ихтыяры белән бер мәгарәдә 300 ел йоклап үткәргән егетләрнең эте. Аллаһы аны, эт исеменнән чыгарып, тәкә сурәтенә куя, шуннан соң ул җәннәткә кертелә. Башкача *Камтир / Кыйтмир* яки *Һубан* дип тә атыйлар.

***ТУРАН*** *ф.* — "Борынгы вакытларда күчмә иранлылар яшәгән өлкәләр. Иран белән туран чикләре Аму-Дәрья елгалары хисапланган. (Ш.Абилов.) Соңыннанрак — иранлылар тарафыннан төрки халыклар яшәгән җирләргә бирелгән исем, Төркестан — Ираннан төньяк-көнчыгышта урнашкан төбәкләр. Бу сүз әдәбиятта гомумән "төрки халыклар" мәгънәсендә дә йөри ("әкъваме турания"). Борынгы Туран иле атамасы һәм аның патшасы *Әфрасиаб* исеме легендаларда сакланган. 1916 елда Татарстанда Шәле авылында язып алынган бер әкияттә патша кызы *Турандук* турында сөйләнә. Бу исемне көнбатышка да билгеле төрки принцесса *Турандот* исеменең татар варианты дип карарга мөмкин.
*/ / Туранчы галимнәр. Пантуранизм.*

***ТУСНАК*** *иск.* — Бурычлы кол, тоткын кол (бурычын түли алмаганга кол булып калучы). Русча — "*долговой раб*". Р.Әхмәтьяновта — "пленный раб". */ / Габдулла килеп безгә бер туснакыңыз юк диде.* (Борынгы документтан.)

***ТУТ ИСЕ*** — Кыш көне тышта кипкән кердә була торган үзенчәлекле хуш исне Пермь татарлары шулай атыйлар (руста — "*морозная свежесть*"). Шул ук якларда кыш көне ак керне агартыр өчен ачык һавада элеп киптерүне *тутка элү* диләр. Күрәсең, монда кернең бозланып кату һәм сублимация күренешләренең роле бардыр. */ / Кышкыда булса, төн кунган кердән тут исе килә.* "Диалектологик сүзлек". *Тутлау* — уңу, кояш ашау.

***ТУТАШ*** — "Тута" сүзеннән татарча сүз ясагыч кушымча ярдәмендә ясалган "яңарак" сүз (*энекәш, сеңелкәш* сүзләре үрнәгендә). Ризаэддин Фәхреддин заманында бу сүзгә автор аңлатмасы соралган әле (1898). "Сәлимә яки гыйффәт" дигән әсәрендә Р.Фәхреддин бит астында түбәндәге искәрмәсен бирә: "Кызларның үз хозурларында һәм артларында, тәгъзыйм вә олуглап әйтеленәчәк бер хөрмәтле ләкабтер. Русларның "барышня", французларның "мадмуазель"ләре урынында истигъмаль иделенәдер. Соң заманнарда гарәп җаридәләре истигмаль итмәктә улан "анса" сүзе бигайниһи "туташ мәгънәсендәдер" (*ниса*-хатын-кыз). */ / Шәфкать туташы.*

***ТУТЫЯ, ТУТЫЙА*** *тар.* — Тутыяташ, цинк. Шәрыктә, шул исәптән төрки халыкларда, күкташны — бакыр купоросын да тутыйа дип атаганнар һәм аны, мәсәлән, күздәге трахома авыруын дәвалау өчен кулланганнар. *Цинклы мазьны* (дару) да *тутыя* һәм *тутыя мае* дип атау очрый */ / Ак тутыя* — тутыяташ, цинк шпаты (мәгъдән тутыя?). "Татарча-урысча сүзлек"тә (1931) русча ягы "гальменный камень" (?) дип күрсәтелгән. *Тутыя йөгерту*-цинклау. *Тутыялы калай.*

***ТУФАН*** *г.* — Туфан суы, көчле ташкын, су баскыны. "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге"ндә аның тагын "көчле яуган яңгыр" мәгънәсе дә теркәлгән. Гарәпчә *туфан-ун* сүзеннән, мәгънәсе — "ил гизү, дөнья әйләнеп йөрү" ("*тәваф*" сүзе белән бер тамырдан).

Туфан турындагы ривайәт Борынгы Ассирия башкаласы Ниневия хәрабәләрен казыганда табылган чөй язулы балчык җәдвәлләрдә бәян ителгән "Гильгамеш турындагы эпос"ка барып тоташа. Төрле җәдвәл кыйпылчыкларын бергә тәртипләп тезеп текстны укыганнан соң, Библиядәге Нойның (Коръәндәге Нух пәйгамбәрнең) борынгы бабиллар ривайәтендә сурәтләнгән Утнапиштим булуы аңлашыла. Тарих

сәхифәләрен актарып, тагы да тирәнгәрәк төшсәң, Шумер чорындагы Зиасудра дигән тәкъва падишаһның әлеге Утнапитимга һәм Нойга тәңгәл булуын күрәбез. Гыйльми тикшеренүләр Шумерда (Икесу төбәгендә – Месопотамиядә) моннан 5000-6000 еллар элек чыннан да гадәттән тыш көчле су басу булганлыгын раслыйлар. Кыскасы, туфан турындагы коръәни һәм библияви кыйссалар асылда чынбарлыкны чагылдыралар, ләкин, шуның белән бергә, Коръәндә туфан җирле масштабтагы күренеш булган (Аллаһы Тәгалә туфанны Нух пәйгамбәр каумен җәзалау өчен генә җибәрә), ә Библиядә тасвирланган бөтен дөньяны су басу факты фәнни мәгълүматлар белән расланмый. Библиядә туфан 40 тәүлек дәвам итә дигән урын да, 150 тәүлеккә сузыла дигән урын да бар. Ислам риваятьләрендә исә Нух пәйгамбәр Рәҗәбнең 1 сендә көймәгә утырган һәм Гашурә көнне (Мөхәррәмнең 10 сында) Җуди тавына килеп туктаган дип сөйләнә (барысы 187 көн килеп чыга). Коръәннең үзендә конкрет саннар күрсәтелмәгән.

Риваятьләргә караганда, туфан Мөхәммәд Пәйгамбәр мигъраҗ кичәсендә өченче кат күктә очраткан гаять зур *Бәхрел-Нукум* дигән диңгездән чыккан имеш.

Алтайлыларда да туфан турындагы мифлар бар икән. Н.П.Дыренкова үзенең "Культ огня у алтайцев и телеут" дигән хезмәтендә (1927) түбәндәгеләрне яза: "Бөтен дөньяда җирдән, җир иясеннән туфан калка. Күккә каршы җир ияләре күтәрелә" (Н.Фәттах буенча).

Тагын кара: ***НУХ ПӘЙГАМБӘР, БИБЛИЯДӘГЕ КАПМА-КАРШЫЛЫКЛАР.***

***ТУФРАК ЙОЛДЫЗ*** – Сатурн, Зөхәл, Кәйван. Кояш тирәсендә ераклык буенча алтынчы урында әйләнеп йөрүче зур планета. Урта гасырларда аннан арырак планеталар (Уран, Нептун, Плутон) ачылмаган була әле. Мәс., Баласагуни "Котадгу белек"тә Сатурнны башка планеталардан арырак урнашкан дип әйтә. Гомумән, урта гасыр астрологлары аны җиденче кат күктә урнашкан дип күзаллаганнар. Зөхәл йолдыз *кара кургашынга* туры килә дип исәпләнгән. Урта гасырларда гарәп астрологиясендә Марс (*Мәрих*) белән Сатурн (Туфрак йолдыз, *Зөхәл*) бәхетсезлек китерә торган планеталар дип фараз ителгән. Зөхәлне гарәпләр шайтан һәм гыйфритләр белән бәйләгәннәр.

Сатурн планетасының тулы әйләнеш ясау вакыты – 30 ел (хәзерге төгәл хисаплауларга караганда, 29,458 ел).

Борынгы төркиләр бу планетаның хәрәкәтен җентекләп өйрәнгән булганнар. Байкал күле янындагы Мальта авылы тирәсендә табылган бизәкле сөяк пластинка шуны раслый. Җентекле тикшеренүләр һәм хисаплаулар пластинкадагы бизәкләр системасының чын мәгънәсендә мәңгелек календарь булуын, анда хәтта Сатурнның хәрәкәтләре дә исәпкә алынуын күрсәтteләр.

***ТУФРАК КАЛА*** *тар.* – Туфрак кирмән, туфрак кальга (*Әүлия Чәләби* юлъязмасының русчага тәрҗемәсендә: *земляная крепость*).

***ТҮБӘН ФӘННӘР*** – Борынгы Шәрык чыганакларында – табигать турындагы фәннәр яки физика.

***ТҮБӘНӨЙ*** – Аскы өй, гөлбәч (русча – *голбец*); идән асты, аскеләт, подвал. Төзелеш һәм архитектура турындагы текстларда *түбәнөй, гөлбәч* терминнарының кирәклеге сиздерә.

***ТҮБӘТӘЙ*** – Татарларда бизәкле яки чигүле, ситсыдан тегелгән сай гына түгәрәк баш киеме, кәләпүш. Тел галиме Р.Әхмәтьянов "түбәтәй" сүзенең монгол теленнән кергәнлеген әйтә.

Урта Азия түбәтәйләре гадәттә дүрткел формада була.

Шәригать хөкемнәренең дөрес үтәлешен күзәтүче мөхтәсибләр гаепле дип тапкан кешегә җәза биргәннәр, камчы белән суктырганнар, башларына *хурлык түбәтәе* кидергәннәр.

*Дәвамы киләсе саннарда*




Фаяз
Хуҗин

## АЛАБУГАГА НИЧӘ ЯШЬ?

Алабуганы күпләр хаклы рәвештә Татарстанның борынгы шәһәрләре рәтенә кертәләр. Әмма ни дәрәҗәдә борынгы ул, кайсы чорда барлыкка килгән? XVIII гасырдамы? Ә бәлки XVI йөздә үктер? Тагын да борынгырак түгелме? Сораулар күп, тик әлегә кадәр аларга җавап бирерлек фәнни мәгълүматлар гына юк иде.

Халык бит үз шәһәренең тарихы белән барыбер кызыксына, чыганаклары-мәгълүматлары юк икән дип тормый, тарихчылар алдына «ничә яшь Алабугага?» дигән сорау куя. Тегеләре ничек тә авыр хәлдән чыгарга тырыша—төрле фаразлар барлыкка килә. Менә шул фаразларның берсе буенча (сүз уңаеннан әйтим, ул хәзерге энциклопедияләргә дә кергән) Алабуга шәһәренә XVI гасырның урталарында яки икенче яртысында нигез салынган. Бу фаразда мантыйк бар: нәкъ шул чорда хәзерге Алабуга урынында Трехсвятское дигән урыс авылы, ә бераз соңрак Троицкий монастыре барлыкка килә.



*«Шайтан каласы» һәм аның тирә-юнендәге таш бина хәрабәләре. Безнең көннәр.*

Ә менә соңгы елларга кадәр бик киң таралган, хәтта аксиома дәрәҗәсенә җитә язган фараз тарафдарлары Алабуга шәһәре тарихын 1780 елдан башлап җибәрәләр иде. Әлбәттә, бу фаразның да нигезе юк түгел: 1780 елда әби патша Екатерина II фәрманы белән без югарыда телгә алган Трехсвятское авылы һәм шул авыл янында барлыкка килгән кечкенә крепость Алабуга исемле өяз шәһәренә әверелә, ягъни элеккеге авыл шәһәр статусын ала.

—Гафу итегез, аңлашылып җитми,—дип туктатыр безне игътибарлы укучы.—Нишләп соң әле ул шәһәрнең исеме Трехсвятское түгел, ә Алабуга? Кинәт кенә каян килеп чыккан ул исем?

Әйе, бик тә урынлы сорау. Җавап бирәм: эш шунда ки, XVI-XVIII гасыр документларының барысында да диярлек Трехсвятское авылы һәм Троицкий монастыре «Алабуга» исеме белән параллель рәвештә кулланылган. Мәсәлән, «Трехсвятское тож Елабуга», «село Трехсвятское, что на Елабуге», «Троицкий каменного городища монастырь, что на Елабуге». Ни өчен,

дисезме? Чөнки, Трехсвятское һәм Троицкий кебек авыл-монастырьлар күп бит алар, берсен-берсе белән бутамас өчен Алабуганы китереп кушканнар, ягъни, Алабуга янындагы Трехсвятское. Аннан соң, Алабуга бит инде данлыклы кала, ул үзенең «Шайтан» шәһәрчеге белән күпләргә мәгълүм.

Бәс, шулай икән, Алабуга тарихы Трехсвятскоега караганда борынгырак булып чыга түгелме соң?

Әлбәттә. Әле 1960 нчы елларда ук танылган тарихчы Е.И.Чернышев тарафыннан төзелгән «Казан ханлыгы чорындагы торак пунктлары исемлеге»нә юкка гына кертелмәгәндер инде ул («Елабуга-Алабуга—Кама буенда, Җөри юлы өстендә»).

Ханлык чорындагы Алабуга халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә очрый. «Алабуга бәете»н тыңлап карагыз:

*Алабуга—ак шәһәр, тарихы озак яшәр,*
*Дошманга яуга бирелмәс, юлына каршы төшәр.*
*Алабуга урыс кулына Сәүгән ханнан калгандыр,*
*Сәүгән ханның мажарасы тарихта язылгандыр.*

*Атлар җиктем яратып, Саралыга каратып,*
*Саралы, Сәйтәк чукынган, кәфер уты таратып.*
*Алабуга олылары Туйхуҗа белән Аккуҗа*
*Сөрлектеләр илендән,*
*Сарай белән Сәеттәкбәк чыктылар ислам диненнән.*

Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» дигән китабында XIV гасыр ахырларында хакимлек иткән Алабуга ханы Илбакты Уразбакты улы турында риваять китерелә. Хөсәен Әмирханның «Болгар тарихы»нда тупланган мәгълүматларга караганда, Илбактының Сөгүн исемле улы да Алабуга ханы булган, имеш.

Югарыда китерелгән материаллар Алабуганың Алтын Урда чорында ук яшәү ихтималлыгын күрсәтәләр, әмма, болар фаразның дөреслеген исбатлау өчен һич тә җитәрлек түгелләр.

Алабуга—болгар шәһәре һәм ул XII йөздә үк барлыкка килгән! Әлеге сенсацион хәбәр профессор А.Х. Халиков җитәкчелегендәге археологик экспедиция 1993 елда «Шайтан каласы»нда туплаган табылдыкларга нигезләнгән иде. Дөрес, табылдыклар әле азрак, әмма уйландырырлык иде. Алабуганың яше турындагы яңа хәбәрне галимнәр хуплап каршы алды димәс идем. Бигрәк тә урыс туганнарыбыз пошаманга төште кебек. Урыс шәһәре бит инде Елабуга, чишмә башы—Трехсвятскоедан, нигә инде казынып ятарга, янәсе. Җитми мени сезгә Әби патша фәрманы, имеш.

Остазым Альфред ага казуларыннан соң мин дә тынычлыгымны җуйдым. Казан кремлендә археологик тикшерү эшләрен башлап җибәреп, башкалабызның тарихын монголларга кадәре чор белән бәйләрлек табылдыклар килеп чыга башлагач, мин уйга калдым: бу төбәкләрдә, ягъни Кама аръягында гына түгел, аның бирге ягында да борынгы болгар калалары булгандыр ич инде. Казан, аңлавым буенча, бу якларда бердәнбер кала түгел. Димәк, аның яшьтәшләрен эзләп карарга кирәк.

Минем күңелем, табигый ки, Алабугага төште. Нәкъ шул елларда Пермь университетының тарих факультетын тәмамлап, Алабуга педагогика институтында Альберт Нигамаев исемле егетебез эшли башлаган иде. Аның белән таныш идек: археология практикасын ул безнең Биләр экспедициясендә үтте, А.Х. Халиков белән дә Алабуганың «Шайтан каласын, дөресрәге, Ак мәчетне казуда катнашты. Кыскасы, Алабугадагы археологик өйрәнүләрне мин Альбертка тапшырдым. Кем әйтмешли, ут өертеп эшли башлады. Аның эш нәтиҗәләре турында сөйләгәнче, тикшеренүләр тарихына бераз тукталып үтик.

Борынгы Алабуга шәһәрлеге («Шайтан каласы») хәзерге шәһәрнең көньяк-көнбатыш читендә, Каманың кушылдыгы Тойманың уң ягында урнашкан. Елгадан биеклеге 52-60 метрга җиткән биек тау башында.

Табигать тарафыннан бик тә ныгытылган булуга карамастан, ясалма ныгытмалары да бар—җирдән өеп ясалган өч рәт үрләр һәм тирән чокырлар. Шәһәрлекнең гомуми мәйданы 3 гектар чамасы. Кызганыч, бик начар сакланган борынгы калабыз. Ныгытмаларның беренче һәм икенче рәтләре, культура катламының күп өлеше бөтенләй диярлек җимерелгән (бирредә 1990 нчы елларга кадәр таш чыгаралар иде әле).

Болгар чорыннан калган атаклы таш манара—җирле халык бары тик шуны гына «Шайтан каласы» дип йөртә—шәһәрлекнең көнчыгыш өлешендә, Каманың текә ярында урнашкан. Бу манара XY1 гасырның икенче яртысында язылган «Казан тарихы»нда да искә алына. Бушап калган әлеге калачыкта шайтан, җен яшәгән, имеш. Әле болгар чорында ук бирредә мәҗүсиләрнең табыну урыны һәм болгарларның мәчете булган, ди. Бирегә бик күп кешеләр килә торган булган—җирле халык та, чирмешләр дә, христианнар да. Алар теге җенгә корбан китергәннәр, гыйбадәт кылганнар. Җен авыру кешеләрне терелткән, ә аны күрмәмешкә сабышып, корбан бирмичә генә үтеп китүчеләргә зыян салган, елгада батырып үтергән. Берзаман Казан патшабикәсе сәетнең үзен Шайтан каласына җибәрә һәм җеннән сорашып-белешеп кайтырга куша: киләчәк зур сугышта Казан дәүләте исән калырмы, әллә Мәскәү патшасы җиңәрме? Атнадан артык җавап көтәләр болар. Бары тик унынчы көндә генә мәчеттәге кешеләр җен тавышын ишетәләр: «Аптыратмагыз инде мине, моннан соң миңа һәм минем ярдәмгә өметләнмәгез. Китәм мин сездән, минем урынга Христос киләчәк, бу җирләрдә ул патшалык итәчәк». Шуннан соң каладан һәм каладагы мәчет эченнән куе төтен бөркелә, төтен белән бергә һавага утлы елан күтәрелә һәм ул, көнбатыш тарафка очып китеп, күздән дә югала.

«Шайтан каласы»н һәм аның тирә-юнендәге таш бина хәрабәләрен беренчеләрдән булып 1769 елда Н.П. Рычков тикшерә. Ул вакытта әле бу бинаның өч манарасы сакланып калган була. Бу хәрабәләрне Н.П. Рычков болгарлар чорыннан калган мәчетнеке дип билгели.

1825 елда һәм бераз соңрак шәһәрлектә Казан университеты профессоры Ф.И. Эрдман һәм Н.Н .Кафтанников булып китәләр. Бу вакытта инде ныгытмалар эчендәге таш корылманың («мәчет»нең) бер генә манарасы калкып торган, калган икесе җимерелеп юкка чыккан. Ф. И. Эрдман үз мәкаләсендә ике катлы бу манараның рәсемен һәм шәһәрлекнең планын китерә.

1855 елда тиздән дөньякүләм танылачак яшь рәссам И.И. Шишкин, җирле тарихчы К.И. Невоструев үтенече буенча, шәһәрлекнең планын һәм анда әле күрергә мөмкин булган таш корылмаларның хәрабәләрен рәсемгә төшерә.

Бу борынгы корылмалар рәссамның әтисен, Алабуга тарихында якты эз калдырган шәһәр башлыгы И.В. Шишкинны да, күптән кызыксындырып килгән. 1867 елда аның тырышлыгы белән борынгы таш бинаның теге ике катлы манарасы төзекләндерелеп, яңадан элеккеге рәвешенә китерелә. Шул хәлендә әлеге манара—монголлар явына кадәрге болгарларның безнең көннәргәчә сакланып калган бердәнбер архитектура һәйкәле—һаман да Алабуганың күрке, шәһәрнең үзенчәлекле символы булып, еракларадан ук күренеп тора. В. Шишкин 1971 елда Алабуга тарихына багышланган кечкенә генә китап та бастырып чыгара. Үзенең элгәреләре тарафыннан әйтелгән фикерләрне тәнкыйтьсез генә кабул итеп, автор тулы ышаныч белән, бик борынгы чорларда хәзерге Алабуга территориясендә скифлар шәһәре Гелон, ә болгарлар чорында Ибраһим (Бряхимов) каласы урнашкан дип яза.

Тарихчы К.И. Невоструев та урыс елъязмалары буенча мәгълүм Бряхимовны «Шайтан каласы» белән тәңгәлләштереп: «Алабуга шәһәре элек Идел Болгарстаны составына, соңрак Казан ханлыгына кергән, ә аның барлыкка килүе тагын да борынгырак чорларга карый. Бернинди шикләнүләрсез әйтергә мөмкиндер, бирредә элек 1164 елда Андрей Боголюбский гаскәрләре тарафыннан таланган һәм җимертелгән Бряхимов шәһәре торган»,—дип яза.

Алабуга-Бряхимов (Ибраһим) тәңгәллеге соңгырак чор тарихчыларының тәнкыйть утына дучар була. Профессорлар С.М. Шпилевский һәм В.Ф. Смолин хезмәтләрендә XI йөздән башлап монгол яуларына кадәр Идел

буенда урнашкан Болгар шәһәренең Бряхимов исемен йөрткән булуы ышанычлы дәлилләр китереп исбатлана. Бу фикер тарихчы-галимнәр арасында бүген дә бернинди шик уятмый.

1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәр Алабуга шәһәрлегендә казу эшләре бары тик бер генә тапкыр була—1888 елда биредә күренекле рус археологы А.А. Спицын кызыклы тикшеренүләр үткәрә. Ул башта шәһәрлекне планга төшерә, саклану ныгытмаларын өйрәнә, берничә урында шурфлар салып, культура катламының калынлыгын ачыклый, аннан соң бер манарасы сакланып калган таш корылма хәрабәләрен тулысынча казып чыгара. Бу борынгы бинаның нигезе квадрат формасында булып, почмакларына түгәрәк манаралар корылган була. А.А. Спицын раславынча, әлеге бина XIII гасырдан элегрәк төзелгән һәм ул йә кәрван-сарайның бер өлеше, йә берәр атаклы мөселман изгесенең төрбәсе булган. XIV йөз ахырында мәшһүр Аксак Тимер шушы төрбәне карарга килмәдеме икән әле, дип Мөслиминең чынбарлыктан ерак торган, шикле мәгълүматларына таянып яза ул.

Профессиональ археолог буларак, А.А. Спицын казулар вакытында килеп чыккан табылдыкларга да игътибар итә. Алар арасында тимердән һәм бакырдан эшләнгән әйберләр була. Тимер ук очлары монголларгача чорга карый. Балчык савыт-саба калдыкларын А. А. Спицын дүрт төркемгә бүлә: 1) кызыл балчыктан чүлмәк ясау түгәрәге кулланып эшләнгән яхшы сыйфатлы болгар савыт-сабасы; 2) төелгән бака кабырчыгы кушып әзерләнгән балчык измәсен кулдан гына әвәләп ясалган савыт-саба; 3) башка төрле өстәмәләр (елга комы, тирес, кош тизәге һ. б.) кушып әзерләнгән измәдән әвәләп ясалган борынгы чүлмәкләр; 4) соңгырак чорга караган кара-көрән төстәге урыс чүлмәкләре. Бу типология, бер яктан, шәһәрлектә яшәгән халыкның төрле этностан булуын күрсәтеп торса, икенче яктан, аның болгарларга кадәр күпкә элегрәк барлыкка килүе турында сөйли.

1911 елда «Шайтан каласы»ннан бераз читтәрәк, Алабуга шәһәренең үзәк өлешендә, очраклы рәвештә бер хәзинә табыла һәм тиз арада ул Петербургка, Археология комиссиясенә озатыла (хәзерге көндә Эрмитажда саклана). Бу хәзинәдә дүрт көмеш алка, 17 көмеш гривна (борынгы акчалар) һәм өстенә алтын йөгертелгән төймә була. Табылдыклар XI-XIII гасырларга карыйлар. Хәзинәнең тарихи чыганак буларак әһәмияте зур, ул болгарларның калада гына түгел, ә бистәдә дә яшәүләренә ишарәли.

Узган гасыр урталарында Алабуга шәһәрлеге совет чорында болгарны өйрәнү фәненә нигез салган атаклы археолог, профессор А.П. Смирновның да игътибарын җәлеп итә. Ул 1951 елда дөнья күргән «Идел болгарлары» исемле фундаменталь хезмәтендә, «Шайтан каласы» әле Идел Болгарстанына кадәр үк барлыкка килгән һәм бик озак гомер яшәгән, дип раслый. «Әлеге кала борынгы община чорында, моннан якынча 2600—2700 еллар элек, хәрби ныгытма-крепость буларак төзелгән,—ди А. П. Смирнов икенче бер хезмәтендә.—Бу җирләргә X-XI гасырларда болгарлар киләләр һәм борынгы кала территориясендә таштан биек манаралары белән яңа корылма—цитадель торгызып куялар». Болгар иленең төньяк чигендәге иң мөһим терәк пункты була ул. Алабуга каласыннан болгарлар күрше удмурт кабиләләренә яу чапканнар, аларны феодаль бәйлелектә тотканнар, салым түләткәннәр. 1958 елның җәендә болгарчы-археолог Т.А. Хлебникова төркеме эшләп китә. Ул шәһәрлек территориясендә казу эшләре үткәрми, шурфлар гына сала. Аның күзәтүләре буенча, каланың культура катламы тулысынча ананьино чорында (безнең эрага кадәр VII-V гасырлар) тупланган булып чыга; болгарлар килгәч, биредә яңа кала торгызмыйлар, имеш, борынгы ныгытмаларны бераз төзәткәләп, читтәрәк дүрт манаралы таш бина (крепость?) утыртып куялар.

Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты археологы М.М. Кавиев 1981 елда Алабуга каласында уңышлы гына казу эшләре үткәрә. Кала ныгытмаларын казып тикшергәннән соң ул икенче рәт балчык урләрнең болгар чорында өелгән булуы турында ныклы фикергә килә. Казылмалардан чыккан табылдыкларга нигезләнеп (ананьино чорына караган катламнан 341 чүлмәк ватыгы, IV—VII гасырның

Имәнкискә катламыннан—64 фрагмент, болгар катламыннан—11 фрагмент һ. б. кайбер табылдыклар), М.М.Кавиев та, калада болгарлар даими яшәмәгәннәр, сугыш куркынычы килеп туганда, качу-саклану урыны буларак кына файдаланганнар, дигән нәтиҗә ясый.

Киң тикшеренү эшләре Алабуга шәһәрлегендә 1990 нчы елларда башланып китте. «Шайтан каласы» (заманында И. В. Шишкин торгызган манара) тирәсен, Казан археологлары белән киңәшмичә генә, Алабуга пединститутына археология укытырга чакырылган удмурт егете К.И. Корепанов казып карарга булган. Казу эшләренең икенче сезонын башлап җибәрү алдыннан (1992 елның мае иде бугай) безнең археологлар алдында, әллә никадәр сызымнар-рәсемнәр күрсәтеп (дөрес, фотолары юк иде), доклад белән чыгыш ясаганы хәтердә. Мең квадрат метрга якын мәйданда эшләп янәсе, искитәрлек ачышлар ясаган: квадрат формасындагы таш цитадель һәм аның почмак манаралары, бу уникаль корылмага нигез салганда мәҗүси аллага корбан итеп китерелгән ике бала кабере, шушы таш цитадель эчендә 16 учак урыны, тегендә-монда аунап яткан ат һәм сыер сөякләре—мәҗүсиләрнең корбан чалу урыннары, балчык савытларда спираль рәвешендә бөгелеп киткән койрыклы әллә нинди фантастик хайван сурәтләре...

Шикләндерә торган, мантыйкка сыймастай сүзләр күп иде коллегабызның чыгышында. Кайбер сорауларыбызга да ышандырырлык җавап ала алмадык. Болгар материаллары буенча белеме дә чамалы икән. Тикшеренүләрне дәвам иткән очракта, ашыкмаска, бик сак булырга кушып таралыштык. Профессор А.Х. Халиков канәгатьсезлеген яшермәде: «Ай-һай, башкарып чыга алыр микән бу моны, тәҗрибәсе аз, тәкәбберлек хәттин ашкан, бозып ташламаса инде калабызны»,—дип борчылуын белдерде.

Тиздән барыбыз да экспедицияләргә чыгып киттек. Сентябрь башында гына яңадан очраштык. Күрешеп хәл-әхвәл сорашуга ук Альфред ага миңа: «Әйдә, җыен, барып кайтыйк әле Алабугага, теге малайның эшләре ничек икән»,—диде. Машинасына утырып чыгып киттек.

... «Шайтан каласы». Калатау өсте актарылып ташланган. Кая карама—балчык, таш өемнәре. Аңламыйча карап торабыз: кайда соң монда цитадель яки крепость диварлары? Безгә күрсәткән сызымнарда ул стеналар ап-ачык төшерелгән иде бит. Ә хәзер без ни күрәбез—казылмаларның бөтен мәйданы таш һәм известь кушылган балчык измә белән капланган. К.И. Корепановны чакырып, аңлатып бирүен сорадык. Аңлата алмады, стеналар юк иде.

Сөйләшә торгач шул билгеле булды: безнең егетебез, XIX гасыр ахырында биредә эшләгән А.А.Спицынның (хәтерегездә булса, ул әлеге таш корылманы тулысынча казып чыгарган була) сызымнарын алган да, үзенең эш хисабына бу корылма 1991 елда тикшерелде дип теркәп куйган. Аз гына үзгәрешләр кертеп, әлбәттә. Авызыбызны ачтык та калдык. Еларга да, көләргә дә белмәссең! Өстәвенә, ул Мәскәүдән рөхсәт кәгазе булмаган килеш тә эшләгән икән (археологка казырга рөхсәт бирә торган бу документ «Открытый лист» дип йөртелә һәм ул махсус гариза нигезендә Фәннәр академиясенең Археология институтыннан бирелә). Ни эшләргә? Казу эшләрен мәҗбүриләп туктаттырдык.

1993 елда Корепанов казылмаларын профессор А.Х. Халиков үзе дәвам итте һәм уңышлы тәгәлләде. Башта ул культура катламының стратиграфиясен ачыклады: Алабуга каласындагы иң борынгы катлам безнең эрага кадәр VII—V гасырларда яшәгән ананьино кабиләләре яшәгән чорга карый: аннан соңгы катлам пьянобор-азелино (безнең эраның II—V гасырлары) һәм имәнкискә (VI—VII гасырлар) кабиләләре белән бәйләнгән; тагын да «яшьрәк» катлам болгар чорында (X гасыр ахыры—XIII гасыр башы) тупланган. Иң соңгы катламнарда Троицкий монастыреннән ерак түгел XVII–XVIII гасырларда барлыкка килгән христиан зираты ачылды.

Болгар катламы калын булмаса да (уртача алганда 20-30 сантиметр чамасы гына), нәкъ шул катламда таш бина хәрабәләре ята иде. Аның нигезе болай яхшы сакланган: һәр як стенасының озынлыгы 21 метр, почмакларда диаметры 6 метрга җитә торган түгәрәк манаралар. Бүгенге көнгә кадәр сакланган манараның гына диаметры зуррак—10 метр чамасы.

Күрәсең, ул башкаларына караганда биегрәк тә булгандыр. Бинаның тагын бер кызыклы һәм әлегә кадәр аңлашылып җитми торган үзенчәлеге бар: өч якның стеналары уртасында ярымтүгәрәк, ә көньяк-көнбатыш стена уртасында өчпочмаклы манаралар. Ягъни, манаралар арасы уртача алганда 3-4 метрдан артмый. Нигә кирәк булган алар? Игътибарны тагын бер нәрсә җәлеп итә: бина өчпочмаклы «манаралы» ягы белән көньяк-көнбатышка—кыйблага карап тора. Нәкъ шуңа күрә дә А.Х. Халиков аны мәчет дип атады. Бер үк вакытта ул кечкенә кальга ролен дә үтәгәндер, мөгаен. Төзелү вакыты XII гасырның икенче яртысы дип фаразлана, әмма тагын да борынгырак булуы мөмкин.

Казулар вакытында табылган әйберләр артык күп түгел. Беренче урында, әлбәттә, керамика—балчык савыт-саба китекләре. Аларның бер төркеме югары сыйфатлы болгар савытлары, икенче төркеме—түгәрәк төпле, балчык измәсенә бака кабырчыгы кушып ясалган тәбәнәк чүлмәкләр. Соңгылары, белгечләр фикеренчә, төркиләшкән угорлар тарафыннан X гасыр ахырында—XI гасыр башында эшләнгән. «Җукәтау» тибындагы керамика сан ягыннан өченче урында тора. Шул ук вакытта берән-сәрән генә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караган керамика да очраштыргалый. Болардан тыш, табылдыклар арасында тимер ук очлары, йозак һәм ачкычлар, балык кармаклары, пычаклар, шифер (шәмәхә төстәге йомшак таш) һәм балчык орчык башлары, муенса төймәләре бар иде.

Калатауда өстәмә казу эшләре Альберт Нигамаев тарафыннан 1996, 1999 елларда үткәрелде. X–XIII йөзләргә караган табылдыклар азрак булды, әмма болгарларның бер генә йорт һәм хуҗалык корылмалары да килеп чыкмады. Димәк, биредә даими яшәүчеләр булмаган, дияргә кала.

Нигамаевның 1994 елгы тикшеренүләре кызыклы нәтиҗәләргә китерде. Кала ныгытмаларыннан 130 метр көньяк-көнчыгышка китеп, культура катламының җимерелгән урыннарын чистартканда, археологлар хатын-кыз каберлегенә юлыгалар. Кызганычка каршы, ул нык кына таланган була инде. Сакланып калган әйберләр арасында көмештән эшләнгән чигә алкасы һәм бакырдан эшләнгән шалтыравык асма бизәк чылбырлары бар иде. Чигә алкасы X-XI гасырларда Идел Болгарстанында, ә асма бизәкләр борынгы удмуртларда һәм угор халыкларында бик еш очрый торган бизәнү әйберләреннән санала. Шул тирәдән үк тимер сөңге очы да табылган. Ул XI-XII гасырларга карый.

Тарих фәннәре докторы Е.П. Казаков фикере буенча, бу каберлектә X гасыр ахырында ерак Урал якларыннан Кама елгасы буйлап күчеп килгән угор телле халыкның бер вәкиле күмелгән (угор телле халыкларга хантлар, мансилар һәм венгр-маҗарлар керә). Бу фикер белән без дә килешәбез. Болар инде шактый гына төркиләшкән угорлар булгандыр дип кенә өстәмәкче булам. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк: Алабуга шәһәрлегендә тупланган табылдыкларның яртысыннан артыгракы шул угорларга карый.

Угорлар артыннан ук бирегә болгарлар килеп җитә. Бу вакытта Болгар дәүләте күзгә күренеп ныгый бара, чикләрен төньякка һәм көнчыгышка таба киңәйтә, яңа җирләр үзләштерә, күрше фин халыклары (мари, удмурт, комиларның борынгы бабалары) белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләрен җайга сала. Болгарлар Алабуга каласында тукталып калалар. Бар яктан да уңайлы урын була ул: табигать тарафыннан яхшы ук ныгытылган, сәүдә итү өчен янәшәдә генә су юлы, тирә-юньдә бай көтүлекләр, урманнар...

Шулаен ул шулай, әмма кайда яшәгән соң ул борынгы Алабуга халкы? Калатауда эзләре бар, хәтта таш мәчетләре дә шунда булган, дидек. Ләкин... Хәзерге Алабуганың элгәресе, чишмә башы дип санап буламы соң шул «Шайта каласы»н? Бик шикле. Эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк.

Әлеге табышмакны әкренләп кенә археолог Альберт Нигамаев чишә башлады. Ул хәзерге Алабуганың үзәк өлешендә, «иске шәһәр»дә әле 1911 елда ук табылган хәзинәне искә төшерә. Җитмәсә, 1994 һәм 1997 елгы җир эшләре вакытында шул ук тирәдә мөселманча күмелгән шактый борынгы каберлекләр дә килеп чыга. Бер чокырдан болгар чүлмәкләре дә табып алалар. Әлбәттә, бу табылдыклар очраклы түгел. Шәһәрнең иске

өлешендә, Спас һәм Покров чиркәүләре арасында археологик тикшеренүләр үткәрергә кирәк, дигән карар кабул ителә.

1997—2000 һәм 2003 елларда Зур Покров урамының 26, 28, 30 нчы йортлары каршындагы ишегалдында археологик казу эшләре үткәрелде. Культура катламы артык калын булмаса да, җентекләп тикшергәннән соң, болгар (X-XIII гасырлар) һәм болгар-татар (XIV-XVI гасыр уртасы) чорында тупланганнарын аерып алырга мөмкин булды. Бу катламнарда табылган керамика бик үзенчәлекле: 600 ләп фрагмент болгарларныкы, 41 фрагмент—Казан ханлыгы чорында яшәгән татарларныкы, 987 фрагмент—Югары Кама, ягъни хәзерге Пермь якларыннан күчеп килгән фин-угорларныкы иде. Соңгы төркемдә (балчыкка төелгән бака кабырчыгын кушып кулдан гына әвәләп ясалган, тоткы, аксыл соры төстәге тәбәнәк чүлмәкләр бар. Аларның зигзаг рәвешле гади генә бизәкләре югары сыйфатлы болгар савытларыннан нык аерылып торалар. Шулай итеп, бик тә кызык килеп чыга: табылдыкларның яртысыннан артыгы болгар-татарларныкы түгел, бәлки читтән килгән халыкныкы. Ә менә казылмаларда килеп чыккан XIII-XV гасыр каберлегендәге мәетләр (барлыгы уналты) башлыча мөселман йоласы буенча күмелгәннәр. Дөрес, йоладан кайбер тайпылышларны да күрмичә мөмкин түгел: берничә скелетның кабыргалары, умыртка сөякләре юк (борынгы заманнарда моны махсус шулай эшләгәннәр—мәетне, исәннәргә зыян салмасын дип, «зарарсызландырганнар»), берсенең башы янында тимер ук очы, биле тирәсендә кадак ята иде.

Табылдыклар коллекциясенә күз төшерик: пыяладан һәм төрле асылташлардан ясалган муенса төймәләре, бакырдан эшләнгән беләзек, үрдәк рәвешле шалтыравык асма бизәк, тимер кайчы, пычаклар, ачкыч-йозаклар, ук очлары, орчык башлары һ. б. Үзбәк хан хакимлек иткән чорда (1312—1342 еллар) сугылган бакыр тәңкә һөнәрчелек белән бәйле (?) бер чокырдан килеп чыкты. Бу чокырда бик күп тимер-томыр, көл-күмер, таш-кирпеч ватыклары табылды.

Болгар-татар катламнары белән бәйле корылмалар арасында иң кызыклысы XII-XIV гасырларга караган саклану ныгытмасы иде. Ул безнең көннәргә киңлеге 6, тирәнлеге 2 метрдан артык булган чокыр һәм аның бер ягындагы бүрәнә стена (койма), дөресрәге, шуннан калган багана чокырлары рәвешендә килеп җиткән. Казылмага эләккән өлеше тугыз метрдан аз гына артык. Бу чокырдан килеп чыккан табылдыклар арасында игътибарга лаеклысы—ат формасында ясалган бронза йозак. Мондый йозакларны монголларга кадәрге чорда башлыча Биләр остаханәләрендә эшләгәннәр. Безнең табылдык XIII гасырга карый. Нәкъ шундый ук болгар йозагы Пермь өлкәсенең Чердынь музеенда саклана.

Борынгы Алабуга территориясендә урнашкан тагын бер зират (дүртенче некрополь) Тукай урамындагы 2 «а» номерлы йортның яшелчә бакчасында хуҗалык чокыры казыганда очраклы рәвештә табылган. Унбишләп муенса төймәсе, көмештән ясалган чигә алкасы, болгар чүлмәге ише табылдыклар турындагы хәбәрне ишетүгә үк Альберт Нигамаев йорт хуҗасы янына килеп җитә, җайлап кына сөйләшеп, археологик казу эшләренә рөхсәт ала.

Алабуганың яшен ачыклауда әлеге казылмалар хәлиткеч роль уйнады дисәк тә артык булмастыр. Биредә А. Нигамаев дүрт каберлек ачты. Аларның беренчесендә, 75-85 сантиметр тирәнлектәге чокырда, 20-30 яшьләрдәге хатын-кыз күмелгән иде. Башы белән төньяк—төньяк-көнбатышка, йөзен көньякка каратып салганнар, куллары гәүдә уңаена сузылган. Кием һәм агач табут эзләре сакланмаган. Баш янына болгар кувшины куелган, кулбашы тирәсендә муенса төймәләре сибелгән, шул тирәдә үк көмеш чигә алкасы. Төймәләр зәңгәр, куе кызыл һәм көрән төстәге пыяладан эшләнгәннәр. Күбесенең өслегенә күзгә охшатып ясалган, берничәсенә «күз һәм керфекләр» рәвешендәге бизәкләр төшерелгән. Скелетның күкрәк өлешендә ике ягына вак кына чылбырлар белән шалтырама шарчыклар эленгән бакыр колак чистарткыч ята иде. Уң кулының терсәге янында тимер пычак куелган. Санап кителгән табылдык

X гасырның ахыры—XI гасыр башларына нисбәтле.

Икенче каберлектә тәртипсез рәвештә аунап яткан кеше сөякләре, шул исәптән 16-18 яшьлек хатын-кызның баш сөяге, каеш каптырмасы, пычак һәм чүлмәк китеге генә табылды. Бу каберлек тә монголларга кадәрге болгар чорына карый.

Өченче каберлектә 16-20 яшьлек хатын-кыз мөселман йоласы буенча күмелгән. Баш тирәсендә дүрт кадак ята иде, башка әйберләр табылмады. Бәлки, мәет агач табутта күмелгәндер? Тимер кадаклар шуңа ишарәли. Болгар бабаларыбыз XI—XIII гасырларда шул рәвешле күмә торган булганнар.

Соңгы каберлек бик нык җимерелгән, скелеттан калган бер-ике сөяк кенә аунап ята иде. Табылдыклардан бер тоткалы «җукәтау» тибындагы чүлмәк һәм шалтырамалы асма бизәктән бер деталь сакланган. Каберлек якынча XI-XII гасырларга карый.

Табылдыкларны хронологик яктан анализлап, археолог А.З. Нигамаев, әлеге зиратка X гасыр ахырыннан башлап XII гасырга кадәрге мәетләр күмелгән дигән нәтиҗә чыгара. Әмма бу саф болгар зираты түгел, биредә мәҗүсилектән мөселманлыкка күчү һәм болгарлаша бару чорындагы фин кабиләсе вәкилләре (удмуртлар яисә комилар) җирләнмәгән микән?

Борынгы Алабуга казылмаларында табылган әйберләрне өйрәнеп, археологлар шәһәрнең X гасыр ахырында, йә булмаса XI гасыр башында барлыкка килүе мөмкин, дигән фикергә килделәр. Икенче төрле итеп әйткәндә, Алабуга Казанның яшьтәше булып чыга. Бу фикерне Алабугадагы казу эшләрендә катнашып, табылдыкларны карап-тикшереп киткәннән соң Россия Фәннәр академиясе академиклары В.В. Седов, В.Л. Янин, профессорлар М.В. Седова (Мәскәү), М.Г. Иванова (Ижевск), А.М. Белавин (Пермь) һәм башка археологлар да яклап чыктылар.

Алабуганың шул вакытларда ук барлыкка килүенә шикләнеп карарга ярамый, киресенчә, моны бик тә табигый, шулай булырга тиешле хәл итеп кабул итәргә кирәктер, минемчә. Түбән Кама төбәгендә X гасыр ахырларына килеп туган сәяси һәм икътисади вәзгыятькә күз төшереп алыйк. Хәзәр каһанлыгы җимерелгән, Төньяк-Көнчыгыш Русе әле көч туплап өлгермәгән шартларда Идел Болгарстаны Уралдан алып Югары Иделгә кадәр булган иксез-чиксез киңлекләрдә бердәнбер куәтле дәүләт буларак таныла. Болгар дәүләте үзенең чәчәк ату чорына керә: яңгырдан соң чыккан гөмбәләрдәй, илнең әле бер, әле икенче почмагында бер-бер артлы кала-шәһәрләр—һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре үсеп чыга. Болгар һөнәрчеләренең югары сыйфатлы тауарларын сату өчен эчке базар гына җитми, тышкы базар да кирәк була башлый. Сәүдәгәрләр карашларын әкренләп күрше фин-угор халыкларына юнәлтәләр. Болгар халкының X гасырда ук инде Мишә, Казансу, Нократ елгаларына килеп төпләнүе, Кама буйлап һаман югары күтәрелүе, гомумән, төньяк-көнчыгыш тарафларга китеп урнашуы, беренче чиратта, нәкъ менә сәүдә-икътисад мәнфәгатьләре белән аңлатыла. Алабуганың Кама сәүдә юлында урнашуы табигый—күрше фин-угор кабиләләренә болгарлар шул юлдан барып йөргәннәр бит. Хуш, фин-угорлар да бу якларга Кама буйлап төшәләр һәм ананьино-имәнкискә заманнарыннан ук калган ныгытмалы калатауга килеп төпләнәләр. Тиздән алар биредә, булачак Алабуга җирендә, болгарлар белән очрашалар. Болгарлар борынгы ныгытмага яңадан җан өреп җибәрәләр. Таштан дүрт манаралы мәчет торгызып куялар. Бер үк вакытта хәзерге шәһәрнең үзәк өлешендә дә яши башлыйлар.

Шулай итеп, Болгар иленең төньяк-көнчыгыш чигендә, Кама сәүдә юлында Алабуга барлыкка килә. Ул озак вакытлар бу төбәкне колонизацияләүдә форпост итеп файдаланалар. Бүген безнең кулда булган археология материаллары Алабуганың иң борынгы чорын шулайрак күз алдына китереп бастыралар.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Карашәм

Карашәм авылы Яшел Үзән районында, Зөя суының түбән агымында урнашкан. Ул Зөянең Иделгә коя торган урыныннан 35-40, ә Гөбенә суының Зөягә кушылган жиреннән төньяк-көнбатыштарак 7-8 чакрым ераклыкта тау итәгенә утырган. Район үзәгеннән Карашәм авылы 40 чакрымда, жирле үзидарә үзәгеннән—5, Гөбенә тимер юл станциясеннән—7, Борындык пристаненнән 17 чакрым ераклыкта.

Карашәм атамасы шактый күп тарихи чыганакларда искә алына. Казан ханлыгы чоры атамаларын исәпкә алган исемлектә Зөя өязендәге Карашәм авылының исеме очрый.

Карашәм авылы янында археологлар болгар—Алтын Урда чорларына нисбәтле кыйммәтле бизәнү әйберләре, керамика кыйпылчыклары, акча һәм әйбер хәзинәләре тапканнар.

Д. А. Корсаков тарафыннан 1908 елда Казанда чыгарылган «Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке» дип аталган хезмәттә дә Карашәм авылы исеме теркәлгән. Анда 47 йомышлы татар һәм 2 керәшен яшәгәнлеге күрсәтелә. А. Артемьев (1866) мәгълүматларына караганда, Карашәм суы буена утырган Карашәм авылының 61 йортында 207 ир-ат һәм 227 хатын-кыз исәпләнгән, мәчет эшләгән. Шулай ук авыл атамасы «Аграрный вопрос и крестьянское движение 50-70-х годов XIX в.» дип аталган китапта (М.-Л., 1936, 96-99) 1882 елның 4 июль көнне жир бүлү вакытында килеп чыккан низаглар белән бәйләнешле рәвештә искә алына. 1898 елгы жыентыкта Карашәм авылында татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. Икенче тарихи хезмәттә (К.П.Берстель, 1908) Карашәм авылында 817 татар кешесе көн итүе билгеләнә. Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Карашәм авылы халкы күршедәге Мамадыш-Әкил, Татар Танае, Татар Әжәлесе, Кызыл Яр авыллары белән бергә июнь ае уртасында Кала ала жыены (икенче исеме Түбәтәй жыены) бәйрәм иткән.

Карашәм авылының оешуы һәм тарихы белән авыл халкы да бик нык кызыксынган. Өлкәннәр бу турыда байтак уйлаганнар һәм булган мәгълүматларны язып та калдырганнар. Шунысы куанычлы, авылларда яши торган халык арасында үз төбәкләренең, үз авылларының тарихы белән кызыксынучылар элек тә булган, хәзер дә бар. Алар язган истәлекләр буыннан-буынга күчеп, безнең көннәргәчә килеп житкән.

1978 елда Татарстан китап нәшриятында Кәрим Абдюшевның «Карашәм» дип аталган китабыннан мондый юллар укыйбыз: «Безнең авылның бу урында бик күптәннән төпләнүен раслый торган бер язма да бар. Ул—Карашәм кешеләренең нәсел шәжәрәсе. Аны моннан 100-105 ел элек Габдуш улы Һидиятулла бабай төзегән. Үз чорының укымышлы кешеләреннән булган Һидиятулла бабай 1919 елны 90 яшендә Карашәмдә вафат булган».

Төп нөсхәсе Казан дәүләт университетының Лобачевский исемендәге гыйльми

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

китапханәдә «Т-4308 № 13 шифры» белән саклана торган бу шәҗәрәдә Карашәм халкынын беренче бабасы Абелхаликъ булып күренә. Ләкин бу шәҗәрәдә Һидиятулла бабай кулы белән язылган искәрмә бар. Аннан күренгәнчә, Карашәм авылына башлап төп чыгышы Болгар шәһәреннән булган Чадаш бәк уллары Инсан һәм Ихсан нигез салганнар.

Һидиятулла бабай язганнарга таянып, Кәрим Абдюшев Карашәм авылы 700-800 еллар элек оешкан болгар-татар авылы дигән фикер әйтә. Бу фикер файдасына сөйли торган фактлар шактый. Һидиятулла бабайнын авыл тарихын ачыклый торган, күп буыннарны эченә алган нәсел шәҗәрәсе төзүе генә дә авылнын борынгыдан килә торган традицияләре булганлыгын күрсәтә. Безнен борынгы бабаларыбыз җиде һәм тугыз буынга кадәр булган бабаларынын исемнәрен бик әйбәт белгәннәр. Аны белү һәркемнен намус эше исәпләнгән.

М. Әхмәтҗановнын «Татар шәҗәрәләре» китабында Карашәм авылыннан Дусмәт шәҗәрәсе китерелгән. Анын берничә варианты бар икән.

Шәҗәрә К. Насыйри йогынтысында кәгазьгә төшкән, күрәсен, чөнки ул 1870 елларда шул якларда йөргән. Бу нәселнен ышанычлы тарихы XVII гасырнын икенче яртыларыннан гына башлана. Чадаш бик, Инсан, Ихсан исемнәре «Дастан» китабы белән танышкач килеп кергән, күрәсен. Ләкин Үлмәс абыз һәм Габделхаликъ исемнәре Карашәм ягында йөргән риваятьләрдән алынган. Бу ике шәхес «Казан бәете»ндә төп каһарманнар булып тора. Шунлыктан Үлмәс абыз XVI-XVII гасырларда Тау ягында яшәгән бер тарихи шәхес булса кирәк. Шәҗәрәдә телгә алынган Габделкасыйм 998/1500 нче елда үлгән Касыйм бине Ибраһим әл-Казани образы булса кирәк. Бу шәхеснен исеме Тау ягында бик популяр. Норлат авылы янында (Яшел Үзән районы) Касыйм бабай кабере дигән мәшһүр бер кабер бар. Бу кабер шулай ук Х. Мөслиминен «Тәварихы Болгария» китабында да искә алына (Әхмәтҗанов).

1978 елда авылда барлыгы 150 хуҗалык булган. 1992 елга авылдагы йортлар саны аннан ким инде. Чөнки узган дистә елларда авыллар таралды да таралды. Халыкнын бер өлеше читкә, шахталарга киткән, икенче өлеше Мәскәү метросы төзүдә катнашкан. Тырыш, булдыклы, унган милләттәшләребез кайда ниләр генә эшләмәгән! Кешеләр үзләре теләп тә киткәннәр, китәргә мәҗбүр дә ителгәннәр. Шулай итеп, бер урында оешып утырган халык төрле җирләргә сибелгән.

Авылнын урыны матур һәм унайлы. Ул тау арасына, тирән чокырлар буена яшеренгән. Авыл башлангыч чорында шул тау арасындагы чокырнын түбән өлешенә сыенган булган. Сәлимгәрәй Зиннәтуллин, Гафият Гыйсмәтуллин, Нуретдин Хөснетдинов дигән кешеләрнен йорт урыннары авылнын беренче төп нигезе булган.

Карашәм авылынын бер бабасы турында халыкта мондый риваять йөри икән: «Карашәмнен Әбелкасыйм баба Тау иле авылында яшәгән. Тау иле халкы аны ни өчендер яратмый һәм ул карангы төнне кара шәм яндырып хәзерге Карашәм авылына килеп урнашкан. Шуна күрә авылны Карашәм дип атаганнар. Бер заман бу бабай үлгән. Шуннан бабайны күмәргә кабер янына куйганнар. Шулвакыт ул кабыгы белән күтәрелеп очып киткән. Күмүчеләр артыннан барганнар. Ул Ислам кырына килеп төшкән һәм аны шунда күмгәннәр. Анда шулай ук Гайшәбикә тутай, Зөһрә, Әбелхарис бабай каберләре дә бар икән».

Тарихи чыганакларда язылганча, XIV гасырнын икенче яртысында һәм XV йөзләрдә Болгар дәүләте халкы Кама алды төбәкләренә һәм төньяк-көнбатыш—Зөя елгасынын түбән агымындагы җирләргә күчеп киткән, яна җирләрне үзләштергән, урман кисеп җир ачкан. Карашәм күршесендәге Әҗәле һәм Наратлы авылларынын атамалары «Список с писцовой и межевой книги города Свияжска и уезда. Письма и межевания Никиты Васильевича Борисова и Дмитрия Андреевича Кикина» (1565-67 г.—Казань, 1909) хезмәтендә искә алыналар. Авыл микротопонимнары арасында «Алып бабай чабата каккан җир» дип аталган урын бар. Биеклеге—3, әйләнәсе 10-15 метр чамасы тәшкил иткән калкулыкны берләштергән бу географик берәмлек авылнын шактый ук борынгы чорларда барлыкка килүенә ишарә итә. Археологлар Карашәм авылы янында сонгы болгар

чорларына караган акча хәзинәсе һәм башка табылдык әйберләр теркәгәннәр.

Авылның иске һәм яна зиратлары тоташ бер каберлекне тәшкил итә. Каберләр өстенә агачлар утыртылган, чардуганнар тотылган, ташлар куелган, зират әйләнә-тирәсе әйбәтләп рәшәткә белән әйләндереп алынган.

Карашәм авылының тирә-юнендәге наратлыкларның истәлеге буларак, авыл янында әле дә бик юан ике нарат агачы үсеп утыра. Әлегә кадәр киселеп бетмәгән калын урманнарның аерым кишәрлекләренә халык исемнәр биргән. Руша, Учаскы, Бачка (Васька) урманнары—бу исемнәр әллә ни ерак заманнарга карамасалар да, тарихчы өчен мәгълүмат бирә алалар.

Казан арты микротопонимиясендә «ышна» берәмлеге еш очрый. «Ышна»—Тау ягы төбендә урнашкан авылларда да шактый күзәтелә. Карашәм авылы басуларында Салих ышнасы, Кәрим бабай ышнасы, Гыйлаж ышнасы һ. б. бар. Инде әйткәнебезчә, ышна ачып чәчүлек җире хәстәрләгән авыллар, кагыйдә буларак, шактый борынгы булалар.

Карашәм крәстиәннәренең чәчүлек җирләре Октябрь инкыйлабына кадәр бик таркау, төрле урынга сибелгән була. Шулардан берсе 12-13 чакрымда, Норлат авылының төньягындагы Тау Иле—Косяково авыллары янында; икенчесе—Норлаттан 2-3 чакрым ераклыкта—Рус Исламы һәм Татар Исламы авыллары арасында урнашкан булган. Бу җирләрнең беренчесен авыл халкы «Тау Иле басуы», икенчесен «Касыйм кыры» дип атаган. «Бу кырлар,—дип яза Кәрим Абдюшев,—ни өчен Карашәмнеке булганнар, хәзергә бертөрле дә нигезле мәгълүматлар табылмады. Тау Иле Касыйм кырларындагы җирләрен күп хуҗалыклар, бигрәк тә атсыз хуҗалыклар, үзләре чәчә алмаганнар. Казан арты, Кама арьягы җирләрендәге аерым авылларның чәчүлек җирләре яисә болыннары авылдан шактый ерак урыннарда, аерым алганда ун, унбиш, егерме, утыз, кырык, илле чакрым җирләрдә урнашкан булган».

«Карашәм» сүзенең килеп чыгышына карата Кәрим Абдюшев китабында ике риваять китерелә. Бик борынгы риваятьләрнең берсенә караганда, Карашәм дигән сүз таулар арасында посып утырган авыл халкының кичләрен һәм кышкы төннәрдә кабызган чырага нисбәттә әйтелгән мәгънәдән килеп чыккан. Яктысы үзеннән әллә ни еракка китә алмаган бу чыралар кара шәм, караңгы шәм булганнар. Караңгы шәм... Караңгы тормыш... Икенче бер риваятькә караганда, Карашәм авылы төпләнгән урында зифа каеннар бик күп булган, шуларны күргән бабаларыбызның берсе гаҗәпләнеп: «Кара, кара! Шәм кебек!» дип кычкырып җибәргән, имеш. Шуннан башлап авылны Карашәм дип атыйлар икән.

Ләкин бу риваятьләрдә Карашәм атамасының мәгънәсе ачылмый. Карашәм атамасын турыдан-туры «кара шәм» сүзе белән бәйләү урынлы булырмы икән? Бу гөманлау фәндә «халык этимологиясе» дип атала торган аңлатмага бик охшаган.

Карашәм атамасы «кара» сүзе белән төрки телләрнең угыз төркеменә керә торган әзәрбәйҗан һәм төрек телләрендә «нарат» мәгънәсе алган «шәм» сүзе кушылмасыннан тора дигән фикер бар. Болай фараз иткәндә, Карашәм атамасы «кара нарат, куе наратлык», яки «кара, куе, тыгыз нарат урманы» (татар телендә тыгыз, куе, караңгы урман, карурман, кара урман дип әйтелә) мәгънәсен белдерә (Саттаров). Шулай ук бу очракта мисал итеп тагын Татар Наратлысы һәм Рус Наратлысы атамаларын китерү дә урынлы булыр.

Татарстан җирендә «шәм» берәмлеген үз эченә алган атамалар еш очрый. Мәсәлән, Шәм Суар, Шәм Балыкчы һәм башкалар. Карачай-Чиркәс җирләрендә дә бер урын исеме Шәм Теберда дип атала. Санап үтелгән соңгы өч атаманы бу ояга кертеп карау дөрес булырмы икән? Карашәм атамасында «шәм» сүзе, «нарат» мәгънәсен белдерә, ә Шәм Суар атамасындагы «шәм» сүзе, Һ. Йосыпов фикеренчә, «кояш» төшенчәсен аңлаткан гарәп сүзе «шәмс» белән бәйләнешле. «Суар» сүзе—этноним. Шәм Суар атамасы Кояшлы Суар, кояшка охшаган матур Суар төшенчәсен бирә. Балыкчы сүзе дә—этноним. Шәм Балыкчы атамасының мәгънәсе «Кояшка охшаган матур Балыкчы» булып чыга. «Теберда» сүзе дә этноним булса, аның мәгънәсе «Кояшка охшаган матур Теберда» дип аңлатылыр иде.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң буйсындырылган җирләр урыс

феодалларына бүлеп бирелә һәм бу җирләрдә урыс авыллары калкып чыга башлый. Буйсындырылган җирләрнең чикләрен саклау өчен хәзерге Татарстан җирләренә йомышлы мишәрләр һ. б. күчереп китерелә. Тау ягы җирләренә дә чит милләт вәкилләре күпләп китереп утыртыла. Уңдырышлы, әйбәт һәм матур җирләр урыс алпавытлары кулына эләгеп кала. Җирле халыкларның бер өлеше күчеп китә, калганнары исә зур көч куеп, бөтен тырышлыкларын җигеп дөнья көтәләр.

Карашәм авылы халкы, югарыда әйтелгәнчә, «беркетелмеш» (крепостной) булмаган. Ләкин монда татарлар тормышны авырлык белән генә алып барганнар. Яхшы уңдырышлы җирләр, болыннар һәм урманнарның да бер өлеше алпавыт милке булып саналган. Ул җирләрне Гурди кыры дип йөрткәннәр. Бачка (Васька) урманы дип аталган урман да Гордеево алпавытыныкы булган. Авылның көнбатыш ягындагы яхшы җирләр Панаево алпавыты Филипсонныкы һәм Рус Танае алпавыты Обуховныкы булганнар. Боларын Алпут кыры дип йөрткәннәр.

Җир аз, тормыш авыр булганга, крәстиәннәр алпавыт җирләрен уртакка эшкәртеп бирә торган гадәт керткәннәр. Карашәм авылы халкы алпавыт Филипсон җирләрен шулай эшкәртә торган булган. Ләкин тормыш алып баруның мондый юлы крәстиәнне мантытмаган, көнкүреш алга китмәгән. Халык ярлылыктан җәфа чиккән.

Безнең игътибарны Карашәм һәм Татар Әҗәлесе авыллары арасында урнашкан Карашәм күле җәлеп итте. Ике калкулык арасына сыенган бу күл элек ике авыл арасындагы ызанга туры килгән. Күл Карашәм ягына кереп калган. Халык аны бик тирән, төбендә куәтле чишмәсе бар, дип сөйли. Күлнең бер ягы салкын, икенче ягы җылы сулы. Күлдә батып үлүчеләр дә булгалаган. Бу күл үзенең матур үзенчәлекләре белән төбәкне бизәп торучы бер табигать һәйкәле булып санала. Суы кара-кучкыл булып, тирәсендә камышлар үсә. Кызганыч, башка күлләрнең күбесе кипкән яисә бетерелгән, печән үсә торган болыннар сукаланган. Карашәм һәм Татар Әҗәлесе авылларын берләштерә торган «Комсомолец» колхозы җирләрендә 149 гектар болын кайчандыр табигый печәнлек булган. Шундагы дүрт күлдә һәм аның тирәсендәге куаклы сазлыкта су кошлары оя корып бала чыгарганнар, китәр-кайтыр кошлар шунда туктап азык тапканнар, ял иткәннәр, кешеләр балык тотканнар, колхоз мул итеп печән җыеп алган. Торгынлык елларында күлләр юкка чыккан, болын сукаланган. Хәзер печән дә юк, иген уңышы да юк дәрәҗәсендә, элекке болынны чүп үләннәр басып киткән.

Авыл ягыннан Карашәм исемле кечкенә генә инеш тә ага. Ул Гөбенә суына килеп кушыла.

Авыл тирә-юнендәге чишмә-чыганакларның да шактые хәзер кипкән.

Исемле чишмәләрдән Беренче чишмәне яисә Сабит бабай кизләвен, Тукташ кизләвен яисә Җәлалетдин кизләвен, Авыл кизләвен, Түбән чалу кизләвен (алар икәү), Югары кизләүне, Аргы кизләүне, Шуалан кизләвен (халык аны Шаулы алан кизләве дип аңлата), Мир кизләвен һәм башкаларны атап күрсәтергә мөмкин. Мир кизләвенең суы бик тәмле, халык аннан су ала, янына бик матур итеп чишмә йорты салып куйган. Ләкин башка чишмәләрне караучы юк, коелар да чистартылмый. Карашәм урамнарында колонкалар бар-барын, ләкин без күргәндә аларның күбесе эшләми иде.

Авылның борынгылыгы шик тудырмый. Аның үз традицияләре, үзенә хас тарихы, үзе хәл итәсе мәсьәләләре дә бар.

Авыл халкы элек-электән ата-ана хакын хаклап, борынгы гореф-гадәтләргә тугрылыклы булып калган, балаларны игелекле итеп тәрбияләргә тырышкан. Авылда мәдрәсә булу да унай нәтиҗә биргән.

Совет чоры әдәбиятында мәдрәсәләр гел сүгелде, алар кара буяу белән генә сурәтләнделәр. Ләкин мәгърифәтле, дөньяга киң карашлы, зыялы шәхесләр мәктәп һәм мәдрәсәләрдән чыкканнар. Мәдрәсәләрнең данлылары да, артык билгеле булмаганнары да халыкны агартуга өлеш керткән. Хәзергә алар житәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, тарихлары еш кына фаҗигале, киләчәктә алар турындагы мәгълүматлар җентекләп җыелырга тиешле. Татар халкының мәдәниятен мәдрәсәләрдән аерып карау—мирасыбызның бер өлешен читкә тибәрү дигән сүз.

Карашәм авылындагы мәдрәсәне 1900 елларда Шәриповлар гаиләсе салдырган. Зур һәм кечкенә бүлмәдән торган 35-40 квадрат метрлы булган ул. Анда малайлар һәм үсмерләр укыган. Мәдрәсәдә укулар көз көннәрендә кар явар алдыннан башланган, язга чыккач, ташу аккан чакларда тукталган.

Кызлар өчен махсус мәдрәсә булмаган. Алар мулла-мөәзиннәрнең өенә барып, абыстайлардан укыганнар.

Муллалардан ачы көлеп, хәтта мәсхәрә итеп язган әсәрләр, публицистик язмалар, сәхнә кәмитләре бик күп. Ләкин һәр авылда мулла йортында китап булган. Китап булган урында гыйлем таралган. Гарәп хәрефләре белән язылган бик күп фәнни китапларны тар-мар итүдән саклап калучылар да шул ук муллалар булган бит.

Авыл халкы һәр очракта илгә килгән бәлане бөтен кеше белән бергә күтәрә. Шушы кечкенә генә авылдан Бөек Ватан сугышы кырында 72 кеше һәлак булып калган. Ул елларны халыкның олысы-кечесе ал-ял белми эшләгән. Ил алдында Карашәмлеләрнең йөзе ак.

Авылда мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, элемтә үзәге эшли. Карашәмдә мәчет ачылган.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Авыл халкы зиратны игътибар үзәгендә тота.

Халкының тормышы нык, алар киләчәккә ышаныч белән карыйлар.

Шагыйрь һәм прозаик Фаил Хафиз улы Шәфигуллин Карашәм авылында туып-үсә (1939—1982).

---

## *Василий Радловның тууына 170 ел*

*Василий Васильевич Радлов (Friedrich Wilhelm) (5.01.1837—12.05.1918)— шәркыять галиме, тюрколог, этнограф, Петербург Фәннәр академиясе академигы. 1871—1884 елларда Казанда яшәгән, Казан татар укытучылар мәктәбенең беренче инспекторы. Иң зур хезмәтләре: борынгы төрки рун язмаларын, төрки телдә язылган XI гасыр әдәби ядкәре «Котадгу белек»не өйрәнү, төрки телләр сүзлеген әзерләп бастыру һ.б. Фәнни эшчәнлегенә илле ел тулу уңаеннан 1909 елда «Шура» журналында дөнья күргән мәкаләне хәзерге әдәби тел нормаларына якынайтып укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. Журналда имзасыз басылган бу мәкалә күренекле галим һәм әдип Ризаэтдин Фәхретдин каләменә нисбәт ителә.*

## Ризаэтдин Фәхретдин

### Василий Васильевич Радлов җәнапләренең илле еллык (1859—1909) бәйрәме

Гыйлем һәм мәгърифәт әһелләре, нинди мәмләкәткә, нинди халык һәм мәзһәбкә нисбәтле булсалар да, мөхтәрәм тотылалар, хезмәтләре тәкъдир ителә. Бу исә кешелекнең мөкатдәс бурычы. Шәриф Разый хәзрәтләренең бөек галим һәм шөһрәтле остаз булганы күп кешеләргә мәгълүм. Менә бу мөхтәрәм зат, үзенең

замандашы Әбү Исхак Ибраһим әс-Саибине мактаган, 90 биттән гыйбарәт «Касыйдәи Далийә» әсәрен иҗат иткән. Халык мона гаҗәпләнеп: «изге пәйгамбәр хәзрәтләренен баласы булган хәлдә бер мәҗүсине болай мактавын дәрәҗәнә лаекмы?»—дигән. Шәриф хәзрәтләре: «мәҗүсине түгел, бәлки гыйлем һәм камиллекне мактадым!»—дип җавап биргән. Мөселманнарда гыйлем һәм яхшы сыйфатлылык, әдәп һәм тәрбия бөек дәрәҗәләргә җиткән дәверләрдә гадәтләр һәм мөгамәлә шул рәвештә иде. Шәриф белән Саиби вакыйгасын без фәкать мисал өчен яздык.

Мәшһүр сәяхәтче һәм Шәрык галимнәреннән Василий Васильевич Радлов җәнапләренең гыйлемгә хезмәт итә башлавына быел майның 14 нче көнендә илле ел тулды. Алман гаиләсендә туган Радлов Германия университетларында төрле телләр буенча белем алганнан соң Шәрык телләрен өйрәнү максаты белән Русиягә 1858 елда килеп, Барнаул шәһәрендә мөгаллим итеп билгеләнгән. 50 ел тоташтан каләм белән китап, уку белән укыту юлында йөрү аз бер эш түгел. Шуның өчен Русиядә булган гыйлем һәм әдәбият әһелләре мона ядкәр, мәгърифәт юлында рәхмәт чиккән кешенең хезмәтләренә беркадәр булса да бүләк булсын өчен 14 нче май көнендә шөһрәтле төстә бер юбилей ясадылар. Еракта булганнар исә бу бәйрәм белән тәбрик иттеләр һәм хиссиятләрен белдерделәр. Русиядә нәшер ителә торган төрки-татар газеталар белән бергә «Шура» журналы да Радлов җәнапләренең 50 еллык юбилее белән тәбрикләп, бигрәк тә, төрки халыкларга бәйле кыйммәтле ачышлары өчен ихтирамын юллый.

Радлов җәнапләре 1837 нче елда дөньяга килгән. Көнбатыш телләреннән башка дөньяда булган төрки телләрнең һәрберсен, чирмеш һәм чуаш телләрен яхшы белә, болар хакында язган әсәрләрен бүгенге әдипләр, тел галимнәре кулланалар. Үзе бүген дә Петербург музеенда мөдир һәм Академиядә әгъза буларак Петербург шәһәрендә тора.

Радловның төрки халыклар өчен кылган хезмәте һич онытылмаячак хезмәтләрдән. Төркиләр мәдәнияттән мәхрүм бер кавем булганга бөтен эшләре гауга һәм сугышу, шәһәр һәм авылларны яндырудан гыйбарәт булган дип танылган бер заманда Радлов җәнапләре тарафыннан табылып укылган Орхон язулары төркиләрнең гыйлемле һәм мәдәни бер халык булганлыгын исбат итте.

Петербург профессорларыннан берсенең хосусый бер хатыннан (риза булып-булмаячагын белмәгәнгә профессорның исемен искә алырга кыюлыгым җитмәде) Радловка бәйле җөмләләрен бу урында язарга тиешле күрдек. Профессор җәнапләре озын бер бәхәснең ахырында болай ди: «мина ачык мәгълүм ки, бүгендә Орхон вә уйгур язуларын белүче бер төрки кешесе дә юк. Кызганыч ки, Петербургта укучы төрки студентлар Ислам дине таралганчыга кадәр төркиләрдә булган Орхон һәм уйгур язуларын өйрәнүгә тиешле игътибар бирмиләр. Тарихи һәм географик сәбәпләргә күрә төрки телләрен тикшерүчеләр—рус мөстәшрикълары (шәркыятче галимнәр). Боларның башында дөньяда беренче урынны алган хөрмәтле Радлов тора. Бу зат инде олыгайды. Әгәр төрки яшьләре (госманлылар, казакъ һәм татарлар, казанлылар) үз милләттәшләренә җиткерү нияте белән бу мөхтәрәм картның төркилеккә бәйле гыйлемнәреннән файдаланып калмасалар—зур хәсрәт булыр. Академия әгъзасы Василий Васильевич Радлов җәнапләре иң бөек тюрколог галимнәрдән. Төрки нәселләрен һәм телләрен тикшерү өлкәсендә бу заманнарга кадәр Радлов мәртәбәсендә берәр кеше булганлыгы мәгълүм түгел». Менә Радлов хакында университет галиме шундый шәһадәт бирә.

Радлов җәнапләренең үз кавем һәм кабиләбез хакындагы хезмәтләрен тәкъдир итү иң ләззәтле бурычыбыз. Шулай ук, моның белән бәрабәр, бу юбилей яшьләребезнең күңелләренә төрки халыкларны, борынгы төрки ядкәрләрен, төрки телен тикшерү гайрәтен хәрәкәт иттерәчәге дә зур өметләребезнең берсе. Хак сөбханә вә тәгалә хәзрәтләре насыйп итсен!

*(«Шура» журналы.—1909.—№ 10.—305—306 битләр).*

# Хатыйп Миңнегулов

## «ЯҢА ЯПУН МӨХБИРЕ» МӘҖМУГАСЫ

Татарда «иртә уңмаган—кич уңмас, кич уңмаган—һич уңмас» дигән мәкаль бар. Бу афористик фикерне мин шушы язмага карата да кулланыр идем. Моның сәбәпләре дә бар. Тәүге мәртәбә бу журнал белән 1990 елда Финляндиядә таныштым. Таныштым дию төгәл булмас, аның барлыгын белдем, аерым саннарын актарып чыктым. Әмма вакыт тар булу сәбәпле, мәҗмуга җентекле танышудан читтә калды. Алга таба исә, вакыт булса да, журнал булмады диярлек. Мәҗмуганың берничә санын гына кулга төшерә алдым. Шул сәбәпле, "Яңа милли юл", «Казан», «Азат Ватан» журналлары хакындагы язмаларым кебек, махсус мәкалә язылмыйча торды. Башка мәсьәләләргә бәйле рәвештә бары аерым белешмәләр бирү белән генә чикләнергә туры килде. Бу мәкалә дә «Яңа япун мөхбире» хакында тулылыкка, бөтенлеккә дәгъва итми. Моның өчен журналның барлык яисә күпчелек саннары белән җентекле танышу зарури. Кызганыч ки, бездә хәзергә андый мөмкинлек юк. Бары тик аерым фикер-күзәтүләр, мәгълүматлар бирү белән генә чикләнергә мәҗбүрбез. Бәлкем, Ходай Тәгалә насыйп итсә, киләчәктә киңрәк мөмкинлекләр туар.

* * *

Читтәге башка басмалар кебек, «Яңа япун мөхбире»нең дә язмышы мөһаҗир татарлар, төгәлрәк әйткәндә, Ерак Шәрыктагы, Япониядәге милләттәшләребез язмышы белән тыгыз бәйләнешле. Мәгълүм ки, бу төбәкләр безнең халык өчен элек-электән чит түгел. Татар кавеменең аерым генетик тамырлары хәзерге Кытай, Монголия җирләре белән бәйләнешле булуы да күп нәрсә хакында сөйли. Безнең борынгы әби-бабаларыбыз Алтын Урда, татар мәмләкәтләре чорларында да Ерак Шәрык якларына барып чыккан: сәүдә иткән, төрле иҗтимагый, сәяси, мәдәни вазыйфалар башкарган. Мондый бәйләнышлар Россия, Советлар Берлеге империяләре дәверендә дә дәвам иткән. 1897-1903 елларда Россия тарафыннан төзелгән «Көнчыгыш Кытай тимер юлы» (Аны еш кына КВЖД дип тә йөртәләр. Ул Чита тирәсеннән башланып, Харбинга килә. Аннан, ике тармакка аерылып, Тын океанга кадәр барып житә. Озынлыгы—2536 километр). Ерак Шәрыкка урыс-ларның, татарларның күпләп күчүенә дә сәбәпче була. Харбин, Хайлар, Мукден шәһәрләрендә, Пограничная, Маньчжурия станцияләрендә шактый гына милләттәшләребез тупланә, алар тимер юлда, авыл хуҗалыгында, сәүдә системасында эшлиләр. Октябрь инкыйлабыннан соң, аеруча гражданнар сугышы елларында бирегә күченүче татарлар саны тагын да ишәя.




Рус-япон сугышында Россия җиңелгәннән соң, Ерак Шәрыкта Япониянең роле елдан-ел арта бара. Чынлыкта Кытай, аеруча Маньчжурия, Корея 1945 елга кадәр Япониянең көчле сәяси йогынтысы астында булалар. Шул сәбәпле төньяк-көнчыгыш Кытайдагы татарлар Япониягә дә барып чыгалар. Харбин, Хайлар, Муклен, Шанхай,

Пусан, Токио, Кобе һәм кайбер башка шәһәрләрдәге милләттәшләребез үзара аралашып торалар, бер төбәктән икенчесенә күчешләр дә күзәтелә.

Татар дөньясында Япония белән кызыксыну аеруча рус-япон сугышыннан соң көчәеп китә. Мәшһүр рухани, җәмәгать эшлеклесе Габдеррәшид Ибраһимовның (1857-1944) 1908 елда Японияда биш айлап булуы, Токиода мәчет салдырырга урын алып йөрүе заманында татар матбугатында зур кызыксыну тудырган. Бу факт хәтта Тукайның шигырьләренә дә килеп кергән («Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит—мәчет Токиода»...). Шуңа күрә мөһаҗир татарлар өчен Япония бөтенләй белмәгән-ишетмәгән мәмләкәт булмый. Милләттәшләребезнең күпчелеге бирегә сәүдә эшләре белән килә, бераздан алар үз яннарына гаиләләрен, туган-тумачаларын, танышларын алдыра. Узган гасырның 30 нчы елларында Японияда инде өч меннән артык татар яшәве мәгълүм. Аларның күпчелеге Токио һәм Кобе шәһәрләрендә гомер кичерә.

Ерак Шәрыкның башка төбәкләрендәге кебек, Японияга күчеп килгән татарлар да, милли телне, гореф-гадәтләрне, иманны саклау өчен, мәктәп-мәчетләр ачарга, газит-журналлар булдырырга омтылалар. Мәсәлән, Токио, Кобе, Нагоя калаларында XX йөзнең 20-30 елларында ук берәр мәчет, берәр татар мәктәбе эшләве мәгълүм. Гадәттә, милли-дини мәсьәләләр белән мөһаҗир татарларның үзләре тарафыннан төзелгән «Мәхәлләи исламия» (мөселман мәхәлләсе) җитәкчелек итә. Токиода андый җәмгыять 1925 елдан эшли башлый. Аның тәүге рәисе—«япон телен японнар кебек белгән» Габделхәй Корбангали (1892-1972). Ул бер вакытта Токио мәчетенең имамы да булып тора.

«Мәхәлләи исламия» тиз арада үзенең нәшриятын оештырып җибәрә. Милләттәшебез, үзе дә Ерак Шәрыкта туып-үскән һәм укыган Мәхмүт Таһир (1922, Харбин—26.12.1992, Әнкара) үзенең «Матбагаи исламия» исемле мәкаләсендә («Казан».—1975.—№16.—15-20 б.) бу нәшриятның оештырылуы, хезмәткәрләре (Мөхәммәд Алтынбай, Әхмәдулла, Сания, Рәисә, Хуҗа Әхмәд Ваһап һ.б.) хакында мәгълүматлар бирә һәм анда 1930-1949 елларда басылган шактый гына китапларның исемлеген урнаштыра, тиражларын да күрсәтә. Болар арасында «Коръән», «Һәфтияк», «Иман шарты», «Мөхәммәд галәйһиссәлам тарихы» һәм башка дини басмалар, «Габдулла Тукай мәҗмугасы» (биш томда; тиражы—647), «Татар нәхүе», «Татарча сарыф» шикелле әдәби, педагогик китаплар да бар. Алар Японияда генә түгел, дөньяның милләттәшләребез яшәгән башка төбәкләрендә дә таралыш таба. Токио китапларын минем Финляндия, Төркия, Эстония татарлары арасында да күргәнем бар. Гарәпчә дини басмалар билгеле бер дәрәҗәдә гарәп мәмләкәтләренә дә ирешә.

«Яңа япун мөхбире» мәҗмугасының туу һәм яшәү тарихы да турыдан-туры Ерак Шәрык татарларының рухи ихтыяҗлары, андагы матбагачылар вәзгыяте белән бәйле. Бу татарча журнал Токиодагы «Матбагаи исламия»дә гарәп хәрефләре белән басыла. Сирәк-мирәк кенә, тышлыгында, японча, гарәпчә язмалар да күзгә ташлана. Мәҗмуга 1931 елда «Япун мөхбире» исеме белән чыга башлый. 1932 елда бу атамага «яңа» сүзе өстәлә. Әммә моңа карап журналның мәсләге, эчтәлеге үзгәрми. Шуңа күрә «Япон мөхбире»н һәм «Яңа япун мөхбире»н икесе-ике мәҗмуга дип карарга ярамый. Алар—бер, үзара аерылгысыз керешкән. Мәгълүм ки, Берлинда 1928-1939 елларда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы да әүвәл «Милли юл» исеме белән чыга. Әммә моңа карап без аны да аерып, ике мәҗмуга дип йөртмибез. Чынбарлыкка нисбәтән кайбер хосусый үзгәрешләр булса да, аның төп кыйбласы, асыл максаты бер—татар халкын туплау, аның асылын саклау, милли бәйсезлеге, табигый хокуклары өчен көрәш. (Бәлкем «Япон мөхбире»нең исеменә үзгәреш керүдә Берлин мәҗмугасының да өлешчә тәэсире булгандыр!?).

Әйткәнебезчә, «Яңа япун мөхбире»нең «рәисе»—Габделхәй Корбангали. Ул бу вазыйфаны, нигездә, 1937 елларга кадәр алып бара. Мәҗмуга журналистларының кемнәр булуы тәмам ачыкланмаган. (Бәлкем алар шул ук «Матбагаи исламия»нең хезмәткәрләредер!?). Берара анда Рокыя Дәүләткилле дә эшләп ала. Әммә Г. Исхакый белән Р. Корбангали арасында бәхәсләр башлангач, ул мәҗмуга белән хезмәттәшлеген туктата.

«Яңа япун мөхбире»—уртача форматлы айлык журнал. Күләме төрлечә: 50 биттән артып киткән саннары да, 30-40 сәхифәлекләре дә бар. Юка, әмма сыйфатлы тышлыкта. Техник ягы уку, файдалану өчен уңайлы. Иллюстратив-күрсәтмә материаллар да бар. Алар арасында Япониядәге, Ерак Шәрыктагы милләттәшләребезнең дини, мәдәни, иҗтимагый тормышына мөнәсәбәтле фотосурәтләр төп урынны алып тора. Мәчет, мәктәп күренешләре, төрле кичәләрнең сурәтләре аеруча еш очрый. Япониянең табигатен, яшәешен чагылдырган фоторәсемнәр дә бар.

«Яңа япун мөхбире» хезмәткәрләре мәҗмуганың «гыйльми, әдәби, тиҗари (сәүдәви[1]), сәнагый, икътисадый, иҗтимагый вә тәрбияви» характерда булуын һәр санның тышлыгында искәртеп баралар. Әлбәттә, боларның һәммәсе дә һәр санда чагылыш таба алмый. Әмма, гомумән алганда, журнал үзенең шигаренә, максатына тугры кала. Чыннан да ул—күпкырлы, күптармаклы мәҗмуга.

Журнал, әйткәнебезчә, шул илдә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан Токиода нәшер ителә, аңа рәсми хакимият тә билгеле бер күләмдә ярдәм итә. Япония—ул елларда ук күп яктан бик алга киткән ил. Ул үзенең халыкара йогынтысын да төрле юллар һәм чаралар белән көчәйтергә омтыла. Рәсми Токионы аеруча мөселман дөньясы, төрки-татар кавемнәре кызыксындыра. Аларга тәэсирен арттыруда ул гарәп хәрефләре белән нәшер ителүче, мөселман рухлы «Яңа япун мөхбире»н дә файдалана.

Журналның һәр санында Япония тематикасы мөһим урынны били. Мәҗмугада илнең иктисады, мәдәнияте, көнкүреше, халыкара бәйләнешләре хакында, бу халыктагы сакура (чия чәчәге), хризантема бәйрәмнәре турында даими рәвештә материаллар биреп барыла. Аларның рәсми чыганаклардан алынуы, факт-мәгълүматларга, күзәтүләргә байлыгы күзгә ташланып тора. Япон тормышы, бу илнең яшәеше, гореф-гадәтләре үрнәк, өлге рәвешендә тәкъдим ителә.[2] Бу юнәлештә журнал билгеле бер дәрәҗәдә Исмәгыйль Гаспралының «Тәрҗеман»ындагы традицияләрне дә дәвам иттерә, үстерә. «Яңа япун мөхбире»ндәге аерым мәкаләләрдә төрки һәм япон кавемнәре арасындагы охшашлыклар, типологик якынлыклар хакында да сүз алып барыла. Мәсәлән, алман профессоры Эдмонд Тоуманның хезмәтенә нигезләнеп язылган «Япон-төрк кардәшлеге» (1934.—№21.—5-10 б. Язманың авторы Г.Хайлари) бу ике халык арасындагы лексика, фонетика, музыка һәм гореф-гадәтләр өлкәсендәге аерым охшашлыклар ассызыклана. «Җыр җырлауда һәм моңлы касыйдәләр көйләп укуда да,—диелә анда,—япон белән төрек арасында охшашлык күрү бик җинел. Аурупа халыклары авызларын зур итеп ачып, тулы күкрәк белән кычкырып йырлаган заманда, төрк һәм японлар борын эченнән чыккан моңлы ыңгырашу тавышына охшаган бер рәвештә йырлыйлар, шул сәбәпле аурупалыларга ямьсез, төссез кеби күренәләр. Япон белән төрк өчен матур, кызыклы булган җыр формасы аурупалылар карашыннан йитешмәгән, чи күренә. Японлар да төрк-татарлар кеби аурупалыларның кычкырып йырлауларына хайван бакыруы дип карыйлар. Тәкъдиргә буйсыну һәр ике милләттә дә көчле булганы... төрки-татарларда «язмыштан узмыш юк» мәкале шәһадәт итә...» (6-8 б.).

Журнал сәхифәләрендә мөселман дөньясы, аның күренекле шәхесләре,

[1] Монда һәм алга таба җәяләр эчендәге аңлатмалар Х. Миңнегуловныкы.—Ред.

[2] Мәсәлән, «Японияне үгрәнүнең мөселманнар өчен әһәмияте» мәкаләсендә (1938.—№ 61.—1-3 б.) мондый юллар бар: «Япония мәмләкәте» вә япон халкы башка Шәрык халыклары кебек саф Шәрык халкы вә Шәрык мәмләкәте булып, үзенең тизлек берлән Аурупа мәдәниятен, мәдәнияи матдияне (матди культураны.) кабул итүе вә шуның илә бәрабәр миллият вә гадәтен саклап мәдәниләшкән вә хәзер дөньяда беренче дәүләтләрдән саналган бердәнбер Шәрык мәмләкәте вә Шәрык халкы булуы ягыннан башка Шәрык милләтләренә зур вә кадерле үрнәк вә мисал икәнлеге шөбһәсездер... Үз илендә үз телендә җырларга оялып, аурупача, урыс кебек уларга үгрәнергә башлаган булса да, каршысында япаның Шәрык көйләре, япон көе берлән озын-озын японча җырлавын күреп искә төшерә вә монда инде ул аурупача, урысча көй белән җырлауны уңгайсыз бер эшкә, оятка саный башлыйдыр.»

дини бәйрәмнәр һәм чаралар да даими игътибар үзәгендә. Кытайдагы хәлләр, көньяк-көнчыгыш Азиядәге мөһим вакыйгалар да мәҗмугадан читтә калмый.

Әмма ничек кенә булмасын, «Яңа япун мөхбире»нең үзәгендә—татар тематикасы, аның тарихы, бүгенгесе, гореф-гадәтләре, яшәү рәвеше. Бу ягы белән ул «Яңа милли юл», «Казан» журналларына билгеле бер дәрәҗәдә якынаеп та китә. Татар телендә чыгуы, татар авторлары тарафыннан әзерләнүе үзеннән-үзе мәҗмугага милли рух өсти. Журналда аеруча мөһаҗир татарларның яшәеше, алар тормышындагы вакыйга-хәлләр мөһим урынны били. Мәсәлән, мәҗмуганың бер санында (кызганыч ки, аның елын, санын күрсәткән тышлыгы юк. 1937 елгы булса кирәк) «Польша-Ляһестан төрк-татар мөселманнары» мәкаләсендә (27-28 б.) шундагы татарларның тарихы, хәзерге хәле хакында кызыклы гына мәгълүматлар бирелә. «Хәзер,—диелә анда,—Польшада 16 мәчет, 19 имам бар. Мөфтиләре «Ягъкуб әфәнде Шенкеевич (Сенкеевич) хәзрәтләре (журналда аның рәсеме дә бирелгән) хәзер 47 яшьләрендә булып, элек Минск шәһәрендә тәхсыйльдән (укудан) соң Петроград гали мөһәндис (югары инженерлык) мәктәбен» бетерә. Сугышта офицер буларак катнаша. Кырым хөкүмәтендә хезмәт итә. Берлин университетының шәрык бүлеген тәмамлый, докторлык дәрәҗәсен ала... «Мөфти җәнапләре Вильно дарелфөнүнендә гарәпчә, төрекчә вә фарсыча дәресләр бирә». Бу телләрне камил белә. Шулай ук алманча, русча, полякча иркен сөйләшә. Ягъкуб әфәнде «Яңа япун мөхбире»нең рәисе Габделхәй хәзрәт белән хатлар алыша. Шулай ук мәҗмуганың бу санында «Мәрхүм Морад әфәнде Мәккәи» дигән язма да (32-36 б.) кызыклы. Бирелә мәшһүр тарихчы, рухани, публицист Морад Рәмзинең (1854-1934) тормыш юлы, эшчәнлеге бәян ителә. Мәгълүм ки, Сарман районы Әлмәт авылында туып, Кышкарда, Бохарада, Пешаварда укыган бу зат гомеренең шактый өлешен Мәккәдә уздыра, суфыйчылыктагы Нәкышбәнди тарафдары буларак таныла, бик күп мәкалә-хезмәтләр яза, «Коръән»не татарчага тәрҗемә итә.

Совет режимын, большевиклар сәясәтен тәнкыйтьләү, илдәге татарларның милли, дини яктан кысылуларын яктырту Октябрьдән соңгы мөһаҗирлектәге татар газета-журналларының күпчелегенә хас. «Яңа япун мөхбире» дә моннан чыгарма түгел. Мәсәлән, мәҗмуганың 1936 елгы 43 нче санында СССРның Ерак Шәрыкта солыхны бозу сәясәте алып баруы, сугышка әзерләнүе ассызыклана (23 б.).

«Яңа япун мөхбире»нең аерым саннарында Г. Исхакыйны тәнкыйтьләгән мәкаләләр дә бар. Мәгълүм булганча, «Инкыйраз» авторы Ерак Шәрык, шул исәптән Япония, андагы милләттәшләребез белән шактый тыгыз мөнәсәбәтләрдә тора. Кайберләре белән ватанда вакытта ук таныш була. Аннан соң да үзара хәбәрләшүләр, очрашулар еш күзәтелә. Г.Исхакый Кытайда һәм Японияда тәүге мәртәбә 1919 елда була. Шуннан ул Аурупага китеп бара. Г. Исхакый икенче гапкыр Ерак Шәрыкка 1933 елның көзендә килә. Японияда, Кытайда өч еллап гомерен уздыра. Бу вакыт эчендә ул мөһаҗир татарларны туплау, милли рухта тәрбияләү юнәлешендә гаять актив эшчәнлек алып бара: корылтайлар уздыра, «Милли Байрак» газетасын нигезли, төрле очрашулар оештыра, мәкаләләр бастыра. Шушы елларда аның Кытайда, Японияда «Зөләйха», «Җан Баевич», «Дулкын эчендә» һ.б. әсәрләре сәхнәләштерелә. Әлбәттә, Г. Исхакыйның Ерак Шәрыктагы күпкырлы эшчәнлеге шома гына бармый, ул төрле каршылыкларга, хәтта тәэрлекләүләргә дә дучар ителә. Мәсәлән, 1934 елның 11 февралендә «Токио Идел-Урал төрк-татарларының мәдәният җәмгыяте»н оештыру җыелышында бер төркем урыслар Г.Исхакыйны кыйный башлый. Фаҗигане япон полициясе катнашу гына булдырмый кала. Шул ук елны Мукденда, нахак бәла ягылып, Г. Исхакый кулга алына. Аны бу күңелсез хәлдән Төркиянең Япониядәге хәрби атташесы Рөштү Әрдәлһүн коткарып кала.

Г. Исхакыйга милләттәшләребез арасындагы каршы көчләрнең башында

Токиодагы «Ислам мәхәлләсе» рәисе, «Яңа япун мөхбире» журналының башлыгы Габделхәй Корбангали тора. Шунысын да әйтик: Япониядәге милләттәшләребезнең дини, милли-мәдәни тормышын оештыруга, китаплар бастыруга бу зат шактый зур өлеш кертә. Әмма Г. Исхакый аны сүлпәнлектә, шәхси мәнфәгатьләрен күбрәк кайгыртуда гаепли, аның адресына шактый саллы тәнкыйть фикерләрен көндәлек тормышта да, матбугат аша да житкереп тора. Г. Корбангали исә Г. Исхакыйның Идел-Урал идеясен, милли бәйсезлек өчен көрәш сәясәтен кабул итми, «...Инкыйраз» авторының Ерак Шәрыкта абруе күтәрелүгә дә көнләшә. Конфронтация көчәйгәннән-көчәя бара, шуның нәтиҗәсендә дә «Яңа япун мөхбире» битләрендә Г. Исхакыйны мыскыллаган, нахак бәлаләр яккан материаллар басыла. Мәсәлән, бер мәкаләдә (1934.—№21) без мондый юлларны укыйбыз: «Милләтемезнең кирәк әфрады (шәхесләре) арасында вә кирәк бер кавеме илә икенче кавеме арасында ун ел буенча камил өлфәт (дуслык) вә бер-берсенә хөрмәт урнашкан иде. Ерак Шәрыкка Гаяз Исхакыйның килүе мөнәсәбәте илә, аның вә фетнәчеләрнең коткысы берлән көнчелек һәм каршылыклар кузгалып Ерак Шәрыктагы тынычлыгымызга да кара тап төште. Аурупада төрле мәмләкәтләрдә сачеп йөрегән тынычсызлык вә көнчелек авыруын Гаяз Исхакый Ерак Шәрыкка алып килде...» (4 б.). «Инкыйраз» авторының эшчәнлеге белән азмы-күпме таныш булган һәр кешегә бу төр гаепләүләрнең чынбарлыкка туры килмәвен аңлау һич кыенлык тудырмый. Ә инде кайберәүләрнең Г.Исхакыйны «совет шпионы», «Мәскәү агенты» дип атаулары гаҗәпләнү генә тудыра.

«Яңа япун мөхбире» кайчанга кадәр чыккан соң? Кайберәүләр аны 1937 ел белән чиклиләр. Әмма бу чынбарлыкка туры килми. Безнең кулда аның 1938 елның апрель аенда нәшер ителгән 61 нче саны бар. Мәхмүт Таһир бу мәжмуганың, «Милли Байрак» кебек, 1945 елга кадәр нәшер кылынуын искәртә.

Шунысын да әйтик: 1945 елда Япония җиңелгәннән соң, Ерак Шәрыктагы күпчелек мөһажир татарлар Төркия, Австралия, Канада, АКШ һәм башка тарафларга качып, күчеп китәләр. Шактый өлеше Совет органнары тарафыннан кулга алынып, төрмәләргә утыртыла, сөргеннәргә сөрелә. Габделхәй Корбангали дә, мәсәлән, шундый язмышка дучар ителә. Ул 10 ел гомерен төрмәдә уздыра («Казан» журналы.—№9. - 50-51 б.). Зинданда үлеп калучылар да була. Хәзерге вакытта Кытайның элек татарлар күпләп яшәгән Харбин, Хайлар, Мукден шәһәрләрендә татарлар юк дәрәҗәсендә. Япониядә гомер кичерүче милләттәшләребез дә хәзер бик аз.

* * *

Мәгълүм ки, Ерак Шәрыкта узган гасырның 20-40 нчы елларында дистәләгән газета-журналлар чыга: «Ерак Шәрык» (мәжмуга, Харбин, 1920-1922), «Ерак Шәрык» (гәжит, Харбин, 1924-1925), «Шәкертләр таңы» (Мукден, 1934-1935), «Мең ел» (Харбин, 1922), «Чаткы» (Харбин, 1932-1933), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934), «Милли Байрак» (Мукден, 1935-1945) һ.б. Боларның һәммәсенең үз йөзе, куйган максаты бар. Әмма аларның барчасы да татар телендә, татар укучысына, аны тәрбияләүгә юнәлтелгән. Ерак Шәрыктагы бу басмалар арасында «Яңа япун мөхбире»нең дә үз урыны, кылган игелекле эш-гамәлләре бар. Әлбәттә, анда «Яңа милли юл», «Казан», «Азат Ватан» журналларындагы кебек, милләт язмышы бөтен тулылыгында һәм кискенлеге белән куелмаган. Әдәби, әдәби-тәнкыйди материаллар да күзгә бик ташланмый. Әмма шулай да «Яңа япун мөхбире»—безнең рухи тарихыбызның бер өлеше. Анда иҗтимагый, дини, тарихи, сәяси яктан кызыклы гына факт-мәгълүматлар бар. Аларны тулырак өйрәнү, гыйльми әйләнешкә кертү безнең күзаллауларыбызны тагын да тулыландырачак, зиһенебезне баетачак.

Журнал укучылар игътибарына «Яңа япун мөхбире»ндә басылган ике язманы тәкъдим итәбез.

# ЯПУНИЯНЕ ҮГРӘНҮНЕҢ МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН ӘҺӘМИЯТЕ[1]

Япуния мәмләкәте вә япун халкы башка Шәрык халыклары кебек саф Шәрык халкы вә Шәрык мәмләкәте булып, үзенен тизлек берлән Аурупа мәдәниятен–мәдәнияи мадцияне (матди культураны.) кабул итүе вә шунын илә бәрабәр миллият вә гадәтен саклап мәдәниләшкән вә хәзер дөньяда беренче дәүләтләрдән саналган бердәнбер Шәрык мәмләкәте вә Шәрык халкы булуы ягыннан башка Шәрык милләтләренә зур вә кадерле үрнәк вә мисал икәнлеге шөбһәсездер.

Гаребнен (көнбатышнын) күршесендә вә анын кул астында яшәүче милләтләр низам вә интизамнын (канун-оешканлыкнын), тәртипле, вакытында йөрүче төрәннен (поезднын), тәмиз (чиста) вә мөкәммәл вапурнын (пароходнын), авылларына кадәр асфальт берлән түшәлгән юллары бар мәмләкәтнен, әһалидәге (кешеләрдәге) нәзафәт (чисталык) вә нәзакәтнен Гаребтән башка жирдә булуына күзе житмидер. Шул сәбәпле Шәрыктан (шәрыкка) килүче сәях мәзкүр шәйләрне (югарыда телгә алынган нәрсәләрне) мөкәммәл сурәттә Япуниядә күргәннән сонра анын күнелендә вә фикерендә житди бер инкыйлаб (үзгәреш) хасил була.

Монда Япуниягә килүче шәрыклылар башлап япун вапурына вә яки төрәненә утырдыкларында андагы тәртип вә интизам вә нәзакәтне һәм бөтен идарәсенен япуннар кулында гына булуын күреп, бу милләтнен истигъдадына (булдыклылыгына) тәхсин вә афәрин укып (мактап һәм хуплап) беренче класс төрәнендә утыручы кимоноле япунга карап күзеннән ихтыярсыз яшь чыгадыр. Тәрәкъкыйнын (алга китүнен) киемдә түгел, бәлки башта икәне ихтыярсыз анын башына килеп керә, үзенен дә милли киеме барлыгы, вәләкин ул аны монача кияргә оялып йөрегәне хәтеренә килә. Үз илендә үз телендә жырларга оялып, аурупача, урыс кебек уларга үгрәнергә башлаган булса да, каршысындагы япуннын Шәрык көйләре, япун көе берлән озын-озын япун жырларын жырлавын күреп искә төшерә вә монда инде ул аурупача, урысча көй берлән жырлауны уңгайсыз бер эшкә, оятка саный башлыйдыр. Бинтү-беренж (дөге) ашаучы япунны күреп, пылауны искә төшерә. Анын тезләнеп утыруын күреп, илдәге гадәтләрен күз алдына китерәдер.

Япуния мәмләкәтенен эченә килеп Симунусекидан төрәннән кузгалганда, бу тарафка Чин яки Кореядан килүчеләрнен күнелендә гаҗәеп бер шатлык хисе гүя дөнья читенә кергән кебек күнелдә бер иркенлек вә тынычлык туадыр.

Бу мәмләкәт кешеләренен бер-берсенә гаять нәзакәтле сәламләшүләре, әдәпле сөхбәтләре (әнгәмәләре) күнелгә хушлык бирәдер.

Мәмләкәт шәһәрләренә килгәч, андагы мөкәммәл мәдәният, мөкәммәл хәрәкәт әсбабы өчен автомобильләр (10 километрга кадәр жиргә 50 сән–автор иск.), шатранж; чатырашы (шахмат тактасы) кебек тулы (тигез) тимер юллары, автобуслар вә трамвайлар дөньянын ин мәдәни бер мәмләкәтендә булуны белдерәләр. Фәүкыльгадә (гадәттән тыш) тәмиз (чиста) вә комфортлы отельләр вә андагы нәзакәт вә әдәп һәм очызлык (очсызлык), көндә ике дәфга (мәртәбә) миллионнарча нөсхә чыкмакта улан гәзитәләр вә соңгы вакытта аларны көндә 3 дәфга чыкмага башлавы вә данәсе бер бочык (ярты) сәнгә (сән–акча берәмлеге) сатылуы вә ин түбән эшченен бөйлә ике-өч гәзитә укуы бу мәмләкәтнен мәдәниятенә хәйранга калдыра торган эшләреннәндер. Шулар арасында егерме сәнлек гыйта (аяк кабы–автор иск.) вә 70 сәнлек киемне киеп, барлыгы бер иен 50 сәнлек әлбисәдә (киемдә) дарелфөнүнгә (университетка) йөреп укучыдан меннәрчә япун шәкертләре, су берлән әйләндерелә торган моторлар вә электриклар (электр станцияләре), бик нәфис нәрсәләр сатып утыра торган гаять кечкенә кибет вә дөканнар (киосклар), гаиләви ысулга куелып 4-5 кешелек эшчедән «тегелеп,

[1] Баш мәкалә рәвешендә бирелгән бу язманың авторы «М.Г.» инициаллары белән генә күрсәтелгән.

барлыгын жыйганда миллиардларча маллар чыгара торган япун сәнагате бу мәмләкәтнең нәкадәр табигый вә кулай юл берлән тәрәкъкый итмәктә улдыгын күрсәтмәктәдер.

Япуния үзенең гаиләви хәятыннан, мәктәбеннән, гаскәреннән, әлбисәсеннән, ашавыннан, нәзафәтеннән (пакьлегеннән), әхлагыннан, мәдәниятеннән, тиҗарәтеннән (сәүдәсеннән), сәнагатеннән, тарихыннан Шәрык өчен меннәрчә дәрсе гыйбрәт улан (гыйбрәт үрнәге булган) бер газиз мәмләкәттер.

Япуннар кебек үк башка Шәрык халыклары да тәрәкъкый итмеш улсалар иде, алар да башка Гареб милләтләре илә тигез булырлар иде вә бәни бәшәрнең (адәм балаларының) язмышын Гаребкә тапшырып куймыйча, үзләре дә дөньядагы тигезлек вә солых өчен тавыш чыгарыр вә сүзләрен үткәрерләр иде.

Мәга-тәәссеф (кызганыч ки), алар япуннар дәрәҗәсендә мәдәни түгелләр, япуннардан меннәрчә дәрәҗә түбән торалар вә шул сәбәпле теләк вә сүзләрен үткәрә вә гамәлгә куя алмыйлар.

Шәрык милләтләренең бәхетсезлегенең башы шул япунлар дәрәҗәсенә ирешә алмауда булып, бәхетнең кустәрмәсе (үрнәге) дә–Япуния мәмләкәтендә вә япун милләтендәдер. Шул сәбәпле хәзерге көндә Шәрык халыклары вә, хосусан, Шәрыкның иң зур мәгънәви көченә малик (ия) булган безнең мөселман милләтләре өчен иң мөһим нәрсә: Япуния вә япуннар берлән танышу вә алардан үрнәк вә гыйбрәт алудыр.

*(Яңа япун мөхбире.—1938—№ 61.—3 б.)*

## Япуниядә җәйге бәйрәмнәр[1]

Япуниядә җәйге бәйрәмнәрдән берсе Танабата яки Хучи матсури, ягъни Йолдыз бәйрәме диелгән бәйрәм булып, июльнең 7 сендә ясаладыр. Бу бәйрәм япуннарның иске гадәтләреннән калмыш вә бүгенге көндә балалар арасында ясаладыр.

Иске хикәяләргә күрә, йолдызлар дөньясында Кингыю исемле ир йолдызы вә Чукузю исемле кызлар йолдызы булып, сыгырларны (сыерларны) караучы, алардан яхшылап игеннәр сөрдерүче вә сөтләр бирдерүче йолдыз булып, бу йолдыз Йолдызлар елгасы булган (тезелеп күренүче йолдызларны япуннар шулай диләр) Аману Гава әйләнәсендә тора.

Чукузю йолдызы эрләү вә тугучыларны (тукучыларны) караучы йолдыз булып, анын атасы йолдызлар падишаһы булмыштыр, диерләр. Бу йолдыз гаять ижтиһадлы (булган, тырыш) вә зирәк булып, матурлык илә йолдызлар арасында урын тотучыдыр. Бервакыт бу йолдызлар бер-берсенә гашыйк булганнар. Чукузюның атасы бу кызга Кингыю илә никахланырга рөхсәт биргән вә ике йолдыз бер-берсе илә дустлашып, бер-берсе илә мәшгуль уларак, үз эшләрен, ягъни сыгырны карау вә кием хәзерләү эшләрен ташлаганнар. Моңа Чукузюның атасы ачуланып, боларны бер-берсеннән аерган вә икесен йодызлар елгасының ике тарафына чыгарган. Тик елга бер мәртәбә генә күрешергә аларга рөхсәт бирелгән. Ләкин Аману Гавада күпер булмау сәбәпле, болар бер-берсе илә елга бер мәртәбә күрешүдән дә гаҗиз булганнар. Болар еглый башлаганнар. Кошлардан бер зур саескан боларның хәлен сорашкан вә сәбәбен анлагач, күпер салуга булып канатларын ике тарафка киереп, шул канатлар аркылы йолдызлар елгадан чыгып бер-берсе илә күрешкәннәр. Шуны 7 нче июльдә булган, диләр. Шул сәбәпле бу көн шул Танабата бәйрәме ясаладыр. Ләкин бу көн ягъмур яуса, саескан ягъмурда чыгып, күпер ясарга яратмаганлыктан, бу бәйрәм ясалмый каладыр.

Бу көн бәйрәм ясауның сәбәбе Чукузю йолдызы байрак тугуга оста булганлыктан, хатыннарның эше үз мәмләкәтләренә милли байрак тугу икәнен искә төшертү өчен ясаладыр. Кингыю йолдызы сыгыр тәрбиясенә оста

[1] Мәкаләнең авторы күрсәтелмәгән – Х. М.

булганлыктан, ирлек вазыйфасы—ашарга хәзерләү булганын искә төшерү өчен ясаладыр.

Бу бәйрәмдә бамбук агачының ботакларын җыеп, шуна шигырьләр язылган кәгазьләр бәйлиләр һәм кызлар өчен киемнәр теккәндә киселгән төрле төсле кәгазьләр бәйлиләр вә ирләр өчен сыгыр кебек итеп киселгән кәгазьләр бәйлиләр. Балалар бу кич фрукты хәзерләп, йолдыз бәйрәмен ясыйлар. Иртәсе көн бу бамбукларны җыеп елгада агызалар. Ягъни, аларны дингезгә кадәр бара торган зур агымга кертәләр (Дуслашып, тормышка керүне хәтерләтү өчен).

Янә җәйге бәйрәмнәрнен зурысы «Обун»дыр («Убун»?) Обун-үлекләргә дога бәйрәме, рухларны шатландыру бәйрәмедер. 1300 елдан бирле-Япуниягә буддизм дине кергәннән бирле бәйрәм ясалып киләдер.

Будда мәзһәбенчә, июльнен 13, 14 һәм 15ләрендә үлекләрнен рухлары йортына кайтып киләдер. Шул сәбәпле һәр йорт үз үлекләренен рухын каршы алуга хәзерләнәдер. 13ендә япуннар кич каберстанга барып, кабергә шәм куялар һәм хуш исле агачлар ягалар. Бу рухларны каршы алу мәгънәсендә эшләнәдер: рухларны хөрмәтләп, аларны шатландыралар.

Гаиләгә әкърибалары (якыннары) чакырылып, вафат булган кардәшләрен искә төшерәләр вә аларнын изгелекләрен, яхшы әхлакларын зикер итәләр. Вә мәрхүмнәрнен яраткан ашларыннан аш хәзерләп, папасны (руханины) чакырып дога кылдыралар. Бу мәҗлестә күбрәк мусуби дигән гереч-сандвичлары (бутерброд) ясалып ашаладыр. Вә йортны яктыртып чын-чыннан кунак озаткан шәкел биреләдер. Кич саламнан ящиклар, кутулар (тартмалар) ясап, эченә аш вә япып торган шәм куеп, шуны елгага агызалар. Бу бәйрәмдә хайван ите ашалмый вә балыклар да ашамыйлар. Төрле үлән вә үсемлекләр ашала вә дингез вә елга хайваннарына гүя хөрмәт өчен бу фонарьлар вә ашлар җибәреләдер.

Обун Япуниядә елнын яртысында булу сәбәпле, бу бәйрәмдә япуннар бер-берсенә кылган ярдәмнәре өчен тәшәккер кылышалар (рәхмәт укыйлар), һәдияләр (бүләкләр) бирешәләр. Ширкәтләр үз хадимләренә (хезмәткәрләренә) вә хосусый өйләр хадимләренә тәгътыйль (ял) бирәләр. Аларга ярты еллык яхшы хезмәте өчен һәдияләр бирәләр; вә Обунны хезмәттә булган кешеләр сагынып көтеп алалар вә елнын яртысын зур хатирәләр берлән үткәрәләр.

«Бун одуры» 15 июльдә Обуннын ахыргы көнендә рухларны озату өчен шатлык данеслары (биюләре) ясаладыр. Бун одуры бик рухлы бер бәйрәм булып, монда бөтен япуннар диярлек барабан кагып, шигырьләр вә догалар укып, галәхосус (аеруча) карьяләрдә (авылларда) бу бәйрәмне сагынып каршы алалар вә төрле вилайәтләрдә төрле шәкел данеслар вә төрле гадәтләр бар. Бәгъзе йирдә бу данесларны төн буенча ясыйлар.

Япуниядә Бун одуры ясала торган урыннарнын иң мәшһүрләре Никкудан 4 миль кадәр ераклыкта булган Киютаки дигән җирдә ясала торган одуры-данеслардыр. Бу данеслар 1916 нчы ел Тайсу императоры барып караганнан соң тарихи шөһрәт кәсеп итмештер.

*(Яңа япун мөхбире.—1936. - № 43.—4-7 б.)*

# ТАТАР ТЕЛЕН ФӘННӘН КУАЛАУ

Матбугаттан белгәнебезчә, галимнәребез Татар энциклопедиясенең русча басмада инде өченче томын чыгаруга ирешкәннәр. Ә менә аның татар телендәгесенең әлегә беренче томын да күргән юк. Һәм әйтергә кирәк, бу һич кенә дә татар галимнәренең житәрлек эшләмәвеннән түгел. Киресенчә, энциклопедия төзүнең иң авыр башы татар галимнәре җилкәсенә төшә. Эшнең авырлыгы шунда ки, рус теленнән аермалы буларак, туган телебездә үсемлекләрнең фәнни флористик системага салынган тотрыклы терминологиясе юк. Гасырлардан килгән бу кимчелек «Татар энциклопедия сүзлеге»н өстән генә карап чыкканда да күзгә бәрелеп тора. Шунысы яхшы: энциклопедиянең үзен язарга керешкәнче, әлеге сүзлекне тәкъдим итеп, институт галимнәре бик кирәкле эш башкарганнар. Анда очраган кимчелекләрне табып барлаганда, татар телендә исемсез йөрүче күп төрдәге үсемлекләрнең барысына да ук булмаса да, күбесенә алга таба фәнни нигезләнгән үз исемнәрен куеп булачак.

Энциклопедия сүзлеген төзүчеләрнең: «Һәр файдалы тәкъдимне рәхмәт белән кабул итеп, киләчәктә энциклопедия басмаларын әзерләүдә аларны искә алачакбыз», —дигән мөрәҗәгате үзе үк менә шуңа өметләндерә. Әмма ясаган тәкъдимнәреннән чыннан да файда чыгарлыкмы? Башта менә шуны ачыкларга кирәк. Бик тә сай булган белем багажың һәм урам теленнән алынган буш атамаларың белән кыстап бәхәскә тыгылу фәнни коллективның кыйммәтле вакытын ала, туган телебезне дөнья фәне казанышларына каршы куеп, артка, караңгы наданлыкка өстери, файда урынына зыян гына китерә.

Бу унайдан Таһир Сабирҗановның шушы Энциклопедия сүзлегенә багышлап «Шәһри Казан» газетасында (11.10.2005) басылган «Академикларга ничәле куярга?», дигән мәкаләсе шактый гыйбрәтле: «...Мичкәдәге бер стакан дегеткә тап булу, ай-һай, күнелне әрнетә шул», — дип зарланудан башлый ул язмасын, үзе андагы бер генә хатаны да табып күрсәтә алмаса да. Кайсы мичкәдәге, нинди дегет турында сүз бара? — билгесез. Дегет мичкәсеме ул, әллә башкамы? Бәлки бу аның халык мәкалендәге «Бер мичкә балга бер кашык дегет» дигән әйтемне исенә төшереп азаплануыдыр. Алай дисәң, «бал» сүзе монда бөтенләй телгә дә алынмаган.

Халык мәкальләрен теләсә кем шулай үзенчә боргалап үзгәртә башласа, аның эчтәлеге бутала, тәме калмый. Бу турыда үз вакытында Максим Горькийның да мондыйны «болтливое извращение народной поговорки», дип, бер кисәткәне бар иде.

Әмма Сабирҗанов язмасында бу «бер стакан дегет» белән еш очрашырга туры килә, һәм ул аны халык мәкале сыйфатында түгел, ә акны кара итеп күрсәтү, башкаларга дегет буяп, үзе чиста булып күренү өчен кулланган. Мәсәлән, «Сыйфат ягыннан ашыгу бәласе бу», — дип сөрән сала ул, Энциклопедия сүзлеген гаепләп. Бусы ни дигән сүз була тагын? «Сыйфат ягыннан ашыгу» — эшнең сыйфат ягына өстенлек бирү дигән сүз буламы? Алай дисәң, нигә ул бәлагә сәбәпче булган? Тукта әле ... монда куштырнаклар куелган икән ич! Шулай булгач, җөмләне тулысынча укып карыйк: «Ф.Вәлиев «Казан утлары»ндагы мәкаләсендә язганча «Сыйфат ягыннан ашыгу, кабалану бәласе бу» — диелгән анда. Күрәбез, «Сыйфат ягыннан ашыгу» дигән гарип сүзтезмәне Сабирҗанов үзе түгел, ә Ф.Вәлиев мәкаләсеннән күчереп кенә язган итеп кенә күрсәтә икән. Ә Ф.Вәлиевнең, ягъни минем, «Казан утлары» журналындагы мәкаләдә (2005, №6) андый сүзтезмәнең булганы да юк.

Мондый начар уен Т.Сабирҗановка нәрсәгә кирәк булган? Бәхәскә алай бер-беренне дегеткә буярга ниятләп, мәкерле хәйлә корып кермиләр ич. Бәхәс ул, үз карашыңнан чыгып, хакыйкатьне эзләүдә каршы якка ярдәм итү ниятендә эшләнә торган иң изге һәм иң нәтиҗәле гамәл. Тирән белем, үз фикереңне акыл белән дәлилләү, гаделлек һәм намус җитәрлек булганда гына эзләнә торган хакыйкатькә ирешеп була.

Аннан соң, матбугатта андый пычрак технология куллануның административ җаваплылык йөкли торган гөнаһлы эш икәнен журналист Сабирҗанов белергә тиеш иде, ләбаса!

Ә алга таба, Ф.Вәлиев язмасындагы фикерләрне кабатлап, сүзгә-сүз ияреп барганда киресенчә, куштырнакларны куярга нигәдер «онытa», һәм шул рәвешчә, ул фикерләрне үзенеке итеп күрсәтә. Монысы инде плагиатлык, ягъни әдәби караклык дип атала. Һәм әйтергә кирәк, плагиатлык һөнәрен үзләштерүдә ул зур осталыкка ирешкән: «Татар теленен аңлатмалы сүзлегендә»,—дип яза ул,—«кукуруз—бөрөйлеләр, ә карабодай—ике өлешлеләр семьялыгыннан» — дигән аңлатманы күргәч, аптырап каласың». Бу кадәр оятсыз плагиатлыкка чыннан да аптырап калырлык. Журналист буларак, 20 елдан артык һәрдаим әлеге сүзлектән файдаланып андагы хаталарны күрмәгән Т.Сабирҗанов, менә хәзер, Ф.Вәлиев мәкаләсендә күреп укыгач, аптырап калган.

Әмма, гади плагиатлык кына булса бер хәл икән. Сабирҗанов аның кайсыдыр урынында үз фикере итеп «бер стакан дегет» өсти дә, шуның белән бөтен эшне боза, үсемлекләр терминологиясендә ерып чыккысыз башбаштаклык ясый.

Әйтик, Татар энциклопедия сүзлегендә «мальва» дигән үсемлекнең татарча тәрҗемәсе «Эт борчагы» дип бирелгән. Безненчә, бу бик күнелсез хәл, чөнки мальваны борчак дип атап кузаклылар семьялыгы белән «туганлаштыру» фәндә кабул ителгән флористик системаны бозуга китерә. Бу уңайдан Т.Сабирҗанов та үз фикерен өстәүне кирәк таба; «Татар телендә бер үк үсемлек берничә исемдә йөри»,—дип, мальвага тагы да мәгънәсезрәк үзе белгән исемнәрне санап китә: «Тырнак гөл, мәче борчагы, таяк гөл, песи катламасы, әби күмәче, бояр гөле» ...Менә күрегез, мальва сүзе урынына никадәрле татарча исемнәр белә икән бит безнең Сабирҗанов!

Кызганыч ки, нәкъ менә шушы «бер үк үсемлекнең берничә исемдә йөрүе» татар теленең ин авырткан урыны булып тора да инде. Аның терминологик яктан оешып, урнашып бетмәгәнлеген күрсәтә. Исемнәр күп, ә кулланышка яраклысы бөтенләй юк. Менә кайда буталып юкка чыга татар теле!

Дөрес, халык телендә бер үк үсемлекнең берничә исеме булырга мөмкин, әмма фәнни терминнарны халык атамаларыннан аера белергә кирәк. Фәнни телдә һәр үсемлекнең бинар номенклатурага нигезләнгән бер генә исеме була. Фәнни атамаларның тотрыклы, ышанычлы булуы аның менә шушы бердәмлегенә нигезләнгән.

Ә хәзер Т.Сабирҗановның мона карата фикер сөрешенә күз салыйк: «Дару үсемлекләре» китабында,—дип яза ул,—башка ыругдаш төрләре белән буташтырмас өчен мальваны «бояр гөле» дип тәрҗемә итеп, минемчә, бик дөрес эшләгәннәр». Бу җөмләдәге бер-беренә каршы куелган хаталарның очы-кырые күренми. Беренчедән, мальваның үзен «бояр гөле» дип тәрҗемә иткәч, аның тагын нинди ыругдаш төрләре булсын ди? Күрәбез, ыруг һәм төр дигән категорияләр турында төшенчәсе юк икән бит Сабирҗанов әфәндегең! Ыруг исеменең шушы ыругка керүче барлык төрләр өчен уртак исем икәнен дә белми икән ул. «Ыругдаш төрләр» дигән гыйбарәне дә аның Ф.Вәлиев язмасында күреп, аңламаган килеш кенә күчереп язганы сизелеп тора.

Икенчедән, бер «бояр гөле» генә түгел, ә өстә санап күрсәткән башка татарча исемнәр дә мальваның тәрҗемәсе була алмый, чөнки аларда ыруг һәм төр исемнәре бирелмәгән. Җөмләнең соңгы өлеше: «Мальваны «бояр гөле» дип тәрҗемә итеп, минемчә, бик дөрес эшләгәннәр»—дигән урыны аеруча кызыклы; бу сүзләрдә күпме самими беркатлылык һәм чамадан артык гадилек төсмерләнә. Үсемлек аталышының дөреслеген Сабирҗановтан, яки Вәлиевтән һәм башка шундый очраклы кешеләрдән сораштырып демократик юл белән билгеләмиләр. Аны үсемлекләрнең иерархик классификациясен һәм филогенезын өйрәнүче флорист-систематиклар билгели.

«Эт» сүзе өстәлеп ясалган үсемлек исемнәре бер «эт борчагы» гына түгел. Алар санап бетергесез. Шуларның берсе—«эт җиләге» турында Ф.Вәлиевнең «Казан утлары»ндагы мәкаләсендә шактый тәфсилләп язылган. Мона карата да Т.Сабирҗановның әйтер сүзе бар икән: «Энциклопедия сүзлегендә — дип яза ул,—һәр үсемлекнең башкача атап йөртелүче исемнәре дә бирелсә, аңлаешсыз «эт җиләкләре»нә дә чик куелыр иде». Тукта әле ... бу—тагы шул ук «бер үк үсемлеккә берничә исем» кушып фикер бутарга азаплану була түгелме соң? Ничек итеп чик куелсын ди? «Эт җиләге» үзе дә шул ук «башкача атап йөртелүче исемнәрнең» берсе була, ләбаса!

Ярый, алга таба укыйк: «Русларның алтын хәзинәсе саналган В.Дальнең «Толковый словарь ...» китабында бу нәк шулай эшләнгән дә! ... Ф.Вәлиевне бик нык аптырашта калдырган «эт җиләге—белодонна»ның В.Даль сүзлегендә «бешеница, бешеная ягода, волчья ягода, красавица, огурник, песьи вишни, сонная одурь, черная псинка, паслен» дигән өстәмә 9 исеме бирелгән» — дип яза Т.Сабиржанов.

Ф.Вәлиев язмасындагы «белладонна» сүзенең нәрсә икәнен аңламыйча, күчереп язганда ук «бел**о**донна» дип, бер сүздә ике хата җибәргән журналист бу темага тагын нигә кагылган; терминологияне мыскыл итеп укучының башын бутаргамы, әллә үзенең белемсезлеген фаш итү өченме? «Белладонна» дигән андый үсемлек, гомумән дөньяда юк. Чынлыкта, ул «красавка белладонна» дигән үсемлектә аның төр исемен билгеләүче сыйфат буларак кына катнаша. Ә «красавка белладонна» дигәне үзе дә, бездә генә түгел, Россия җирлегендә дә кыргый хәлдә очрамый. Дару чималы буларак аны Краснодар якларында культурада (чәчеп) үстерәләр. Фәнни телдә ул «атропа белладонна» (Atropa belladonna) дип атала. «Белладонна» сүзе итальян телендәге «чибәр туташ» (прекрасная дама) дигән сүз була. Атропин дигән кыйммәтле дару менә шушы Atropa belladonna дигән үсемлектән ясала.

В.Дальнең «алтын хәзинәсеннән» алынган 9 өстәмә исемнең дә, укучының башын бутаудан башка бер әһәмияте дә юк. Шулар арасыннан берсен — «волчья ягода» дигәнен алып тикшереп карыйк. В.Даль сүзлегенә ул каян килеп кергән соң? Ул бит бөтенләй башка, «бүрежиләкчәләр» семьялыгындагы үсемлек. Руслар хәзер аны В.Даль сүзлегендәгечә архаик-кустар исемдә «волчья ягода» дип түгел, ә фәнни кулланышка җайлап «волчеягодник» дип атап йөртәләр. Бездә сирәк очрый торган, умырзаялар төркемендәге бу кызыклы үсемлек «бүрежиләк — Daphne» турында күбрәк язып булыр иде, әмма безнең Т.Сабиржанов язмасындагы башка гыйбрәтле буталчыкларны ачыклап бетерәсе бар.

«Рус телендәге «дикая редька» үсемлеге дә энциклопедиядә нииндидер «сарыбаш» төшенчәсен алган. Югыйсә, «Русча-татарча биология атамалары сүзлегендә сарыбашның русча «желтушник» үсемлеген аңлатканы акка кара белән язылган», — дип укыйбыз алга таба.

Энциклопедия кадәр энциклопедиягә гаеп ташлау өчен үсемлекнең төрле сүзлекләрдә «акка кара белән язылган» исемнәрен күреп чагыштыру гына җитми шул. Моның өчен һич югында аны натурада төскә-биткә танып аера белергә кирәк.

«Дикая редька» һәм «желтушник» исемнәре Энциклопедия сүзлегендә бөтенләй язылмаган да. Андагы «Тиле торма — к. сарыбаш» дигән тәрҗемәдәге ялгышлыкны «желтушник»ның латинча исеме Erysimum сүзе аша гына ачыклап булуы турында Ф.Вәлиевнең язмасында күрсәтелгән. Ә «сарыбаш» төшенчәсе — татар телендә исемсез йөрүче сары чәчәкле барлык үсемлекләрнең дә гомум уртак исеме.

Гап-гади сүзлекләргә дә Коръәнгә ышанган кебек ышанучы Сабиржанов, икенче бер сүзлектә русчасы «скерда» дип аталган үсемлекнең дә «сарыбаш» дигән тәрҗемәсен күргәч, аптырап калган. Ә бит «желтушник— Erysimum»нан башка тагы күпме төрдәге үсемлекләр «сарыбаш» исемендә йөри: «жерушник» (Rorippa), «сурепица» (Barbarea), «рогачка» (Erucastrum), «гулявник»(Sisymbrium), «дескурайния» (Descurainia) һ.б. Хәзергә болар барысы да — «сарыбаш», чөнки татар телендә үз исемнәре юк.

Һәр үсемлекнең исеме артыннан шушы тәртиптә аның латинча исемнәрен язып бару — бу педантлык галәмәте дип уйламагыз. Ул үсемлек аталышының дөреслеген контрольдә тоту өчен куела торган халыкара фәнни кагыйдә таләбе.

Бар белгәне русча-татарча сүзлекләрдәге «акка кара белән язылганны» барлаудан узмаган Сабиржанов, узган гасырда ук чыгарылган төрле сүзлекләрдәге бу кимчелекләрне, ни гаҗәп, энциклопедия төзүчеләрдән күрә: «Мондый буталчыкны бетерәсе урынга Татар энциклопедия сүзлеге көчәйткән генә. Монарчы татар кулында булган русча-татарча үсемлек атамалары, биология, медицина сүзлекләренә мөрәҗәгать итмәүләре аркасында килеп чыккан серле башваткыч бу!» — дип, энциклопедия төзүче галимнәрне гаепли.

Кара инде син бу татар галимнәрен, ...татар кулында, ягъни Т.Сабиржанов кулында булган русча-татарча сүзлекләргә дә мөрәҗәгать итмичә, энциклопедия язабыз дигән булып «серле башваткыч» ясап утыралар икән бит!

... Энциклопедия төзүче галимнәр ул сүзлекләрне яттан беләләр. Алай гына да түгел, бу сүзлекләрне аларның күбесе үзе төзегән, яки төзүдә катнашкан. Әмма

шунысы бар, бу сүзлекләр, Сабиржанов уйлаганча, фәннен соңгы казанышы һәм бердән бер белем чыганагы түгел. Аларның үзләрендә дә хаталар еш очрый, һәм бу һич кенә дә татар галимнәренең гаебеннән түгел. Бу — татар телендә үсемлекләр терминологиясенең гасырлардан килгән кимчелеге.

Хәлбуки, фәндә бөек систематик Карл Линнейның бинар номенклатурасы кабул ителгәннән соң узган өч гасырга якын дәвердә барлык алдынгы телләр флористик систематиканы һәм терминологияне камилләштерүдә гаять зур үсешкә ирешкәннәр. Безгә күбрәк таныш булган латин һәм рус телләрендә, мәсәлән, һәр үсемлекнең аталышында аның ыруг һәм төр исемнәрен генә түгел, ә флористик системаның кайсы тармагындарак урнашканын да күреп була.

Ә безнең татар телендә исә, кулланыш һәм игътибар җитмәү сәбәпле, үсемлекләр терминологиясе Т.Сабиржанов санап күрсәткән «Таяк гөл, мәче борчагы, песи катламасы» һ.б. кебек, берни дә аңлатмаган эчтәлексез ике урынлы кушма сүзләрдән торган кушаматлар хәлендә катып калган.

«Ике урынлы кушма сүзләр» дигән гыйбарәсе никтер аңлашылып җитми» — дип яза Т.Сабиржанов, Ф.Вәлиев мәкаләсендәге кимчелекләрне барлап. Моны «аңлап җиткерү» өчен ана күренекле тел галиме профессор Ф.Ганиевның кушма сүзләр турындагы хезмәтләре белән танышырга кирәктер. Ф.Ганиев үзе аны («Ватаным Татарстан», 13.01.1998) «ике сүзле кушма сүз» дип тә атап йөртә. Хәер, бу мәсьәлә аерым тикшерүне сорый торган үзе бер зур һәм авыр тема булып тора.

Үсемлекләр терминологиясен фәнни нигездә коруда нәкъ менә шушы ике урынлы кушма сүзләр уңайсыз киртә булып торалар да инде. Ике урынлы булулары белән, беренче карашка, алар К.Линнейның бинар системасындагы аталыш кебек булып күренәләр һәм күпләр шуңа алданып, аның буш сүзтезмә икәнен күрми. Әмма аерма шунда: К.Линнейның бинар аталышында флористик системаның соңгы ике буыны — ыруг һәм төр исемнәре бирелсә (әче әрем, кара әрем, тәбәнәк әрем, бөдрә мальва, яткын мальва, мавритан мальвасы һ.б.) Сабиржанов санап биргән кушма сүзләрдә исә (таяк гөл, мәче борчагы, песи катламасы, әби күмәче һ.б.) ыруг һәм төр дигән төшенчәләрнең исе дә сизелми.

«Ике урынлы кушма сүзләр аңлашылып җитми» — дип зарлана Сабиржанов, ә үзенең шул ук кушма сүзләрне кулыннан төшергәне юк. Мисал өчен аның «Мәгариф» журналында (2004, №10) ирешкән «ачыш-табышларына» күз салыйк. Анда, журналның тышлыгында таныш булмаган ниндидер бер ят үсемлекнең рәсеме астына «аю балаңы» дип язып куелган. Фәнни күзлектән караганда көтелмәгән зур ачыш бу! Әле мона кадәр бу үсемлекнең «кызыл балан» дигән бер генә төрен белә идек бит. Баланның мондый яңа төрен каян тапкан диген! Әгәр монда язылганнар хак булса, ягъни аның чыннан да балан икәне исбатланса, аны әле «аю баланы» дип кенә атамаслар иде. Аны әле баланның бу көнгә кадәр билгеле булмаган яңа төрен ачкан галимнең авторлык хокукын рәсмиләштереп, фәнни телдә «Viburnum Sabyrjanovi» дип, ягъни «Сабиржанов баланы» дип атарлар һәм шул исемдә Халыкара каталогка теркәп куярлар иде.

Әмма янәшәдә генә аның «бузина черная» дигән русча исеме дә язылган икән. Шулай булгач аңлашыла ки, ул балан түгел, ә кайдадыр җылы якларда гына үсә торган «кара шифан» дигән үсемлек икәнен беләбез. «Бер үк үсемлеккә берничә өстәмә исем» эзләүче Т.Сабиржанов менә кая барып чыккан: үсемлекнең «шифан» дигән гади һәм дөрес исемен «аю баланы»на алмаштырып, терминологиядә ерып чыккысыз буталчык ясаган. Бусы инде «бер стакан дегет»тән артыбрак китә. Бусы инде халыкара кабул ителгән фәнни флористик системаның астын өскә китереп, татар телен фәннән куалау дигән сүз була.

«Бузина—шифан»ның Россиядә үсә торган 3-4 төре билгеле. Шуларның берсен — «бузина черная» дигәнен Т.Сабиржанов «аю баланы» дип атаган. Калган төрләрен, ярый әле, белми торгандыр. Белә калса, аларын да шул ук тәртиптә «бүре баланы», «куян баланы» һәм башка шуның кебек өстәмә яңа исемнәр табып куя башласа ни хәл итәрсең.

Һәр үсемлекнең исеме артыннан аның латинча атамасын язып бару, инде әйткәнебезчә, халыкара фәнни кагыйдә таләбе. Ул туган телдә язылган исемнең дөреслеген контрольдә тота һәм тагын да әһәмиятлерәге шул: анда нәрсә турында сүз барганны барлык милләт вәкилләре дә аңласын өчен шулай эшләнә. Үсемлекләр терминологиясе фәнни нигезгә салынмаган татар теле өчен бу бигрәк тә әһәмиятле.

Безнең бәхеткә, Татар энциклопедия сүзлегендә бу кагыйдә дөрес сакланган. Үсемлекләр, хайваннар һәм кошлар аталышына кагылышлы һәр очракта аларның латинча исемнәре бирелеп барган. Бу җәһәттән, энциклопедия төзүче галимнәрнең эшне фәнни нигездә коруда кыю, ышанычлы адым ясаганнарын унай бәяләргә кирәк.

Россиядә борынгыдан барлык фәннәрне өйрәнү латин телендә алып барылган һәм, шунын тәэсире буларак, рус телендә үсемлекләр терминологиясе зур үсешкә ирешкән. Ныклабрак карасаң, рус телендәге күп кенә үсемлекләрнең исеме турыдан-туры латиннан тәрҗемә икәнен күрергә була.

Ә нигә соң әле безгә дә шушы юл белән кайбер исемсез үсемлекләргә татарча үз исемнәрен табып урнаштырмаска? Әйтик, рус телендә «череда» дип йөртелгән үсемлек Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «эт тигәнәге» дип, ә Энциклопедия сүзлегендә «эт сырганагы» дип бирелгән. Әлеге атамаларның һәр икесе дә дөреслеккә туры килми. «Череда»ның тигәнәк (репейник) яки сырганак (облепиха) белән бернинди уртаклыгы да юк ич. «Череда»ның латинча исеме «Bidens» — тәрҗемәдә «икетешле» (двузубец) дигәнне белдерә. Үсемлек орлыгының формасын һәм аның холык-фигылен (яшәү рәвешен) бик дөрес чагылдыручы исем бу. Менә шуна охшатыбрак, аны «тешләвек» дип атасаң, бер генә ыругның булса да татар телендә мөстәкыйль үз исеме булыр иде.

Русча «пустырник» дигән үсемлекнең татарча «сукыр кычыткан» дип аталып йөрүе дә шулай ук татарның дөнья фәненнән читтә, терминологик йөгәнсезлектә яшәвен күрсәтә. Каян килеп «пустырник» кычыткан булсын ди? Ул бит бөтенләй башка, «иренчәчәклеләр» семьялыгындагы үсемлек. Чәчәклек сабагының охшашлыгыннан чыгып, фәнни телдә аны «Leonurus» (Leon — арыслан һәм Urus — койрык), ягни «арысланкойрык» дип атаганнар. Татарча аталыш өчен безгә моннан да кулайрак исемне эзлисе дә юк бит. Тик аны «арыслан койрыгы» дип, ике сүздә түгел, ә фәнни куллнышка җайлап, бер генә сүздә, «арысланкойрык» дип язу дөрес була.

Шушы тәртиптә, латин һәм рус телләре үрнәгендә, безгә дә кайбер үсемлекләргә систематик нигезләнгән үз исемнәрен табып урнаштырып булыр иде дә бит... Әмма, ни кызганыч, татар телендә әлегә моңа ныклы ихтыяҗ да сизелми. Күз алдында булган берничә үсемлекнең өстәмә исемнәрен белсәк, үзебезне бик белемлегә санап, канәгать булып йөрибез. Ә калган йөзләрчә-меңнәрчә төрдәге үсемлекләрнең татар телендә исемсез йөрүе гамебездә дә юк. Ыруг һәм төр категорияләре турында төшенчәсе дә булмаган Т.Сабиржановның «галимнәребез баш түбәсе өстендә ажаган уйнатырга» кизәнеп күсәк болгавы үзе үк бу өлкәдә анархия һәм башбаштаклык хөкем сөргәнне күрсәтә. Әйтерсең, В.Маяковскийның сабыйларга багышлаган «нәрсә ул яхшы һәм нәрсә ул начар» дигән гади соравын да үзебезгә ачыклый алганыбыз юк кебек.

«Язмабызның башында куелган «Академикларга ничәле куярга?» - дигән сорауга, руслар әйтмешли, «пять с плюсом», дип кистереп җавап бирерлек булсын» дип тәмамлый Т.Сабиржанов үзенең гыйбрәтле язмасын. Академиклар югарылыгында фикер йөртү һәм аларга бәя кую шифан куагын «балан» дип бутаган Т.Сабиржановның гына буе житәрлек эш түгелдер шул. Ә инде «пять с плюсом» дип кистереп әйтү өчен тел сорап күрше кесәсенә керергә кирәк булса, анда, русларда, акыллы гына тагын бер мәкаль дә бар: «Каждый сверчок, знай свой шесток!»

**Фоат ВӘЛИЕВ,**
*биология фәннәре кандидаты.*

# МИЛЛИ МИРАСЫБЫЗ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

## 1

2006 елда татар театрының оешуына—Казанда губернатор рөхсәте белән беренче рәсми спектакль куелуга 100 ел, татарның күренекле драматургларыннан берсе булган Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 115 ел тулды. Хәер, 1906 елны гомумән дә татар җәмәгатьчелеге өчен бик истә калырдай, тарихи вакыйгаларга бай ел булган дип әйтергә ярыйдыр. Нәкъ шул елда татар халкы бергә тупланып яшәгән байтак төбәкләрдә (Казан, Оренбург, Җаек, Әстерхан калаларында) үз милли телебездәге күпчелек газеталар, журналлар басыла башлый. Шушы җитди вакыйгаларның бер гасырлык юбилее уңаеннан 2006 ел, мөхтәрәм президентыбыз Минтимер Шәймиевнең махсус указы белән, «Әдәбият һәм сәнгать елы» дип билгеләнде.

XIX-XX гасырлар чигенә кергән еллар татар милләтенең кабат уяну, мәдәни вә рухи күтәрелеш дәвере буларак күзаллана. Бу чорда, иҗтимагый-тарихи һәм динирухи әдәбият белән беррәттән, матур әдәбият өлкәсендә дә зур уңышларга ирешелә. Рус һәм көнбатыш әдәбияты үрнәгендә беренче драма әсәрләре языла. Татар телендә спектакльләр куярга омтылыш туа. Мондый хәл татар дөньясының башкаласы булган Казаннан тыш Әстерхан, Оренбург, Уфа, Җаек, Касыйм, Орск, Троицк, Чистай кебек шәһәрләрдә дә күзгә ташлана. Санкт-Петербургтагы татар җәмгыяте белән Касыймлылар электән тыгыз элемтәдә торган, татарлар арасында беренче булып рәсми хәйрия оешмасын төзегән. Театрлар тарихы белгече Һәнүз Мәхмүтов хәбәр итүенчә, «Касыймда... 1899-1901 елларда татар телендә беренче ачык спектакльләр булып үтә.» Казанда «шундый кичәләрнең беренчесе Казан җәмгыяте хәйриясе файдасына 1901 елның 27 гыйнварында шәһәр театрында оештырыла. Аңа дүрт йөзләп татар тамашачысы килә.» Дөрес, бу спектакль әле рус артистлары тарафыннан рус телендә уйнала. Әлеге Хәйрия җәмгыяте рәистәшләренең берсе, Кавказ халыклары иреге өчен көрәшкән мәгълүм шәех Шамил оныгы Заһид Шамилнең бу спектакльне «яртылаш булса да татарча куярга» тырышуы хөкүмәт түрәләре һәм үзебезнең «халык вәкилләре» тарафыннан кире кагыла.

Казанда татарча спектакль куярга омтылыш иң элек «урыс хәлфәләре» әзерләүче Татар укытучылар мәктәбе яшьләре арасында туа. 1898 елда ук алар шундый үтенеч белән түрәләргә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин аларга «театр уеннарын рус телендә уйнарга» гына рөхсәт бирелә. Шул рөхсәтнең дә киләчәк өчен файдасы зур була. Рус телендәге спектакльләрдә уйнау тәҗрибәсен алган яшьләр татар театрларын нигезләүче төп көчләргә әвереләләр. Шундыйларның беренчеләре арасында без Гаяз Исхакый, Гафур Коләхмәтев, Хөсәен Ямашев, Шакир Мөхәммәдьяров, Ильясбәк Кудашев (сәхнәдә—Ашказарский), Габдерахман Мостафин, Габдерәүф Ниязбаев (булачак драматург), Шәриф Сүнчәләй һ.б.ны күрәбез. Боларның күпчелеге Казаннан еракта урнашкан мәдрәсәләрдә башлангыч белем алган һәм киләчәктә үз мәдрәсәсенә кайтып укытырга тиешле яшьләр була. Аларның бер өлеше «Шимбә» түгәрәген оештыруда да катнаша.

Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсеннән дә бу уку йортына ел саен дүрт-биш шәкерт җибәрелеп тора. Мәсәлән, Казанда уку дәверендә һәвәскәр артист буларак сәхнәгә тәүге тапкыр аяк баскан шәкертләрдән И. Кудашев, Ш. Мөхәммәдьяров, Г. Ниязбаев соңыннан Оренбург төбәгендә татар театрын булдыру эшенә зур

өлеш кертәләр. Гармунда, скрипкада һәм пианинода ярыйсы ук оста уйнаучы, үз ана һәм рус телләрендә иркен сөйләшә белүче Ильясбәк Кудашев та, 1904 елда укуын тәмамлап «Хөсәения»гә кайткач, җиң сызганып театр оештыру эшләренә керешә. Үз тирәсенә Вәли Мортазин, Исхак Әлмәшев, Әхмәт Ишморатов, Габдерахман Мангушев, Нури Сакаев кебек сәләтле шәкертләрне туплап репетицияләр үткәрә башлый. Шул рәвешле, бер-ике елдан соң ул татарлар арасында беренче профессиональ театр труппасын оештыручы буларак танылa. 1907 елның март-апрелендә ул оештырган артистлар төркеме якташлары Ярулла Вәлинең «Оят яки Күз яше», Александр Островскийның Ильясбәк тәрҗемә иткән «Галимлек вә наданлык» пьесаларын Оренбург тамашачысына уйнап күрсәтәләр. Һәм тәвәккәлләп Бозаулык, Самара, Сембер, Казан, Чистай якларына гастрольләргә чыгып китәләр. Казанда аларга беренче хатын-кыз артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина (сәхнә псевдонимы Волжская), ә Мәкәрҗә ярминкәсендә исә Габдулла Кариев килеп кушылалар. Ашказарский җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасы ирешкән иң зур уңыш Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә туры килә. Алар куйган бер спектакльне Түбән Новгород губернасы губернаторы да карый һәм хуплый.

Татар театрының 100 еллык юбилеен үткәрүгә сәбәп булган, рәсми рөхсәт алып беренче мәртәбә Казанда уйналган ачык спектакль артистлары да, нигездә, шушы Татар укытучылар мәктәбе шәкертләре, ике-өч студент һәм гимназиядә укучы кызлар була. 1906 елның 22 декабрендә куелган ул спектакльнең беренче бүлегендә уйналган «Кызганыч бала» драмасында төп рольләрне, өч гимназистка белән бергә, Шакир Мөхәммәдъяров һәм Шәриф Сүнчәләй башкара. Икенче бүлектә уйналган «Гыйшык бәласе» комедиясендә шул ук кызлар һәм өч студент катнаша...

Ильясбәк Кудашев-Ашказарский исә бу вакыйгага кадәр төгәл бер ел элегрәк, 1905 елның 3 декабрендә Оренбургта, татарча беренче спектакль куярга талпынып карый. Рус драма театры бинасы арендага алына, шунда репетицияләр уздырыла. Әмма «Оренбургская газета»ның 27 ноябрь санында ике телдә игълан басылгач, типографиядән кайтарылган афишалар таратыла башлагач, мөселманнар арасында шау-шу куба. Губернатор галиҗанәпләре хозурына, «рөхсәт итмәскә» дип ялварып, «чалмалы вә дәү корсаклы» вәкилләр килеп җитә. Спектакль башланырга ике-өч көн калгач, губернаторның әлеге тамашаны тыю турындагы әмере чыга. Оренбургта яшәгән төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова 1980-1990 елларда шушы вакыйгага кагылышлы күп кенә материал туплаган, берничә мәкалә язып бастырган иде. 1905 елның 3 декабренә билгеләнгән спектакль афишасы, газета белдерүләре, анда катнашачак яшьләрнең исем-фамилияләре һәм киләчәк язмышлары да аның тарафыннан барланган иде. Узган елда Оренбургка барганда ул архивның хәзер кемдә булуын ачыклый алмадым. Мәдинә апада шулай ук И. Кудашев-Ашказарский тарафыннан 1907 елның башында оештырылган профессиональ «Сәйяр» театры, соңрак Оренбургта эшләгән «Нур», «Ширкәт» театрлары турында да бай мәгълүмат, шул исәптән ул чор артистлары фоторәсемнәре тупланган ике альбом бар иде. Альбомнарның берсе бүген өлкә китапханәсе фондында саклана. Икенчесенең, ягъни егерменче еллардан башлап алтмышынчы еллар ахырынача Оренбург татар театрында эшләгән һәм үз дәвере артистларын якыннан белгән Хәдичә Таһирова-Ханская альбомының язмышы әлегә билгесез. Шуны да әйтеп китү кирәктер: Оренбургның милләтчел зыялылары тырышлыгы белән ул шәһәрдәге театр труппасы да (хәзер Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге театр), 1906 елда ачылган татар китапханәсе дә өзлексез рәвештә эшләп киләләр. Бу ике оешма шул төбәктә татар телен, рухын саклауда бик зур вазифа башкарды. 1980 еллар ахырында кабат оешкан барлык рәсми милли җәмгыятьләргә ныклы нигез булды. (Оешкан дәвердә—«Белек», 1914-1925 елларда Исмәгыйль Гаспринский, 1925тән соң Хөсәен Ямашев исемен йөртүче бу өлкә китапханәсе дә 2006 елның октябрендә 100 еллык юбилеен билгеләп үтте.)

## 2

«Хөсәения» мәдрәсәсенең хәлфә һәм шәкертләреннән бер төркем татарча театр уеннарын оештыру хыялы белән йөргән вакытта, 1906 елның көзендә, бу уку йортына шигъри җанлы Мирхәйдәр Фәйзи килеп керә. Ул Казан, Оренбург һәм

башка төбәкләрдә чыга башлаган татарча газеталарны, әдәби әсәрләрне даими укып баручы, ил-дөнья тормышы белән кызыксынып торучы яшьләрнең берсе була. Өстәвенә, Орск шәһәре мәдрәсәсендә укыган дүрт кышта үзлегеннән каләм тоткаларга да өйрәнеп килә. Аерым шигъри юллар, бәетләрдән тыш ул әле яңарак кына «Татар туе» исемле бер күренешле сәхнә әсәрен дә язган була. Шул пьесасын күпсанлы җингә һәм кодачалары алдында укып, «аларны хәйран калдыра». Әлбәттә инде, мәдрәсәгә яңа гына килеп керүенә карамастан, Ильяс хәлфә тирәсендәге шәкертләргә якынрак булырга тырыша.

Мирхәйдәр, гаиләдә унберенче бала буларак, 1891 елның 1 ноябрендә дөньяга килә. Шул сәбәпле бик иркә булып үсә. Алар яшәгән Күкшел авылы элекке өяз үзәге Орск шәһәреннән илле чакрымнар төньяк-көнбатыштарак, Уралтауның бер тармагы булган Гөберлә тау-калкулыклары арасында, Гөберлә суы буенда урнашкан. Утызлап йортлы Күкшел утарын булачак драматургның атасы Мостафа карт 1870 еллар ахырында нигезләгән була. Чистай өязе Шахмай авылыннан (хәзер Татарстанның Яңа Чишмә районына керә) унтугыз яшендә, 1854 елда чыгып китеп, Орск каласына килеп урнашкан Мостафа мәхдүмне—биредә шәһәр сәүдәгәрләре үз итеп кабул иткән. Миллионер Хөсәенев байларның яңа сатып алынган иркен җир-суларын, анда утлап йөрүче бихисап мал-туар көтүләрен кулда тотардай идарәче кирәк булгач та аларга язу таныган мулла баласын—«мишәр Мостафа»ны тәкъдим итәләр. Бертуган Хөсәеневләрнең җир биләмәләре управляющие вазифасын ул 1905 елга чаклы, чирек гасырдан артыграк үти. Күренә ки, Мирхәйдәр Фәйзи гади бер авыл баласы түгел.Ул ярыйсы ук төпле тәрбия алган, зәвык күргән яшүсмер булып буй җитә. Тәскә-биткә бик чибәр, чандыр гәүдәле була. «Һәрвакыт җыйнак, пөхтә итеп киенгән булыр иде. Сабыр холыклы, тыйнак кеше иде»,—дип искә алалар аны якыннан белүчеләр. Ул балачактан ук бик күп җирләрдә була, төрле катламнан чыккан зыялы затлар белән аралашу бәхетен татый.

Абыйсы Сәетгәрәй туена Оренбургтан Мәхмүт бай Хөсәенев белән аның яшь хатыны, Хөсәенев байларда эшләүче Мәхмүтгәрәй хатыны Фәриха белән, Казаннан сәүдәгәр һәм фабрикант Габдерахман Ишморатов ике хатыны белән киләләр. Ишан хәзрәтләренә фикердәш булган дәү чалмалы, абруйлы муллалар да ул туйда катнаша, килгән кунаклар алдында үз уй-фикерләре белән уртаклашалар, билгеле. Туйдан кайтышлый Мирхәйдәрләр берничә көнгә Казанда туктала. Аларны Әхмәт бай Хөсәеневнең Кабан күле буендагы затлы өендә кунак итәләр.

Ә 1906 елның җәендә исә Фәйзуллиннар токымы кабат Казанда, Түнтәрдә һәм Шода авылында (Сәетгәрәй муллада) булганнан соң, Чистайда тукталып, Шахмай авылына да сәяхәт кылалар. Соңрак Мирхәйдәр көндәлегенә: «Шахмай уртасында бабамның ике катлы өе исән», дип теркәп куячак.

Мондый сәяхәтләр, төрле дәрәҗәдәге төрле холык-гадәтле кешеләр белән якыннан аралашу яшүсмер Мирхәйдәрнең зиһен офыкларын киңәйтә, билгеле. Язучының киләчәк әсәрләрендәге төрле холыктагы персонажларны оста тасвирлый алу сәләтен үстерә.

Оренбургта ул Мәхмүтгәрәй агасы белән Фәрихә җиңгәсе карамагында, алар өендә яши. Дәрестән кайткач та күп укый, яза. Шигырь-бәетләрен, мәкалә-хәбәрләрен газета-журналларга да тәкъдим иткәли. Аларның кайберләре Тимерша Соловьев нәшер иткән «Чүкеч» журналында, Казанда чыгучы «Әлислах» һ.б. газеталарда басылалар. Шул көннәрдә ул көндәлегенә: «Хәлфәләр зобани төсле түгел... Бу яңа хәят мине бик тиз җәлеп итте. Башта яңа уйлар, яңа хыяллар хөкем сөрә. Шагыйрь булу, артист булу, музыкант булу кебек уйлар белән җенләнәм», дип язып куя.

## 3

Ләкин аңа «Хөсәения» мәдрәсәсендә озак уку насыйп булмый. Күп уку, кичләр буе баш иеп язып утырулар Мирхәйдәрнең сәламәтлеген какшата. 1907 елның язында врач аңа тумыштан йөрәк авырулы булганлыгын белдерә. Йөрәк өянәгеннән сакланып, физик көч сарыф итмичә авыл шартларында яшәргә киңәш бирә. Ильяс хәлфә шәһәр күләмендә беренче ачык спектаклен куярга җыенган бер вакытта,

март ае ахырларында Мирхәйдәргә Оренбургны калдырып китәргә туры килә. Ул Орск шәһәреннән егерме биш-утыз чакрымнардагы Җүнәй авылында яшәүче абыйларына кайта. Бу вакытта инде аның ата-анасы авылдан киткән, Орскиның үзәк урамнарының берсендә төзелгән ике катлы үз йортларына күчкән була. Мирхәйдәр берникадәр вакыт үз яшьтәшләре белән аралашмый диярлек. Хәятен биләп алган хасталык болыты кышын шәһәргә кайткач та тиз генә таралмый. Чөнки барча таныш-белеше диярлек: «Порок сердцалы кеше озак яшәми»,—дип тәкърарлап тора. Шушы сүзләр аны гомере буе сагалап йөриячәк, буйдак булып яшәргә хөкем итәчәк.

Ә бу вакытта Орск яшьләре шау-гөр килеп театр куярга дип янып йөриләр. Бу эшкә тотынырга аларны Казан каласыннан кунакка кайткан якташлары Шакир Мөхәммәдъяров күндерә. Ләкин әле алар «аулак өйләр»дә сөйләшеп утырулардан узмыйлар. Шакир да калага кабат тиз генә кайта алмый. Гаяз Исхакый җитәкләгән таңчылар төркеменең актив әгъзасы буларак, шул ук көздә аңа Казанны калдырып китәргә туры килә. Университетта уку хыялын тормышка ашыру өчен ул Орскидан бик еракта урнашкан С.-Петербургка барып төпләнә. Үз шәһәрендә исә театр уены уйнарга хиресләнеп өлгергән яшьләр—бертуган Гобәйдуллиннар, Габдулла Мангутов, Әхмәтгали Багданов, Мәгъсүм Шәмсетдинов кебек теләктәшләре генә кала.

1907 елда Орскиның зыялырак һәм баерак катламы хәйрия оешмасына берләшә, «Шәрекъ көтепханәсе» исемендә китап кибете ачуга ирешә. Аның уку залына татарча, русча һәм төрекчә басылучы газета-журналлар кайтарыла. Һәркем аларны анда барып укый ала. «Шәрекъ көтепханәсе» үзе дә Оренбург, Казан басмаханәләренә заказлар биреп, бернечә заманча китап чыгаруга ирешә. Форштат бистәсе тарафындарак урнашкан ул «кыйраәтханә»гә тиздән Мирхәйдәр дә бик теләп йөри башлый. 1911 елда Хәйрия җәмгыяте мөстәкыйль китапханә ачу өчен шәһәр уртасында иркен бер бинаны сатып ала. (Фәйзуллиннар яшәгән урам чатында урнашкан ул милли китапханә 1962 елга чаклы шәһәр халкына хезмәт итте.) Себер белән иркен казакъ иле чикләрендәге өяз башкаласы Орскига аратирә рус театр төркемнәре килеп чыккалый. Гимназия укытучылары белән шәһәр яшьләре үзләре дә спектакльләр куйгалый. (Аларда тәүге артистлык чиркануын икенче бер якташыбыз, совет чорының күренекле язучысы Лидия Сәйфуллина да ала. Атасы ягынннан ул да Чистай өязенә бәйле.) Андый спектакльләрне карарга Мирхәйдәр дә баргалый. Һәм 1909 елның кышында шундый бер тамашадан соң «Ике Хәсән» исемле пьесасын яза. Пьеса яшьтәшләре тарафыннан хуплап кабул ителә. Театр уены уйнарга хыялланучы яшьләрнең тәмам тупланып җитүенә ул бер этәргеч була. Шундый яшьләрнең беренчеләре сафына кергән Мәгъсүм ага Шәмсетдиневнең соңыннан сөйләвенчә, «Ике Хәсән»не аулак өй утырышларында бернечә мәртәбә уйнап караганнар, әмма халык алдына чыгарга аларга мөмкинчелек бирмәгәннәр.

1909-1911 еллар аралыгында Мирхәйдәр байтак кына шигырь иҗат итә. Үрнәк, өлге итеп, нигездә, Габдулла Тукай шигъриятен сайлый. Мирхәйдәр шигырьләрен бу елларда Казан, Әстерхан, Троицкида нәшер ителүче газета-журналлар бик теләп бастыралар. 1912 елда ул шигырьләр Казанда китап буларак укучы хөкеменә тапшырыла. Шушы ук дәвердә ул Клавдия Лукашевичның «Чәчәкләр арасында» исемле пьесасын тәрҗемә итә һәм ул тәрҗемәне «Сабах» китап ширкәте бастырып та чыгара. Бу пьеса Мирхәйдәрне театр сөючеләр арасында таныткан беренче әсәр була. «Чәчәкләр арасында»ны ул елларда байтак үзешчән төркемнәр сәхнәләштерә.

1911 ел Мирхәйдәрнең күпкырлы иҗатының тәмам ачылып китү елы санала. Шул елның җәендә Орскига «Сәйяр» төркеме килә. Алар күрсәткән өч спектакльнең икесендә Мирхәйдәр дә катнаша. «Орск тарихында татарча театрны башлап уйнаучы «Сәйяр» булса да, сәхнәдән иң беренче сүзне әйтү миңа насыйб булды. «Оят яки Күз яше» драмасындагы Маһи булып сәхнәгә иң тәү кердем,» дип яза ул көндәлегенә. Көндәлекнең алдагырак битләрендә: «Кыштан ук театр кую уе белән репетициягә тотындык. Беркөн беребезнең, беркөн икенчебезнең өенә барып репетиция ясыйбыз», дип тә теркәп куелган. Ләкин ни сәбәпледер ул кышта алар зур сәхнәгә чыга алмыйлар. Спектакль куярга губернатор рөхсәте

соңлабрак килгәндер, мөгаен. Ә менә «Сәйяр» төркеме китеп өлгермәстән, бер ай дәвамында ике зур театраль кичә уздырыла. 1911 елның 9 августында зур сәхнәдә «Югалган хатын» белән «Түләшү» пьесалары куела. 11 сентябрьдә «Бүләк өчен», «Кияү эзләү», «Кызлар шулай кызык итәләр», ә 10 декабрьдә «Яшь хатын» әсәрләре уйнала. Боларны сәхнәләштерүдә унөч ир-егет (өч бертуган Гобәйдуллиннар, Габдулла Хәсәнев, Гариф Галиәкбәрев һ.б.) катнаша. Мирхәйдәр шуларның һәрберсендә хатын-кыз рольләрен башкара («Сәйяр» афишасыннан башлап аның сәхнә псевдонимы М.Мирфанская була). Шушы вакыйгалардан соң Орск яшьләре һәр елда татарча дүртәр-бишәр спектакль куярга керешәләр. Спектакль куюдан җыелган акчаны Хәйрия җәмгыятенә тапшыралар. Тәүге «артистлар» төркеменә тиздән булачак халык артисты Хәким Сәлимҗановның ике абыйсы һәм беренчеләрдән булып мактаулы Хезмәт батыры исемен алачак артист Мифтах Әпсәләмев тә килеп кушыла. 1918 елда шәһәрдә совет хакимияте урнаштырылгач, бу төркем шактый киңәйтелеп, яңа вазифалар йөкләнеп, «Төрек-татар яшьләре оешмасы» исеме белән йөртелә башлый. «Төрек-татар яшьләре»нең тәүге зур эше «Галиябану» пьесасын кабат сәхнәләштерү була.

1911 елда Мирхәйдәр Фәйзи тиз арада популярлашып киткән, байтак театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелгән «Яшьләр алдатмыйлар» һәм төркемдәше, фикердәше Габдулла Әмиров белән бергә «Бизәнү» комедияләрен язып төгәлли. «Яшьләр алдатмыйлар»ның тиздән китап булып басылып чыгуы һәм «Сәйяр» тарафыннан сәхнәләштерелүе Мирхәйдәргә иҗади дәрт өсти.

1913 елда аның икенче шигырь китабы «Яшь күңел» Казанда басылып чыга. Шул кышта ул Орскида «Кызганыч» (1914 тә аерым китап булып басыла), «Тәкъдирнең шаяруы» драмаларын, җәй айларында Җүнәйдә бер пәрдәлек «Авыл бәйрәме» исемле шаян пьесасын язып төгәлли. Бу өч әсәр дә төрле-төрле тарафларда уйнала башлый. »Авыл бәйрәме»н 1921 елда автор ике пәрдәле итеп үзгәртә һәм иң элек Юлык авылы яшьләре белән бергә сәхнәләштерә. (Бу пьеса 1924 елда Казанда нәшер ителә.)

Татар драматурглары арасыннан шундый бәхеткә ирешүчеләр исемлегендә, мөгаен, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин теркәлә аладыр. Мәгәр, Мирхәйдәр Фәйзи иҗат иткән, татар халкының иң олуг мирасына әверелгән әсәр—«Галиябану» музыкаль драмасыдыр. Ул әсәр инде татар сәхнәсенең сүнмәс бер җәүһәре булып калыр. Элекке СССР биләмәсендәге төрки телдә эшләүче театрлар арасында «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне бик сирәктер.

### 4

М. Фәйзи җәйге айларда авылда яшәүне хуп күрә. Авыл яшьләрен самимирак, узара аралашуда үзе кебек үк гади дип исәпли. Аның көндәлекләрендә бу фикерне раслаучы язмалар бик күп. Менә 1913 елның декабрендә Җүнәйдә узган туй күренеше язмалары. Ул анда Гариф Галиәкбәревнең туенда кияү егете сыйфатында катнаша. «Кыз (өе) янында Җүнәй һәм Дүрткүл егетләре җыелган. (Җүнәй утарының төп халкы күршедәге зур Дүрткүл авылыннан чыккан.) Кунакларны араларыннан гармунда уйнап, җырлап үткәрделәр. Сыйлар мул: каз итләре табаклап. Уен, җыр, бию. Үтә матур тавыш белән яшь кенә егетләр җырлыйлар. Берсе артыннан берсе төшеп шундый өздереп бииләр. Яраббым, бөтен матурлыкны авыл өстенә генә түккәнсең икән... Дүрткүлдән Хәсән Зөфәрев исемле унсигез яшьлек егетнең җырлары шундый үзәгемә үтте, шундый көчле тәэсир бирде ки. Шундый саф, матур тавышлы егетләре бар халык та бәхетле булмаса...»

Көндәлектән мондый озын өзекнең китерелү сәбәбен укучы озакламый аңлар. Мирхәйдәр Фәйзинең иң югары бәяләнгән, бүген дә сәхнә түреннән төшмәгән иҗат җимеше—«Галиябану» музыкаль драмасының автор күңелендә бөреләнә башлаган көннәргә якынлашабыз. 1913-1916 еллар аралыгында Мирхәйдәр Җүнәй белән Дүрткүл яшьләре уеннарында еш катнаша. Кичке уеннарда кызларның да үзләрен тиң, тигез тотуларын билгеләп үтә. Яшьләрнең һич кыстатмыйча җырлый

алуларына, житез итеп, тыпырдап биеп китүләренә соклануларын көндәлекләренә даими теркәп бара. Шәһәр яшьләре андый түгел, үзләрен авылныкылар кебек иркен тота белмиләр, дип зарлана. Авылга кайтканда үзенең дә мандолинасын калдырмавын белдерә.

Менә 1914 елның 12 июленә караган язма. «Мәмәшевләр яшьләр өчен зур гына мәҗлес ясады. Дурткүлдән дә байтак егетләр, шул җөмләдән Хәсән дә килде. Гатиятулла, Хәким—оста гармунчылар, Хәсән, Шаһидулла, Хәким—шәп җырчылар, Хәмкәй, Локман, Фәтхулла—матур биючеләр... Сиптерәбез!» Ләкин андый күңелле кичәләр озакка бармый. Шул елның августында башланган Беренче Бөтендөнья сугышы бу яшьләрнең күбесен юк итәчәк яки гарипләндереп кайтарачак. Озакламыйча җырчы Хәсән дә иптәшләре белән шунда китеп югалачак. Мирхәйдәр сугышка китүче Хәсәнне үз атына утыртып озата барган, аның моң-хәсрәтле соңгы җырлавын озак вакыт оныта алмаган. Хәсәннең госпитальдә үлү хәбәрен ишеткәч тә ул бик өзгәләнә. Менә 1916 елның 28 октябренә караган көндәлек язуы: «Күңелемә бик якын тоелган Хәсәннең лазаретта үлгәнлеген ишетеп иңрәдем. Моңлы жаның мәңге ямьнәрдә йөзсен, дус!.. Илеңне күрәлмый тилмереп үлдеңме, яшь жан? Синең үлемең мине рухан газаплый... Синең матур хәрәкәтләрең, мәгъсүм кыяфәтең, саф тавышың күңелемдә кадерләп тирбәтелер, туган! Синең белән ике ел таныш булып, егерме тапкыр күрештем. Ямьле йөрешләр, күңелле утырышлар бар иде. Алар үтте, син үлдең, хуш!» Әдипнең «Җырчы Хәсәнгә» дип исемләнгән шигыре дә бар. Аның бер өлеше шушы икеюллык белән тәмамлана:

*Мин сөямен халкымны, син халыкның алтыны,*
*Моңнар белән сызылып чыга яшь күңлеңнең ялкыны.*

1914-1915 елларда Мирхәйдәрнең аерым шигырьләре матбугатта басыла, К.Лукашевичның тагын бер пьесасының тәрҗемәсе «Корым тазартучы» исеме белән «Ак юл» журналында дөнья күрә. Бу елларда Орск яшьләре жиде мәртәбә спектакль куялар. Мирхәйдәрне иң сөендергәне—ниһаять сәхнәдә яшь артистканың пәйда булуы. 1915 елда «өч мәртәбә театр уйнадык. Камилә туташ Гомәрова Орск сәхнәсе тарихында кызлардан беренче каһарман булды», дип яза ул көндәлегенә. Ә аннан алдарак исә шул җәйдә Җүнәй авылында оста гармунчы Вафа Әдһәмов белән очрашу-танышуы тасвир ителә. «Августның 2се. Калага үтеп барган Юлык никрутлары белән күрешү. Вафа исемлесенең гармунны ифрат матур һәм сөйкемле кыланып уйнавы белән күңелемнең самими дуслыгын казануы... Бер елга калып, Орскидан кайтып барышында Вафа белән кабат утырыш: матур көйләр уйнавы, күңелемдә матур типлар, матур уйлар тудыруы», дигән сүзләр теркәлгән ул очрашу турында. Кайбер Европа мәмләкәтләре биләмәсенә тиң жирбиләмәгә ия булган Орск өязенең бер читендәрәк урнашкан Юлык авылы белән Мирхәйдәр Фәйзи тагын дүрт ел чамасы вакыт үткәч якыннанрак танышачак. 1919 елның февралендә аны Рәмиев байларның Юлыкта ачкан китапханәсен саклап калу өчен шунда эшкә җибәрәчәкләр.

1916 елның җәендә Орскига «Нур» театры артистлары килә. Бу театр житәкчеләреннән Исхак Әлмәшев белән Мирхәйдәр «Хөсәения»дә бергә уку көннәреннән бирле, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина белән «Сәйяр» труппасының шәһәргә беренче мәртәбә сәфәр кылган көннәреннән таныш була. Бу юлы да Мирхәйдәр сәхнәдә алар белән бергә берничә роль башкара.

Шул ук көннәрдә ерак Малмыж шәһәреннән борчулы хәбәр алына: Фатыйма апасының хәле начар икән. Мәшәкатьле озын сәфәргә чыгып китәсе була. Сәетгәрәй агасының Орскига кунакка килгән улы Сәгыйть белән алар 7 июль иртәсендә юлга кузгалалар. (Сәгыйть Гәрәй улы Фәйзуллин соңрак Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, әдипнең әдәби мирасын барлап чыгаручы буларак дан казанды.) Мирхәйдәр, Малмыжда озак тормастан, агасы яшәгән Шода авылына юл тота. (Бу авыл хәзер Татарстанның Балтач районына керә.) Әдипнең көндәлегендә Шода авылы тирәлеге күренешләрен, анда яшәүчеләрнең гореф-гадәтләрен тасвирлауга багышланган битләр байтак. Аларны көндәлек сәхифәләре итеп түгел, саф әдәби әсәр битләре кебек мавыгып укыйсың. «Кешеләрнең киенү

рәвеше дә бездәгенең тәмам киресе дип әйтерлек. Хатын-кызларда да аякта чабата, тула оек. Күбесенең өстендә кызыл күлмәк. Кызларның билендә матур альяпкыч. Кырдан кайтканда кызлар бик киенешеп кайталар...Ялтырап торган ураkларын кулларына тотып, ваграк атлап, нык басып китүләрен авылның иң матур күренешләреннән санарга ярый.» Шушы сүзләр янәшәсендә мондый юллар да бар: «Иген уру машиналары татар авылларында таралмаган әле, кул белән уралар. Җир өсте кызыл яулыклы абыстайлар белән тулган була.»

Әмма бу авылда Мирхәйдәр күңеленә иң хуш килгәне—яшьләрнең саф сулы чишмә буенда очрашу-аралашулары, шул тирәдәге болында яшьләр оештырган уеннар була. Үзенең алардан өлкәнрәк булуына карамастан (ана инде егерме биш яшь тулып килә), Мирхәйдәр дә яшьләр уенына бик теләп катнаша. Хәтта ки бер яшь кыз белән дус, сердәш булу дәрәҗәсенә ирешә. Авылга 1923 елда килүеннән соң Мирхәйдәр Шода авылы истәлекләренә багышлап «Сәрвиназ» исемле хикәя һәм «Ибрай яры янында» шигырен яза.

*Тау башында Сабир, Габдулла, мин,*
*Тау астында кызлар су ала;*
*Ал чиләген асып, вак-вак басып*
*Гыйлембану килгәч, бу бала*
*Алларына бәхте баскан кебек,*
*Күккә ашкан кебек куана.*

Бу шигырьдә Мирхәйдәрнең бер яшь кызга булган хис-тойгылары чагылыш тапкан. Кызга гыйшык тотып йөргән һәм соңрак аңа өйләнгән «Ибрай»ның шигырь авторына дус булганлыгына ишарә дә бар соңгы строфада. «Сәрвиназ» хикәясендә исә шушы ук мәхәббәт өчпочмагы чак кына башкачарак тасвир ителә.

Малмыж-Шода якларында йөреп кайтканнан соң Мирхәйдәр Фәйзи яңа әсәр язарга керешәчәген белдерә. Менә аның 1916 елның 8 октябрендәге көндәлек язмасы: «Казан ягы авылларында йөреп кайттым. Бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады.» Шушы юллардан соң чак кына арырак, 28 октябрь битендә җырчы Хәсәннең «лазаретта үлеп калуы» турындагы хәбәргә бәйле кайгы-хәсрәт сүзләре теркәлгән. Бу көндәлек язмаларыннан күренә ки, булачак пьеса каһарманнары Хәлил, Исмәгыйль, Галиябану образларын тудырган дәвердә авторның күзалдында Шода авылы яшьләренең тормыш-яшәеше генә түгел, шулай ук Җүнәй белән Дүрткүл яшьләренең үзара багланышлары да торган. Кайбер хезмәт авторлары язганча, Хәлил образына төп оеткы салучы оста гармунчы һәм җырчы Вафа Әдһәмов кына булмаган. Сәхнәдә атып үтереләчәк Хәлил артында, аңа сөялеп фаҗигале язмышлы җырчы Хәсән дә тора, Шода авылы егете «Ибрай» да шул тирәдә шәйләнә. Галиябану образы да ниндидер мифик бер Сәгадәтбану копиясе генә түгел. Ул образ артында Шода, Җүнәй, Дүрткүл кызлары шәүләсен дә, Орск сәхнәсендә балкып алган «мөкаммәл кыяфәтле» Камилә туташ Гомәрова язмышы чагылышын да күреп була. (Камиләне үзе теләмәгән, өлкәнрәк яшьтәге кешегә кияүгә бирәләр.) Әсәрнең тәүге исеменә карата да кайберәүләр белән бәхәскә керәсе килә. Сәгадәтбану исем-атамасын хәзерге татарчага күчерсәң, Бәхетлебану була. Бәхетлеме соң пьесада сурәтләнгән кыз? Юк, әлбәттә. Күзалдында сөйгән яры атып үтерелгән кыз берничек тә бәхетле була алмый. Миңа калса, Мирхәйдәр Фәйзи бу әсәрен язарга керешер алдыннан бәхетле кыз образын тудырмакчы булган. Әмма язып бетерү дәверендә инде ул аның язмышын үзгәрткән. Ә баштарак, пьеса исемен сайлаганда аның күптәнге кумиры Галимҗан Ибраһимовның «Сөю—сәгадәт» әсәре йогынтысында булуы да бик ихтимал. Мирхәйдәр дә авыл яшьләренең үзара мөнәсәбәтләре, сөю-сөешүләре йогынтысында шушы әсәрен язарга утыра. (Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романын укыганнан соң әсәрләнгән Мирхәйдәрнең шундук мәкалә язып, аны «Идел» газетасында бастыруын да искә төшерик.)

Соңгы унбиш-егерме елда татар һәм башкорт матбугатында (бигрәк тә Башкортстандагы күршеләрдә) «Галиябану» әсәренең язылу вакыты һәм анда

тасвирланган вакыйгаларның җирлеге мәсьәләсендә байтак кына хата фикерләр әйтелде һәм язылды. Имеш, ул пьеса Юлык вакыйгаларына бәйләп, Юлык авылында язылган. (Алда әйткәнемчә, Мирхәйдәр Юлыкка эшкә 1919 елның башында җибәрелә. 1921 елда ул Юлыкта «Кызыл йолдыз» драмасын яза.) Әле 2006 елда гына да Башкортстанда яшәүче бер татар журналисты Казанда басылган мәкаләсендә: «Галиябану» Баймак төбәге вакыйгаларын чагылдыра, әсәр шунда язылган, дигәнрәк фикер белән чыкты. Шундыйрак «гыйльми язма»ларны укыгач, бер сорау туа: Мирхәйдәр көндәлекләрен алып укыганмы соң бу каләм әһелләре? Мирхәйдәр эзләреннән йөргәннәрме? Ул көндәлекләрдә акка кара белән язылган ич: «Галиябану» пьесасы 1916 елның октябрь урталарында языла башлый һәм өч айдан соң Орск шәһәрендә тәмамлана. 1917 елның башында ул Оренбургка, «Ширкәт» труппасы режиссеры Вәли Мортазин-Иманскийга җибәрелә. Вәли үз тәкъдимнәрен язып пьесаны кире кайтара. Мирхәйдәр кульязмага өстәмәләр кертә һәм аны тиз арада кабат Оренбургка озата. «Ширкәт» артистларына әсәр ошый, бик хуп күреп, аны тиз арада сәхнәгә чыгаралар. «Галиябану» Оренбург театры бинасында шул елның 19 март кичендә халыкка тәкъдим ителә. Галиябану ролен татар халкының булачак күренекле артисты, мөлаем тембрлы тавышлы Сара Байкина, Хәлил ролен Вәли Мортазин, Исмәгыйль ролен Госман Садыйков бик оста башкарып чыгалар. Алар уенын халык дәррәү кубып хуплый. Шул ук елның 15 декабрендә пьеса Оренбургта кабат уйнала. 1918 елның кышында исә Казан сәхнәсендә куела. Ә 1922 елда Г.Ибраһимовның хуплаулы кереш сүзе белән Казанда китап итеп басыла.

«Галиябану»ның беренче мәртәбә сәхнәгә куелуын бозып күрсәткән тагын бер үкенечле фактны билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Милләтебез данын дистә еллар дәвамында акларга тиешле, дәүләт күләмендә әһәмияте зур булган «Татар энциклопедиясе» китабының икенче томында, шушы әсәргә багышланган мәкаләсендә, театр белгече И.Илялова «беренче тапкыр Оренбургта аны «Нур» труппасы куйды», дип яза. Ә бу труппага багышланган махсус язмаларда исә: «Нур» 1916 елның язында Оренбургтан китә, шул елның көзендә эшчәнлеген Уфада дәвам иттерә», дип белдерелгән.

Орск шәһәре үзешчәннәре дә «Галиябану» әсәрен 1917 елның 29 декбарендә сәхнәләштерәләр. Монда Галиябану ролен икенче бер күренекле шәхес—Башкортстанның булачак халык артисты Майбәдәр Юсупова башкара. Галиябану—Бәдәрнең Орск сәхнәсендә уйнаган икенче роле. 1917 елда инде ул Идрис Богдановның «Югалган хатын» пьесасын куюда Люси псевдонимы белән катнашкан була. Соңрак та ул Орск сәхнәсендә берничә пьесада җырлы-биюле рольләрне башкара. Орскида укытучылар курсын тәмамлаган, татар, башкорт мәктәпләрендә укыткан һәвәскәр артистка Майбәдәрне 1926 елда Башкорт дәүләт театрына кабул итәләр. Тиздән ул театрның йөзек кашына әверелә.

Орск сәхнәсендә уйнаучылар рәсми рәвештә артист исемен йөртмәсәләр һәм рәсми театр трупппасы дип игълан ителмәгән булсалар да, Мирхәйдәр Фәйзиләр чорынннан алып 1960 елларга кадәр шәһәр халкына даими рәвештә театр уеннарын уйнап киләләр. Егерменче еллардан башлап ул шәһәрдә Беренче Май исемен йөртүче татар клубы эшли, аның штатында драма түгәрәген җитәкләүче ике кеше була. Соңгы шундый җитәкчеләрнең берсе мәшһүр шахматист Гата Камскийның бабасы, профессиональ артист Сабиров-Камский иде. Ләкин 1960 елда ул клуб ябылды. Шул рәвешле илле еллык тарихы булган Орск шәһәренең милли театры да таркалды.

## 5

Чирек гасырлык иҗат гомерендә Мирхәйдәр Фәйзи җәмгысы 16 оригинал һәм 7 тәрҗемә пьеса авторы буларак танылa. Ике шигырь җыентыгы, үзе җыеп туплаган «Халык җырлары» китабы, кечерәк бер китаплык хикәяләр һәм җитмештән артыграк дәфтәрне берләштергән көндәлекләр дә—аның шома каләме белән язылган иҗат җимешләре. Аның драма әсәрләреннән «Асылъяр» (1919, Орск), «Кызыл йолдыз» (1921, Юлык), «Ак калфак» (1922, Темәс авылы), «Адашкан күңел» (Темәстә языла башлый, 1923 тә Уфада тәгәлләнә) татар һәм башкорт театрлары тарафыннан

һәммәсе дә кат-кат сәхнәләштерелгәннәр. «Кызыл йолдыз» белән «Адашкан күңел» пьесалары—Татарстан Республикасы күләмендә оештырылган конкурсларда алдынгы урыннарны яулап алган әсәрләр. Бу төркемдәге пьесалар һәм «Галиябану» берничәшәр тапкыр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт театры сәхнәсендә дә куела. Мондый бәхеткә сирәк драматурглар ирешә алган. Андый бәхетлеләр исемлеге зур түгел. «Галиябану» музыкаль драмасы шундый жанрдагы беренче татарча пьеса рәвешендә дә, эшләнеше ягыннан камил, төгәл, җитлеккән әсәр буларак та милли җәүһәрләребезнең тәүгеләреннәндер. Ул әсәр татар сәхнәсенең сүнмәс бер йолдызы. Элекке СССР мәмләкәтенә кергән төрки телдә эшләүче театрлар арасында «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне бик сирәктер. Башка бер милләт җимеше булса, андый әсәр күптән инде әллә кайчан рус теленә һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән булыр иде.

Алда сурәтләнгән фактлардан соң күрәбез ки—татар театрының 100 еллык олуг юбилена драматург Мирхәйдәр Фәйзинең кертккән өлеше дә зур икән.

Соңгы сүз итеп, аның иҗатын һәм исемен киләчәк буыннарга саклау кирәклеге турындагы фикерләремне дә әйтеп үтәсем килә.

1. Орск шәһәрендә ул яшәгән йорт диварына 1972 елда истәлек тактасы беркетелгән иде. (Язучылар берлеге исеменнән ул эшне башкаруда мин турыдан-туры катнаштым, ике мәртәбә барып ул шәһәр җитәкчеләре белән сөйләштем. Хат-юллама копияләре әле дә миндә саклана.) Кызганыч ки, 1994 елда әлеге шәһәргә барганда без, Зөфәр Бәширов белән икебез, андый истәлек тактасын күрмәдек. Кемдер аны йолкып ташлаган, аны алдыру турында рәсми карар булмады, дип аңлаттылар. Шул эшне яңадан кузгатасы, ул истәлек тактасын урынына кайтару чарасын күрәсе иде.

2. М. Фәйзи 1928 елда хәзерге Баймак шәһәрендә вафат була һәм бик хөрмәтләп шәһәр уртасындагы революция каһарманнары каберлегендә җирләнә. Туфан Миннуллинның да тырышлыгы белән сиксәненче елларда кабер өстенә җыйнак кына мәрмәр таш куелган иде. Шул ук 1994 елда ул каберлектә булганда без кабер ташын да очратмадык. Аның урынында тимер казык кына тырпаеп тора иде. Бу вандализмны башкаручылар татарны сөймәс бәндәләр, әлбәттә.


3. Шушы язмама тотыныр алдыннан шәһәр үзәгендәге бер-ике китапханәгә кереп, Мирхәйдәр Фәйзинең 1957 елда чыккан ике томлыгын эзләгән идем. (Ул томнар Сәгыйть ага Фәйзуллин тырышлыгы белән дөнья күргән иде.) Аларда юк андый китап. Милли китапханәбез фондында ул ике томлык бар, әлбәттә. Ләкин кулга алгач та таралып китәргә торган, меңләгән куллар аша үтеп, тузып беткәннәр. Мирхәйдәр Фәйзи кебек олуг шәхеснең китапларының илле ел дәвамында бер тапкыр да кабат басылмавы аяныч хәл, билгеле. Аның иң популяр әсәрләрен туплаган бер томлыгын һәм аерым китап итеп үзенең һәм атасының көндәлекләрен бастырырга күптән вакыт җиткәндер инде.

Шул томнарны кулга тотып уку өмете белән
**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

# ЯФРАКЛАР БАЛЕТ БИЮЕ БАШКАРА

Без аның өендә—тыйнак, тыныч, аулак бер бүлмәдә сөйләшеп утырабыз. Инде сиксән яшен ваклап килүче бу кешенең күзләрендә әле дә булса романтика очкыннары төсмерләнә, кул хәрәкәтләрендә яшьлек елларындагы җиңел талпынышлар үзен сиздереп куя. Еллар үтә торгач гәүдәгә шактый тулышкандыр, әлбәттә, әмма бәдәне нык-таза күренә. Минем каршыда—заманында ничә еллар буе сәхнә тоткан, узган гасырның егерме-утызынчы елларында тамашачы күңеленә канатлы биюче буларак кереп калган, гомеренең иң матур елларын татар бию сәнгатенә, балетка багышлаган Гай Хажи улы Таһиров утыра.

Әңгәмә корып утыруыбызның бер мәлендә күз кырыем белән генә тәрәзәгә караш ташладым. Ике сары яфрак, бер-берсе белән куыша-куыша, тәрәзәнең дымлы пыяласына килеп ябышкан иде. Ике күзен мөлдерәтеп, гүя тыштан күз карый. Әйе, ишегалдында—1985 елның октябре хакимлек иткән гади бер көн иде бу.



Беренче татар балеты «Шүрәле»не язган, Ватан сугышы кырларында хәбәрсез югалган композиторыбыз Фәрит Яруллин турында роман-хроника язар өчен материаллар туплап йөргән чагым. Мәскәүдә бергәләп укулары, «Шүрәле» балетын сәхнәләштерүдә дәртләнеп эшләүләре дисеңме—алар, икесе дә, якыннан аралашып яшәгәннәр, иҗат утында бергәләп дөрләгәннәр...

Әңгәмәбез озак дәвам итте. Арасында хатлар, фотосурәтләр, либреттолар, кайбер партитуралар белән дә танышып өлгерәбез. (Җәяләр эчендә булса да әйтеп китик: гомеренең соңгы елларын түгәрәкләп килгәндә Г. Таһиров «Шүрәле» балетының 141 битлек партитурасын композиторның энесе Мирсәет Яруллинга үз куллары белән тапшыра.)

Гай ага Таһировның озын-озак итеп сөйләгәннәреннән үткәндәге байтак сәхифәләрне күзалларга мөмкин булды.

...Совет чорында зур сәнгатькә килүчеләрнең күбесенә хас булганча, яшүсмер егет хезмәт биографиясен гади эшче буларак башлап җибәрә. Яшьтән үк бию белән мавыга, эшчеләр клубындагы үзешчән түгәрәкләргә йөри. Татар театры техникумы практиканты буларак, 1925 елда Татар дәүләт академия театры карамагына җибәрелә. Өч-дүрт елдан соң ул инде ныклап биюче солист дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

1930 ел татар сәнгате тарихындагы гаять зур вакыйга—«Сания» операсының сәхнәгә менүе. Моның өчен күпме илһам, күпме иҗади көчләр сарыф ителгәнен күз алдына китерү кыен түгел дер. Операның куелышы унаеннан «Кызыл Татарстан» газетасы Салих Сәйдәшевнең дирижерлыгын, яшь балетмейстер Гай Таһиров

эшчәнлеген сезондагы зур уңышларның берсе дип бәяләп чыга.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы карары белән 1938 елны Казанда Татар дәүләт опера театры оеша. Директор Зыя Бермилеев имзасы белән беренче приказлар күренә башлый. Әдәби бүлекне Муса Җәлил житәкли. Мәскәүнең Зур Театр хореография училищесын тәмамлап чыккан Гай Таһиров театрның баш балетмейстеры итеп билгеләнә.



*«Шүрәле» балетыннан бер күренеш.*

Опера театры икән, иҗат коллективының көчен һәм сәләтен раслау өчен аның репертуарында балетның күренүе дә мәжбүри бер нәрсә. Шулай итеп, «Шүрәле» балеты һәм аны сәхнәләштерү мәшәкатьләре көн тәртибенә килеп баса.

Балетмейстер Гай Таһировның «Шүрәле» балетына кушылып китү тарихы үзенә бер кызыклы. Ул, Мәскәүдә яшәп яткан Әхмәт Фәйзи белән Фәрит Яруллинның зур әсәргә тотынуларын бөтенләй дә белмичә, шулай ук «Шүрәле» әкияте сюжетыннан файдаланып, 1938 елда ук инде балалар өчен бер пәрдәле, ике картиналы балетка либретто язарга керешә...

Озак та үтми, Гай Таһиров исеменә Мәскәүдән көтелмәгән бер хат килеп төшә.

*«Мәскәү, 9. 11. 1939.*

*Хөрмәтле коллегам Гай!*

*Сезне «Шүрәле» дигән бер пәрдәле балетка либретто язу белән мәшгуль икән дип ишеттем.*

*Бу хатны язарга мәжбүр иткән нәрсә шул булды: шагыйрь Әхмәт Фәйзи әлеге темага өч пәрдәле балет өчен менә дигән либретто язды; ә композитор Яруллин беренче пәрдәсен язып бетереп, икенчесен тәмамлап килә. Аның музыкасы, биюне һәм яңгырашны күздә тотканда, мактап кына да бетерә торган түгел.*

*Балетка хас нечкәлекләрне яхшы белүегез өчен хөрмәт иткәнлектән, Сезне Әхмәт Фәйзи белән Яруллин эшләгән һәм гамәлгә ашырып килә торган теманы кабатлаудан коткармакчы булам, янә дә килеп, бу коллектив эшен тәмамлаган дәвердә аңа хореографик характеристикалар һәм дә хронометраж мәсьәләләрендә Сезнең ярдәм итүегезне үтенмәкче булам.*

*Үз фикерегезне миңа язсагыз иде.*

*Изге теләктә калам.*

*Литинский Генрих Ильич.*

*Адресым...»*

Профессор Литинский ягындагы дәлилләр шактый саллы һәм киң колачлы күренә: балет—өч пәрдәле, биш күренешле, прологлы зур спектакль, уннарча бит партитурага салынган тулы бер хезмәт, аның музыкасы гына да ике сәгатьтән артыкка сузылачак икән. Хатлар аша хәбәрләшкәннән соң, Таһиров, хореография өлешен үз өстенә алу шарты белән, бергәләшеп эшләргә ризалык бирә.

Гай Таhировның үз куллары белән язган истәлегендә түбәндәге юллар да бар:

*«Фәрит Яруллин белән минем Казанда ныклап аралашып яшәвем сугыш алды елларында булды...*

*Горурлыгыбыз булган «Шүрәле» балеты жинел тумады. Аның либреттосының өч варианты һәм Фәрит кулы белән язылган ноталар—караламаларның аерым кисәкләре саклана. Димәк, ул өч тапкыр яңадан эшләгән. Никадәр көч, түземлелек, фидакарьлек кирәк мона!»*

Ләкин ашкынулы өметләр чынга ашмый: балет моннарын канлы симфония—1941 елда башланган сугышның снаряд һәм бомбалар шартлавы каплап китә!..

Бары тик 1945 елның 12 мартында гына Казан тамашачылары, ниһаять, «Шүрәле» балетының беренче куелышын карау бәхетенә ирешәләр. Танылган балетмейстер Л. Жуков белән берлектә, Гай Таhиров сугышчы-композиторның моңнарын, әйтер сүзен халыкка житкерүдә гаять зур тырышлык куялар.

Гай Таhировның сәхнә эшчәнлеген күз алдына китерү өчен, кыскалык җәһәтеннән, өч кенә санны атап китик булмаса. Татар дәүләт академия театрында куелган 37 сәхнә әсәре, опера һәм балет театрындагы 35 спектакль, Татар дәүләт жыр һәм бию ансамблендәге 70 ләп бию-композиция—боларның һәммәсе дә аның исеме, ижади хезмәте белән бәйле. Бу шәхеснең Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Нәжип Жиһанов, Муса Жәлил, Әхмәт Фәйзи һ. б. күренекле кешеләр белән аралашып яшәве дә безгә күп нәрсә турында сөйли.

Инде килеп, аның 1984 елны Казанда басылып чыккан «Татарские танцы» (рус телендә) дигән китабы хакында берничә сүз. Кыйммәте вә яңалыгы күзгә бәрелеп торган искиткеч зур, саллы хезмәт! Болар—үзебезнең жыр һәм бию ансамбле, шулай ук И. Моисеев житәкләгән СССР халыклары биюенең дәүләт академия ансамбле репертуарына кергән 15 бию язмасы. Төсле рәсемнәр, ноталар, аңлатманы текстлар белән бирелгән ул. Жөмләдән, кайберләре: «Рәйхан», «Зәңгәр шәл», «Самавыр белән бию», «Кияү каршы алу» һ. б. Боларның һәммәсендә фантазия, очыш, очкын, халык биюләренең нечкәлекләрен белү ярылып ята. Рәссам Т. Хажиәхмәтов тарафыннан ясалган читек, калфак, түбәтәй, хәситә, беләзек үрнәкләре китапның эчтәлеген тагын да тулыландыра, баета.

...1985 елның матур бер көзендә әнә шулай очрашкан идек. Әңгәмә соңында Гай ага мине, карышып торсам да, озата чыкты. Аяк астыбызда көзге яфраклар ниндидер якты моң, моңсулык белән кыштырдый. Үзләре генә белгән телдә алар нидер әйтергә тели шикелле. Биектәге каен очларыннан бөтерелә-бөтерелә әле һаман да берәм-берәмләп тә, парлап-парлап та алтынсу яфраклар коела.

—Күрәсеңме, яфраклар балет биюе башкара...—диде Гай ага, әле һаман да үзенең үткәннәреннән аерылып бетә алмыйча, күрәмсең.

Балет—Ходай тарафыннан бирелгән могжизалы манзара, фәрештәләр биюе. Аның кайтавазы хәтта табигать фасылларында да өр-яңа төсмерләр белән кабатлана икән... Минем ачышым шул иде.

**Рашат НИЗАМИ**

# МИЛЛӘТ ҖАНЛЫ КАЛӘМДӘШЕБЕЗ

Мәхмүт Әхмәтҗановның китапларын укыган саен уйга калам: йа Ходай, нинди иллә тереклек итеп, никадәр мәгънәсез хәл-гамәлләр уртасында кайнарга, һәр адымда җан сызлавын тоеп гомер итәргә насыйп булган безгә?! Әйтерсең лә, бу империя Җир йөзенә галелсезлекләре, үз халкын кырдыру өчен әледән-әле сугышлар, төрле җәфалар, бәхетсезлекләр тудырып торуы белән бөтен дөньяны чиркандыру, гыйбрәт алдырту һәм «әстагъфируллаһ, мондый көнгә калырга, мондый тормышта яшәргә язмасын!» дилертү өчен яратылган... Бу иллә еш кына: төрле милләтләрне, халыкларны канга батыручылар—герой, азатлык өчен көрәшүчеләр—бандит, хезмәт ияләрен талап байлык туплаучылар—хөрмәтле олигарх, намуслы хезмәт белән көн күрүчеләр—аләм актыгы (чернь, изгой), ялагайлар, ялганчылар—үз кеше, гадел фикер йөртүчеләр һәм чынбарлыкны фаш итеп язучылар—дошман, экстремист дип таныла. Бигрәк тә акыл ияләрен, зирәк сәясәтчеләрне, халыкка дөрес юл күрсәтүчеләрне сөйми бу империя! Шунадыр, каләмдәшебез Мәхмүт Әхмәтҗановны коммунистлар судтан судка йөртсә, «демократик» матбугатта «аны һичшиксез атарга кирәк!» дигән тәкъдимнәр дә күренде... Аның иҗатын бик чамалы гына белгән яки монарчы белергә өлгермәгән укучының: «Ни өчен?!» дип гаҗәпләнүе ихтимал. Ул сорауга, мөгаен, аның китаплары һәм әлегә китап буларак чыкмаган—газета-журнал битләрендә дөнья күргән йөзләрчә язмалары җавап бирүе ихтимал. Текемләп-анализлап укый алсаң, әлбәттә...



Шөкер, Мәхмүт ага әле дә исән! Алай гына да түгел, үткер каләме һәм гомере буе милләтенә кылган файдалы гамәле белән яши-яши 80 яшенә җиткән...

Гомер диген... Аның белән беренче танышуым әле кичә генә сыман. Ә инде исәпләп карагач, ис китәрлек: кырык ел үткән дә киткән.

Ул чакларда милләт өчен Татарстанда ике генә шәһәр бар иде сыман: Казан һәм Минзәлә. Икесе дә уку йортларының, күрлеге сәнгать үсеше белән дан тота. Минзәлә райкомының беренче секретаре—Социалистик Хезмәт герое, житмәсә, абруйлы, данлы кеше. Шуңа күрәдер, башкалалан журналистлар, язучылар, сәнгать әһелләре берәмләп тә, кем әйтмешли, көтүе-көтүе белән дә агылып тора Минзәләгә. Һәркайсы диярлек минем эш өстәлем торган редакциягә дә килеп керә. Әнә, чираттагысы атлый тупсадан. Моңысы инде, ни хикмәттер, кеше сурәтендәге фәрештә сыман: үтә матур, үтә пөхтә вә һәм дә артыгы белән тыйнак...

Дөресен әйтим, артык пөхтә, артык итагатьле, шулай ук һәр сүзен үлчәп кенә чыгара торган затларга шикләнеп карау балачагымнан ук килә минем. Андыйлар белән дуслыкның яки якыннан аралашуның күп тапкырлар кыен хәлләргә юлыктыруы аркасында тугандыр, мөгаен, андый галәмәт... Хезмәт юлына кергәч, күптин-күп кешеләр белән аралаша башлагач, ошбу карашым тагын да ныгыган иде сыман... Бу агай да шик тудырды күңелдә...

Хуш... Керде бу, сизелер-сизелмәс елмаюын да кушып, итагатьле генә исәнләште.

—Казаннан мин. Мәхмүт Әхмәтҗанов дигән абыең булам... Редакторыгыз кирәк иде, хәзергә юк икән, - диде.

Минекенә терәп куелган каршылагы өстәл буш иде ул көнне. Шунда утырып торырга

тәкъдим иттем. Ул утыра, ә мин (ашыгычрак материал әзерләргә тиеш булганмындыр, күрәмсен) язып утырам. Үзем язам, үзем теге кунакның карашы белән мина текәлеп утыруын да тоям. Әледән-але җәт кенә күз дә төшереп алгалыйм тегенә: «Әһе, чибәр генә түгел, йөзе дә якты, карашы да нурлы икән әле моның... Әткәй әйтмешли, иманы килбәтеннән күренеп тора». Язуымны дәвам итәм. Ә үземне һаман тутый кош каршында утыручы корымлы морҗадан чыккан чыпчык итеп тоям. Соңгы ноктамны куюга, кунак телгә килде:

—Синең Казанда чыккан әйберләрне укып барам, энем. Республика матбугатына күбрәк яз. Синнән күләмлерәк язмалар, очерклар көтәбез.

Сөйләшә башлагач, мәгълүм булды: СССР журналистлар союзының Татарстан бүлегеннән килгән бу. Матбугатта очерк жанрын көчәйтү максаты белән җыелышлар, очрашулар үткәреп йөри икән республика буйлап...

Урамга чыккач, парк аша атладык. Ямьле җәй, тирә як-чәчәктә... Шәхси тормышым белән, ничек үсүем белән кызыксына сөйкемле абый.

—Ничек дип инде... Әткәй гомере буе репрессия чыбыркысын татып яшәде. Сөргеннәр, төрмәләр, конфискацияләр... Кулак, дин башлыгының улы, халык дошманы, имеш... Хәтта сайлау хокукыннан да мәхрүм ителеп яшәгән. Әнкәй дә «дошман хатыны» буларак төрмәдә булды. Шул вакытта сеңелләрем, энеләрем ачлыктан, салкын тиюдән, кызамыктан үлеп бетте. Анадан берүзем калдым...

—Әй-е,—дип куйды кунак, уздалдына нәтиҗә ясагандай.—Балалар фаҗигасе күңелләрне генә түгел, илләрне дә тетрәтә ул.

—«Тетрәндерә» диясездер инде сез?

—Юк... Сүземне сайлап әйттем... Тетрәтә!

—Ил булып ил тетрәмәстер...

—Бер гөнаһ та эзсез югалмый. Яши-яши, үзебез дә күрербездер әле...

Олыгайган саен сизәм: быелтыр яки бер-ике ай элек кенә ишеткән сүзләр дә истән чыга. Ә минә бала чакта, яшь чакта ишеткән хикмәтле, мәгънәле кәлимәләрнең сүзе-сүзгә хәтергә сеңеп кала икән. Алай гына да түгел, күп очракта теге яки бу сүзне әйтүченең ничек сулыш алганына, карашының нинди булганына кадәр гомер буе онытылмый.

Менә хәзер, дөресрәге, тетрәүләрдән һәм тетрәнүләрдән генә гыйбарәт шушы чорда әледән-але уйлап куям: кырык ел элек үк шушы хәлләрне алдан сизде микән әллә Мәхмүт Әхмәтҗанов дигән агаем? Әнә бит, бөтен кешелекне калтыратып торган, дөньяны фаҗигаләргә дучар иткән, бихисап олыларны гына түгел, миллионнарча сабыйларның да кырылуына сәбәпче булган большевизм, үз гөнаһларының авырлыгына түзә алмыйча, тетри-тетри убылып төште. Йөзләрчә милләтләрне коллыкта, хурлыкта яшәргә мәҗбүр иткән СССР дигән явызлык империясе дә, аяк астындагы җире тетрәгәндәй, көне-сәгате белән диярлек җимерелде, күп илләргә бүленеп таркалды.

Тарихның андый катаклизмнары бүтән кыйтгаларда да җитәрлек.

Әйе, яши-яши аларын да күрдек һәм инде менә Россиянең Америка, Израиль һәм башка илләр аягы астында олтыракка әйләнә бару чорын да күреп яшибез. Бу хәлләрне берәүләр, ягъни урыс шовинистлары—кара көеп, империя богауларыннан котылуга сусаганнар—куанып күзәтә. Ә инде кешелек тарихын, дөнья фәлсәфәсен һәм сәясәтен тирәнтен өйрәнгән Мәхмүт Әхмәтҗанов кебек акыл ияләре, кызмыйча-кайнарланмыйча, салмак кына анализ ясый: мондый дәһшәтле җимерелүнең сәбәбе нәрсәдә? Үзләрен галим дип санаучы күпләр череп аву хәленә җиткән Россия дигән зур агачның өске ботакларына, яфракларына карап кына фикер йөртәләр:

—Икътисади яктан артта калганбыз,—диләр...

—Коммунистик системада озак яшәү зәхмәтенең сәбәбе бу,—диләр. Яки бөтенләй киресенчә:

—Сүз ирегенә, демократиягә алданып, коммунистлар партиясенең абруен бетерүгә юл куйдык. Ул тыюлар әле хәзер дә кыршаулап тотар иде СССРны, —дип тә көеналәр...

Ә инде әлеге «агачның» тамырына карап фикер йөртүче галим һәм язучы Мәхмүт Әхмәтҗановның фәнни-публицистик хезмәтләрен күпмедер дәрәҗәдә өйрәнгән, укыган милләттәшләр яхшы белә: урыс империясен генә түгел, башка империяләрне дә аяктан еккан төп сәбәп—«великий-бөек» милләтнең башка милләтләрне түбәнсетеп, мыскыл итеп яшәве, аларны һәлакәтле язмышка илтүе, корбан сарыгы итеп кенә күрергә тырышуы —бер сүз белән әйткәндә, тоташ гаделсезлек. Ә инде икътисад җимерелүенә килсәк, анысы

инде шушы гаделсезлекләрнен бер баласы гына: рухлары төшкән, кыерсытылган кешеләр икътисадны күтәрүгә атлыгып торалармыни?!

...Уйларым кабат, Мәхмүт аганың гыйльми-иҗади юлын барлый-барлый, безне таныштырган һәм тора-бара фикердәшләр, якын дуслар иткән алтмышынчы еллардан болайга—егерме беренче гасыр башына таба—урап кайта. Әлбәттә, «коммунизм чәчәк аткан» тоталитар чорда СССРның тетрәячәге турында ышанычлы, акыллы кешеләр белән генә сөйләшеп була иде. Анысы да саклык, сизгерлек сорый иде. Әйтик, шул хакта матбугатта ниндидер язма бастырып чыгарырга омтылу гомеренне ахмакларча кисүгә генә кайтып калыр иде. Мәхмүт Әхмәтҗановның да нәкъ менә сабыр, тотырыклы юл сайлавы табигый хәл. «Милләт» сүзен дә әйтергә ярамаган чорларда ул, кара цензура урманнарыннан сукмаклар таба-таба, үз халкында милли горурлык тәрбияли. Мәсәлән, беренче карашка гап-гади темалар: өйләнешү-никах, гаиләдә бала тәрбияләү, әтисез калган балалар, аналар кадере, гореф-гадәтләр... Бер уйласаң, камил акыллы булган һәркем язарлык сыман. Ләкин олуг галимнәр, язучылар арасында ярымшаяртып та, җитди дә итеп «аяклы энциклопедия», «дөнья гыйлемен сыйдырган компьютер» дип йөртелүче Мәхмүт әфәнде кебек нечкәләп, күңеленне тәрбияләрлек, үзенне зур халыкның улы яки кызы итеп тойдырырлык хезмәтне язу өчен аеруча зур талант сорала. Кабатлап әйтү кирәктер: аның татар тормышына багышланган язмаларын укыганда да бөтен дөньяны күргәндәй һәм шул дөньяның яналанына серләрен ачкандай буласың. Чөнки галим татар милләтенен кемлеген, ниндилеген язганда да тылсымлы виртуоз кебек: бер карыйсың, тирән тарихка кереп чыга, шуның белән мавыктырып өлгерүе була, кешелек дөньясының зур акыл ияләренә мөрәҗәгать итә, берочтан, әдәби осталыгын да җигеп, синең башыңны гыйбрәтле һәм кызыклы вакыйгаларга чумдырып ала... Кайсы да булса әсәрен укып чыккач, адәм баласы рухи канатының ныгуын, гыйлеменең артуын, күңеленең сафлануын, үз милләтенен көчлелеген тоя. Шушындый тәрбия алган кешегә: «Син әнә нинди көчле, үзеңне аямыйча, азатлык яула!» дип өндәүнең дә кирәге юк. Ул кадәресе хакында үзе дә уйлый белергә өйрәнә укучы мондый галимнәрнең хезмәтләрен укыганда!

Сәясәт белән кызыксынучылар Мәхмүт Әхмәтҗановны—зур сәясәтче, мәгърифәтчеләр—олуг педагог, тарихчылар—танылган тарихчы, каләм ияләре оста публицист яки әдәбият белгече дип исбатлыйлар. Һәм шуларның берсе дә ялгышмый. Чөнки бу академик фәнни-сәяси-иҗтимагый тормышыбызда кимендә ун шәхескә торырлык. Бу очракта аның тирән һәм күпьяклы гыйлеме генә түгел, киң колачлы иҗаты да күздә тотыла. Без инде хәзер аның яшенә җиткән күп язучыларны, сәясәтче һәм галимнәрне пенсия ашап ятучы картлар итеп кенә беләбез. Бу хакта көлмичә, гаеп итмичә әйтәбез. Табигый хәл чөнки... Әмма шул ук вакытта аларның кордашы Мәхмүт агабызга карап сокланабыз: аның язмаларыннан башка нинди газит яки журнал чыга? Юк сыман. Ә инде Татарстан радиосыннан даими рәвештә яңгырап торучы сәяси тәрбия «дәресләрен» әзерләүгә каян вакыт һәм ныклык таба? Чыгышларының фикер тирәнлеге, темаларының байлыгы, мавыктыргыч булуы гына түгел, ягымлы дикциясе дә күңелләрне әсир итә...

Аның киң колачлы иҗаты хакында уйланган чакларымда китап киштәмдә... түбәнә «Мәхмүт Әхмәтҗанов» дип язылган күптомлык күрәм. Әлбәттә, монысы теләк һәм хыял галәмәте генә... Әгәр дә шундый мөмкинлек килсә һәм һәр китапханәгә шундый томлыкларны куя алсак, яшь буыныбыз милли горурлык мәктәбен дә үтәр иде, өлкәннәр исә зирәгрәк, иманлырак булып китәр иде. Каюм Насыйрилар, Риза Фәхретдиннәр кебек олы шәхеснең үз чорында да барлыгын тояр иде безнең халык! Ә хәзергә... менә кадәр төрле елларда чыккан, укый-укый тузып беткән унөч китабын эзләп табкалау насыйбына гына өмет бар. Бигрәк тә «Килер бер көн (1998), «Тормыш мизгелләре» (2002), «Яманны юлдаш итмә» (2007) дигәннәрен табасы иде...

Әйе, инде әйтелгәнчә, Мәхмүт агабыз—ил карты хәзер. Юбилей-даталары да күп булды. Тик шунысы гаҗәп, ни хикмәттер, юбилейларында лаек хөрмәт күрсәтү түгел, аның түгәрәк даталарын ел саен чыгып килүче календарьлар да «оныта». Кемнәрдер, кайдандыр шундый күрсәтмәләр бирәләрдер, мөгаен. Бизнес караклары да, сәхнәгә менә башлаган яшь җырчылар да, яшь табиблар һәм калэм чарлый башлаган журналистлар да, совет власте өчен көрәшкән хәрбиләр дә зур шәхесләр итеп бирелгән календарьларда галим һәм адип Мәхмүт Рәхимҗан улы Әхмәтҗанов булмый... «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?!» дигән Тукаебыз тагын бер мәртәбә хаклы!

Әлбәттә, аңа карап кына исеме дә югалмый, абруе да төшми гыйлем һәм каләм иясенең. Чөнки ул андый интригалардан артык өстен, артык югары. Язмалары дөньяның күп илләрендә басылып торган, күп милләтләр хөрмәт иткән галимнең, бәлки, «ник мине Татарстанымда гына санга сукмыйсыз, туганнар» дип зарланырга да хакы бардыр барын... Ләкин, нәрсә дигән әле борынгы бабаларыбыз? Игелек кыл да суга сал, халык күрмәсә балык күрер, дигәннәрме? Кайбер галимнәрне үз тирәсендәге кешеләр генә белсә, моны һәр авылда, һәр шәһәрдә беләләр. Бигрәк тә сәясәт, милләт турында сүз, бәхәс чыкса:

—Бу хакта академик Әхмәтҗанов болай язды, болай диде!..—дип, фикерләренә таяныч табалар.

—Ул әйтсә, дөрес әйтә шул инде!—дип тә өстиләр.

Һәм тагын бер бәя еш ишетелә: «Җанны, иманны ныгыта торган академик!»

Әхмәтҗановның үзен халкы ныгыта, таланты күтәрә. Бүгенгедәй хәтердә, аны Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул иткән көннәрдә бер әдип болай дигән иде: «Язучылар берлегенә кабул ителмәгән суріәттә, Мәхмүт ага күпме нәрсә югалтадыр —төгәл әйтә алмыйм. Ә инде берлекнең биниһая күп югалтачагын яхшы беләм. Халык хөрмәтен яулаган бу абруйлы шәхес безнең сафта булса, берлегебез абруе тагын күтәрелер иде!»

Кабул иткәндә шунысын да онытмадык: киң кырлы башка хезмәтләреннән тыш, ике йөзләп язучының иҗат портретларын да (тормыш һәм иҗат юлларын) гыйльми осталык һәм гаделлек белән язган шәхес ул! Тагын... Әйе, тагын бер зур гамәл кылды каләмдәшләре өчен —ул әзерләгән сценарийлар буенча 57 татар язучысы турында фильмнар төшерелеп (һәркайсы сәгать ярымлык), аларның тиражлары республика уку йортларына таратылды.

Сиксән яшенә җитеп тә матбугат мәйданының уртасында, хәлен әз генә дә югалтмаган батырдай горур көрәшүче —милләтенең мәнфәгатен яклаучы Мәхмүт агай турында еш кына болай уйланам: Ходай аның биниһая хезмәтләренә карап-карап торадыр да, «файдалы гамәлләре ташый бу бәндәмнең. Яшәсен әле, яшәсен! Дөньяны гаделлеккә каратсын, диядер.»

Яшәү дигәннән, аны атарга тәкъдим итүчеләр язган бер мәкаләне укыгач, сорап куйдым үзеннән:

—Куркытмыйммы үлем белән янаулар?

Монсу елмаеп җавап бирде:

—Һәркемнең үз үлеме белән үләсе килә... Ләкин бу җәһәттән безнең нәсел күнекте бугай инде ул көтелмәгән афәтләргә. 1938 елда Сталин әнкәемнең абыйсы командарм Барый Тажетдиновны аттырды... Генерал полковник дәрәҗәсенә менеп җиткән иде татар башы белән... Тагын бер якын туганыбызны—Нигъмәт Хәкимне—«Идегәй»нең тулы вариантын табып, күчереп алганы өчен аттылар... Тагын...

Укучы белеп үтсен, аның бу истәлекләре үзе туган, үскән авылга —Башкортстанның Салават районындагы Нәсибаш авылына—андагы вакыйгаларга, шуннан чыккан шәхесләргә барып тоташа.

... Азатлык өчен көрәшләр корбансыз, кан коюсыз гына булмый шул. Газиз җиребезгә милләт каһарманнарыбызның да каны күп сеңгән... Шунысын да күреп, аңлап торабыз тагын: Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган публицист, Кол Гали һәм Хөсәен Ямашев исемнәрендәге бүләк иясе, РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы, академик Мәхмүт Рәхимҗан улы Әхмәтҗанов кылыч яки автомат күтәреп яу кырына чыккан, кан түккән кеше түгел. Әмма, изге Коръәнебез гыйлем ияләренең кәгазьгә түккән (язган) язу карасының һәм азатлык өчен шәһит киткәннәр түккән канның Аллаһы Тәгалә хозурында тигез күрелүен әйтә. Милли азатлык һәм гаделлек өчен гомер буе газапка тин борчылулар кичергән Мәхмүт Әхмәтҗанов кебек олуг затлар күздә тотыладыр Изге Китапта...

Монысы да Ходайның рәхмәтедер: изге җанлы галимебез ошбу юбилеен да иман нуры сеңгән матурлыгы, милләтенә изге нияте белән, яшьләрчә иҗат рухы белән каршылый. Әле күп җаннарны ныгытыр ул, аның хезмәтләре милләтебез азатлыгын яулауда күпләр өчен кулланма булыр, белем чыганагы булыр!

**Фәнзаман БАТТАЛ**

# ҺӘРБЕР МУЗЕЙ—ТОРМЫШ ДӘВАМЫ

*«Каяндыр тетрәндергеч моң килә...*
*Тәннәр чымырдый... Гүя гильотина*
*балтасы батырларның башын чапмаган...*
*Гүя әле алар үлем алдыннан*
*«Сибелә чәчәкне җырлыйлар...*
*Бу моң чигәләргә суга, гадел булып,*
*халык өчен яшисе килә...*
*Карадуганның М. Җәлил музее йөрәктә*
*бер моңлы шигырь булып калыр,*
*ахрысы. Онытылмас.*
*Мәктәп директоры һәм әлеге музейны*
*төзүче Бакый Зыятдиновка, ил күңелле*
*фидакарьгә чын йөрәктән мең-мең рәхмәт яусын».*

Рахмай Хисмәтуллин.
13 август, 1983 ел.

Күренекле педагог А. Луначарский «Музей—кешелекнең искиткеч зур хәтер китабы» дип әйтүе белән бик тә хаклы. Авылыбызда «Себер тракты тарихы» һәм Муса Җәлил музее бар. Җәлил музеенын барлыкка килү тарихы исә шактый кызыклы.

Безнең мәктәпнең пионер дружинасы 1955 елдан бирле Муса Җәлил исемен йөртте. Укучы балаларга гына түгел, хәтта ата-аналарга да бу исем шулкадәр якын булды. Без Җәлилне өйрәнүебез, аңа охшарга тырышуыбыз белән дә горурлана идек. Шагыйрьнең тормыш юлын җентекләп өйрәндек. Тик өйрәнү өчен шагыйрьнең шигырьләре, әдәби китаплар, башка материаллар юк дәрәҗәсендә иде шул. Булган кадәресе белән стендлар төзедек, М. Җәлилне белүчеләр белән һәртөрле элемтәләр булдырырга тырыштык, эзләндек.

1975 елда география һәм рәсем укытучы Ибраһимов Әнәс, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әминә Хөсәенова житәкчелегендәге 18 укучылы бер төркем Җәлил эзләре буйлап Оренбург өлкәсенә сәяхәт ясады. Алар шагыйрьнең туган авылы Мостафада булды, М. Җәлилнең авылдашлары, туганнары белән очрашты, истәлекле язмалар һәм әнисе каберennнән изге туфрак алдылар. Яшь эзтабарлар Мостафа авылыннан Оренбург каласына кадәр Җәлил эзләре буйлап җәяүләп бардылар. Укучылар Оренбургта Муса Җәлил белән бергә укыган, эшләгән Фатыйх Солтанов, Рокыя Рәхимова, Гөлсем Хөсәенова белән очрашты. Без Оренбургтагы Хөсәен Ямашев исемендәге татар китапханәсе белән хатлар алыша идек. Очрашуны да алар оештырды. Оренбургтагы төп очрашу, билгеле, Муса Җәлилнең сеңлесе Хәдичә апа белән булды. Без аның белән хәбәрләшеп тора идек, шуңа да ул безне бик җылы кабул итте. Укучыларыбыз бу сәяхәттән бай материал туплап кайтты.

Сәяхәттән алып кайткан хис-тойгылар бездә тагын да зур теләк уятты—чын-чынлап музей төзергә уйладык. 1976 елның 15 февралендә Муса Җәлилнең туууына 70 яшь тулу көнендә музейны тантаналы рәвештә ачтык. Быел музейга инде 30 ел тулды.

Музей төзү, аңа исем бирү эше шома гына бармады. Каршылыклы фикерләр,

сораулар туып кына торды. Хәтта кибетләрдә музей идәненә палас эзләгәндә дә «Нигә сезгә андый музей, Муса Җәлил Карадуганда булганмы соң?» дигән беркатлы сорауларга нигезле җавап бирергә кирәк иде. Мондый сораулар урынсыз тоелды. Уйландырды...

Уйласаң, үзебезнең чын татар егете иseme акланып, арабызга кайткан икән, алай гына да түгел, дошманның үз оясында күзенә карап, безнең азатлык өчен үткен сүзләре— шигырьләре белән көрәшеп, башын кистерүгә кадәр барып җиткән икән, үз каһарманыбызның тормышын өйрәнү, аны башкаларга җиткерү эше безнең— исән калганнарның бурычы бит ул! Ә аның төрмәдә язган шигырьләрендә дә туган илгә мәхәббәт, тугрылык чагылып ята:

*Син яшәмә җирдә файдасыз бер*
*Түмгәк булып тигез урында.*
*Янып калсын гомерең маяк булып,*
*Үзеңнән соң килер буынга.*
*(«Бер үгет»)*

Күбрәк эзләнергә, белергә һәм белгәнебезне (һәр истәлекле язманы, экспонатны) югалтмыйча сакларга, килер буыннарга тапшырырга дигән изге ниятебез безне һәрчак алга—ерак юлларга, кыю эшләргә чакырып торды. Музей, һичшиксез, кирәк иде һәм ул үзенең изге бурычын үти. Алда язылган, Рахмай Хисмәтуллинның тәэсирле сүзләре моңа шаһит.

Җәлил батырлыгын, җәлилчеләр эшен өйрәнүчеләргә зур ихтирам белән халык шагыйре, мәрхүм Илдар Юзеев:

*«Төрмә диварлары әйтер, бәлки:*
*Шагыйрьләрнең җыры өзелгән...*
*Өзелерлек түгел Җәлил гомере*
*Сез барганда алар эзеннән»,*

—дип язды 1984 елда. «Карадуган мәктәбе каршындагы «Кызыл ромашка» музеен карап, бик рәхәт минутлар кичердек. Бу музейны оештыручылар—чын мәгънәсендә тәрбиячеләр. Бу культура учагы—гасырларга эшләячәк»,—дип яза бер төркем язучылар исеменнән Мөхәммәт Мәһдиев.

«Без
яшәргә
хөкем ителгән!
Киләчәк буыннар хәтеренә калырлык эш-гамәлләрегез өчен рәхмәт Сезгә!»,—дип язды Равил Фәйзуллин Карадугандагы очрашу истәлеге итеп.

Аннары Новгород өлкәсенә—Муса Җәлил әсирлеккә эләккән, «Отвага» редакциясе эшләгән урынга—«Үлем үзәненә» сәяхәт ясадык. Ул сәяхәттә безне шул якта туып-үскән, бу урынны яхшы белүче, Җәлилне өйрәнүче язучы-галим Рафаэль Мостафинга юл күрсәтеп йөргән Николай Орлов таныштырып йөрде. Укучылар бу сәяхәттән кайтканда Мәскәүдә Мусаның хатыны Әминә апа һәм кызы Чулпан белән дә очраштылар.

Мусаның көрәштәше Гайнан Кормаш укыган һәм эшләгән Мари Республикасының Бәрәңге һәм Куян авылларына, Татарстандагы Муса Җәлил белән бәйле урыннарга сәяхәт кылдык. «Муса Җәлил» теплоходы экипажы белән элемтәгә кердек, 1978 елда экипаж капитаны чакыруы буенча теплоходта кунакта булдык. Одесса каласында причалдан махсус көймәләр безне диңгез теплоходына китереп куйдылар. Теплоход кадәр теплоходның алтынсыман итеп язылган «Муса Җәлил» исемен ялтыратып океаннарны айкап йөрүе безне гаҗәеп сихерле дөньяда гиздерде. Теплоходта алган тәэсирләр шулкадәр көчле иде, балалар үзләрен Муса Җәлил кочагында итеп тойдылар. Шатлыкларының, кызыксынуларының чиге юк иде. Бу хисләр герой шагыйрь М. Җәлилнең батырлыгын тоемлаудан туган иң саф һәм һичкайчан югалмас хисләр булып балаларның күңел түренә урнашты, безгә тагын да зур горурлык хисе өстәде.

Шулай итеп, музей янадан-яна экспонатлар, материаллар белән баетыла торды.

Музейның эшен «Кызыл ромашка» дигән укучылар оешмасы алып бара. Һәр елның февраль аенда бездә Муса Җәлил көннәре уза. Анда шигырь укучылар, җырчылар конкурсы үткәрелә, Муса Җәлил призына хоккей ярышы оештырыла. Муса Җәлилнең туган көнендә «Кызыл ромашка» оешмасына тантаналы төстә яңа әгъзалар кабул ителә.

Бу музейның ачылу елыннан башлап, тантаналарга Муса Җәлилне белгән, аның белән эшләгән, көрәшкән кешеләрне чакырабыз. Музей оештырган бу очрашуларда Җәлилнең көрәштәшләре Рушад Хисаметдинов, Фәрит Солтанбәков, туганнан туганы Таһир Корбанов, улы Альберт Җәлилов, аның белән эшләгән, аны яхшы белгән Усман Әлмиев, Фатыйх Исхаков, Муса Җәлилне белгән, аның сынын эшләгән татарның бөек рәссамы Бакый Урманче, Муса Җәлилне өйрәнүче галимнәр, язучылар Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев, Исхак Зәбиров, Фоат Мостафин, Муса Җәлил турында «Моңлы бер җыр» спектаклендә Муса ролен башкарган Ринат Таҗетдин, әнисе ролен башкарган Рәшидә Җиһаншина, ул әсәрнең авторы Туфан Миңнуллин, халык язучылары һәм шагыйрьләре Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Сәләхов, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, композитор Фасил Әхмәтов һәм башкалар булдылар. Хәзер бу очрашуларга без Муса Җәлил премияләре лауреатларын чакыра башладык, соңгы елларда бу очрашуларда Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Равил Шәрәфиев, Мөдәррис Вәлиев, Гөлзада Сафиуллиналар булды. Бу очрашуларга безгә районның күрше мәктәпләреннән әдәбият укытучылары җитәкчелегендә укучылар делегацияләре дә килә. Очрашулар бик тәэсирле үтә. Алар балаларда үз милләтенә, үз халкына карата горурлык уята.

30 ел буена очрашуларны барлап, күз алдыннан үткәреп, ләззәтле минутлар кичерәм. Чыннан да, М. Җәлил музее, шушы очрашулары белән безнең кешелек дәрәҗәбезне тәрбияли, җир йөзендә ни өчен яшәвебез турында уйланырга мәҗбүр итә. Ә менә Колыма салкыннарын җиңгән, Сталин чоры каһәрләренә түзеп исән калып (билгеле, күңел җәрәхәте һәм тән гариплеге белән, бер аякка калып) туган ягына җәлилчеләр чакыруы буенча кайткан Ибраһим ага Сәләхов та, Карадуган музеенда булып, үзенең җылы сүзләрен язып калдырды.

Мин шул очрашуларның аеруча тәэсирлесе, гыйбрәтлесе булган, музей тарихында аерым урын алып торучы—Мусаның тоткынлыктагы көрәштәше Рушад абый Хисаметдинов белән булган очрашуны киңрәк итеп язасы иттем.

Кулдагы адреслар буенча без хатлар язып күп кешеләр белән элемтәгә кердек, шул исәптән без Кыргызстанның Ош шәһәрендә яшәүче, Муса Җәлил белән фашист тоткынлыгында булган Рушад абый белән дә элемтә урнаштырдык. Җәлилче батырны үзебезгә кунакка да чакырган идек, ул үзенең безгә махсус кайта алмаганлыгын, моны ул Казанга килгәннән соң гына эшләп булачагын әйтеп язды. 1986 елда Казанда Муса Җәлилнең 80 еллыгы унае белән үткәрелә торган тантанага безне дә чакырдылар. Менә шул тантана вакытында без Муса Җәлил белән бергә тоткынлыкта булган Рушад Хисаметдинов, Фәрит Солтанбәков һәм Михаил Иконниковлар белән очрашып сөйләшү бәхетенә ирештек һәм әле бергәләп фотога да төштек.

Рушад абый үзенең безгә кайтырга исәбе барлыгын, ләкин Казандагы вакыты бик чикләнгән һәм тыгыз булуын, вакыты белән үзе генә идарә итмәвен әйтте, шулай да иртәгә үзе урнашкан кунакханәгә килеп карарга киңәш итте. Мин иртән Обком гостиницасына килеп, Рушад абый һәм хатыны Таифә апа белән очраштым. Шул вакытта кунакханәгә партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Рәис Кыямович Беляев килеп керде. Ул Рушад абый һәм Таифә апалар белән күрешеп хәлләрен белешкәннән соң минем белән дә шактый җылы итеп күреште һәм нинди эш белән килүемне сорады. Рушад абыйны музейга алып кайтасы килүемне, ләкин бу мәсьәләнең уңай хәл ителүе Рушад абыйдан гына тормаганын әйттем. Ул шул вакытта кистереп: «Карадуганга барасыз, Муса Җәлилгә багышланган андый яхшы мәктәп музее күргәнем юк әле»,—дип мәсьәләне хәл итте дә куйды! Рәис Беляев 1985 елның 11 октябрендә безнең музейда булып, үзенә музейның бик ошаганын язып та киткән иде.

Менә, ниһаять, 1986 елның 19 февралендә без Рушад абыйларны Карадуганга алып кайттык. Ул килү көненә туры китереп, музейның «Кызыл ромашка» штабының

махсус утырышын үткәреп, аны бу оешманың почетлы члены итеп алдык. Бу очрашу үзе һәм Рушад абый Хисаметдиновның чыгышы искиткеч тәэсирле булды. Ул Муса Җәлилнең бик күп шигырьләрен яттан сөйләве белән укучыларны шаккатырды, 75 яшьлек кешенең тоткынлыкта ишетеп, тоткынлыкта ятлаган шигырьләр сөйләве йөрәкләргә үтеп керде.

Рушад абый легионерлар составында оста рәсем ясаучы Җәүдәт Шамбасов дигән кеше булуын, аның Муса шигырьләренә иллюстрацияләр ясавын сөйләгән иде. Без Кырымның Саки шәһәрендә яшәүче бу абыйга берничә хат язсак та җавап булмады. 1981 елда «Кызыл ромашка» штабы членнары белән Казанга экскурсиягә баргач, М. Горький музеенда бер кечерәк кенә гәүдәле өлкән яшьтәге кеше, Карадуганнан икәнебезне белеп, безнең янга килеп күреште. Үзенең Җәүдәт Шамбасов булуын, бездән хатлар алуын әйтте, җавап бирмәгән өчен гафу үтенде. Мин сезгә нәрсә бирим икән дип уйланып торды да, музей хезмәткәрләреннән кәгазь сорап алып ансат кына агач башмак рәсеме ясап бирде, ул аның немец тоткыннары кия торган башмак икәнен әйтте. Без аның чыннан да оста рәсемче икәнен сиздек. Ул безгә үзенең Муса Җәлил киңәше белән ясаган рәсемен җибәрергә вәгъдә бирде һәм сүзендә торды: кое янында көянтә-чиләкле татар кызының рәсеме, еракта манаралы мәчет күренә. Җәүдәт абый Муса бу рәсемгә «Ул көтә» дигән исем биргәнен язды.

Безнең музей Рушад абыйга бик тә ошады.Ул үзенең бик күп урыннарда Муса Җәлил музейларында булуын, ләкин безнең музей кебек бай, зәвык белән бизәлгән һәм даими эзләнүләр алып баручы башка мондый музей күргәнем юк иде дип, безне шатландырды, укучыларның башлары күккә тиде.

Билгеле, балалар һәм укытучылар, халык белән очрашуда ул үзенең фашист тоткынлыгында күргәннәрен, җәлилчеләр батырлыгын гына сөйләде, безнең илгә кайтканнан соң ниләр күргәнен сөйләмәде, чөнки әле бу 1986 ел—коммунистларның «властьны үз кулларында тоткан вакыт, әсирлектә булган кешеләр белән Совет хөкүмәте нәрсә эшләгәнне сөйли торган вакыт түгел.

Кунакханәдә без төне буе Рушад абый белән сөйләшеп чыктык. Бу очрашуда минем Түбән Камадагы энем Азат Зыятдинов та катнашты. Сүз уңаенда Азат Рушад абыйны, Таифә апаны һәм туганының кызы Азалияне Түбән Камага чакырып, Рушад абыйга багышлап «Җидегән чишмә»нең бик матур кичәсен үткәрүләрен әйтеп китү урынлы булыр. Менә шушы төнге сөйләшүләрдә безне бик якын итеп ул үзенең тормыш юлын, бигрәк тә совет лагерьларында күргәннәрен сөйләп, безнең күңелләрне тетрәндергән иде. Нинди батыр йөрәкле кеше, әмма аерым бер урыннарда, КГБчыларның явызлыкларын сөйләгәндә күзләреннән яшь тама иде. Мин аның сөйләгәннәреннән кайбер эпизодларны искә төшерәм. Җәлилчеләрнең барысының да башларын кисмәгәннәр. Ул яшерен оешманың иң актив члены булган, шулай да үлем җәзасыннан котылып калган. Монда аңа аның сугышка кадәр 1932—1940 елларда чик буе гаскәрләрендә хезмәт итүе, ягъни чекист булуы ярдәм иткән. Беренчедән, ул листовкаларны ераграк яшергән, үзе йоклаган урынга гына куймаган, икенчедән, иң мөһиме, сорау алу вакытында үзен ничек тотарга икәнен яхшы белгән һәм үлем җәзасыннан котылган, аңа гомерлек төрмә җәзасы бирелә. Аларны бер төрмәдән икенчесенә күчергәндә, ике кешенең богауларын бергә бикләп, вагоннарга төяп озаталар. Поездны юлда бомбага тоталар. Рушад абый Татарстаннан Гатин Зиннур дигән кеше белән бергә богауланган була, ә Рушад абый чекист буларак богауның йозагын ача белгән. Ул йозакны ача һәм, бомбага тоту моментыннан файдаланып, алар икесе ике якка качалар. Рушад абый әйткән Гатин Зиннур белән кызыксындым, соңга калып булса да 2001 елның апрелендә аны Алабуга картлар йортыннан таптым. Ул, чыннан да, үзенең Рушад Хисаметдинов белән богаулары бергә йозакланган булуын, Рушад йозакны ача алуы аркасында исән калуын сөйләде. Зиннур абый да немец пленыннан котылгач, бездәге төрмәләрдә, лагерьларда күп газаплар чиккән. Поездда кайтканда, ничектер вагон идәнендә очраклы рәвештә газета кисәге табып алган һәм шунда Рушад абый турында язма укыган. Аның кайда яшәгәнен белгән. Шул адрес буенча Ош шәһәренә барып, Рушад абыйны тапкан. Искиткеч булган икесе бергә богауланып йөргән дусларның бу очрашуы! Зиннур абый үзенең туган ягына Тәберле Чаллысына (Балык Бистәсе районы) чакырган.

Авыл халкы Рушад абыйны зурлап өйдән-өйгә йөртеп кунак иткән. Бик кызганыч булды Зиннур абый белән минем бу очрашу. Ул инде бик бетерешкән. Мин аның гомеренең соңгы чорын картлар йортында үткәрүенә борчылып кайтып киттем. Язмыштан узмыш юк дияргә генә кала. Без элегрәк очраша-табыша алмавыбызга үкенеп аерылыштык.

Рушад абый француз партизаннарына эләгә һәм анда россиялеләрдән оешкан отрядның командиры була, алар үзләрен французларга караганда остарак сугышканнарын исбат итәләр. Рушад абыйлар безнең якка чыкканнан соң тикшерүләр үтәләр һәм ул 1945 ел ахырында үзенең туган ягына Урта Азиягә кайта, туганнары һәм хатыны Таифә, улы Равил белән очраша. Ош шәһәрендә ит комбинатында баш ветеринария врачы булып эшкә урнаша. Ул сугышка кадәр үк ветеринария техникумын тәмамлап, ветврач булып эшли, армиядә дә кавалериядә хезмәт итә. Ана 1949 елда әсирлектә булган өчен яман аты чыккан 58 статья белән 25 елга төрмә җәзасы бирәләр. Монда төп гаеп итеп Муса Җәлил житәкләгән каршылык хәрәкәтендә катнашу күрсәтелә, чөнки бу вакытта Муса сатлык итеп санала. Монда тагын бер чигенеш ясап алыйк. Фәрит абый Солтанбәковка үзеннән беренче мәртәбә сорау алганда татар тикшерүчесе туры килә. Ул, миһербанлы бәндә, Фәрит абыйга Муса оештырган яшерен оешма эшендә катнашуын әйтмәскә киңәш итә. Һәм Фәрит абый, аның киңәшен тотып, совет төрмәсе газапларыннан котылып кала. Мин Рушад абый сөйләгәннәрнең бөтенесен тасвирлап язып тормыйм. 1953 елда Кемерово өлкәсендә урман кискән жирдән аларны ерак төньякка алып китәләр. Татар бугазындагы Ванино портыннан Төньяк Боз океанына кадәр йөк пароходының трюмында (йөк тутыра торган аскы кат) алып баралар. Анда ачлыктан, һава житмәүдән, төрле авырулардан кешеләр кырыла, үлекләрне диңгезгә ташлый баралар. Монда Рушад абыйга аның ветеринария врачы булуы күпмедер ярдәмгә килә. Корабльдәге тоткыннар врачына Рушад абый булышкалый, чөнки дарулар, инструментлар аңа ветврач буларак таныш була. Көннәрдән бер көнне врач үлеп китә һәм аның сумкасы Рушад абый кулында кала. Ул бу сумканы тапшырырга кирәклеген әйтеп, часовойга мөрәҗәгать итә. Аңа өскә менәргә рөхсәт бирәләр. Шул вакытта палубага менеп, саф һава сулагач туган кичерешләрен искә төшереп сөйләгән иде. Корабльнең капитанына сумканы тапшырганда, ул Рушад абыйдан сумканың ничек аның кулына эләгүен һәм һөнәрен сорый. Рушад абыйга сумканы кире биреп, булдыра алган кадәр тоткыннарга ярдәм итәргә куша. Алар, Камчатка, Чукот ярымутрауларын урап үтеп Төньяк Боз океаны буйлап Яна елгасы тамагына кадәр баралар. Шуннан соң диңгез корабыннан елга пароходына күчеп утырып Яна елгасы буенча күтәрелеп, бер урында туктыйлар. Шунда алар буш урында концлагерь төзергә тиеш булалар. Лагерь начальнигы Украин кешесе (хохол), бөтен тоткыннарны тезеп, төрле һөнәр кешеләрен ачыклый башлый: «...Балта осталары, бер адым алга! Ташчылар, бер адым алга!» һәм башкаларны аерып төрле һөнәр кешеләренең төркемнәрен төзи. Ахырдан чират медицина хезмәткәрләрен сорауга барып житә...

Шуннан ул үзенә тапшырылган кешеләр белән амбулатория өчен палатка төзи. Рушад абый: «Иң үзәккә үткәне шул иде,—дип сөйли.—Безне караклык өчен җәзага тартылганнар һәм авыр җинаять эшләүчеләр белән бергә урнаштырдылар». Алар исә сәяси тоткыннарны күпме кирәк шуның кадәр җәберләгәннәр. Ашханәләрдә, складларда, башка җиңелрәк эшләрдә эшләүгә 58 нче статья белән утыручылар якын китерелмәгән. Коммунистлар өчен караклар, кеше талаучылар, үтерүчеләр куркыныч булмаган, ә пленда булган яки контр сүз белән эләккән тоткыннар куркынычрак булган икән. Лагерьның исеме дә тоткыннардан көлү кебегрәк яңгырый—«Депутатский».

Рушад абый беркадәр фельдшерлык эшен башкаргач, монда чынлап та «кеше врачы» бер хатын-кызны җибәрәләр, шулай да Рушад абый аның ярдәмчесе булып кала. Тоткыннар төсле металл чыгаруда эшлиләр, аларны эшләтүче мастер ирекле ялланып эшләүче була. Югарыда телгә алынган врач бу мастерга кияүгә чыга, авырга уза һәм декрет ялына китә. Көннәрдән бер көнне Рушад абыйны шәфкать туташы чакыруы турында әйтәләр, ә ул барып керсә, аның бала таба алмыйча ятканы билгеле була. Рушад абый берничек тә ярдәм итеп булмаганын күреп, кире кайтып китә,

шуннан соң аны кире чакырып китерәләр, шәфкать туташы ана баланы ярып алырга куша. Рушад абый мин башкара торган эш түгел дип, баш тарта. «Барыбер үләм, зинһар, ярдәм ит,»—дип елап ялынгач, ул—йөрәкләнеп, бу эшкә ризалык бирә. Рация аркылы хәбәр иткәч, район больницасыннан тиешле инструмент һәм медикаментларны самолет белән килеп ташлап китәләр. Рушад абый үзенең бар белгәннәрен искә төшереп, бөтен көчен, акылын туплап, чыннан да баланы ярып ала (кесерево сечение), бала күгәреп беткән була, аны үзенең ярдәмчеләренә биреп, салкын суга батырып алырга һәм суккаларга куша, шуннан бала кычкырып җибәрә һәм Рушад абый моңа куанып, яраларны тырышып тегеп, операцияне уңышлы тәмамлый. Без аның сөйләгәннәреннән ничек бу эшкә алынуын сорагач, «Безне ветеринария уку йортында хайван суярга яки дару эчерергә һәм справка язарга гына өйрәтмәделәр, операция ясарга да өйрәттеләр,»—дип көлгән иде. Күп тә үтми, бу шәфкать туташы ире белән район үзәгенә күчеп китәләр. 1956 елда Рушад абый амнистиягә эләгеп, төткынлыктан азат ителә. Тиешле документларны рәсмиләштерү өчен район үзәгенә китә һәм сорашып теге шәфкать туташларын таба. Килеп керүгә Рушад абыйны кочаклап алалар, ә Рушад абый туарга булышкан малай инде йөгереп йөри. Шәфкать туташының ире бөтен документларны рәсмиләштерүне үз өстенә ала, Рушад абыйга өйдә ял итеп кенә утырырга куша. Монда берничә көн кунак булгач, Рушад абыйны Иркутскига самолетка билет алып озаталар. Рушад абый төткынлыктан чыккан килеш кенә өйгә кайтырга уңайсызлана. Себердә бераз акча эшләп, өс-башын карап, шуннан соң гына кайтырмын дип, кунакханәгә (дөресрәге крестьян йортына) урнаша. Шуннан киемнәрен алыштыру өчен чемоданын актара башлагач, аның төбеннән бер пачка эре акчалар килеп чыга. Рушад абый теге кешеләрнең яхшылыгына куанып, елап җибәрә. Бу акчаны мин берничә ай эшләп тә ала алмаган булыр идем»,—ди. Шуннан соң үзенең өс-башын юнәтеп, гаиләсенә бүләкләр дә алып, туп-туры Ош шәһәренә кайта.

Ул сөйләгән истәлекләрдән Рушад абыйның нинди йөрәкле, кешелекле, ярдәмчел, курку белмәс кеше икәнлегенә, чыннан да легендар шәхес булуына ышанасың.

Муса Җәлил музееның тагын бер эшчәнлеген әйтеп китү уңышлы булыр. Безнең музейга 1979 елда мәктәп музее статусы бирелеп, ул мәктәп музейларының Бөтенсоюз каталогына кертелде һәм аның эше турында Мәскәүдә «Литература в школе», «Пионерская правда» газеталарында мәкаләләр чыкты. Шуннан соң безгә элекке союзның барлык почмакларыннан хатлар ява башлады. Камчаткадан башлап, Украина, Эстониягә кадәр, Урта Азия республикаларыннан, хәтта ГДР дан хатлар килде. Баксаң, илнең бар почмакларындагы мәктәпләрдә Муса Җәлил исемендәге пионер дружиналары, отрядлары, интернациональ дуслык клублары бар икән. Алар бездән Муса Җәлил турында күбрәк белергә теләүләрен, аны өйрәнүләрен, хәтта музей төзергә әзерләнүләрен әйтеп бездән ярдәм сорап хатлар яздылар. Без Муса Җәлил турында Казанда чыккан китапларны күпләп алып, шул сораган урыннарга җибәреп тордык. Үзебездә булган истәлекләрнең күчермәләрен дә җибәрдек.

1990 елда Муса Җәлил батырлыгын, иҗатын пропагандалаудагы зур хезмәтебез өчен безнең музейга Муса Җәлил премиясе бирелде.

**Бакый ЗЫЯТДИНОВ,**
*Карадугандагы Муса Җәлил музее директоры,*
*Татарстанның һәм Россиянең атказанган укытучысы.*

# АНЫҢ «САФ КҮҢЕЛ»Е, «АГЫЙДЕЛ»Е...

*Татар әдәбиятының алтын фондына кереп калган «Саф күңел» романы, «Агыйдел», «Балыкчы ялганнары» повестьлары, «Миңлекамал», «Тормыш җыры» драмалары һәм күп санлы хикәяләр авторы Мирсәй Әмиргә 6 январьда 100 яшь тулган булыр иде. Әнә шундый үлемсез әсәрләр иҗат итү белән бер рәттән әдип үтә җаваплы җәмәгать эшләре дә алып бара: берничә чакырылыш рәттән РСФСР Верховный Советы депутаты, РСФСР Верховный Совет Президиумы Председателе урынбасары, РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены булып сайлана, 1937 һәм 1961—1968 елларда республика язучылар оешмасына җитәкчелек итә.*

*М. Әмир озак еллар буе көндәлек тә алып бара. Түбәндә без укучыларга әнә шул көндәлекнең бер өлешен—1964 елга багышланган язмаларны—тәкъдим итәбез. Аларда әдипнең тынгысыз тормышы, әһәмиятле уй-фикерләре чагыла.*

**24/II-64. «Москва» кунакханәсе. №879.**

Яна гына килеп кердем: ялт итеп торган кояшлы бүлмә. Тәрәзәсе ишек алдына караган, димәк тавыштан тыныч, аулак. Күңел күтәрелеп китте дә, иң элек шушы дәфтәрне алып, язып куярга булдым.

Поездда һәм вокзалдан машинада Ахазов Тимофей Аркадьевич белән бергә килдек (ул хатыны белән). Поездда танковое училище парторгы Сивов Геннадий Яковлевич белән бер купеда килдек. Ул хатыны белән ялга бара икән—Сухумига.

Иртәгә В. Совет президиумы утырышы, шуңа чакырып китерделәр. Бер унайдан Союз һәм нәшриятлар белән бәйле кайбер эшләрне дә башкарып кайтасы бар.

Кич с. 11. Көндез «Сов. писатель» издательствосында булдым. Кирьянов һәм поэзия бүлеге редакторы янында булдым (Регистан юк, аның урынына калган Денисов, бугай, бар иде). Алар аркылы 1965 нче ел планы белән танышкач, издательствоның директоры Ник. Вас. Лесючевский янына кердем. Бик әйбәт сөйләшеп утырдык. Үземнең китабымны язып бирдем.

1965 нче ел планына М. Җәлил, Г. Ибраһимов һәм хәзергеләрдән Г. Мөхәммәтшин, И. Юзеев, Ә. Давыдов, Г. Афзал җыентыкларын кертү турында сөйләштем, һ. б...

Кичен МХАТ бинасында Малый театр куйган спектакльне карадым. Оскар Уайльдның «Веер леди Уиндермиер» дигән комедиясен уйнадылар. Матур гына спектакль. Комедия дип аталса да, нигезендә бик көчле драма ята. Халык күп иде, сатып алырга билет булмагач, администраторга мөрәҗәгать иткән идем, правительство ложасына билетсыз утыртты.

**25/II-64. «Москва». № 819.**

Иртәнге 10 нан көндезге 3 кә кадәр президиум утырышында булдым. Батыев та килеп чыкты. Ул Москвага якын санаторийда ял итә икән. «Чистая душа»ны рәхәтләнеп укып чыктым, диде. Укып бетерергә тагын ничә бит калды икән дип, бер генә тапкыр да карамадым, ди. Шулай дип күңелемне күтәрде, рәхмәт инде.

Утырыштан соң магазиннарга кергәләп йөрдем, ләкин Ибраһим Газый кушып җибәргән дарудан башка берни дә алмадым шикелле.

Кичен А. С. Пушкин исемендәге драм. театрда Юлиан Семеновның «Петровка, 38» пьесасының спектаклен карадым. Кызыксынып карап утырдым, ләкин тирән эз калдыра алмады, халык бик яратып йөри булса кирәк. Билет табу кыен иде. Администратор рөхсәте белән, өстәмә урындык куеп, түләүсез урынга гына утырттылар.

**27/II-64. «Москва». №819.**

Кичә көндез Үзәк Комитетка кереп Жильцова Нина Павловна белән танышып, сөйләшеп чыктым. Аннары Детгизда булдым. Галия ханым Кәримова белән татар әдәбиятыннан 1965-ел планына кемнәрне кертү турында сөйләштек. Аннары «Москва»га кайтып ашап чыктым да, РСФСР Язучылары союзына—Софийская Набережная 30га—бардым. Анда Мостай Кәрим белән сөйләшеп утырдык. Казаннан сөйләшеп китү буенча, бу вакытка анда Гомәр Бәширов килергә тиеш иде. Ләкин ул килмәде. Мин Шкаев Василий белән җәйге һәм көзге эшләр планы турында сөйләштем. Август айларында Мәскәүдә татар поэзиясе атналыгы планлаштырыла. Ә көзгә—октябрь азакларында—Казанда РСФСР Язучылар союзының күчмә секретариатын уздырырга тәкъдим итәләр. Милли романнарга бәйләп, традицияләр һәм аларның перспективалары турында сөйләшергә уйланыла. Ул тәкъдимне кабул итәргә һәм эшләргә кирәк булыр.

Кичен арып-талып гостиницага кайтсам, Гомәр килгән, вестибюльдә миңа калдырырга дип записка язып утыра. Минем бүлмәгә кереп, бер бутылка коньяк янында шактый озак сөйләшеп утырдык.

Бер кызык деталь булып алды: безгә ашарга китергән хатын счет язып бирде. Мин шуны укыр өчен күзлегемне эзли башладым.

—Әнә бит күзлек, ки шуны!—диде официантка.

Урындык өстендә матур гына кысалы күзлек ята икән. Димәк Гомәрнеке. Ул, әлбәттә, минекеннән дә «яшерәк» күзлек кими инде. Алып күземә кидем дә, счетны укыдым. Күзлек бик яхшы күрсәтте. Ә буфетчы хатын нигәдер серле генә көлеп тора, Гомәр дә нәрсәдәндер көлүен яшереп читкә борылды. Игътибар итмәдем, исәпне өздем. Буфетчы чыгып киткәч, Гомәр әйтте: теге күзлекнең пыяласы юк имеш. Ул пыяласыз кыса гына икән. Мин аны белмичә алып кигәнмен һәм иң гаҗәбе: шуны кигәч күзем яхшы күрде, әйе, күзлексез килеш бөтенләй аера алмаган цифрларны бик ачык күрдем. Шулай ук внушение көче картлык дальнозоркостын да җиңәргә мөмкин микәнни?! Рәхәтләнеп көлештек. Әйе, кеше сөйләсә, ышанмас идек, ләкин факт! Шулай булды...

Бүген РСФСР язучыларының секретариат утырышында булдым. Мусрепов, Баруздин, Петрусь Бровка, Натан Рыбак, Константин Федин, Чаковский, Грибачев һәм башкаларның доклад һәм чыгышларын тыңладым. Молдагалиев белән Мостай Кәрим дә сөйләделәр. Сүз төрле милләт язучылары арасында үзара дуслык бәйләнеше, әдәбиятләрнең бер-берсенә йогынтысы турында, шул эшне ничек яхшырту турыларында барды, әйтерлек яңалыклар юк.

«Дружба народов» журналы кешеләре белән сөйләштем. Г. Гулиа, В. П. Лукашевичларны күрдем, сөйләштем. Аларга мин үземнең китабымны җибәргән идем, алганнар, рәхмәт әйттеләр.

Иртәгә Совет Мирага һәм Гослитиздатка кереп чыгасым бар. Кичен Казанга кайтып китәм, билет кесәдә.

**15/V-64. Москва, гостиница «Минск». № 836.**

Бу «Минск» дигән гостиницаның яңа ачылган көненә туры килдек. Бу бүлмәгә мин беренче башлап керүче булдым. Күрше бүлмәдә (837 дә) Җиһанов Нәҗип. Өченчебез Тутаев Мөнәвәр—ул 523 енчедә.

Без ЦК каршындагы идеология комиссиясе җыйган киңәшмәгә килдек, чакырып алдылар. Хөкүмәт җитәкчеләре белән әдәбият-сәнгать эшлеклеләре арасында булган мәгълүм очрашулардан соң узган елдан артык вакытка йомгак ясау һәм шул унай белән алда торган проблемаларны хәл кылу теләгеннән чыгып оештырылган киңәшмә бу. ЦКның кинозал бүлмәсе тулы халык, 500 дән артык кеше бар.

Бүген иртән 10 да кинәшмәне Ильичев ачып җибәрде. Аннары иҗат оешмалары вәкилләреннән Георгий Марков (Союз писателей), Пырьев (кино), Белашова (художники), Хренников (Композиторлар союзы) иптәшләрнең докладларын тыңладык.

Прениларда Б. Полевой, Черкасов, Неизвестный, Аксенов, А. Сурков һәм тагын берничә кеше сөйләделәр. Иртәгә дәвамы була.

Әле генә Казан белән—Фәүзия белән—сөйләштем. Ятам. С. 12. 10.

**29/V-64. Киев.**

26 майда иртән килеп төштек (Гомәр Бәширов белән икәү). Биредә 27 нче майдан башлап 2 нче июньгә кадәр Шевченко көннәре үткәрелә. 27 сендә СССР Язучылары союзы белән Украина Язучылары союзының берләштерелгән пленумы утырышы ачылды. Мондый тантаналы утырышка хас булганча барлык Союзный республикаларның һәм берничә автономияле республикаларның вәкилләре чыгышлар ясадылар. Бездән Гомәр Бәширов чыкты.

Шунысы характерлы: һәрбер халык вәкиле Тарас Григорьевичны үз шагыйре итеп тануын әйтә. Һәм чынлап та гаҗәп бер даһи булган ул Шевченко: бик күп шәһәрләрне, халыкларны күргән, ләкин күреп кенә калмаган, аларга үзенчә бәя биреп, аларга нинди мөнәсәбәттә булуын, кыска гына формада булса да, әйтеп, әйтеп кенә түгел, язып калдыра алган. Ә аның әйткән сүзләре, биргән бәяләре безнең бүгенге карашларга бик яраклы килеп тора.

Күрәсең, чын мәгънәсендә үз халкының мәнфәгате өчен янып яшәгән кеше һәрвакыт дөрес сүз генә яза һәм ул дөреслек озын гомерле дә була.

Шевченко турында бик күп чыгышлар тыңлаганнан соң, үземнең аны аз белгәнлегемне аңладым, әйе, җитәрлек белмим икән. Мотлак укырга кирәк.

Пленум 28 ендә ябылды. 29 ында Берләшкән Милләтләр Оешмасының культура бүлеге җыйган Форум башланды, монда инде күбрәк чит илләрдән килгән вәкилләр сөйли. Һиндстан, Канада, Италия, Германия, Франция, Польша, Румыния вәкилләре сөйләде, Америка художнигы Рокуэл Кентны тыңладык. Үзебезнекеләрдән Борис Полевой әйбәт кенә чыгыш ясады. Беренче доклад Украина язучысы Новиченконыкы иде.

Кичә Ленин премияләре комиссиясенең утырышы булды: Олесь Гончарга 1963 нче ел буенча, «Тронка» дигән китабы өчен бирелгән премияне тапшыру церемониясе булды. Бик күңелле, кызыклы тантана.

Киев искиткеч матур, төзек, чиста шәһәр икән. Бу көннәрдә ул бигрәк тә матур: бөтен урамнарында диярлек чәчәккә күмелгән каштаннар күкрәп утыра. Минем каштан агачларын моңарчы да күп күргәнем бар иде, ләкин чәчәк аткан чагын күргәнем юк иде әле. Күргәч: «Чәчәк аткан чагын күргәнең булмаса, минем каштан агачын күргәнем бар дип йөрмә икән!» дигән фикергә килдем. Һәм бу бик кызыклы хакыйкать. Чәчәк аткан чагы, әлбәттә, аның берничә көнгә генә бара. Ә шул берничә көн аның бер еллык гомере өчен иң характерлы чагы. Бу бит бик күп нәрсәгә карата шулай, һәр әйбернең типик ягы бик кыска вакытта гына чагыла дисән дә дөрес булыр.

**3/X-64. Москва, гост. «Украина». № 1121.**

Москвага—татар әдәбияты көннәре уздырырга килдек. Группада: Х. Туфан, С. Хәким, Ф. Хөсни, Хатип Госман, Ә. Исхак, Г. Ахунов, Н. Дәүли, З. Нури, Сажидә Сөләйманова, Рөстәм Кутуй, Рафаэль Мостафин, Гамил Афзал иптәшләр. Москвала яшәүче Ә. Ерикәй дә кушыла. Җитәкчесе—М. Әмир.

Октябрьнең 1ендә килеп төштек, Москва язучыларыннан күп кенә иптәшләр вокзалга килгән иде, чәчәкләр белән каршы алдылар. Алар арасында Николай Чуковский, Ильин, Белла Ахмадуллина, Михаил Львов һ. б. берничә язучы, үзебезнең татарлар, студентлар бар иде. Шул ук көнне кич Трехгорная Мануфактурадагы эшчеләр дворецында (Ленин исемендә) беренче кичәбез булды. 250-300 чамасы кеше бар иде. Зур күпчелек татарлар булды. Кичә ике телдә барды (ләкин тәрҗемә итеп түгел). Русча чыгышларыбыз да, татарчалары да тыңлаучылар тарафыннан

яхшы кабул ителде. Артистлардан Эмиль Җәләлетдинов, Венера Шәрипова, Әхтәмова Халидә (скрипка) чыгышлары әйбәт булды.

2 сендә Язучыларның Үзәк Клубында атналыкны официаль ачу кичәсе булды. Кичәне Николай Чуковский ачты. Мин кереш сүз сөйләдем. Программаны монда да Рафаэль Мостафин алып барды. Ул рус телендә бик иркен һәм оста сөйли, бик культуралы итеп алып бара белә. Гомумән бу яшь тәнкыйтьче-әдәбиятчы миңа бик ошый. Шушындый яшьләребез күбрәк булса бик шәп булыр иде, аз шул. Хәтта Мостафин кебеге бер генә, үзе генә дияргә мөмкин.

Язучылар йортының зур тамаша залы тулы иде. Монда да күпчелек татарлар иде. Кичә ике телдә барды. Татар телендә укылган шигырьләр аеруча яхшы каршы алындылар. Хәсән Туфанны берничә кат чыгардылар, шулай ук С. Хәким, Ә. Исхак шигырьләре дә бик әйбәт кабул ителде.

Шул көнне (2/Х-дә) көндез «Лит. Россия» редакциясендә очрашу булды. Бу очрашу бик җитди, эшлекле төстә һәм иптәшләрчә җылы рухта барды. Редактор Конст. Иванович Поздняев, аның урынбасары Григ. Самойлович Куклис бездә аеруча яхшы тәэсир калдырдылар. Безнең иптәшләрдән Хатип Госмановның чыгышын редакция кешеләре бик яраттылар. Ул татар әдәбиятының зур һәм бай тарихы турында кыска һәм ачык итеп, чыннан да кешене кызыксындырырлык итеп әйтә алды. Дөресен әйткәндә, безнең әдәбиятыбыз тарихы турында монарчы берни ишетмәгән рус иптәшләр өчен генә түгел, безнең үзебез өчен дә ул чыгышны тыңлау бик әйбәт булды. Атналыкка Хатип Госманны алып килүебез, аның шушы чыгышы өчен генә булса да, бик дөрес булган. Редакция кешеләре ул күтәргән мәсьәлә белән кызыксындылар. Аларда шушы уңай белән татар әдәбиятының тарихына кагылышлы материаллар оештыру идеясы туды, башка халык әдәбиятларына карата да бу турыда җитди уйларга кирәк дигән фикергә килделәр.

Әдәби портретлар турында, рядовой әсәрләрдән шедеврларны аеру кирәклеге турыларында сөйләнелде.

Безнең өчен бик нык искә алынырга тиеш булганы: үзебезнең иҗатыбызны һәм үзебез турындагы материалларны «Лит. Россия» битләрендә күбрәк күрүгә ирешү өчен үз тарафыбыздан өлексез инициатива һәм активлык кирәклеге турында әйтелде. Хәзергә исә бездә үз тарафыбыздан активлык җитми. Хәтта сораган әйберләрне дә бирмибез. Бу турыда Михаил Львов бик кистереп әйтте.

Кичә—4/Х—якшәмбе көн бер хәрби частьтә очрашу булды. Кичә күңелле генә узды. Соңыннан оештыручылар белән бергә чәй янында сөйләшеп утырдык. Рус иптәшләрдән Василий Журавлев, Борис Дубровин килгәннәр иде.

**26/Х-64. Клязьма. Санаторий Верховного Сов. РСФСР «Клязьма».**

Фәүзия белән икәү 23/Х дә килеп төштек. Казаннан 20 ендә кич чыгып киткән идек. 21-22 ләрендә Москвада булдык. Фәүзиягә күлмәк заказать иттек, иртәгә аны примеркага алып барасы бар.

Фәүзия соңгы көннәрдә үзен бик начар хис итә иде. Минем белән бергә санаторийга килергә дә бик нык икеләнеп килде. Соңгы көнгә кадәр билет алмый йөрдек. Шул үт капчыгындагы ташы борчый (үзе шуннан күрә инде; башка берәр кизү эләгеп хәле начарланса да шунардан дип уйлый торгандыр инде). Мин аның ай-ваена карамаска тырыштым: Казанда калса ана тынычлык булмас, хуже булыр дип уйладым. Якыннарыбыз да шулай дип киңәш бирделәр, һәм дөрес тә булды, дип уйлыйм. Дөрес, ул монда да авыргалый, һәрхәлдә Казандагыдан яхшырак. Ичмасам, андагы кебек хәлсезләнеп ятмый. Йөри, ашый, эчә. Покой бар, диета бар. Эче авыртса, грелка куеп, йоклап ала да, тагын торып китә.

«Клязьма» дигән санаторийда мин беренче тапкыр. Бик бай санаторий түгел икән, тору бер корпуста, дәвалану—икенчедә, ашау-эчү—өченчедә, әледән-әле киенергә дә чишенергә туры килә.

Үземнең хәл ярыйсы. Соңгы айларда бик нык арганлык хис итә идем. Монда килгәннән бирле йокыдан айный алмыйм. Төнлә дә яхшы йоклыйм, көндез дә.

**9/XI-64. Клязьма.**

Килгәнебезгә 15 көн узып та киткән икән. 30 ында Верх. Сов. РСФСРның президиум утырышы булды. Шунда бардым. Фәүзия дә ул көнне Москвала үзенең хатын-кыз эшләре белән йөрде. Күлмәк тегәргә заказ биргән иде, шуның примеркасында булган, магазиннарда йөргән. Мин көне буена диярлек президиум утырышында булып, кайтышлый кәҗүнни машинага Фәүзияне утыртып алып кайтып киттем.

Санаторийга килер алдыннан 10 көн чамасы элек Ник. Гр-вич Игнатов янында булган идем. Соңгы елларда Татарстаннан тыш өлкәләрдә яшәүче татар авылларында (сүз берниндн рус белән аралашмаган татар авыллары турында бара) балаларны 1 нче класстан ук турыдан-туры рус телендә укытуга көчү күренешләре бар. Шул турыда мина зарланучылар булуы һәм үземнен дә мондый практиканы дөрес түгел дип санавым турында Игнатовка әйткән идем. Игнатов минем карашыма кушылды һәм бу эшне тикшереп, төзәтү чаралары билгеләүне В. Советның зав.отделом по вопросам советовка иптәш Старовойтов Ник. Георгиевичка тапшырган иде. Мин ана, Старовойтовка, үз исемемнән кыскача гына заявление язып, минем исемемә килгән материалларны да җибәргән идем (Х. Госман, К. Газый, И. Гыйльфанов үзләренә килгән хатларны, үзләре күргән фактларны язып биргәннәр иде). Президиум утырышы барган көнне Старовойтовны күреп сөйләштем (дөресе, ул үзе мине күреп сөйләште). Минем заявление буенча тикшерү-танышу эшләре башланган, чынлап та күп кенә урыннарда бу мәсьәлә буенча Ленин милли политикасын бозулар бар икән. Тиешле чара күрү турында Игнатов хат язып, диде. Афанасенконың (РСФСР мәгариф министры) бу турыда бер ялгыш приказы булган икән ди, шуны тапканнар. Чынлап та, бу ифрат вакытсыз әшәке күренешне төзәтү буенча бер файдалы нәтиҗәгә ирешеп булса, бик зур эш булыр иде. Старовойтов әйтте, Казанга киткәнче обязательно кереп белешеп чыгарсын, диде.

Мәскәүдә яшәүче татар эшчеләре арасында минем «Саф күңел» романы буенча укучылар конференциясе уздырырга теләүчеләр бар икән. 17 ноябрьдә уздырырбыз дип ризалык бирдем. Казанга кайтышлый тукталырбыз, дип уйлыйм.

Санаторийда ялны врач таләп иткән тәртиптә генә алып барып булмый. Һаман Москвага баргалап торырга туры килә.

Эчне пошыра, хәтта иманны какшата торган бер хәл: Москвада кешегә яшәү өчен кирәк шартлар артыгы белән тудырылган: азык-төлек, торак, транспорт, культура хезмәте күрсәтү мәсьәләләре. Ә шушыннан безнең Казанга кайтып карасаң—коточкыч контраст. Ит-май һаман юк, булса да базардан мең азап белән эзләп табу, чират тору өстенә, 3-4 хакын түләп алырга туры килә. Хәтта адәм рәтле эчемлек тә юк бит.

Ә Казан белән чагыштырганда—авыл шулай.

«Кем дисез бу фетнәле эшләр башы?», дигән сорауга соңгы вакытта җавап табылып тора: прожектер, самодур Хрущев, диләр. Ул кешене бик капыл һәм бик җиңел генә урыныннан алып ташладылар. 18 нче октябрьдә бугай ҮК КПССның пленумы булды, шунда аны, Сочида гамьсез генә ял итеп яткан җиреннән чакыртып кайтарганнар да, әйткәннәр: житте, отставкага китүне сорап заявление бир, юк исә алып ташлыйбыз дигәннәр. Бик күп кирәкмәс перестройкалар белән мавыгуы, соңгы ике ел эчендә коллектив белән исәпләшмичә, илнең язмышына бәйле катлаулы мәсьәләләрне үз башына гына хәл кылуы, тормышка ашмас хыяллар белән мавыгуы, илнең экономикасын, хуҗалык-идарә эшләрен чыгырыннан чыгаруы турында әйткәннәр.

Дөрес, булды, чорт попутал, дияргә мәҗбүр булган. Минемчә, бу хәл бик вакытлы һәм бик әйбәт булды. Юк исә, ул артык иркен кылана башлагач та, аның житәкчелегендә яшәү, ничектер, лихач шофер машинасына утырып бару кебек хәтәр иде. Ул сине коммунизмга алып барам, ди. Ләкин коммунизм юлының нинди катлаулы борылышлар, нинди текә үрләр белән тулы булуын исәпкә алмыйча, баш әйләндергеч дуамал тизлек белән очырта, кая, нинди кыяга китереп бәрә бу, яки нинди упкынга дип, жаныңны уч төбендә хис итеп барасың.

Ул авыл һәм шәһәр идарәләрен икегә аеру ни пычагыма кирәк иде? Ул 11 еллык

мәктәпләр, балаларны уку яшендә көчләп производствога җибәрүләр ни пычагыма кирәк иде? Шул үзгәрешләрне кертү өчен ничә миллиард халык акчасы әрәм ителде.

Икенче культка әйләнгән иде кеше. Дөнья каршында тагын бер тапкыр адәм көлкесенә калу алдына килеп баскан идек. Ярый әле, Үзәк Комитетта акыллы, көчле ихтыярлы, тәвәккәл кешеләр бар икән.

Октябрьнең 47 еллыгына багышланган тантаналы утырышта Брежнев ясаган доклад әйбәт. Тик шул нигездә һәр коммунист үзен ирләрчә батыр йөрәкле итеп тотса, уен, убеждениесын вакытында бернидән курыкмыйча әйтә алса бик яхшы булыр иде. Үземә бурыч куям: шулай булырга тырышырга кирәк. Шулай булырга мешайт итүче көч булса да (миндә дип әйтүем) куркаклык булмас, ялкаулык булыр, яки просто энергия җитмәү. Чөнки үз уйларыңны яшермичә әйтү өчен коры җүләр батырлык (ягъни тормышыңны яки положениеңны югалтудан курыкмау) кына түгел, аларны нигезләп әйтә белер өчен тырышлык, хезмәт сөю дә кирәк. Ә безгә хәзер үз уеңны (ягъни коммунист буларак) курыкмый, яшерми әйтү өчен зәмин бар, чөнки аны тыңлаучылар бар.

Тик менә бюрократларга, культсыз яки алласыз яшь алмаучы фанатик карьеристларга, подхалимнарга юл куймаска кирәк: иң куркыныч кешеләр, революциянең, коммунизмның башын ашаучылар булса, шулар булыр. Капиталистның, империалистның үзенең генә мона көче җитми хәзер.

Эх, язарга иде хәзер! Житди, рус әйтмешли, сногсшибательный әсәрләр язарга иде! Картайылмады микән? Үземә калса, әле яшьлегем җитәрлек кебек.

**20/XI-64. Казан.**

Клязьмадан кичә кайтып төштек. Кайтышлый Москвада бер кич кундык. Старовойтовның эш урынында чагын туры китерә алмадым. Моннан шалтыратып карарга кирәк булыр.

Казанга кайтып төшкәч, эшләрнең күплеген һәм ашыгычлыгын күреп, башларым әйләнеп китте. А. Гомәр больницада ята. Мостафинны отпускка җибәрдем. Ноябрьга билгеләнгән яшьләр семинары үткәрелмәгән. Нефть районнарына 3 бригада чыгарылырга тиеш.

Декабрьнең 17 сендә РСФСР Верх. Сов. сессиясе.

Январь башында съезд алды җыелышы.

Январьның 15 ендә Ш. Маннурга 60.

Февральдә РСФСР язучылары съезды. Ел азагы—хуҗалык һәм финанс эшләре... Әй, ник язып торам соң, вакыт әрәм итеп...

**14/XII-64. Москва. Гостиница «Москва». № 1063.**

Бүген килеп урнаштым. Бүген үк РСФСР Язучылары союзында автономияле республикалардан килгән язучылар вәкилләре катнашы белән съезд алды киңәшмәсе булды.

Соболев кереш сүз әйтте. Башкалар үз теләкләрен, фикерләрен чыгып әйттеләр. Мин дә сөйләдем. Издательство һәм комитет печати белән бәгълы буларак эчне пошырган хәлләр турында сөйләдем. Мәктәпләргә карата милли политикабызны бозу фактлары барлыгын әйттем. Чыгышымны хупладылар. Утырышта Комитет печати кешесе Карелин да булган икән. Ул минем тәнкыйтемә аңлатма бирергә тырышты. Соныннан мине комитетка килергә, бергәләп аңлашырга чакырды. Барырга кирәк булыр.

**16/XII-64. «Москва» гостиницасы. 1039 номерга күчтем.**

Кичә көнем «Сов. писатель» нәшриятында, аннары РСФСР Язучылар союзында үтте.

Нәшриятнын баш редакторы Карпова Валентина Михайловна белән сөйләштем. Без тәкъдим иткән әйберләрне бик игътибар белән кабул итәләр. Иң әһәмиятлесе—яхшы әсәрләр язу өстенә, аларны рус телендә чыгару өчен үзебезнең тарафтан да бик тынгысыз кеше булырга кирәк икән. Бүген мин Гослитиздатта, аннары «Сов. Россия» нәшриятында булдым. Һәркайсы белән сөйләшү шул нәтиҗәгә китерә.

Мин, председатель буларак, бу мәсьәләдә монарчы ничек эш итәргә кирәклеген анламаганмын икән. Хәзер эш бераз алга китәр дип уйлыйм.

**19/XII-64. «Москва». № 1039. Кич.**

17, 18 ендә 4 нче сессия булды. (Верх. Сов. РСФСР нын 6 нчы чакырылыш) Татарстаннан Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары Мартынов чыгыш ясады.

«План развития народного хозяйства в 1965 году» турында госплан начальнигы Герасимовның доклады һәм Бюджетның (63 нче ел) ничек үтәлеше һәм 65 нче елга ничек билгеләнүе турында Фадеев (министр финансов) доклады тынланды.

Бүген с. 1 гә кадәр президиум утырышында булдым.

Утырыш алдыннан РСФСР Министрлар Советы председателенең культура мәсьәләләре буенча урынбасары Кочемасов Вячеслав Иванович янында булдым. «Совет әдәбияты»нын штатын һәм хезмәт хакларын арттыру мәсьәләсе белән булдым. Язуыбызны алып калды, ЦК белән кинәшеп эшләнә бу эш, диде.

Издательство мәсьәләләре турында сөйләштем. Күп томлы әсәрләр һәм классикларны баса алмавыбыз турында әйттем.

Нигезләп, язып бирегез, диде.

Тукай премиясен янадан тергезү турында мәсьәлә күзгаттым. Правительствогыз исеменнән ходатайство кертегез, мин яклыйм, диде.

Татар мәктәпләрен административ төстә рус теленә күчерү фактлары турында Верх. Сов-ка биргән хатлар буенча язып җибәргәннәр. Мәсьәләне тикшерү өчен Мәгариф министрына биргәннәр (Афанасенкога), шуннан сон Совминда тикшерәчәкбез, диде. Ул да, бу эш ата-аналар соравы буенча эшләнә, димәкче. Мин әйттем, Татарстаннан читтә яшәүче авыллардагы татарлар үзләренен ана телләреннән бизгәннәр икән, бу әле аларнын коммунизмга үсеп житкәнлекләрен күрсәтми. Димәк ул жирләрдә ана теленә карата дискриминация бар, ана телендә бернинди культура чаралары да күрелми, дигән сүз дип анлаттым.

Карарбыз, тикшерербез, дип калды.

Үзенә «Чистая душа» китабымны бүләк иттем. Хуп күреп алды, рәхмәт әйтеп калды, мотлак укыйм, диде.

Бу көннәрдә шуны белдем: зуррак начальство тирәсендә ешрак булырга, республикабызнын культурасына кагылышлы мәсьәләләрне кыюрак куярга кирәк икән. Һәм безнең хәзер шундый кешеләребез юк диярлек икән.

⁕

Әзһәр
Шакиров

# ЯЗМЫШ ҺӘМ УЗМЫШ

(АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ)

Сезнең: “Нәрсә, Марсель Сәлимҗанов белән бер роль дә эшләмәденмени?”— дип әйтүегез ихтимал. Мин Марсельдә шактый күп рольләр уйнадым, ләкин алар минем өчен ниндидер зур, кызыклы ачышлар ясый торган образлар түгел иде. Аларны мин уйнаганнан спектакльнең язмышы хәл ителми иде. Гадәттә, мин Шәүкәт абый, Илшат Йомаголов артыннан уйнагач, минем эшләремә әллә ни игътибар да бирмиләр иде. Һәм, гомумән, икенче составтагы артистның эшенә хезмәттәшләре дә бәя биреп бетермиләр. Премьерада уйнау икенче составтагы артистка бик сирәк эләгә. Тукта әле, бу рольдә Әзһәр Шакиров та уйный бит дип, спектакльне бер караган кайсы тамашачы яңадан килеп карасын инде? Мондый хәл бик сирәк була. Шулай да А. Вампиловның татарчага “Булмас димә—дөнья бу” дип тәрҗемә ителгән әсәре нигезендә куелган спектакльдә—Колошин, Ю. Сафиуллинның “Идегәй” трагедиясендәге Туктамыш хан рольләрендә М. Сәлимҗанов Шәүкәт Биктимеровны түгел, ә бәлки мине күрсәтергә тырышты. Мондый хәл, әлбәттә, бик сирәк була. Режиссер, роль биргәндә үк, үзе өчен иң кирәкле артистларга таяна. Икенче составтагы артист тормышта төрле хәлләр килеп чыгуын истә тотып куела. Аннан соң безнең эш бит “производство”, ягъни үзенә күрә бер завод кебек инде. Һәр көнне спектакль күрсәтергә кирәк. Телисеңме, теләмисеңме, кайвакытта бер рольгә ике артистны билгеләргә туры килә. Шуңа күрә Марсель мине бик яратып, үзенең спектакленә икенче состав итеп алгандыр дип әйтә алмыйм, аны эш шулай эшләргә мәҗбүр итә иде. Мин уйнамасам да, аның спектакльләре гөрләп барды, театрыбызның иң зур уңышларыннан саналды. Уйлавымча, ул минем сәләтемә артык мохтаҗ түгел иде шикелле. Аның минем турыда ни гәҗиттә, ни радио-телевидениедә бер мәртәбә дә җылы сүз әйткәнен ишеткәнем, укыганым булмады. Ә соңгы елларында иптәшләрем хакында якты, тирән мәгънәле, онытылмаслык фикерләр әйтеп калдырды.

Хәер, мин ул куйган спектакльләрдә баш рольләрне уйнасам, бөек артист булыр идем. Уйнатмады бит дип, ана рәнҗи дә алмыйм. Иптәшләрем белән М. Сәлимҗанов турында сөйләшкәндә, алар миңа һәрвакыт: “Марсель сине яратты, роль артыннан роль бирде”,—дип, минем күңелемне күтәрергә, Марсель Хәкимовичка үзләренең хөрмәтләрен күрсәтергә телиләр. Әйдә, шулай булсын, читтән яхшырак күренә ул. Марсель Сәлимҗанов дүрт дистә елга якын театрның баш режиссеры булып торды. Ул театрны шул дәрәҗәгә күтәрде ки, без үзебезнең нинди театр икәнлегебезне Россиядә генә түгел, ә бәлки дөньяның шактый илләрендә дә таныттык. Моның өчен ничек инде аны хөрмәт белән искә алмаска мөмкин!

*Ургылып-ургылып агадыр кар суы,*
*Ник басылмый икән бу йөрәкнең ярсуы?*

Ләкин барыбер артистның чын талантын, эчке дөньясын, аның тамашачыга тәэсир итү көчен, серен аңлый торган, кирәк чакта шуны куллана белгән режиссер

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2006 ел, 11 санында.*

гына сина үз язмышын, спектакль язмышын тапшыра. Минем рухи дөньямны анлаган режиссерларның берсе Гали Хөсәенов булды. Бер вакытны ул эстон язучысы Э. Раннетның "Юлдан язган" әсәре буенча телеспектакль куйды. Мине дәшеп алып уйнатты. Беренче мәртәбә телевидениедә шундый зур эш эшләдем. Куанычымнан ана:

—Гали абый, мин бит фаҗигале язмышларны уйный торган талантлы артист,— дидем.

Әсәрнең исеме дә—"Юлдан язган" бит. Шуңа күрә Март Туйск роле эчке дөньямны ачарга бик нык ярдәм итте. Телевидениедә артистның кадрда ничек "яшәгәне" бөтен тирәнлеге белән күренә. Репетиция вакытында Гали абыйның күзеннән яшьләр ага. Бу мина шул кадәр ярдәм итте ки, әгәр дә мина шул вакытта "йөрәгенне алып бир", дисәләр, аны да кызганмас идем. Икебез дә елыйбыз. Тоткарланып торган җаным ачылып китте. Ничек уйнарга кирәклеген аңладым. Режиссерның артистны ничек аңлаганын, сина нинди зур ышаныч күрсәткәнен, синдә булган бөтен мөмкинлекләрне ачарга тырышканын беренче тапкыр күрдем. Гали абый Хөсәенов Әлмәт татар дәүләт драма театрында баш режиссер булып эшләгәндә "Юлдан язган" спектаклен яңадан куйды да, мине чакырып, Март Туйск ролендә уйнатты. Әлбәттә, ул театрда эшләсәм, минем язмышым бөтенләй бүтәнчә булыр иде. Әйтергә кирәк, Гали Хөсәенов Әлмәт театрын заманасы өчен бик югары баскычка күтәрде. Казандагы гастрольләре зур уңыш белән үтте. Без артистларның иҗат осталыклары үскәнен күреп, чын күнелдән сокланып, сөенеп карадык. Мондый режиссерны—сәнгатьне изге эш итеп караган кешене ничек сагынып искә алмыйсың!

*Чумдым тирән уйларга,*
*Баскычлар юк чыгарга:*
*Гомеремнең очын эзлим*
*Кулларыма урарга.*

*Ф. Яруллин.*

Артистны кеше дип әйтеп буламы? Әлбәттә, юк. Шуңа күрә артист бит инде ул—Кеше түгел. Артистлар алар балалар, ләкин "kahәр суккан" балалар дип әйтәләр бит. Әгәр дә ул режиссерның гаделсезлеген күрсә, театрны, эшләгән эшен яратмый башлый. Директор һәм режиссер белән көрәшергә аның көче житми, берданбер юл—театрдан китү. Минем дә андый чакларым булмады түгел, тик татар академия театрын ташлап кая барасың? Әлмәт белән Минзәләгәме? Марсель Сәлимжановның мина: "Эшенне эшлә, артынны кысып, тик кенә тор, юкны сөйләп йөрмә",—дип әйткәне бар иде. Мин моны урысчадан тәржемә итәм, урысча бик яхшы янгырый. Ә театрны ташлап китү татар артистына гаиләсен ташлап китү белән бер. Безне үзенне түгел, сәнгатьне яратырга өйрәттеләр бит. Син үзең беркем дә түгел, ә минә эшләгән эшең—бөек.

Без яшь чакта артистның талантлы булуын нинди рольләр уйнавына карап кына түгел, ә бәлки мактаулы исеменә, дәрәҗәсенә карап бәялиләр иде. Исеме юк икән, бу талантлы артист дип кабул итмиләр, хезмәт хакы да шуннан билгеләнә. Шуңа күрә исем алу артистның төп максатына әверелде. Шуның өчен партиягә керделәр, җәмәгать эшләрендә актив катнашырга тырыштылар. Исем биргәндә болар кайвакыт хәлиткеч роль уйнады. Сорыйлар иде: "Ул коммунистмы? Җәмәгать эшләре алып барамы? Партиягә, совет дәүләтенә карашы нинди?"

Исемә төште: Мәскәүдә партия Үзәк Комитетындагы чыгышымнан соң минем белән тагын шундыйрак хәл булып алды. Театрда марксизм-ленинизм тәгълиматы турында дәресләр бара. Шунда мина чыгыш ясарга туры килде. Мин:

—Америкада өч йөз мең фермер эшли, алар 300 миллион чамасындагы халыкны туендырып тора. Шуның өстәвенә 500 миллионга якын бүтән халыкларны ашатып-эчертеп тора,—дип, бик ялкынлы чыгыш ясап, алеге фермерларны мактадым. Мин әйтәм:—Бездә 1 миллион 200 меңнән артык колхоз бар, ә ашарга икмәкне чит илләрдән сатып алабыз!—дип, илнең авыл хуҗалыгында артта калуын бик ачынып сөйләдем.

Бу вакыйгадан бераз вакытлар узгач, М. Сәлимжанов репетициягә килеп керде дә мина ташланды:

—Мин әле генә шәһәр партконференциясендә булдым. Безнең театрда партиягә, совет дәүләтенә каршы бер оешма эшли. Башында артист Шакиров тора. Аның иярчене—Әюпов! Сезнең аркада мине бөтен партактив каршында мыскыл итеп сүктеләр. Синең аркада театрның нинди дәрәжәгә төшкәнен ничек аңламыйсың, мин һәрвакыт синең аркада җәфа чигәм!

Шулай итеп, жан ачуы белән бик каты сүкте дә, гомердә дә онытылмаслык итеп кисәтте бу. Ярый әле театрның директоры Әзһәр Хөсәенов белән партбюро секретаре Шәүкәт абый Биктимеров партконференциядә чыгыш ясап, андый хәлнең безнең театрда булуы мөмкин түгел, дип яклап чыкканнар. Икенче көнне Гәүһәр апа Камалова миңа әйтә:

—Райком исеменә "объяснителни записка" яз. Театрда партиягә, совет властена каршы бернинди оешма да юк, бөтен гаепне үз өстемә алам диген...

Мин райком исеменә бик зур үтенеч язып, Гәүһәр апа кушканча эшләдем. Наил Әюпов миңа караганда көчлерәк булып чыкты: анардан да яздырып кул куйдырмакчылар иде. "Пошли вы туда!.."—дип, партбюрога кереп тә тормады.

(Минем өстән ул шикаятьне кем язган икән дип, байтак уйландым. Соңыннан белдем-белүен, кәгазьләре дә бар. Тик хәзер исә, исемнәрен фаш итеп, ваклаңып торасым килми инде.)

Шулай да болар ни өчен искә килеп төште соң әле? Әлбәттә, әлеге вакыйганың үсә торган, дәрәжәле исемнәр алырга җыенган баш режиссер язмышына зур зыян китерүе бар иде. Әйтүе генә җиңел! Хәзер дә, ул заманда да театр өчен бөтен жаваплылык баш режиссер җилкәсенә төшә. Марсель миңа сабакны шуңа күрә нык укытты, гомергә онытылмаслык итеп. Кабатлап әйтәм, кешенең характеры—аның язмышы ул. Артист бәхете күбәләк кебек бит: ул артист артыннан очып йөрми, без аның артыннан чабарга мәҗбүрбез. Инглизләр әйтә: "Не будь так скромен—ты еще не настолько велик!"

Минем өчен истәлекле тагын бер зур вакыйга хәтеремә онытылмаслык булып сеңеп калган. РСФСРның халык артисты исеме бирергә җыендылар. Театрыбыз директоры Шамил Зиннурович Закиров миңа тиешле кәгазьләрне тутыртты. Икенче көнне Марсель Сәлимжанов:

—Иртәгә җыелыш үткәрәбез. Сиңа исем бирергәме-юкмы икәнен коллектив хәл итәчәк,—диде.

Төне буена йокламыйча уйландым: артистка исемне ничек инде җыелышка куеп бирсеннәр ди? Минем мондый хәлне ишеткәнем дә, күргәнем дә булмады. Иртәгә театрга керергәме, кермәскәме дип, күз дә йоммыйча җәфаланып чыктым.

Менә җыелыш башланып китте.

Марсель Сәлимжанов әйтә:

—Иптәшләр, Шакировны званиегә тәкъдим итәләр. Аны бүген сез хәл итәргә тиеш, лаеклымы ул шул исемгә, әллә юкмы? Хәзер демократия заманы, житәкчеләрне дә коллектив сайлый. Тартынмагыз, тәкъдимнәрегезне әйтегез!

Артистлар берәм-берәм торып, мине якладылар, минем турыда җылы сүзләр әйттеләр. Марсель Хәкимович бәлкем моны болай ук көтмәгәндер дә. Артист Шакиров ул исемгә лаек дип, барысы да бердәм рәвештә кулларын күтәрделәр.

Җыелыштан әкрен генә, башымны иеп чыгып киттем. Сез минем хәлемне аңлыйсыздыр, күз алдыгызга китерәсездер. Түзмәдем, театрга кире кердем, Марсельне эзләп таптым:

—Берәр артистка исем биргәндә син аны җыелышка куйдыңмы? Артистларга исемне җыелышка куеп бирмиләр! Мондый гаделсезлекне күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Әгәр коллектив каршы килгән булса? Юк, мондый гаделсез кешеләр булмый,—дип, бик рәнжеп әйттем.

Сүз дә юк, минем өчен академия театры артистлары мәрхәмәтле, кешелекле булдылар, мин моны гомеремдә дә онытмаячакмын. Артистларның миңа булган хөрмәте, ярдәме беренче мәртәбә генә түгел. Г. Тукай бүләгенә тәкъдим иткәндә дә житәкчебез түгел, ә алар күтәреп чыктылар. Аларның киң күңелле, мәрхәмәтле

булуына ничек сөенмисең! Әйе, бергә эшләгән иптәшләреңнең хөрмәте—иң зур бәхет! Картлык шундый әйбер ул: син тормышны һаман яратасың, ә ул инде—юк. Тормышка җинел карарга кирәк дип, тикмәгә генә әйтмиләр ич. Бергә көлгән, шаярган кешене онытырга мөмкин, ә синең белән бергә утырып елаган кешене гомергә оныта алмыйсың. Шулай инде, эшли белгәннәр эшли, белмәгәне өйрәтә. Үз акылың булмаса, кешенеке белән яшәп булмый.

*Ә мин Ходайга ялварам: – Бир канат!*
*Бир көч, Тәңрем – кул болгарга соң кабат...*
*Р.Гаташ.*

Рәхмәт инде Ходай Тәгаләгә: Гали абый Хөсәенов телевидениедән китеп баргач, андагы баш режиссер Әхтәм Зарипов белән уртак тел табып, театрда уйналмаган рольләрне телевидениедә эшләргә туры килде. Ул вакытта Бразилия сериаллары юк, бөтен халык татар телевидениесен карый. Театрда ала алмаган дан-шөһрәтне бер көндә казанасың, чөнки сине берьюлы меңнәрчә тамашачы карый иде. Популяр артист менә шунда туа инде ул. Иптәшләремне урамда танымаган кеше юк! Безне һәркем белә! Артист өчен бу да куанычлы бәхет. Телевидениедә шундый эшләр була: менә инде ничәмә-ничә еллар узган, ә телеспектакльләрнең кайберләре әле дә рухи кыйммәтләрен, сыйфатларын югалтып бетермәгәннәр. Күр инде, нинди әсәрләр эшләнгән дип, еш кына сөенеп тә куясың. Әйе, әгәр җаныңны биреп эшләсәң, чын хезмәт барыбер тиз генә юкка чыкмый.

Минем бер бәхетсезлегем бар: мин сәнгатьтә гаделлек эзләдем, ә тормышта булмаган гаделлек театрга каян килсен? Аннан соң бит әле ул мин аңлаган, мин күргән, мин бәя биргән гаделлек. Бәлки мин үз эшләремә ихлас, риясыз бәя бирә алмый да торганмындыр. Гадәттә без үз-үзебезне һәрвакыт яхшы итеп күрсәтергә тырышабыз. Бу хәл миңа да кагыла. Әйткәнемчә, тормыш—тормыш инде; тормыш—ананны ормыш диләр ич.

Ә шулай да мин бергә укыган иптәшләрем белән һәрвакыт чын күңелемнән горурландым. Алар 50 елга якын академия театры сәхнәсен үз кулларында тоттылар, алардан башка татар театрының 100 еллыгын күз алдына китерүе мөмкин дә түгел.

*Бәхетне бит була табып кына,*
*Биреп булмый әҗәткә.*
*И.Гыйләҗев.*

Артист вакытында туарга, вакытында үләргә тиеш. Әгәр халык күңеленә якты йолдыз булып кереп каласы килсә. Кайвакыт шулай була: артист озак еллар сәхнәдән төшмичә уйнап килә. Ләкин син аны күргәч, бик кызганып куясың: нишләп инде сәхнәдә интегеп йөри, үзенең дәрәҗәсен төшереп?

Моның мәгънәсе нәрсәдә соң? Күрәсең, сәхнәдә һәр артистның үз вакыты бар. Аның шундыйлары була: картаеп, авырып, тормышта көчкә генә атлап йөриләр. Ә менә сәхнәгә чыккач, бөтенләй икенче кешегә әйләнәләр. Аларның уйнаганын каравы күңелгә чиксез рәхәтлек бирә, җаның тынычлана. Кара инде, нинди талантлы артист бит, дип сөенеп куясың, аның картлыгы да, авыруы да онытыла. Мондыйлар гаять сирәк була шул.

Артистның гомере зур рольләр көтеп уза. Нәкъ балыкчы кебек. Шуңа күрә ул үз гомеренең узып киткәнлеген сизмичә дә кала. Миндә нибары: "Бернәрсә дә эшли алмадым",—дигән тойгы гына калды.

*Ахыры киләсе санда*

# «ТӘРБИЯИ ӘТФАЛЬ» ЖУРНАЛЫНА ЙӨЗ ЕЛ

«Тәрбияи әтфаль» (балалар тәрбиясе) татар балаларына ан-мәгълүмат биреп, милли рухта тәрбияләү максатында чыккан беренче балалар журналы.

Бу журнал 1907 елда Мәскәү шәһәрендә Мөхәммәтзаһид Шамил мөхәррирлеге һәм наширлегендә, Фатыйх Әмирхан сәркятиблегендә чыккан. Кызганыч ки, «сабак балаларына махсус әдәби, фәнни вә рәсемле» журналның биш саны гына дөнья күреп калган.



Мәшһүр дагыстанлы Шамилнең оныгы Заһид Шамил (1868–1920) белән Фатыйх Әмирхан 1906 елның гыйнвар аенда Петербургта уздырылган Бөтенрусия мөселманнары съездында очрашалар. З.Шамил үзенең журнал чыгару нияте барлыгын белдереп, Ф.Әмирханны журналда эшләргә чакыра. Яшь Фатыйх бу чакыруны теләп кабул итә һәм 1906 елның октябрендә Мәскәүгә барып урнаша. Журналның беренче санын декабрь аенда чыгару ниятләнсә дә, ул 1907 елның 1 гыйнварында дөнья күрә.

«Тәрбияи әтфаль» журналының мәсләге һәм эчтәлегеннән Фатыйх Әмирхан рухы ачыктан-ачык сизелеп тора. Шулай ук мәкалә-язмаларның да күбесе аның каләменнән чыккан.

Беренче санындагы баш мәкаләдән журналның максат-ниятләре күзаллана: «...Мәктәп, мәктәп вә мәктәп—бу заманыбызның иң әүвәлге вә иң зарур ихтыяҗыдыр. Китаплар, китаплар вә китаплар—бу мөмкин кадәр җитди вә тиешенчә ачылырга кирәк мәсьәләнең икенчеседер. ...Бармы бездә балалар әдәбияты, хәтта гомумән нинди дә булса әдәбият? Менә, балаларның бу хаклы таләпләреннән бер кыйсемене генә булса да үтәмәк—безнең мәҗәлләмезнең (журналыбызның) вазыйфасы... Без ата-аналарга ярдәмче вә балаларга мөгаллим вә остаз гына түгел, бәлки аларның яхшы иптәшләре булырга телимез... Без укучыларымызны мәдәниятле халыкларның әдәбияты белән белешләндерү, тарих вә хәзерге заман хәлләре белән таныштыру, табигыять хакында мәгълүмат бирү...» һ.б. Шул рәвешчә, «Тәрбияи әтфаль» журналы гыйлем таратуны, татар балаларының мәгълүмат офыкларын киңәйтүне төп максат итеп куя һәм ан-белемнең карангылык-наданлыкка каршы көрәштә кайчан да булса җиңәчәгенә ышана.

Милли мәгариф өлкәсендә зур хезмәт куйган Исмәгыйль Гаспралы, Галимҗан Баруди кебек күренекле затлар турында журналда язмалар дөнья күргән, шул чорда бөтен татар-мөселман дөньясында шөһрәт казанган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең тарихы һәм эшчәнлеге тәфсилләп яктыртылган. Русия татарларының уку-укыту хәлләре белән бергә чит илләрдәге мәгариф эшләренең торышыннан да мисаллар китерелгән.

«Тәрбияи әтфаль»дә әдәби әсәрләргә дә зур әһәмият бирелгән. Анда Андерсеннан Ф.Әмирхан тәрҗемә иткән «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» әкияте, Нәҗип Думавыйның балалар өчен шигырьләре һ.б. дөнья күргән. Каләм ияләреннән мәшһүр Гаяз

Исхакый, Галимәтелбәнат Сөләйманияләрнен тормышлары һәм иҗатларын тасвирлаган мәкаләләр, күренекле затлардан Әхмәт бай Хөсәенов, галим Д.И.Менделеев, Кавказ каһарманы Шамил, госманлы дәүләтен нигезләгән солтан Госман хан хакындагы язмалар бирелгән.

Русиянең шул чактагы иҗтимагый-сәяси хәлләре, Дәүләт Думасы, халык вәкилләре-депутатлар турындагы язмалар да журналнын игътибар үзәгендә булган. «Тәрбияи әтфаль» битләрендә даими рәвештә аерым шәһәрләрнең (Петербург, Мәскәү, Истанбул, Мәккә, Мәдинә) тарихи, географик, сәяси һәм икътисади хәлләрен яктырткан мәкаләләр дә дөнья күргән, һәр санында төрле фәннәрдән башлангыч мәгълүмат, тәҗрибә-фокуслар, башваткычлар биреп бару да журналнын эчтәлеген баеткан.

Материалларнын күпчелеге укучы балаларга адресланса да, ул балалар журналы кысаларында гына калмыйча, тормышнын төрле: иҗтимагый-сәяси һ.б. мәсьәләләренә кагыла. Мәктәп яшендәге балалар кабул итү өчен катлаулырак, авыррак өслүбтә язылганнары да бар. Хәлбуки, журналның «ата-аналарга ярдәмче булырга» теләген искә алганда, бу кытыршылыклар аңлашыла. Шулай ук ул елларда татар вакытлы матбугатынын әле яшь һәм беренче адымнарын гына ясаган чоры икәнен онытмаска кирәк.

«Тәрбияи әтфаль» журналы XX гасыр башында чыккан татар тәрбия-тәгълим журналлары арасында эшләнеше-бизәлеше ягыннан беренче урынны били. Ул үз чорынын фотосурәтләргә ин бай журналларыннан. Биш кенә сан чыгып калган «Тәрбияи әтфаль» журналында яхшы сыйфатлы 50 фоторәсем басылган. Гомумән, 1917 елга кадәр чыккан башка педагогик журналлар белән чагыштырганда, «Тәрбияи әтфаль» тематик яктан баерак, аның колачлау офыгы да киңрәк.

Журнал чыгунын тоткарлануын аңлатып «Тәрбияи әтфаль» идарәсе үзенең укучыларына башка газеталар аша матбагадагы тоткарлыклар сәбәпле 6, 7, 8 саннары хәзерләнгән булса да, чыга алмый торуын хәбәр иткән. Ләкин журнал 5 нче санынннан соң бүтән чыкмаган.

Кыска вакыт эчендә укучылар тарафыннан шактый яратылып өлгергән бу мавыктыргыч журналның кинәт туктавын укучылар авыр кабул иткән. Бу уңайдан ачынган Габдулла Тукайның да «Тәрбияи әтфаль» дигән махсус шигыре дә мәгълүм.

«Тәрбияи әтфаль»нең тулы эчтәлеге тасвирланган белешмә, башка педагогик журналларның библиографик күрсәткечләре белән берлектә, 1997 елда басылып чыкты.

**Раиф МӘРДАНОВ**

---

# «УРАЛ» ГАЗЕТАСЫНА 100 ЕЛ

1907 елның 4 гыйнварында татар телендә социал-демократик «Урал» газетасының беренче саны чыккан.

«Ачык татар телендә, атнасына 2-3 мәртәбә чыга торган, шәһәр һәм авыл җирендәге эшчеләрнең файдасын күзәтүне үзенә мәсләк иткән» бу газета Оренбург шәһәрендә нәшер ителгән. Аның рәсми мөхәррире Хәдичә Ямашева, наширләре— Тимерша Соловьев һәм Гомәр Терегулов булганнар.

«Урал» газетасы шул ук елның 27 апрелендә 31 нче саны басылгач хөкүмәт тарафыннан туктатылган.

Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә чыккан һәм аның эшчәнлеге белән тыгыз бәйле, татар телендәге большевистик басма сүзнең башлангычы буларак, «Урал» газетасы совет чорында иң әтрафлы өйрәнелгән матбугат органы.

Илдар
Хәйруллин

# ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

## Үз кеше

Эштән кайтып килешли Закирҗанны кечкенә генә бер эт тешләде. Эт димәсәң, хәтере калыр, бияләй хәтле генә чәнгелдек бер нәрсә инде шунда. Чеметеп алган кебек кенә бу тешләүгә Закирҗан игътибар итмәде. Әмма иртән гөбедәй шешеп чыккан балтырын күргәч, шүрли калды.

—Хәзер үк бүлнискә йөгер!—диде ана, пошаманга төшкән хатыны.

Кичен кунакка барасын исендә тоткан Закирҗан нәкъ шулай эшләде дә.

...Чакырылган җиргә парлашып килеп кергәндә мәҗлес әле башланып кына килә иде. Кунаклар башта, гадәт буенча, хөкүмәтне сүгеп алдылар. Бераз «пар» чыгаргач, ирләр әкренләп машина, бензин бәяләренә, хатын-кызлар яраткан сериалларга күчте. Шулай матур гына күңел ачканда кемдер Закирҗанның бөтенләй эчми утыруын шәйләп алды.

—Син нәрсә, Закирҗан,—диде табын хуҗасы тавышын калынайта төшеп.—Ураза тотмыйсындыр бит? Давай, кеше кәефен бозып утырма монда, тот рюмкаңны!

Бөтен күзләрнең үзенә текәлгәнен күргәч, Закирҗан читенсенеп китте, аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.

—Ни бит, ярамый,—диде ул, уңайсызлануыннан урындыгында боргаланып.

—Әкият сатма! Ничек инде ул ярамый? Миндә кан басымы, бәҗәйнең, әнә, язва—ярамый дип тормыйбыз. Рас җыелганбыз икән, эчәбез!

Моңа кадәрле мәҗлесләрдә кыстаганны да көтеп тормыйча шайтан суын ялт итеп каплап куя торган Закирҗанның бу юлы фәрештәгә төнеп утыруы шактый гына кызып өлгергән кунакларга бер дә ошамады. Колактан-колакка чыш-пыш китте:

—Без аракы эчәбез, ә ул мыек астыннан мыскыллап көлеп утыра,—диде берсе, кашын-күзен җыерып.

—Эчүен ташлап, машинага акча җыймакчыдыр ул,—диде икенчесе, тешләрен шыгырдатып.

—Юк, юк, алай түгел, кәттиж салырга йөри ул,—диде өченчесе, күзләреннән хәтәр очкыннар чәчеп.

—Пычагым да белмисез! Ана кәттиж дә, машина да кирәкми, акча җыеп, яшь хатынга өйләнмәкче ул,—диде дүртенчесе, астыртын елмаеп.

Соңгы сүзгә Закирҗанның хатыны чыдамады.

—Эч тизрәк, бирән!—диде ул терсәге белән иренең кабыргасына төртеп.

—Кем чакырган аны?—дип нәфрәтләнде бер исерек тавыш.—Чыгып китсен! Утырмыйбыз аның белән!

Ахыр чиктә Закирҗан тамагына утырган төерен көч-хәл белән йотып җибәрде дә, түземлеге бетеп, сикереп торды.

—Их, сез! Урамда эт тешләгәч врач уколдан соң кырык көн аракы эчәргә ярамый дип әйтмәгән булса, утырыр идемме соң мин сезнең алда күз көеге булып, сезнең авыз чайкаганыгызга түзеп?!

Шунда ук барысына да ничектер рәхәт булып китте. Чырае ачылган хуҗа

кунакларын үтереп кыстый башлады. Мәҗлес әле генә игътибар үзәгендә булган Закиржанны бөтенләй онытты. Шулай да салмыш күршесе, күз кысып:

—Маладис, безнең кеше икәнсең!—дип, аркасыннан кагып куйды.

## Шәһәр һәм авыл эротикасы

Шәһәргә бәрәңге сатарга баргач, Ногман гомерендә беренче тапкыр тере эротика күрде. Бик ялварып сорагач, шәһәрдә яшәүче авылдашы ресторанга алып барган иде, шунда күрде ул бу оятсызлыкны. Дөрес, Ногманның аның ишене видиктан да караганы бар иде. Әмма түшәмгә үрелгән колга тирәсендә бөтерелүче озын сыйраклы сары чәчбинең күз алдында чишенүен карап утыруы икенче төрлерәк икән. Ногман хәтта аның чишенгәндә дәртләнеп мышнавына тикле ишетеп торды.

Кинәт аның күз алдына авылда акча көтеп калган хатыны Фирүзә килеп басты. Менә ул зур галушларын лаштыр-лоштыр өстерәп, лапас тәрәзәсеннән бакча якка тирес атып ята. «Дөрес яшәмибез без»,—дип уйлады, күңеле нечкәреп, кәефе кырылган Ногман, алдындагы фужерга мөлдерәмә тутырып аракы салганда. «Нәрсә дөрес түгел?»—дип сорасаң, ул, мөгаен, моны аңлатып бирә алмаган булыр иде. Хәер, нәрсә аңлатып торырга? Дөрес түгел—вчү!

Иртән авылга кайтып яхшылап чутлагач, бәрәңге акчасының шактый юкарган булуы ачыкланды.

—Шәһәрдә бәрәңге арзан,—дип акланды Ногман күзен дә йоммыйча.

—Әкият сатма! Әнә кеше ирләре меңәрләп эшли, син генә күзеңне тондырып йөргәч тә...

Хатыны тарафыннан мондый кырыслыкны көтмәгән ир авыр сулап куйды. Кичен йокларга яткач ул нидер өметләнеп, Фирүзәсенә елышты.

—Кит, оятсыз! Синнән сасы адикалун исе килә,—дип, Фирүзә стенага борылып ятты. Әмма шәһәрдә эротика күреп кайткан ирнен бирешергә исәбе юк иде. Ногманның кулы әкрен генә хатынының шәрә җилкәсе тирәсенә шуышты. Фирүзә бер селтәүдә иренең йонлы кулын читкәрәк алып ыргытты.

—Карале, әй! Ничәмә көн шәһәрдә типтереп йөргәч хатын кирәк булган мона! Акча белән кайтса әле бер хәл иде. Малайның Сабантуйга кроссовка, кызның туфли сораганын белми...

Мондый каршылыкны көтмәгән Ногман, үпкәләп, тынып калды. Бер кызган шәптән Фирүзәсе әйтәсен әйтеп калырга ашыкты:

—Аракы чөмерергә булдыра, үзе сыерны үгезгә алып барырга кирәклеген дә оныткан. Кысыр калса газга, утка каян алып түләрбез?..

Хатынның йомшак беләген сыйпый башлаган Ногман ачуыннан тешләрен шыгырдатты.


—Башында бер генә уй! Кешедән оят! Капка баганасы урам якка кыйшайган, өй түбәсе буялмаган, мунча ишелергә тора, лапас эче тирескә баткан...

Хатынының чәпчүенә чыдар әмәле калмаган Ногман ыңгырашып торып утырды. Аннан сикереп торды да җәһәт кенә киенеп ишегалдына атылды.

Шабыр тиргә батып лапастан тирес атканда ул үгез сораган сыерны, хөкүмәтне, бурычын түли алмыйча таркалган колхозның рәисен, кыйшайган капка баганасын, ишелергә торган мунчаны аты юлы белән сүгеп, сәнәк очына элеп чөйде. Арып-талып өйгә кергәндә рәтләп өстенә дә япмаган Фирүзә мыш-мыш килеп, таралып йоклап ята иде. Ногман тиз генә юрган астына чумды. Аның кытыршы кулларыннан килгән таныш тирес исен сизеп, Фирүзә иренең янагыннан чупылдатып үбеп алды. Ногманга рәхәт иде...

## Фәрит Бәширов

Бәширов Фәрит Кәрим улы 1958 елның 30 ноябрендә Арча районы Шекә авылында туган. Башта үз авылында сигезьеллык мәктәптә, аннары Шушмабаш урта мәктәбендә белем ала.



1976—1981 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый. Аннары СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында аспирантура уза. 1989 елда Гали Халит җитәкчелегендә «Яңа заман татар романы формалашу (XIX йөз ахыры—XX йөз башы)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 2002 елда «XX йөз башы татар прозасының үсеш этаплары» дигән темага диссертация яклап филология фәннәре докторы дигән дәрәҗәгә ия була.

1984—2003 елларда Татарстан Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлегендә кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли. 2003 елдан Татарстан китап нәшриятында бүлек мөдире, соңрак «Матбугат йорты» нәшриятында редактор вазыйфаларын башкара. Республикада чыга торган газета-журналларда фәнни, тәнкыйди мәкаләләр, язмалар белән даими чыгышлар ясый.

Иҗат эшен төп ике юнәлештә алып бара. Беренче тармак—әдәбият фәне өлкәсе: әдәбият тарихы, әдәби процесс, XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX гасырда прозаның үсеш этаплары, классик әдипләрнең иҗат портретлары; икенче тармак әдәби тәнкыйть өлкәсе: бүгенге әдәби-мәдәни хәрәкәт, әдәби жанрларның торышы, заман язучысының иҗат үзенчәлеге. Нәтиҗәдә ике китабы дөнья күрә: «Сөйлә, каләм! (Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр)» Казан, 2001; «XX йөз башы татар прозасы»—Казан, 2002.

1988 елда Дубултыда (Латвия Республикасы) уздырылган Бөтенроссия тәнкыйтьчеләр семинарында катнаша.

Әдәби мирасны укучыга кайтаруга үзеннән өлеш кертә. Башлыча, Г. Ибраһимовның «Адәмнәр», С. Сүнчәләйнен «Күл—күз яше» исемле әсәрләре шундыйлардан. 80 нән артык фәнни хезмәт авторы.

2006 елны Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар: Ф.М. Мусин, М.Х. Вәлиев, Р.Ф. Харрасова) Язучылар берлеге идарәсе Бәширов Фәрит Кәрим улын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

❋

## Галимҗан Гыйльмановка 50 яшь

Язучы, галим Гыйльманов Галимҗан Хәмитҗан улы 1957 елнын 1 февралендә Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылында туа. Мәшһүр шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895—1919) туып-үскән авылда яшәү, белем алу булачак язучынын алдагы язмышында хәлиткеч рольләрнең берсен уйный. Мәктәптә укыганда ук ул әдәби иҗатка тартыла, беренче шигырьләрен, хикәяләрен яза, аларны район газетасында бастыра.



1974 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Г. Гыйльманов Казан университетынын татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, аннары татар әдәбияты кафедрасы каршында аспирантурада укый.

1986 елда Г. Гыйльманов Татарстан китап нәшриятына эшкә керә, матур әдәбият редакциясендә, сонрак балалар-яшүсмерләр редакциясендә редактор, өлкән редактор һәм редакция мөдире вазифаларын башкара.

1999 елда Татарстан Язучылар берлегенен XIII корылтаенда Г. Гыйльманов берлек идарәсенә сайлана, берлекнен рәисе урынбасары итеп билгеләнә һәм 2005 елга кадәр шунда эшли.

Хәзерге көндә ул—ТР Министрлар Кабинеты Аппаратынын Мәдәният һәм ТР халыклары телләрен үстерү бүлеге баш киңәшчесе.

Г. Гыйльмановның башлангыч чор иҗат эшчәнлеге, нигездә, әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть белән бәйле. Ул әдәбият белеменен поэтика, жанр, стиль мәсьәләләрен, баллада жанрын өйрәнүгә күп көч куя. Нәтиҗәдә, яшь галимнен рус телендә «Татарская баллада» (1989) исемле монографиясе һәм Ш.Бабичнын төп әсәрләрен эченә алган бер томлыгы дөнья күрә.

Үткән гасырның сиксәненче елларында ук әдәбиятнын төрле жанрларында көчен сынап караган, беренче хикәя-повестьларын язган Г. Гыйльманов 1994 елда үзенен «Тозлы янгыр» исемле беренче проза китабын бастырып чыгара. Аннары анын «Албастылар» (1999), «Оча торган кешеләр» (2000) исемле күләмле әсәрләре дөнья күрә.

Г. Гыйльманов балалар өчен дә яза. 1995 елда анын «Гөрләвек—Ручеек» исемле китабы дөнья күрә. Аннан сон «Йөгерек гөрләвек» (1998), «Әбием сихерче бугай» (1999) исемле китаплары басыла. Бер үк вакытта халык театрлары, мәктәп драма түгәрәкләре, театр студияләре тарафыннан куелган күп кенә әсәрләрен яза.

Г. Гыйльманов озак еллар дәвамында татар халкынын борынгы мифларын, риваять-легендаларын, им-томнарын, юрамышларын барлау һәм җыю, ияләр-рухлар дөньясын, тәңречелек тәгълиматын өйрәнү юлында гыйльми эзләнүләрен дәвам иттерә. Шунын нәтиҗәсе булып 1996 һәм 1998 елларда «Татар мифлары» исемле ике томлык дөнья күрә.

Галимҗан Гыйльманов—Татарстан Республикасынын атказанган сәнгать эшлеклесе (2003), Язучылар берлегенен Абдулла Алиш исемендәге премиясе лауреаты (2002). 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

***Редакциядән: юбилее уңаеннан каламдәшебезне ихластан котлыйбыз, аңа саулык, яңа иҗат уңышлары телибез!***



Ибраһим Гази (уңда) һәм «Моабит дәфтәре» фильмында Муса Җәлил ролен уйнаган артист Михаил Чернов. 1969 ел.



Чыңгыз Айтматов һәм Шәмси Хамматов. 1972 ел.



Шагыйрьләр (сулдан уңга): Рәфикъ Юныс, Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гаташ. 2005 ел.



*Олуг әдипләр: Хәсән Туфан, Мостай Кәрим, Гомәр Бәширов. 1966 ел.*



*Шагыйрь Әнгам Атнабаев (1928-1999). Үткән гасырның 80 нче елларында алынган рәсем.*



*Бакый Урманче дирижер Фуат Мансуровның рәсемен ясый. 1989 ел.*

## МӘСКӘҮ ТУКАЙНЫ АЛКЫШЛАДЫ

15 декабрьдә Мәскәүнең Кече дәүләт академия театрында Г. Тукайның 120 еллыгына багышланган зур тантана булды.

Анда Президент М. Шәймиев чыгыш ясады. «Еллар үткән саен шагыйрь иҗатында яшь вакытта игътибар итеп бетермәгән төсмерләрне ачасың. Кайбер шигырьләрен күптән яттан беләсең, әмма аларда һаман саен сүзнең колач житмәстәй тирәнлеген тоясың. Бөек татар шагыйренең әсәрләре үзләренең әһәмиятен күп еллар дәвамында югалтмый»,—диде Президент. М. Шәймиев Г. Тукайның тәрҗемәи хәлен дә искә төшереп үтте. Ул шагыйрьнең балачагы узган Кушлавыч һәм Кырлай авылларын, шулай ук Җаек шәһәрен телгә алды. Казакъстандагы әлеге шәһәрдә Г. Тукайга һәйкәл һәм музей ачылуы бик куанычлы хәл. М. Шәймиев моның өчен тантаналы кичә мөнбәреннән Президент Нурсолтан Назарбаевка зур рәхмәт әйтте. Г. Тукай шигырьләре С. Есенинны һәм М. Горькийны да сокландырган. Аның әсәрләрен А. Ахматова һәм С. Липкин бик яратып һәм зур осталык белән тәрҗемә иткән.

Тантаналы кичәдә катнашучыларга РФ Президенты В. Путинның котлавын Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлык житәкчесе М. Швецкой укыды.

Тантанада РФ Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары О. Морозов, РФ мәдәният министры В. Соколов, Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Мөфтиләр шурасы рәисе Р. Гайнетдин һ. б. рәсми кешеләр, шулай ук Татарстан язучылар делегациясе катнашты.

Тантананың рәсми өлешеннән соң Татарстан сәнгать осталарының концерты булды.

## ДӘРӘҖӘЛЕ БҮЛӘК

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Фейсал исемендәге халыкара премиягә лаек булды. Бу хакта Согуд провинциясе Асир губернаторы, Король Фейсал фонды рәисе принц Хәлед әл-Фейсал белдерде, дип хәбәр итте «ИТАР-ТАСС». Хәлед бу премия Президент Минтимер Шәймиевкә республикада Ислам мәдәниятен үстергән, татарстанлыларга Ислам кануннарын өйрәтүдә зур эшләр башкарган өчен бирелде дип билгеләп үтте. Фонд житәкчесе соңгы елларда республикада меңнән артык мәчет төзелүе, Татарстанда Коръән басмасы, дини китаплар, мәдрәсәләр барлыкка килүе, Россия Ислам университетына нигез салынуы хакында әйтте.

## РӘССАМНАР ЮБИЛЕЕ

Татарстан Рәссамнар берлеге күргәзмә залында берлекнең оешуына 70 ел тулу уңаеннан зур күргәзмә оештырылды. Аны ачуда Президент М. Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Казан шәһәре башлыгы И. Метшин һ. б. катнашты.

—Заман авырлыкларына карамастан, фидакарьләрчә иҗат итеп, мирасыбызны баетучы рәссамнарны чын күңелдән тәбрик итәм,—диде Илбашы.—Үз сурәтләрендә тарихыбызны мәңгеләштерүче, безгә үзебез күрә белмәгән матурлыкны күрсәтә килүче бу кешеләргә без һәммәбез дә рәхмәтле булырга тиешбез.

Президент юбилей уңаеннан Рәссамнар берлегенә автобус һәм җиңел машина бүләк итте. Сынлы сәнгать өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, Татарстан сәнгатен үстерүгә керткән өлешләре өчен Р. Килдебәков, В. Акимов—«Татарстанның халык рәссамы», Р. Вахитов, А. Крылов, Р. Сәлахов, А. Миңнуллина—«Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Ә. Фәтхетдинов, Э. Зарипов, Г. Зяблицев—«Фидакарь хезмәт өчен» медаленә, Т. Зуева Президентның Рәхмәт хатына лаек булды.

Татарстан рәссамнарын тәбрикләргә Россия Художество Академиясе вице-президенты, В. Суриков исемендәге сәнгать институты ректоры, Россиянең халык рәссамы А. Бучуков, Россия Рәссамнар берлегенең җаваплы сәркатибе, Россиянең халык рәссамы Н. Соломин да килгән иде.

## УРТАК ШАГЫЙРЕБЕЗ

15-16 декабрьдә Башкортстанда татар, башкорт һәм казакъ халыкларының уртак шагыйре Мифтахетдин Акмулланың тууына 175 ел тулуга багышланган юбилей чаралары узды. Бу бәйрәмгә Казаннан кунак булып Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗанов һәм журналыбызның поэзия бүлеге редакторы шагыйрь Рәдиф Гаташ бардылар. Уфада узган тантаналы кичәдә—Ә. Закирҗанов, Акмулланың туган ягы Миякәдә узган бәйрәмдә—Р. Гаташ чыгыш ясап, бөек шагыйрьнең өч халык улы булуын ассызыклап, мондый юбилейларның тугандаш халыкларның бердәмлеге, дуслыгы юлында мөһим чара булуын әйттеләр.

## «СӨЕМБИКӘ» БӘЙРӘМЕ

18 декабрь көнне М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Сөембикә» журналының нәшер ителә башлавына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Журнал «Азат хатын» исеме белән 1926 елда чыга башлый. Сугыш башлангач, 1941 елда ул ябыла һәм 1958 елга кадәр чыкмый тора. 1958 елда янадан торгызыла. 1991 елдан «Сөембикә» исеме белән нәшер ителә (бу исем белән 1913-18 елларда да журнал чыккан булган). Төрле елларда эшләгән баш мөхәррирләр—Ягъкуб Хәлили, Гөлчирә Гафурова, Рокыя Әхмәтшина, Асия Хәсәнова, Венера Ихсанова, Роза Туфитуллова, Фирая Бәдретдинова.

Кичәдә журнал редакциясен Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева котлады, бер төркем хезмәткәрләргә «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләрен һәм Мәдәният министрлыгының Мактау грамоталарын тапшырды.

Сәхнәгә менеп, котлау сүзләрен житкерүчеләр күп булды әлеге кичәдә. Татарстан социаль яклау министры урынбасары Гүзәлия Минкина, «Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры урынбасары Фәрит Шаһиәхмәтов, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисенен беренче урынбасары Ренат Вәлиуллин һ. б.

Журналның 80 еллыгы тантанасы Татарстан дәүләт жыр һәм бию, Татар дәүләт фольклор ансамбльләре чыгышлары белән бизәлеп, Зөһрә Сәхәбиева, Венера Ганиева, Рөстәм Закиров жырлары белән үрелеп барды. Кичәдә шулай ук Мәскәүдән Роза Хәбибуллина белән Наилә Фатехова, Уфадан Марат Шәрипов, Казакъстаннан нәни кыз Варвара Семенова да чыгыш ясады.

## САГЫНАЛАР СИНЕ ЯКЫН ДУСЛАР

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Татарстанның халык артисты, Россиянен атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, жырчы, композитор Сара Садыйкованың тууына 100 ел тулу уңаеннан «Сагыналар сине якын дуслар» дигән тантаналы кичә булды.

Әлеге чарада Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашып, чыгыш ясады.

Кичә «Сара Садыйковага музыкаль букет» (Леонид Любовский) әсәре белән башланып китте. Аны Татарстан дәүләт симфоник оркестры башкарды.

Кичәдә С. Садыйкованың иҗтимагый фондына мәшһүр композиторыбызның Мөсәвирә ханым куллары белән жем-жем итеп торган сәйләннәрдән чигеп эшләнгән портреты бүләк ителде.

Тантанада С. Садыйкова иҗат иткән жырлар һәм романслар, аның репертуарыннан арияләр Зөһрә Сәхәбиева, Рөстәм Маликов, Гөлнара Мурзиева, Айдар Габдинов, Асылъяр, Айгөл Хәйри һ. б. башкаруында яңгырады.

## ШАГЫЙРЬ СИРИННЕҢ 110 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ

Күренекле татар шагыйре Сириннең тууына 110 ел тулуны аның якташлары—Ютазы һәм Баулы районы җәмәгатьчелеге— бөтен халык бәйрәме төсендә зур итеп билгеләп үттеләр.

Әлеге юбилейга багышланган тантаналар 14 декабрь көнне Кәрәкәшле авылы мәдәният йортында фәнни конференция белән башланып китте. Ютазы муниципаль районы башлыгы урынбасары Р. К. Хәкимова үзенең чыгышында район җәмәгатьчелегенең күренекле якташлары шагыйрь Сириннең исемен мәңгеләштерү өлкәсендә шактый эш башкаргалыкларын, Кәрәкәшледә, Ютазы һәм Баулы район үзәкләрендә урамнарга Сирин исеме бирелгәнлеген билгеләп үтте. Филология фәннәре докторы, Чаллы дәүләт педагогия институты профессоры Әнвәр Шәрипов шагыйрь Сириннең тормыш юлы һәм иҗат мирасы турында доклад сөйләде. Әлмәт Язучылар оешмасы житәкчесе Данил Салихов, Кәрәкәшледәге «Туган як тарихы» музее директоры Сәлимә Шәрәфиевалар шагыйрьнең татар әдәбиятындагы урыны, Сталин репрессияләренең җәмгыятебезгә китергән зыяны турында фикерләре белән уртаклаштылар. Кичәдә Сириннең якын туганнары да бар иде. Шагыйрьнең бертуган энесе Мәхәсимнең улы Рифкать Батыршин үзенең чыгышында бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып Сирин әсәрләренең җыентыгын бастырып чыгару һәм киләчәктә аның иҗатының мәктәп программаларына, дәреслекләргә кертелергә тиеш булуын ассызыклады. Әлеге чыгышлар «Кәрәкәшле бизәкләре» исемле жыр һәм бию ансамбле чыгышлары белән аралашып

барды. Конференция халык тулы зал белән Г. Тукайның «Туган тел» җырын башкару белән тәмамланды. Шул ук көнне шагыйрь Сириннең Баулы зиратындагы каберенә чәчәк салу тантанасы да булды.

### ТАТАР ҖЫРЫ ТАНТАНАСЫ

Соңгы берничә ел эчендә дөньяның байтак төбәкләрен инләп йөргән Рәшит Ваһапов фестивале, ниһаять, быел янәдән башкалабыз Казанда да гөрләде. Белгәнебезчә, халыкара фестиваль быел мәшһүр җырчының туган ягы Түбән Новгородта старт алган иде. Шуннан соң ул республикабызның берничә төбәгендә, Удмуртиядә, Чуашиядә, шулай ук Ульян, Рига һәм Берлин шәһәрләрендә узып Казанга кайтты.

8-9 декабрь көннәрендә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында йомгаклау концертлары булып узды. Анда фестивальнең мактаулы кунагы, СССРның халык артисткасы Бибигөл Туләгәнова, үзебезнең мәшһүр җырчыларыбыз Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева һәм төрле төбәкләрдән килгән артистлар чыгыш ясады.

### ПИАНИСТЛАР КОНКУРСЫ

Сәйдәш исемендәге дәүләт Зур концертлар залында Софья Гобәйдуллина исемендәге I халыкара пианистлар конкурсы (ул Казанда 15 декабрьдә старт алган иде) лауреатларын бүләкләү тантанасы булып узды. Конкурс Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы кысаларында композиторның 75 яшьлек юбилее җәһәтеннән үткәрелде.

«Тәүге адымнар авырлыгын җиңеп, без бу бәйгене бик зур киләчәк көтәсенә ышанабыз. Чөнки монын өчен бездә барысы да—менә дигән мәктәп тә, менә дигән музыкантлар да бар»,—дип ассызыклады ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тантананы ачып. Рәсми өлештән соң пианистлар конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү булды.

Конкурста Россиядән, Казакъстан, Украина, АКШ, Япониядән барлыгы 22 пианист катнашты. Гран-при һәм 300 мең сум акчалата премиягә Казан консерваториясен тәмамлаган музыкант Софья Гуляк лаек дип табылды.

### ЭСТРАДА ҖЫРЫ ФЕСТИВАЛЕ

«Барс Медиа» компаниясе оештырып килгән «Татар җыры» фестивале быел җиденче мәртәбә уздырылды. Ике көн дәвамында «Пирамида» мәдәни күнел ачу үзәгендә ел буе «Татар радиосы»ннан җырлап торган җырчылар сәхнә тотты.

«Барс медиа» компаниясенең генераль директоры Марат Гәрәевнең әйтүенә караганда, алар күпкә зуррак залларны да тутыра алган булырлар иде. Быел җырчыларны сайлап алу рәвеше бераз үзгәртелгән иде. Татар эстрадасының үсешенә этәргеч ясау максатыннан бу юлы 17 номинациядә иң яхшылар билгеләнде. 10 миллион сумга төшкән әлеге фестивальдә кемнәргә «Алтын барс» сыны өләштеләр соң?

«Елның иң яхшы җыры» дип Булат Нигъмәтуллин башкарган «Чая кыз», Асылъярның «Миннән башка син дә канатсыз», Ләйсән Гыймаеваның «Җидегән йолдыз», Илдар Хәкимовның «Зарланма» дигән җырлары табылды. «Ел ачышы»—Илдар Әхмәтов, Иркә. «Иң яхшы чит төбәк башкаручысы»—Идрис Газиев. «Иң халыкчан җырчы»—Нәфкать Нигъмәтуллин, Хания Фәрхи, Рәсим Низамов. «Елның иң яхшы альбомы» иясе—Әлфинә Әзһәмова («Мин—синең йолдызын»). «Елның иң яхшы парлы җырчысы»—Зәйнәп Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов. «Елның иң яхшы җыры»—Гүзәл Әхмәтова («Яратам»). «Елның иң яхшы җырчысы»—Салават Фәтхетдинов, Гүзәл Уразова, Илнар Сәйфиев. «Елның иң яхшы клибы»—Айдар Галимов («Синең күзләр»). «Иң яхшы музыкаль төркем»—«Эссе». «Елның иң яхшы проекты»—Рита («Сагынма, жимешем»). «Иң яхшы бию проекты»—Салават Миннеханов. «Фильмга иң яхшы саундтрек (музыка)»—эстрада йолдызлары («Әтәчсез иртә ни китерә?»)

Шулай итеп, фестивальдә катнашкан һәрбер җырчы теге яки бу номинациядә җиңеп, «Алтын барс» сыны иясе булды.

### МИЛЛИ МУЗЕЙНЫҢ ЯҢА КАЗАНЫШЫ

Компьютер сәнгатенең юнәлешләреннән берсе булган мультимедианы популярлаштыру, бу өлкәдә заманча базар формалаштыру максатыннан 1997 елдан бирле иҗади интерактив мультимедиа контенты (дисклардагы мәгълүмат) фестиваль-конкурсы уздырыла. Аның чираттагысы Мәскәүдә «Мәгълүмати җәмгыятьнең мәдәнияте һәм технологияләре. XXI гасыр» дип аталган IX халыкара конференция кысасында үтте.

«Контент»—бәйсез конкурс. Жюри рәисе режиссер Дмитрий Наумов. Финалга төрле юнәлеш һәм эчтәлектәге 12 мультимедиа продукциясе узды. Гран-при беркемгә дә бирелмәде, ә «Минем Ватаным» номинациясендәге төп призга һәм «Виртуаль музейда классик рухны саклаган өчен» «Мир ПК» журналының махсус призына «ТР Милли музее хәзинәләре» DVD дискы ия булды. 2004 елны башкалабыз юбилеена багышлап чыгарылган «Казан 1005-2005» дискы да инде бу бүләкне алган булган.

110 ел буе эшләп килүче Милли музейда 800000 экспонат бар. Дискка аларның 2500е кертелгән. Анда табигый һәйкәлләр, Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгының тормыш-көнкүреше, сынлы сәнгать, китап байлыгы чагылыш тапкан.

## РЕКТОРЫ—РӘФЫЙК МӨХӘММӘТШИН

Соңгы елларда Казандагы Россия Ислам университетының җитәкче даирәләре арасында үзгәрешләр еш булды. Әле күптән түгел генә бу уку йортын гамәлгә куючылар советы, элек ректор вазифаларын башкарып килгән Илдус Зәһидуллин урынына, Татар энциклопедиясе институты директоры урынбасары, Татарстан фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтының урта гасырлар бүлеге мөдире, сәяси фәннәр докторы, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшинны билгеләп куйды.

Ректорны билгеләү җыелышында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакый, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе урынбасары Марат хәзрәт Мортазин Татарстан Президенты Аппараты вәкиле Александр Терентьев катнашты.

## 35 ЯШЬЛЕК БАСМАХАНӘ

Кайчандыр ул Татарстан газета-журнал нәшрияты дип йөртелә иде. Ә хәзерге исеме—«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ачык акционерлар җәмгыяте.

«Идел-Пресс»ның генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов билгеләп үткәнчә, хәзер оешма Мәскәү, Башкортстан, Свердловск өлкәсе һ. б. төбәкләрдәге эре нәшриятлар белән хезмәттәшлек итә. Татарстан китап нәшрияты һәм «Мәгариф» милли нәшрияты басмаларының 90 процентка якыны нәкъ менә «Идел-Пресс»та дөнья күрә. Соңгы 7 елда җәмгыять җитештергән продукция 5 тапкырга арткан.

## УЧИЛИЩЕ ИСЕМЕН ҮЗГӘРТӘ

Казан сәнгать училищесы В. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт архитектура-сәнгать институтының филиалы булачак. Бу турыда институт ректоры, Россия Сәнгать академиясе вице-президенты Анатолий Бичуков хәбәр итте.

Филиал булдыру турында килешүгә кул куелган инде, хәзер педагоглар туплана, ректор кандидатурасы тикшерелә. Барлык оештыру эшләре 2007 елның 1 сентябренә кадәр тәгәлләнергә тиеш. МДАСИның Казандагы филиалында студентлар нәкыш, скульптура, графика һәм нәфис-декоратив сәнгать факультетларында белем алачак.

## КҮРШЕЛӘРГӘ БЕР СӘФӘР

7-9 декабрьдә язучылар—журналыбызның редколлегия әгъзасы, «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры Фоат Галимуллин Уфага һәм Стәрлетамакка сәфәр кылып, андагы педагогик уку йортлары җитәкчеләре, республиканың татар теле укытучылары һәм Башкортстан мәктәпләре өчен татар теле дәреслекләре авторлары белән очраштылар, Солтанморат авылындагы Г. Ибраһимов музеенда булдылар.

## ЯЗУЧЫ ХАҖДА БУЛДЫ

Хаҗ кылу—һәр мөселман өчен иң мөһим бурыч-фарызларның берсе санала. Белешмә-мәгълүматларга караганда, дөньяның төрле почмакларыннан килеп, хаҗ кылуда берничә миллион кеше катнаша. Быел Россиядән Мәккәгә килүчеләр саны 18 меңнән артык. Шуларның 1058е—Татарстаннан. Алар арасында күренекле язучыбыз Рабит Батулла да бар иде. Шулай итеп, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты Рабит Мөхлис улы Батулла хаҗи да булды.

## ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЛАРЫ

Туган республикабыз хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеше өчен шагыйрә, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе ачык акционерлык җәмгыятенең радиотапшырулар баш редакторы **Җиһангирова Шәмсия Гатуф кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Туган республикабыз хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен шагыйрә **Булатова Клара Гариф кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Иске Казан. Печән базары». **Алсу Тимергалина** рәсеме.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Хәбир Ибраһим**.

# ӘМИНӘ ҖӘЛИЛОВА

2006 елның 13 декабрендә, 94 нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң герой-шагыйрь Муса Җәлилнең хатыны Әминә Котдус кызы Җәлилова вафат булды.

Әминә Җәлилова 1913 елның 21 июнендә Казанда, шәһәр сәүдәгәрендә приказчик булып хезмәт иткән Котдус Шакир улы Сәйфуллин гаиләсендә туа. 20 нче елларның ахырында Әминә Котдус кызы Мәскәүгә китә һәм төзүчеләр техникумына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң Мәскәүдәге «Теплоэлектроцентраль» заводында техник-конструктор булып эшли. 1936 елда ул Муса Җәлилгә кияүгә чыга, икенче елны аларның кызлары Чулпан туа. Яшь гаилә башта Мәскәүдә яши, соңыннан—1939 елда—Казанга күченеп кайта. 1941 елның июлендә Әминә Котдус кызы ирен фронтка озата. Ул М. Җәлилнең әсирлеккә төшүе һәм нахакка гаепләнүе белән бәйле барлык кыенлыкларны кичерде, иренең тулысынча аклануы өчен көрәште. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, Әминә Котдус кызы төрле учреждениеләрдә, шул исәптән СССР Министрлар Советында икътисадчы булып эшли. Игелекле хезмәтләре өчен күп кенә Мактау грамоталарына һәм Рәхмәт хатларына лаек була.

Шуның белән бергә ул Муса Җәлилнең батырлыгын һәм иҗатын популярлаштыруда зур җәмәгать эшчәнлеге алып бара, яшьләр, сугыш ветераннары белән еш очраша, Бөтендөнья Тынычлык Советының әгъзасы буларак, чит илләргә дә чыга. Без Әминә Котдус кызы Җәлилованың вафат булуы сәбәпле, тирән кайгыбызны белдерәбез һәм мәрхүмәнең туганнары һәм якыннары кайгысын ихлас күңелдән уртаклашабыз.

Герой-шагыйребезнең тугры тормыш юлдашы Әминә Котдус кызының якты истәлеге безнең күңелләрдә һәрчак сакланыр.

**М. Шәймиев, Р. Миңнеханов, Р. Мөхәммәтшин, Ю. Камалтынов, З. Вәлиева, Н. Мириханов, И. Метшин, Р. Вәлиев, И. Ибраһимов, Р. Мостафин, Р. Фәйзуллин, Т. Миңнуллин.**

* * *

16 декабрь көнне Мәскәүнең Ваганково каберлеге комплексында мәрхүмә белән хушлашу булды. Кремация алдыннан хушлашу мәрәсимендә кызы Чулпан Җәлилова, туганнары, дуслары, Татарстаннан килгән язучылар делегациясе вәкилләре—Илфак Ибраһимов, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәмис Аймәт булды. Алар Муса Җәлилнең иҗади тормышында зур роль уйнаган Әминә ханым турында җылы сүзләр әйттеләр, туганнарының кайгысын уртаклаштылар. Хушлашу церемониясендә Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле Вәкил урынбасары Алмаз Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

# Яңа китаплар




Хөрмәтле укучыларыбыз!

Чыгачагы турында сезгә алдан ук игълан ителгән «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап-антология, ниһаять, дөнья күрде! Форматы ягыннан энциклопедик басмалардан зуррак, күләме 90 табак чамасы булган бу китапның икенчел, анлатма исеме дә бар: «Мең санлы хәзинәдән»; ягъни «Казан утлары» (элеккеге исемнәре «Безнең юл», «Атака», «Яналиф», «Совет әдәбияты») журналының мең саны (мененче сан үткән елның февраль аенда чыккан иде. Сез кулыгызга тоткан журналның тәртип саны 1012) эченнән иң-иң яхшы әсәр-язмалардан торган сайланма китап дигән сүз.

Китап үткәнебезнең төп иҗтимагый-тарихи этапларын чагылдырган җиде бүлектән тора: «Без тарихта эзлебез» (революциягә кадәрге чор), «Ил корабын җил сөрә» (1917—1936), «Болгавыр еллар» (1937—1941), «Без сугышта юлбарыстан көчлебез!» (1941—1945), «Торыгыз, Мусалар» (1945—1965), «Язмышлар ярында» (1965—1990), «Без яшәргә хөкем ителгән!» (1990 елдан соңгы чор). Китапка кергән язмалар да, әдәби әсәрме яки бүтән жанр материалымы, кайчан язылуына карамастан, әлеге бүлекләр кысасында бирелде, икенче төрле әйткәндә гомумтарихыйлык принцибы сакланды.

Матбагачылык тарихыбызда әлегә аналогы булмаган бу басма, һичшиксез, күп меңләгән укучыларыбызның өстәл китабы, иң мөһиме — әдәбият тарихы, гомумән рухи мирасыбыз белән кызыксынган һәр кеше өчен аерылгысыз юлдаш булачак.

Китапның төзүчесе—**Рәфикъ Юныс**, проект авторы һәм шеф-редакторы—**Равил Фәйзуллин**, рәссаме **Лилия Золондинова**.

*«Сүнмәс утлар балкышы»ын үзендә булдырырга теләгән кешеләр өчен белешмә телефоны: 292-38-60. (Казан, Декабристлар ур., 2. 10 кат)*



Хәбир Ибраһим

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)